# казан утлары

4

АПРЕЛЬ-1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

4

АПРЕЛЬ
1971

## Бу санда:

РОМАН, ХИКӘЯ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

ЗӨЛФӘТ. Керә вакыт байракларын җәеп. Шигырь . . . 3
Д. СИРАЙ. Карагачлар. Шигырь . . . 4
М. АВРАМЧИК. Оста. Шигырь . . . 5
ГАБДЕЛ ВАҺҺАБ ӘЛ-БАЯТИ. Ленин. Шигырь . . . 6
ГАВХАНКАР. Таң тимерчеләре. Шигырь . . . 7
ГАУССУ ДИАВАРА. Халыклар юлбашчысы. Шигырь . . . 8
М. ХӘСӘНОВ. Дулкыннар ярга тигәри. Хикәя . . . 9
С. БАТТАЛ. Чирмешән ярларында. Поэма . . . 17
С. РАФИКОВ. Тын елга буенда. Роман . . . 23
М. САДРИ. Кояш кызлары. Шигырьләр циклы . . . 75

СӘРВӘР ӘДҺӘМОВАГА 70 ЯШЬ

С. ӘДҺӘМОВА. Нәфисә апа. Хикәя . . . 81

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Р. МОСТАФИН. «Оҗмахка сәяхәт . . . 89

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

И. ИЛЯЛОВА. Эзләнүчән тынгысыз актриса . . . 117

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

Г. ЛОТФИ. Уникенең берсе . . . 124
Ю. БЕЛОСТОЦКИЙ. Корыч канатлар . . . 128

ТӨРЛЕСЕННӘН

Җ. ФӘЙЗИ. Халык җәүһәрләре . . . 136
М. ГЛУХОВ. Нагайбәкләр янында . . . 147

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

И. НИГЪМӘТУЛЛИНА. Җил җыламый . . . 157

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Иртәгәгә көнгә атлаганда. 167
Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . . 171

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Мәче дөньясы. Тукран сые. Кар бүрек. Поши. Куяннар кайда! Таган. Ботка. Бурыч. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 180

Дусларча шаяру . . . . . . . . . . . . . . 184

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Ф. ХӨСНИ. Кем кемне җиңә!.. . . . . . . 185

Бервакыт шулай була . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.* Корректоры *Р. Сулейманова.*

Производствога бирелде 29/XII-1970 ел. Басарга кул куелды 19/II-1971 ел. ПФ 14010.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 81946 экз.
Заказ С-702. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

## Зөлфәт

### Керә вакыт байракларын җәеп

Дөнья шулай: бөек вакыйгалар
Гади хәрәкәттән башлана.
Ильич баскан җирдә — тарих эзе,
Тарих баскан җирдә —
Таш яна.
Тиздән бер сүз бәреп янгырар
җирдә,
Кратердан бәргән шикелле:
Җитте! —
Революция вата, каера
Россиянең күкрәк читлеген.
...Төнге учак Нева күперендә,
Мәнгелеккә сайлый крейсер порт.
Яныл килә,
жите Петроградка
Большевиклар кабызган бикфорд.
Илнең карашында залп ялкыны,
Илнең кулы мылтык сабында,
Ята мизгел баррикада булып:
Ике заман ике ягында.
Ята мизгел баррикада булып —
Төп-төгәл чик яңа гасырга,
Керә вакыт байракларын җәеп
Россиядән
СССРга.
Керә вакыт броневик булып.
Шушы броневикның өстендә
Бар көченә сүз яңгырар хәзер —
Шушы мизгел сыман төгәл дә ул,
Шушы мизгел сыман кискен дә!
Сүз яңгырар хәзер!
...Урамнарга
Аяк тавышлары төшәлә.
Акыл гильзасына утыртылган
Хыял снарядын
Көпшәдә.
Ильич фикеренең ялкыннары
Илнең йөрәгенә сарылыр.
Шушы бомба баррикадаларның
Арьягына төшеп ярылыр.
...Ильич кулын алга сузган мизгел,
Заман давылы җанга кагыла —

Әйтерсең лә ишарәли Ильич
Космодромлы көннәр ягына.
Батырлыкка туар һәйкәл яши
Хәрәкәтсез мәрмәр эчендә —
Шушы мизгел гаҗәп мәрмәреннән
Чорның сынын койды
Кешегә.
...Татарстаным Анын хатирәсен
Җылы күңеленә төрәчәк:
Ул үлмәгән,
егылмаган килеш
Киләчәккә барып керәчәк...
Безнең өчен Ленин һаман тере,
Броневикның һаман өстендә.
Һәрвакытта таянабыз аңа —
Аның утлы, кайнар исменә.
Саубуллашып кына калмаган ул,
Кулын болгап безнең гасырга:
Броневикта килеп кергән Ильич
Россиядән
СССРга...

## Дифгать Сирай

### Карагачлар

Карагачлар — дала балалары,
Кемнәр сезне монда китерде?
Юл буенда җәелеп утырасыз,
Таҗлар киеп куйган шикелле.
Шул таҗларны селки-селки кинәт
Исеп куяр кебек җил шашып
Һәм яфраклар, бөреләрен ярып,
Сикереп чыгар кебек шаулашып...
Самар шәһәрендә үсә алар,
Үз язларын монда тапканнар,—
Әллә Ильич басып йөргән туфрак —
Изге эзләр инде тартканнар!
Гаҗәп түгел,
Ленин тирәсенә
Тупланды бит җирдә бар милләт.
Үсә алар, карагачлар кебек,
Россияне бизәп, иркенләп.

## Микола Аврамчик

Белорус шагыйре

# Оста

Һич онытмам: шундый матур бер
яз,
Ә тирә-юнь шундый якты, тын...
Тәүге тапкыр курант сукты бездә —
Белдерде ул Мәскәү вакытын.

Кызыксынам. Чабам мәйданга мин.
Әрсезләнү — минем гадәтем.
Осталарны көн дә карап торам
Куйган чакта шәһәр сәгатен.

Ә аларның берсе исә — башлык.
Һәм мин һаман шуны күзәтәм.
Сөйли халык: Кремль курантын да
Нәкъ шул оста, имеш, төзәткән.

— Дөресме? — дим. Ә карт оста әйтә:
— Анысы дөрес, минем кул алтын...
Тик мин түгел, иң зур оста Ленин
Ремонтлады Кремль курантын.

Тавышын да аның, йөрешен дә
Ул үзгәртте — борып янача.
Безнең эшне шулай белгән оста
Булганы юк әле анача!

Тузган нәрсә. Иске механизм...
Ә кирәк бит сүтеп жыярга,
Һәм йөрешне — яңа чорга турылап —
Пөз ел алга борып куярга!..

Ә мин, бала, шуны чын дип белдем,
Остам, дидем, дөрес сүз әйтте:
Гүя минем күз алдында Ленин
Көне буе сәгать төзәтте.

Һаман шул чак искә төшә хәзер
Ишеткәндә курант чыңлавын.
Оста миңа алтын сүзләр әйткән,
Әйбәт булган аны тыңлавым.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе

## Габдел Ваһһаб әл-Баяти

Гыйрак шагыйре

### Ленин

Лениннын тавышы
Таулар ташкыны.
Лениннын тавышы
Көчле дә, саф та!
Нурдай яктыра
Ул тирә-якка,
Байрактай балкый
Таң аткан чакта.
Җиһан йөзенә
Бәхет тарата,
Ленин, Ленин! — дип,
Җир чәчәк ата.

Ленин исеме
Җинүчән давыл,
Чүлләргә янгыр
Булып ява ул,
Төн уртасында
Балкый нурлары,
Ленин — мәңгелек
Чишмә сулары.
Ленин — әлифба,—
Укы, яз, өйрән,
Йортсыз-жирсезгә
Ул йорт-жир биргән!

Ленин бишегендә
Тирбәлә бала,
Дөм сукырны да
Җитәкләп ала.
Ленин — ул бөек
Тарихнын үзе,
Иярә аңа
Бөтен җир йөзе.

Шагыйрьләр интекте коллыкта.
Күп җәфа чиктеләр чын ирләр.
Кайгыны-хәсрәтне җиңәрлек
Бәхеткә омтылды шагыйрьләр.

Ярлылык, хаксызлык яшәде.
Кешеләр үлделәр сугышта.
Тик Ленин балкыгач дөньяга
Аштылар өметләр тормышка.

Таннарда балкыган нурларда
Яктыра ярлылар йөрәге,

Бүгенге тормышта күренә
Борынгы шагыйрьләр теләге!

Мәскәүдә йөрим мин
Кремль янында,
Яшем күк агыла
Жырым шул чагында.
Ленин, дим, Ленин! — дим
Берни дә кирәкми,
Син көч бир жырыма,
Син дәрт бир тагын да!
Ә байлар уйлады
Мактар дип үзләрен,
Сатылыр, дип, мине,
Акчага, алтынга.
Әй, комсыз корсаклар,
Һич житмәс акчагыз.
Йөрәгем тулы ут —
Сүрелмәс ялкынга.
Бу ялкын, бу утны
Ул бирде, беләм мин,
Шул ялкын нурында
Ул бөек атамны —
Ленинны күрәм мин.

## Гавханкар

Һинд шагыйре

## Таң тимерчеләре

Син бездән сорыйсың, сез кем, дип, кайлардан?
Илче без, кара төн китердек байларга,
Планета, өндәден, ниардек — киләбез,
Ярлыга таңнарның нурларын сибәбез!
Юк, монда инмәдек без илнең күгеннән,
Кайгылар чакырды жирнең иң төбеннән,
Без биек күтәргән бу кызыл флагтан
Караңгы явызлык чигенә еракка.
Көч керде, Алласыз уң булды эшебез,
Юл ачты үзебез шикелле кешебез:
Мәңгелек акылы, васыяте һәм даны!
Ленин ул, онытма, кадерлә, Жир, аны!

Бәхетләр бары тик экияттә сөйләнгән,
Чынлыкта халыкны зур кайгы билгәән,
Ә хәзер һәр чорны үзгәртеп төзәрбез,
Хәсрәтне-кайгыны чүп-чардай күмәрбез.
Чикләрне бетерер туганлык сабаны,
Бергәләп коябыз Жир өчен без аны.
Тимерче булдык та киләчәк таңнарга,
Чыктык без, планета, азатлык яуларга!

Бодайны үстерә игенче тир түгеп,
Ә үзе гел яши ачлыктан интегеп.
Эшчеләр дөньяның байлыгын арттыра,
Үзләре гел фәкыйрь, ялангач, ач тора.
Ә байлар халыкны алдалап, туенып,
Яшиләр алтында, рәхәттә коенып.
Зур чүкеч күтәрә эшчеләр ярсудан,
Изелер искелек нәфрәттән, ачудан.
Безгә дип ачылды таңның киң юллары,
Җиңүгә чакыра Ленинның куллары!

## Гауссу Диавара

Мали шагыйре

## Халыклар юлбашчысы

Эзлә син
Бөтен җир йөзеннән,
Ләкин бер илдә дә,
Башка бер телдә дә
Тапмассың данлырак,
Көчлерәк, шанлырак
Исемне, зур сүзне
Син Ленин сүзеннән.
Ленин ул давылы
Заманның, дөньяның!
Куәте, кодрәте
Ташкындай зур аның!
Искене җимерә,
Юк итеп ташлый ул,
Һәркайда өр-яңа
Чын тормыш башлый ул.

Ленин ул май кебек
Яралы йөрәккә,
Һәрвакыт ярдәмгә
Ашыга кирәктә.
Уң кулы белән ул
Коткара колларны,
Сул кулы йолдызга
Ача киң юлларны.
Кояшның нурлары,
Җылы яз нурлары
Таудагы карларны
Эреткән шикелле,
Төннәрне тарата
Ленинның сулышы.
Шәфкатьле кеше ул,
Кадерле, сөйкемле.

Ленин — ул мәңгелек!
Кораблар маякка
Баргандай төн ярып
Океан суыннан,
Халыклар ашкынып,
Кулга-кул тотышып
Аңарга омтыла
Азатлык юлыннан.

**МӨХӘММӘТ САДРИ** тәрҗемәләре

Мәхмүт Хәсәнов

# ДУЛКЫННАР ЯРГА ТӘГӘРИ

хикәя

Пароход кузгалып китәр вакыт якынлашкан саен ыгы-зыгы арта, шау-шу көчәя барды. Пассажирларның барысы да диярлек дебаркадер ягына чыкканлыктан, өч палубалы зур дизель-электроход чак кына бер якка янтайган сыман тоела иде.

Мин дә, пароходка кереп, пассажирларны каршылаучы проводницадан ачкыч алып, каютамны эзләп таптым. Ике генә кешелек иркен, якты каюта иде бу. Бөркү булганлыктан, тәрәзәне ачып җибәрдем. Хәерле юл теләү, саубуллашу-хушлашу авазлары аермачык ишетелә башлады.

«Юлдашым кем булыр икән?..» дип уйларга да өлгерә алмадым, каюта ишеге ачылып китте. Ашыгып-кабаланып берьюлы ике кеше килеп керде. Минем белән исәнләшеп нәк каккандай иттеләр дә, яңадан бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, әйберләрен урнаштыра башладылар.

Беренче сүзләреннән үк аларның аталы-уллы булуларына төшендем. Яшьрәге ап-ак нейлон күлмәк кигән, кара капрон галстук таккан. Өстендә һәйбәт костюм. Менә ул минем якка күз төшереп алды да, чак кына елмайгандай итеп, каяндыр эчке кесәсеннән бер шешә коньяк чыгарып тәрәзә алдындагы өстәлгә утыртты.

— Әти... Менә монысын үз җаең белән карарсың инде. Әнигә сиздермичә генә. Аны беләсең ич... Юлда, эчең пошканда, юанып алгандай итәрсең. Әнә, юлдашың да бар...

Шул вакыт кайдадыр якында гына чаң суккан тавыш һаваны ярды. Репродуктор аша дикторның озатучыларга пароходтан чыгарга дип хәбәр салуы ишетелде. Ул да булмады, барлык шау-шуны басып, дизель-электроходның гудогы яңгырады.

Гарәф тә: «Ярар, әти!.. Хәерле юл сиңа. Һәйбәт кенә ял ит. Бу юлы инде кабаланып кайтма. Иркенләп ял ит»,— дип, әтисе белән саубуллаша башлады. Әмма әти кеше: «Юк, юк, озата чыгам»,— дип, улын-

нан калырга теләмәде. Һәм ул, килеш-килбәте белән яшь профессорны хәтерләткән егеткә ияреп, каютадан чыгып китте.

Мин дә тәрәзә янына килдем. Булачак юлдашым палубада калды. Бераздан Гарәф тә күренде. Ул, житез-жәһәт хәрәкәтләнеп, шунда дебаркадерда торган ике хатын-кыз янына килеп, көлеп-елмаеп палубада калган әтисенә кул болгый башлады. Бу саубуллашуның озакка аерылышу түгеллеге әллә каян күренеп тора: һәркайсының күңеле көр, йөзендә көлү-елмаю. Гарәф, янында торган хатыннарның өлкәнрәген беләгеннән тотып: «Әнине дә үзен белән аласыңмы әллә?» дигән сыман итеп чак кына алгарак чыгарды. Әйе, бу гаилә чыннан да бәхетледер, тигездер дигән уй туды миндә. Чөнки аларның үз-үзләрен тотышларын, үзара мөнәсәбәтләрен күзәтеп тору гына да күңелдә җылы тойгы уята, прексездән куанычлы хисләр тудыра. Кеше бәхете кешегә тәэсир итә шул.

Искәрмәстән генә бөтен ыгы-зыгыны, шау-шуны басып пароходның соңгы гудогы яңгырады. Ул да булмады, пароходның алгы өлеше әкрен генә дебаркадердан аерыла башлады... Озатучылар алга, ә палубадагы пассажирлар, киресенчә, артка таба чайкалып-хәрәкәтләнеп куйдылар...

Бераздан мәһабәт дизель-электроход тан кебек якты булып, жыр кебек матур булып ишелә-ишелә аккан киң Иделнең фарватерына чыкты. Елга порты да күренмәс булды, тәрәзә артында бары тик акчарлаклар гына уйнаклап очып-очып үткәли иде.

Бераздан минем юлдашым да керде. Мөлаем генә йөзле, чәчләре чалара башлаган алтмыш яшьләр чамасындагы абзый кеше иде бу. Керү белән: «Уф-ф, бөркү!» — дип, пиджагын салып элде, күлмәгенең өске төймәләрен ычкындырып җибәрде. Бары тик шуннан соң гына бөтен йөзе белән берьюлы елмаеп миңа таба борылды да:

— Хәзер инде һәйбәтләп, иркенләбрәк танышсак та ярар...— дип миңа кулын сузды.

Шәрәф исемле икән. «Татарның шул инде,— дип уйлап куйдым мин,— ир бала булса әтисенеке, кыз баланың әнисе исеме белән аваздаш була. Боларның да шулай: Гарәф белән Шәрәф икән!»

Бер-беребезнең кая баруыбыз, нинди сәфәргә чыгуыбыз белән кызыксындык. Шәрәф ага ял итәргә бара икән. Аның юлы минекеннән дә арырак булып чыкты.

Борылышларның берсендә тәрәзә аша Идел өстенә күз салдым. Кояш инде баю ягына авышкан. Ә пароход артында җилпәзәне хәтерләтеп як-якка таралышкан дулкыннар гына ургыла. Алар салават күпере төсләренә кереп, искиткеч зур пыяла куыклар сыман, ярларга таба тәгәрәшәләр...

Сүз югында сүз булсын дигәндәй, юлдашым белән көннәрнең матур торуы, гомумән елның ару килүе турында гәп сатып алдык. Аннары, әллә капкалап алабызмы дип, табын хәзерли башладык. Шәрәф ага бая улы Гарәф чыгарып куйган коньяк ягына ым кагып:

— Моңардан да авыз итеп карарбыз...— дип куйды. Шунда ук, өстәл өстендәге стаканнарны алып, ишек катындагы краннан су агызып чайкый башлады.

Мин аны озата килүчеләрнең кем булулары белән кызыксындым.

— Берсе хатыным. Икенчесе киленем. Ә монда кергәне — улым,— диде Шәрәф ага, шешәне кулына алып.— Гадәттә без бергә ял итә идек. Быел бераз җайсызрак туры килде. Гарәф университетта читтән торып укучы студентлардан имтиханнар ала. Доцент ул... Килен — врач. Аны да эшендә тоткарладылар.

Шәрәф ага елкылдап торган стаканнарга бармак илле генә итеп коньяк койды. Тостны да үзе әйтте.

— Әйдәгез, монысы танышу хөрмәтенә булсын!..— диде ул, мәлаем генә елмаеп. Чыннан да Шәрәф ага бик үзенчәлекле, матур итеп елмая. Елмайганда тормыш шактый эз салган йөзе ничектер нурлана башлый кебек.

Мин, бу бәхетле гаилә тормышының серенә төшенергә теләгәндәй, сүзне яңадан аны озатучыларга күчердем. Бу юлы инде Гарәфне дә телгә алдым.

— Сезне, Шәрәф ага, улыгыз аеруча ярата, якын итә, ахрысы...— дидем мин, сүземнең бик үк ятышлы чыкмавын үзем үк сизенеп.

— Әйе, без аның белән дуслар,— диде Шәрәф ага, кабат елмаеп.— Серләребез килешә...

Мин, аның сүзен көчәйтеп, алар гаиләсенең татулыгын, тигезлеген күңелем белән читтән үк сизенеп-тоеп торуымны әйттем.

Шәрәф ага: «Бер-береңне ихтирам итмичә, бер-береңнең җанын кыйнап яшәүне мин дә күз алдыма китерә алмыйм, андый тормышта яшәмәвең лутче»,— дип үзенчә фәлсәфә сатып алгандай итте. Аннары мине гаҗәпкә калдырырлык сүз ычкындырып куйды:— Ә бит Гарәф минем үз улым түгел...— диде ул.

Минем чынлап торып сәерсенүемне күргәч, сорау-фәлән бирүемне дә көтмәстән сүзгә кереште.

— Сугыш елларында мин гаиләсез калдым. Бомба төшеп яки анда фронт тирәсендә калып һәлак булмадылар алар. Монда, тылда үлделәр. Үзем исә, көн дә диярлек ут эчендә газраил белән күзгә-күз карашып, якалашып йөрсәм дә, исән калдым. Ә гаиләм монда, тылда булып та, мине көтеп ала алмады... Хатыным заводта ниндидер газ шартлаудан һәлак булган. Миннән дүрт-биш яшьлек булып калган улым чак кына соңрак, үпкәсенә салкын тиеп, чирләп үлгән... Таныш-белешләр каберләрен генә күрсәттеләр. Күземә ак-кара күренмәс булды. Бер яктан тән яралары сызласа, икенче яктан йөрәк әрнүемә такать тотар хәл юк. Шунда татыдым мин ялгызлыкның нәрсә икәнен. Яшисе килмәгән чаклар да булгалады. Йөрәкне менә шушы зәхмәт суы белән басып та караштыргаладым. Тик ярдәме тимәде. Шуның өстенә, әле мин шофер кеше, көн-төн машинада...

Ул вакытта мин тимер юлдан кырык-кырык биш километр ераклыктагы заводка станциядән йөк ташый идем. Вакыты белән көненә өчәр, хәтта дүртәр рейс ясарга туры килә иде. Ашыгыр җир дә, көтеп торучы да юк, шунлыктан вакыт белән санашып тормый идем...

Станция белән завод арасындагы юл өстендә кечерәк кенә бер поселок бар. Юлга орынып ук тора. Тимер-бетоннан коеп эшләнгән күпернең өске ягында шактый җәелгән буа бар. Шунда иртәнге таңнан кичке караңгыга кадәр бала-чагалар мәш килә: чана шуалар, чаңгыда узышалар...

Шул турыга җитү белән машинамны туктатам да малай-шалайларның уйнауларын карап торам. Аларның тавышларын ишетү, әүмәкләшеп уйнауларын карап торуы гына да күңелләрне әллә нишләтә. «Эх-х, минем улым да исән булса, нәкъ менә шушы ташбашлар кебек танавы бозланганчы карда аунар иде», дим. Гомумән яратам мин чая малайларны. Кем әйтмешли, малай булгач — ут булсын...

Көннәрнең берендә шулай буаның катмый торган җылы урыныннан чиләк белән су алып мендем дә, капотны ачып, радиаторга сала башладым. Нәкъ шул вакыт якында гына торган бер малайның: «Әй-й, Гарәф-Гарәфи... Әйдә, төшсәң төш инде!» — дип искәрмәстән генә кычкырып җибәрүеннән тетрәп киттем. Чөнки минем улымның да исеме Гарәф иде.

Мин эшемнән бүленеп малай-шалайлар ягына борылдым. Минем дә «Гарәф-Гарәфи»не күрәсем килә иде. Карасам, барысы да каршы яктагы текә таудан шуып төшәргә җыенган малайга таба карап кыч-

кырыналар икән. «Гарәф-Гарәфи»гә күп булса ун-унбер яшьләр чамасы булыр. Нәкъ минем Гарәфием кебек. Малайдан мин дә күземне алмыйм. Өс-башы әллә ни шәптән түгел. Бүрек колакчыннары да бик шәлперәйгән. Ә астагы малай-шалайлар акыралар да бакыралар. Хәтта көләләр. «Гарәф-Гарәфи!.. Әйдә төш инде... Әллә курыктынмы?.. Ха-ха!..» — диләр.

Малайга житә калды. Бүреген һәйбәтләп куш кулы белән батырыбрак киде дә, йөгереп килеп, текә таудан томырылып төшеп тә китте...

Бик җилле төшә. Егылмаса гына ярар иде, имгәнүе бар дип, аның өчен җан көеп торам. Менә ул яшен ташы кебек булып тауның уртасына житте... Инде тигезлеккә, елга өстенә төштем дигәндә генә кинәт әллә нәрсә булды... Малай кар бураны тузгытып мәтәлә-кадала әллә кая кадәр очып китте. Бер чаңгысы шунда ук шартлап сынды. Икенчесендә малайның нык итеп бәйләп куйган сыңар киез итеге салынып калды...

Мин: «Бәрелеп имгәнмәдеме икән?» дип, боз өстенә үк төшмәкче идем инде. Әмма иптәшләренең «Гарәф-Гарәфи!..» дип рәхәтләнеп тәгәрәшеп көлүләренә карамыйча, малай җәһәт кенә сикереп торды. Аның ялан аяк икәнлеген күреп-абайлап алган малайларга тагын да мәзәк артты, көлепме көләләр...

Гарәф иң элек чаңгыга эләгеп калган шактый зур, ямаулы киез итеген чишеп алып аягына киде. Аннары сынган чаңгысын кулына тотып, малайларга нәрсәдер аңлата башлады. Аның кулында гап-гади рәшәткә тактасыннан ясалган чаңгы сыман нәрсә иде.

Бу хәлне күреп күңелем сызып куйды: димәк, «Гарәф-Гарәфи»нең чаңгы алып бирерлек тә кешесе юк.

Кинәт кенә башыма шундый уй килде: туктале, малайның күнелен күрергә кирәк, мин әйтәм. Икенче көнне мин моңа чаңгы сатып алып килдем. Тик, үч иткән кебек, ул көнне Гарәфне боз өстендә очрата алмадым.

Шулай да шундагы малайлар арасыннан бер олырагын янымә чакырып алдым да Гарәф турында сораша башладым.

Бүреге күзләренә үк төшеп торган юеш танаулы бер малай:

— Кайсы Гарәф? — дип сорап куйды.

— Соң, теге Гарәф-Гарәфи инде,— дидем мин.

Башын артка ташлап миңа карап торган малайга шул житә калды.

— Ә-ә!..— дип сузды ул, кем турында сорашканлыгымны шунда ук төшенеп.— Алар әнә тегендә, балалар бакчасы янында, кар тавы ясыйлар...

Малайга Гарәфне чакырып килергә куштым. Юеш танау бик күндәм булып чыкты: «Хәзер!..» диде дә үзе: «Әнә тегендә» дип күрсәткән якка йөгерә-чабып китеп тә барды.

Ул арада мин боз өстенә төштем, җылудан тутырып бер чиләк су алып менеп радиаторыма салдым. Ул арада «Гарәф-Гарәфи»дә күренде. Ә йомышчы малай аның әле бер ягына, әле икенче ягына йөгереп чыгып, кулларын болгаштырып нидер сөйли, нәрсәдер төшендерергә тырыша иде.

Гарәф машина янына килеп житү белән, мин үземнең бик күптәнге танышымны очраткандай, нәкъ зурларча: «Нихәл, Гарәф!» дип кулымны суздым. (Ә аның яшендәге малайлар бик тә олы, бик тә эре булырга яраталар бит.)

— Исәнмесез!..— диде малай, шактый сәерсенеп. Мин аның бу гаҗәпләнү-тартынуын кимету нияте белән, беркөнгә текә тау ягына ымлап алдым да: «Чаңгыда бик шәп шуасың икән»,— дидем.

Гарәф-Гарәфи янә унайсызланып куйды, үзенең егылып көлкегә калганлыгын исенә төшерде, ахрысы.

— Һәй-й, чаңгы кадалды ла!..— диде ул, егылганы өчен акланырга теләгәндәй.— Ясаганда бөгелгән иде. Урамга чыгу белән янадан турайды... Шул кадалды да инде.

— Нәрсә, чаңгыны үзең ясаган идеңмени?

— Әйе! Икенчесен һәйбәтрәк итеп ясыйм. Такталарын хәзерләп куйдым инде...

— Нәрсә, чаңгы ясашырга әтиең яки абыең юкмыни?..— дидем мин, сүзнең шома гына ялганып китүенә куанып.

Бу юлы Гарәф-Гарәфи урынына һаман да әле чаж-чож китереп борынын тартып торучы йомышчы малай җавап кайтарды:

— Юк... Аның әтисе дә, абыйсы да юк. Әнисе генә бар аның.

Гарәф: «Кешеләр сөйләшкәндә тыгылып торма әле монда», дигәндәй, малайның аңсыз да кузләренә үк төшеп торган бүреген бөтенләй авыз-борыннары да күренмәслек итеп батырып куйды. Әмма тегесе мондый гына җәберне бар дип тә белмәде, бүреген күтәреп җибәрде дә, янадан авызын ачып, безнең сөйләшүне тынлап тора башлады.

— Кара әле, Гарәф, без бит әле синең белән танышмадык та түгелме соң? — дидем мин, янадан малайны сүзгә чакырып.— Минем исемем Шәрәф... Ә син Гарәф. Шулай булгач, без Гарәф белән Шәрәф булабыз инде...

Ә үзем: «Ничегрәк итеп чаңгыны тапшырырга соң?» дип баш ватам. Малай бер дә килде-киттегә охшамаган, бик горур күренә, хәзерлексезнисез чыгарып бирсәң, алмавы да бар. Мин сүзне янадан әлеге дә баягы бер көн Гарәф мәтәлгән текә тауга күчердем.

— Гарәф,— дидем мин,— синең шул таудан җил уйнатып тагын бер тапкыр шуып төшүеңне күрәсем килә.

Малайга тагын җан керде.

— Һәй-й!..— дип сузды ул.— Аннан кем дә төшә ала. Менә, яна чаңгыны гына ясап бетерим...

Мин аны бүлдердем:

— Чаңгы дигәннән, Гарәф, син аны ясап вакытыңны юкка әрәм итмә әле. Менә миндә дә бар бер чаңгы... Алган идем дә, бәләкәй булып чыкты, җилкәмә дә җитми. Аннары, миңа сакаллы сабыйга, хәзер чаңгы шуып йөрү килешмидер дә... Менә, каешлары да бар. Үзең рәтләрсең шунда. Тик бер шарт: миңа обязательно шул таудан шуып төшеп күрсәтерсең. Сөйләштекме? Менә шул! Мин гел йөреп торам моннан. Көненә әллә ничәшәр тапкыр узам. Моннан соң мин сиңа сигнал бирә торган булырмын. Гомумән, без күрешкәләп торыйк... Ә хәзергә хуш, миңа китәргә кирәк...

Янәбызда торган юеш танаулы малайга: «Мә, конфет алып ашарсың...» дип берничә көмеш акча төрттем дә, бүләгемне тапшыра алуыма куанып, кабинага сикереп менеп тә утырдым...

Шуннан соң мин, берничә көн рәттән дамба өстендә туктап, һәрвакыт диярлек кирәксә-кирәкмәсә дә радиаторга су салып маташтым, хәтта сигналлар да биреп карадым. Әмма Гарәф-Гарәфине күрә алмадым. Берәр хәл булды микән әллә дип борчыла да башлаган идем инде.

Ниһаять, кабат күрдем үзен. Чаңгысын тагып юл буена чыккан иде.

— Шәрәф абый!..— дип, үзе үк әллә кайн кычкырып, елмаеп каршы алды.

— Нихәл, Гарәф-Гарәфи!..— дидем мин, кабинамнан сикереп төшеп.— Нәрсә булды сиңа? Әллә авырдыңмы?

— Һәй-й, юк лә...— диде малай, үзенең нәрсәгәдер ризасызлыгын белдереп.— Мәктәптән кайту белән утынга куа...

— Утынга кая барасың соң?

— Тугай таллыгына. Үч иткән кебек, кары тирәнәйде. Чананы чыгарыр хәл юк...

— Бәләкәй чана белән йөрисеңмени?

— Алай икән,— дидем мин.— Бүген кумадымыни? Әниеңне әйтәм...
Гарәф елмаеп куйды.
— Кичә наруш ике юллаган идем...
Әңгәмәне икенчегә борып, сүзне чаңгыга күчердем.
— Ничек соң? Шәп шуамы?..
— Һәй-й, шәп кенәме соң! Ут!..— диде Гарәф, кинәт җанланып.— Мин хәзер сезгә теге таудан төшеп күрсәтәм...
Малай минем ризалык бирү-бирмәвемне дә көтеп тормады, жил уйнатып тауга таба китеп тә барды. Башта юл буйлап, аннары кисәк борылып «чыршы» ясап, тау бигләтеп өскә таба күтәрелә башлады.
Тау башына менеп баскач: «Әһ-һәй-й!..» дип кычкырып, миңа кул изәп алды да, җан-фәрманга йөгереп килеп, аска таба очты...
Бу юлы да: «Егылмаса гына ярар иде» дип, тын да алмыйча торам. Юк, егылмады, елга өстенә шуып төшеп, пар чыгып торган җылу тирәсенә җитәрәк кинәт кенә борылды да бер урында шып туктады. Чаңгылар астыннан кар тузаны гына бөркелде. Һәм шунда ук: «Булдырабыз аны!» дигән кыяфәт белән, кулларын кирәгеннән артык кин-киң селкеп һәм бер дә исе китмәгән кыяфәт белән минем янга күтәрелде.
Куккә чөеп мактадым үзен. Әмма аның моңа әллә ни исе китмәде. Шул чак сүзгә сүз иярә китеп, тормыш әхвәлләре турында сөйләшеп алдык.
— Шәрәф абый, сезнең үз улыгыз юкмыни? — дип сорап куйды Гарәф, искәрмәстән генә.
— Юк шул,— дидем мин.— Бар иде дә үлде... Мин сугыштан кайтканда ул инде үлгән иде.
— Сез дә сугышта булдыгызмыни?
— Булдым, Гарәф. Башыннан алып ахырына кадәр булдым.
— Ә минем әти сугыштан кайта алмады...— диде Гарәф. Бу сүзләрне әйткәндә аның балалык йөзен җитди кырысландырып күләгә йөгереп үтте.
Ул көнне без тагын да дусланып, кабат очрашырга сүз куешып, чын ирләрчә чалт та чолт куллар бирешеп аерылыштык.
Көннәр үтә торды. Һәм миңа Гарәф-Гарәфи белән очрашу, аның белән бер-ике генә авыз сүз әйтешеп алу да һава кебек үк кирәк була башлады. Мин искәрмәстән генә гаять кыйммәтле, тормышымны тулыландырып-яктыртып җибәргән җан иясе тапкандай булдым. Бер-ике генә көн күрмичә торсам да, күңелем сызып әрни башлый. Ә инде очрашкач, сүзебез бетми. Мин аны берничә тапкыр хәтта кабинага утыртып станциягә дә алып бардым. Ә инде анда иң элек Гарәфне ашханәгә алып кереп һәйбәтләп сыйлыйм. Ул елларда исә туйганчы ашау, кем әйтмешли, үзе бер проблема иде.
Бераздан инде миңа Гарәф кенә түгел, ул яшәгән поселокка кадәр якын була башлады. Шул поселокка якынлашкан саен күңелемне әйтеп бетергесез татлы җылылык биләп ала торган иде.
Шулай январь чилләсе җитте. Чатнама салкыннар башланды. Икенчеме-өченчеме рейсны ясаганда кабат әлеге поселокка якынлашып киләм. Уемда Гарәф кенә. Очрашасы иде үзе белән. Менә елга өсте. Бәхеткә каршы, боз өсте тулы бала-чага. Тик бу юлы алар ничектер барысы да бер урынга җыелып, әүмәкләшеп торалар. Мин гадәттә туктый торган җиремә җитәрәк тормоз салдым. Кабина ишеген ачам. Малай-шалайларның шау-шуы ачыграк ишетелә башлады. Әллә берәр хәл булдымы икән? дигән уй чагылып китте. Шул ук вакыт аермачык булып: «Һәй-й, Гарәф-Гарәфи!..» дигән авазлар колагыма килеп бәрелде. Карасам, чыннан да урта бер җирдә Гарәфи басып тора. Ул бөрешкән, әле генә янында агып яткан җылудан чыккан булса кирәк. Ничек итеп инеш өстенә атылып төшкәнемне сизмичә дә калдым.

— Нәрсә булды?..— дидем мин, балалар арасына бәреп кереп.

— Әнә, Гарәф-Гарәфи суга төште... Капкачы булып тора иде, тайды да китте...

Өстендәге киемнәре бозлана башлаган Гарәфне кулыннан эләктереп алдым да:

— Салкын тидерәсең бит, шайтан малай! Үләсең ич...— дип, җилтерәтеп машинам янына алып менеп тә киттем. Чөеп кенә кабинага менгездем, кайда торганлыгын белештем дә өенә алып киттем үзен. Бәхеткә каршы, әллә ни ерак тормыйлар икән, бик тиз барып җиттек. Бәләкәй генә өй. Киртә-коймаларының, лапас-каралтыларының да рәтечираты юк. Кыскасы, тормышлары коелып төшәргә җитешкән. Ир-ат кулы җитмәгәнлеге әллә каян күренеп тора.

Безне плита янында кер кайнатып маташучы Гарәфнең әнисе каршылады. Өй эче пар-бу белән тулган. Ана кеше әллә ни төпченеп тормады, эшнең ничек булганлыгын чак кына абайлап алу белән идәндә, янган плита каршында яткан тал чыбыкларының җиллерәген сайлап алды да: «Менә сиңа! Менә мә!» дип, Гарәфнең сыртын каезлый да башлады. Мин аны тыеп та караган идем, кая ул!

Малайның исә әнисенең дулавына әллә ни исе китмәде, тиз генә чишенеп ташлап, чиләк-баклар тезелеп торган кайнар плита тирәсенәрәк елышуын белде.

Мин саубуллашкандай иттем дә китеп бардым. Әмма пар-бу белән тулы өй эче, чырае йончыган хатын, янган мич алдында яткан тал чыбыклары минем күз алдымнан тиз генә китмәде.

Шуннан соң мин Гарәфне өч-дүрт көн буе күрмәдем. Машинамны туктатып малайлардан да сораштырып карадым, ләкин күңелне юатырлык җавап бирүче булмады. Әллә авырыймы икән дигән уй тынычлык бирмәде миңа. Ниһаять, түземлегем бетте, нинди булса да сылтау табып, үзем барып чыгарга булдым. Сылтавы да бик тиз табылды. Бер якын танышым прораб булып эшләгән төзелешкә бардым да, акбурнзвестька буялган булса да, тау кадәрле итеп менә дигән коры бүрәнә башлары, калын такталар төяп юлга чыктым. Шоферның юлы туры, бәхетнең юлы тулы дигәндәй, безнең братка бит акмаса да тама...

Мин Гарәфләрнең капка төбенә барып туктаганда өйләрендә беркем дә юк иде. Капканы да көрт баскан. Мин лапас астыннан бер көрәк кисәге табып, карны көрәп, машинаны көч-хәл белән ишек алдына керттем дә йөгемне бушата башладым. Шул вакыт Гарәфнең әнисе кайтып керде. Ул шунда орынып кына торган балалар бакчасында җыештыручы булып эшли икән. Өегез каршына ниндидер машина килеп туктады дип, аңар кереп әйткәннәр.

Утынны күреп хатын куанды да, шул ук вакытта уңайсызланды да. Ничектер сүзе сүзгә ялганмыйчарак торды. Моны сизенгәч, мин дә авызымны йомып тормадым. Утынга Гарәф йөргәнлекне белүемне һәм укуына зарар килмәсен дип менә, бераз калдык-постык такта кисәкләре китерүемне әйттем. Сүз уңаенда, беркөнге хәлдән соң, малайның кәефе белән дә кызыксынып куйдым.

— Һәй-й, җык булсынмыни ул ташбашка!..— дип җавап кайтарды әнисе. Һәм шунда ук, аяк ялы дип, бәлки кибеткә йөгереп барып килергәдер дигән кебегрәк сүзләр ычкындырды. «Хәтеремне калдырырга теләмәсәгез, ул турыда тешегезне дә агартмагыз», дип кырт кистем.

Утынны бушатып бетергәч, мондыйрак сүз булып алды. Иртәгә хуҗа хатынның ял көне икән. Гарәфнең дә көндезен укудан кайткан вакыты була. Мин әбәт вакытларында кабат аларга кереп чыгарга вәгъдә итеп китеп бардым.

Ихлас күңелдән чакыру иде бу. Шуңлыктан мин икенче көнне сөйләшенгән вакытка аларның капка төпләренә килеп туктадым. Иң элек куанычыннан нишләргә белмәгән Гарәф-Гарәфи атылып чыкты. Үзе

көлмәкчән генә. «Салкын тиләрәсең ич, шайтан малай!..» дип битәрләгәндәй иттем үзен.

Шау-гөр килеп өйгә кердек. Бүлмә эче дә курчак өе кебек итеп җыештырылган, ялт итеп тора. Бөтен өйгә ямь өстәп җылы төшкән, тәмле таба исе чыккан. Без исәнлек-саулык сорашкан арада Гарәф өстемдәге кисемнәрне җилтерәтеп салдырып элеп тә куйды. Хуҗа хатыны да бик итагатьле генә итеп: «Юынып алыгыз» дип, юынгычка су салды.

Юк, егетем! Ул минутта минем учыма аккан талгын суның җылылыгы йөрәкләремә кадәр үтеп керде. Ул чакта кичергән хис-тойгыларымны сүз белән генә аңлатырлык түгел иде. Гаилә тормышы, гаилә җылылыгы ул вакытта минем өчен бик тә, бик тә тансык иде шул.

Табын янына утырдык. Хуҗа хатын гаепле кеше сыман итеп: «Сез гафу итегез инде. Мин теге... кибеткә-мазарга бармадым», диде. «Ул турыда сүзнең булуы да мөмкин түгел, мин рульдәге кеше, безнең эштә төрле хәл була», дип тынычландырдым тегене.

Өстәлгә кайнар өчпочмаклар салынган тәлинкәләр килеп утырды. Ә Гарәф-Гарәфи авызын җыя алмый, бөтен табынны бер итеп утыра, безгә авыз ачарга да ирек бирми. Гүя аның куанычы хәттән ашкан, куенына сыймый. Җаен туры китереп, хәтта кыдрачланып та алгалый.

Читенсенү, ятсыну әкренләп кими башлады, хатын да сүз катар хәлгә килде.

— Гарәф инде миңа сезнең турыда барын да сөйләп бетерде. Ятса да, торса да гел ән сез генә аның теленд ә...

Мин дә, сиздермәскә тырышып, хуҗа хатынга күз салгалап алам. Ул да бүген алыштырып куйган кебек. Беренче тапкыр күргәндә ул миңа шактый ук төс салган, аз сүзле, китек күңелле, моңсу кыяфәттәге йомык бер тол хатын булып күренгән иде. Чыннан да теге вакытта аның бары тик өзеп карый торган моңсу күз карашы гына хәтердә калган. Бу юлы исә минем каршымда кылны кырыкка бүләрдәй яшь кенә, иплe-җайлы хәрәкәтле, гаять уңган, җиләк кебек сылу хатын утыра иде.

Ул көнне ашны олылап, өйгә бәрәкәт-муллык теләп, саубуллаштык. Әмма бу өй (өй димәсәң хәтерс калырлык сыман!) минем күңелемне урыныннан кузгатты. Әйтерсең лә, миңа яшьлегем кайтты, гүя миңа бөтенләй искәрмәгән яктан бәхет елмайды. Мин инде Гарәфне дә, аның әнисен дә күрмичә булдыра алмаслык хәлдә идем...

Шул вакыт безнең дизель-электроходка орынып ук диярлек, шау-гөр килеп зур гына пароход узды. Юлдашым да, мин дә берьюлы тәрәзәгә таба борылдык. Идел өстендә төн иде инде. Сирәк-мирәк кенә утлар, төрле төстәге маяклар гына җемелдәшәләр. Кыскасы, шактый соң иде инде. Шуны сизенепме, юлдашым хикәясен очлап кую ягын карады.

— Менә шулай барлыкка килде ул безнең татулык һәм мәшәкать белән тулы гаилә тормышы,— дип, Шәрәф ага сүзен бетерде.

Салих Баттал

# ЧИРМЕШӘН ЯКЛАРЫНДА[1]

IV

Алма шул кичне Сәлимнең
түшәгенә атылды,
әйтте аңа: — Мә, ал, — диде, —
гармун уйнау хакыңны!..

Нәрсә белән түләсә дә
хуҗа кыз хаклы инде.
Гармунчының уналтыдан
яше дә артты инде...

Чиккә җитсә, читкә оча
әдәп-хая һәм саклык.
Нәрсә соң ул сөю хисе? —
үзенә күрә ачлык.

Шуны кандырса, үлсә дә
булыр иде Алма шат,
Садыйкның әти-әнисе
үлгән күк ярма ашап.

Үлмәде Алма. Димәк ки
уларга чарасы юк.—
Сөю ачлыгы булса да,
димәк ки, ярмасы юк...

Ягъни Садыйгы юк аның
гәрчә ул шунда гына
эшләп йөри, Алмаларның
ишек алдында гына.

Ян тәрәзә төпләреннән
алды Алма гөлләрне,
чөнки гөлләр каплый иде
Садыйк эшләп йөргәнне.

Карлар ява эри-эри,
каралты башы чери.
Садыйк, әнә, түбәләрне
кардан тазартып йөри.

Алма шунда чыгып, аңар
карлар көрәшмәк булды,
карлар көрәгән арада
җырлап серләшмәк булды:

«Чәчләремне үзем тарап,
синнән үрдерсәмче, — дип, —
үзең кабызган гыйшыкны
үзең сүрелтсәңче!» — дип...

Чыгып өлгермәде ләкин.
Килеп чыкты шул сәгать
атлыйм дигән адымнарын
атлатмый калган сәбәп.

V

Килеп керде Олы Сәлим.
Бәлки исегездәдер —
анысы — Алма абыйсы, —
ана башка, ата — бер.

Мескен бүреген киеп, ул
башларын түбән иеп
йөри иде. Килгән бүген
борынын өскә чөеп:

Алма! Чакыр әниеңне!
Хәзер сөйлим бер хәбәр,
самоварың өстәлеңдә
биер, ишетсә әгәр.

[1] Ахыры. Башы 3 санда.

Йортыгызда яшерелгән
йөклагән алтын-көмеш...

Тик әйтегез: табып бирсәм
күпмесе миңа тиеш?..

Сез таба алмыйсыз аны.
Мин дә алалмыйм ялгыз...
Уртагыннан эшлибезме?

Ашыкмагыз, уйлагыз...

Сәлим абзый үзе ачты
үзенең табышмагын:
Хәзинәнең «НЭП» икәнен
һәм аның табышларын:

— Бетерелә хәзердән үк
продразверсткалар!

Алма һәм әнисе моны
аңларга тырыштылар.

Аңлатты карт Сәлим:— Җирдә
казындык әрләп кебек,
кышлыкка ипи тупладык.
Ә кемнәр алды килеп?

Садыйклар хуҗалык итте,
Антоннар — килмешәкләр...
Ә без — җирне сөрүчеләр —
булып калдык ишәкләр.

Бу тәртипләр бетерелә,
киртәләр юлдан оча!
Игенчеләр үз милкенә
үзләре хәзер хуҗа.

Хуҗа — Алма! Мине ялла,
мин синең ялчың булам,—
ялчың сыйфатында эшләп,
синең яклаучың булам! —

Табыш — уртак! Я, ризамы?
Якынайсын арабыз.
Комачаулый торганнарны
юлыбыздан алабыз.

Сокращение ясыйбыз,
менә исемлек — алда.
Кемнән башлыйк? Антоннанмы?
— Садыйктан! — диде Алма.

Ниһаять, тапты җыйналган
хисләренең әчкечен:
мәхәббәт урынына хәзер
күрсәтер власть көчен!

Төрле мәкер чаралары —
сайлар ул караларын.
Үзенә булмаса булмас,
бозар ул araларын.

Ачса карын, ташлар ярын!
Җырлады бит ташбака:
«Иске ипигә мәхәббәт
яңа ярны ташлата»...

VI

Садыйк — кеше сыйфатында
гәүдәләнгән эш — үзе
менә хәзер НЭП чорының
иң беренче эшсезе.

Әтисе һәм әнисенең
«әчен» уткәргән залда —
расчетка дип керган Садыйк.
Кем расчет бирә? — Алма!

Тик хәленнән генә килми,
килсә — кол итеп сатыр
Алма кыяфәтендәге
шәфкатьсез бер диктатор.

Әйтеп тә карады Садыйк:
— Җәмәгатем йөкле,— дип,—
кетәр идегез, яңа эш
тапканыма тикле,— дип.

Кулын гына селтн Алма:
— Күпме генә йөрсәң дә,
миңа килеп чыгачаксың,
кай ишектән керсәң дә.

Мин тап идем,— иелә идем,—
әверелдем имәнгә.
Белмәдең кадерләремне
башларымны игәндә!

Үз явызлыгың үзеңә
кайтты инде барысы.
Җәннәткә чакыручыңны
син тамугка салучы...

Кичә Сәлим шунда кереп,
аңар комачаулады:
— Син варисәме, мин — варис,
Юл куймам! — дип шаулады.

Революциядән бирле
ялчы ул суздә генә;
йозләрен ачып байларның
үтте ул үзәгенә.

Кем икмәк яшерә, аңар
Сәлимнең сузе ике.
Яшерми әйтә байларга:
«Яшерелгән — безнеке!»

Һәм таба ул һәммәсен дә.
Тик ала карап кына.
Куярлык аның һәр күзен
Рентген аппаратына.

Менә Садыйкны да бүген
чыкты яклап ул егет,
байлар телендә «елан» ул,
халык телендә — «селек».

Шаңгырдатып, Алманың ул
маһәр сандыгын ачты,
васыятьнамәне алып,
Алма каршына басты:

— Күр, атиең васыятендә
Иң беренче — мин! — диде —
тыныч йокла, Садыйк абзый,
эштән алмыйм мин сине!

Ләкин элекке түгел шул,
Алма да башка хәзер,
шуңар Сәлим чалгысы да
терәлде ташка хәзер...

Алма, алып ул кәгазьне,
бер секундта ертналап:
— Марш подвалыңа! — диде
Сәлимгә кырыс карап.—

Балигъ яшькә җитми торып
борыныңны тыгасың.
Эштән очасың килмәсә —
залда эзең булмасын!

Өенә атлады Садыйк. Ә
күңеле шундый боек...
Кемнәр өчен көрәште ул
ничә ел! Каннар коеп?!

Эсселәп, чиште каешын.
Аркасы чымырдады:
«Ачы сагыш, кулда каеш,—
әллә асылыргамы?..»

Сельсоветның түбәсендә
җилферди кызыл әләм,
күңелеңне төшермә,— ди,—
гүя юллый ул сәлам,

Садыйк, кайтасы юлыннан,
борылды карап шуңа.
Күрде — башкалар да килә
шушы әләм астына.

Аның өске почмагында
чүкеч һәм урак тора.
«Әре буржуйлар дөмекте,
каршыда кулак тора...»

## ТУГЫЗЫНЧЫ КИСӘК

### I

Мәскәү ягына Казаннан
китәргә поезд тора.
Пассажирларны магнит күк
үзенә сырыштыра.

«Үгез вагоны» эченә
басма буйлап менгәндә
кыска, ачык фәлсәфәсен
ишеттерә бер бәндә:

— Кысыла төш! — дип кычкыра
алдагыга бәйләнеп.
Шундук:— кысмагыз! — ди үзе
арткы якка әйләнеп...

Алга кычкыра: «Кер, тизрәк,
әнә, урын бар тагын!»
Артка кычкыра: «Урын юк!
Резина түгел вагон!»

Шулай үтә безнең гомер
бер-беребезне куып,—
алдагыны кысрыклап,
арттагыга юл буып,

үзебезне үзак санап,
без телибез яшәргә.
— Кысылыгыз! — дип картларга,
— Кысмагыз! — дип яшьләргә.

Андый үзак юк асылда,
бары тик кәраш — үзак.
Һәрбер карттан картрак ул,—
Яралгыдан яшьрәк.

Поездга сырыша халык.
Билетлар я мандатлар
уңайлык түгел, кешегә
азап өстәгән чаклар.

Үрмәли кеше. Тик белми —
кире кайтмас көннәре;
юлда шулай үзләренә
үрмәләр тиф бетләре...

Күбесен бу юлга куган
әлегә ачлык инде.
Күбебез ул елны шулай
илләрдән качтык инде.

## II

Кузгалды поезд, составын
меңләгән кулдан өзеп.
Ана эт, ятканда шулай
балаларын имезеп,

үзенең йомышы белән
кинәт кенә кузгала,
имүчеләр кала егылып
төрле-төрле позада.

Тагәри, имгәнә кеше.—
Түшап куймаган мендәр.
Эттән артык азап күреп
тәгәраүчеләр — меңнәр...

Шул ук поезд алып китте
Мәгъзия малаен да —
шул ук вагон түбәсенең
бозланган калаенда.

Ялгыз түгел, каләшен ул
урнаштырды тамбурга
(бәлки тамбурларда алар
яратышканнардыр да...).

Ул зур йомыш белән бара —
«Нәрсә ул? Чыкканмы НЭП?» —
Авылның шушы соравын
ачыклап кайтырга, дип.

Сугышу түгел бит — йөрү,—
армый-талмый йөрер ул,
ахыр чиктә ходок булып
Ленинга да керер ул...

Шул теләк белән җылынып
бара әле түбәдә.
Бозлы томан шинельларне
әйләндерә кәбәгә.

Шакыр-шокыр итә җиңнәр —
тиздән бегелмәячәк.
Һәм үзе дә боздан койган
һәйкәлгә әйләнәчәк.

Халык әйткән юл газабы —
гүр газабы — шул инде.
Тик юлында күп гүрләрне
үткән егет ул инде.

Кылычы да үз янында —
Ул — данлы юллар үткән,—
Садыйкның үз исемен сугып
Буденный бүләк иткән.

Мәнә шуның очы белән
җәен җәйдән аерып,
вагон эченә люк ачты
түбә читен каерып.

Госпитальны хәтерләтеп,
һәм — нашатырь спиртен,
бәрде җылы кеше исе
ачкелтем дә төчкелтем.

Садыйк белән кучте шунда
Кырым геле дә бергә —
тышкы суык,— киң кабердән
эчке җылы — тар гүргә...

## III

Озакламас, аннан кубып,
терелеп чыгар алар.
НЭП юллары буйлап инде
тезеләләр чаналар:

Хәбәр бар Украинадан —
чәчүлек орлык килер.
Шул ук поезд, орлык төяп,
Казанга борылып килер...

Садыйк керткәндәй вагонга
саркын һава хушлыгын,
НЭП китерде шәһәр белән
эшчән авыл дуслыгын.

Без дә романның поездын
куйыйк үз барышына.
Ялганачак аның юлы
Партия тарихына.

## УНЫНЧЫ КИСӘК

### I

Минем геройларым өчен
Ленин белән очрашу
бик үк җиңел булмаса да,—
ул биеклеккә ашу

авыр булмады, һәр халдә
вагонга кергән кебек,
я хәзерге бюрократка
приемга йөргән кебек.

Олы хисләр уяндылар
Садыйкның йөрәгендә:
гәрчә йомышы зур түгел
Россия күләмендә...

Аның каравы, тик шунда
күргәндәй булды Садыйк:
Шундый зур булып үстеләр
профсоюзлар һәм Совет...

## II

Була хәлләр, гомерлеккә
сөйләрлек сагынып кына...
Кабинетта калды менә
Ленин да Садыйк кына.

Каплан салган яралардан
сызланып калган иңен
язылдырып йөренә-йөренә,
Надясын көтә Ленин.

Садыйкка ымлап әйтте ул
секретарен чакырып:
— Бик соң инде, ял итегез
миңе аңар тапшырып.

Баш какты секретарь. Чыкты.
Әйләнеп керде. Шунда
кертте Садыйкның капчыгын
һәм аның кылычын да.

Шыпырт кына әйтте нидер,
сер әйткән кыяфәттә.
Серне ачты Ленин үзе:
— Керсен, керсен, әлбәттә!

Килеп керде Кырым килене
һәм алар күрештеләр
исемнәрен атап:
— Зөһрә...
— Владимир... диештеләр.

Садыйк бу хәлләргә карап,
таң калып торды читтән:
«Ленин бит ул гап-гади бер
Владимир да икән!

Ленин — безнең юлбашчыбыз
максатта һәм мәсләктә.
Ә Владимирга нигә
семья серен әйтмәскә!»

һәм сүз арасы сүз чыгып,
әйтте серен:— Алма бит
сыйнфый дошман гына түгел,
семья дошманы да,— дип.—

Тынгы бирмәс, анда кайтсак
аның мәкерле чирә.
Кырымга китик: Зөһранең
ватаны шунда,— диде.

Ялт итеп борылды Ильич
һәм шик калмаслык итеп,
сорау белән җавап бирде:
— Ә халык йомышы ничек?

Ничек булыр, үтәмичә
хезмәт халкы кушканны,
иренкә калдырсаң анда
шушы сыйнфый дошманны?!

Кылычны карады Ильич.
Аз гына уйга калды.
— Башкарылган эш — зур,— диде,—
башкарыласы — тагы...

Бетте Казан губернасы —
патшалар колониясы.
Туды тарихта беренче
татар автономиясы.

Менә кайда сезнең мәйдан.
Бакча итегез аны.
Сезнең кулда килачәге,—
Республикагыз даны.

Бу — шундый маяк, беләмсез,
илнең чикләре аша
Сун Ят-сен безгә күз төки,—
Мостафа Камал паша:

«Нигә үз илебезне дә
анә шулай итмәскә!» —
Шулай үрнәк алмыймыни
иптәш карап иптәшкә!

Коммунист түгелләр алар.
Һәм, нәкъ шуның өчен дә,
үрнәк күрергә тиешләр
коммунистлар эшендә!

Һәм бу шулай булачак та.—
Бик камил минем өмет.
...Надежда Константиновна
шушында керде килеп.

## III

Ике ир, ике хатын-кыз,
пар-пар булып, янәшә
төрле хәл-әхвәл турында
әзелеп-әзелеп сөйләшә.

Алар сөйләшкәнне тыңлап,
бар җир шары тынды күк;
Мостафа Камал паша да,
Сун Ят-сен да тыңлый күк.

Садыйк гомердә онытмас
Ленинның якты йөзен,
саубуллашып, кулын кысып
Садыйкка әйткән сүзен:

— Буденный гаскәрләренең
йөреп алгы сафында,
тезелешкә кучсә бу кул,
башкарыр анысын да.

Ышанам — килер ул көннәр —
очрашырбыз тагын да;—
исемегез булыр ураклар,
чүкечләр металлында...

Сельсовет байракларында
чүкеч һәм урак тора.
Кайтып рәис булды Садыйк.
Каршында — кулак тора.

Шул кулак әйткән иде бит:
«Күпме генә йөрсәң дә,
миңа килеп чыгачаксың,
кай ишектән керсәң дә...»

Шул әйткән иде Садыйкка:
«Әверелдем имангә...»
Хәзер мөнә миһләт сорап
тора, башын игән дә...

Беләләр бит тегермәннән
күпме табыш алганын!
Продналог түли...— Иртәгә
түләрмен,— ди калганын...

Түләргә унынчы булып
бәлки монда кергәндер...
Ә Садыйк — власть вәкиле,
Ә ул бездә — бердәнбер.

## ТӘМАМЛАУ СҮЗЕ

Җир астыннан чыгар-чыкмас
буылып, чишмә ята.—
Уйсу җирдә, юлчыларның
күзеннән читтә ята.

Тау чишмәләредәй булса,
чылтырап агар иде.
Нишләсен — уйсу урында,—
юк аның агар җире.

Изрәтә бар тирә-юнен
батказлык белән янап.
Тик табылды бер әү. Аңар
утмәде читтән карап.

Шул батказлыкның эченә —
уртага керде кеше;
иң изрәгән урнын сайлап
кирәк батырды кеше.

Ул — мин идем... Ул көннәрем
артта калдылар күптән.
Кулыңдагы Роман-чишмә
бәрде дә чыкты төптән.

Ургылды халык хисләре...
Сиңа аның барысы!
Минем эш — тик казулары
һәм бураган бурасы.

Укучым! Бу чишмәнең мин
сиңа саф суын телим,
тирәсенә, сугарылып
гөлләр үсүен телим.

Өмет әзмим — саф суларын
эчеп үтәрсең бәлки;
гөлләр өзеп, сөйгәнеңә
бүләк итәрсең бәлки?!.

◇◇◇◇◇◇◇◇

Сәббух Рафиков

# ТЫН ЕЛГА БУЕНДА

РОМАН[1]

## 15

Булса була икән инә күзеннән үткәрү... Хуҗаларга тегесе ошаса, монысы ошамый, монысы ошаса, тегесе... Ванна булып ваннаны дүрт тапкыр күчереп куярга туры килде. Соңгы көннәрдә квартирда барлык эшләр тәгәлләнгән, идәннәр кипкән, инде күчеп килергә мөмкин иде кебек. Әле хуҗаларның һаман квартир ачкычын үзләренә алмаулары һәм күчәргә ашыкмаулары төзүчеләрне борчый иде. Прорабны әйткән дә юк, ул, бөтенләй кул селтәгән кебек, соңгы вакытларда килеп тә карамый башлады. Бу көннәрдә вакытлыча торак төзелешенә күчерелгән буяучылар звеносы башлыгы булып йөргән Фарук белән бригадир Кузнецов квартирны соңгы тапкыр карап чыктылар. Монда һәр нәрсә үз урынында, бүлмәләр ялт итеп тора, якты, җылы һәм стеналар күзгә кебек тигез, шома иде.

— Бик шәп! — диде Кузнецов.

— Инде шәплекнең аръягында! Барып чыккан бу, бәреп еккан,— дип Фарук бригадир сүзләренә печать басты.

— Инде хәзер дә гаеп тапмаслар!

— Дөрес! Турыны кыек дип булмый, сүз әйтерлек җире юк инде моның.

Кузнецов белән Фарук шулай үзара киңәш итеп алдылар да Юлдашевка шалтыраттылар. Тиздән җиңел кара машина дүрт катлы яңа йорт янына килеп туктады. Юлдашев, үзенең тиздән күчәчәк квартирын җентекләп карап чыккач, артык аны-моны әйтмәде. Аның төсендә елмаю һәм артык куану билгеләре булмаган кебек, ризасызлык та сизелмәде. Юлдашев кайбер бүлмәләрне кабат-кабат карап чыкты. Мактап яки хурлап бер авыз сүз әйтсә икән. Тик бригадир инде күчәргә вакыт җитүен әйтеп, үзенә квартир ачкычын тәкъдим иткәч кенә теле ачылды:

— Хатын килеп карасын әле. Аннан күз күрер.

---

[1] Дәвамы. Башы 2, 3 саннарда.

Поликлиникада эш көне беткәч, яңа квартирны карарга Юлдашевның хатыны Зәйтүнә Хикмәтовна да килеп житте. Ул, ире кебек үк, һәр бүлмәне, һәр почмакны җентекләп карап чыкты, әлегә кучәргә ашыкмауларын әйтте.

— Нигә? — Бригадирның борынына бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты.

— Кухняны икенче төскә буярга кирәк. Бу төс бармый. Түр бүлмәнең идәне начар буялган. Коридордагы буяуның төсе миңа ошамый...

— Тагы?

Кузнецовның чырае караңгыланды, аның соравы да җавапсыз калды. Бу квартирны буйый-буйый тәмам туеп беткән бригадир Юлдашевның үзенең бернинди дә искәртү ясамавын, барысыннан да риза сыман тавышсыз-тынсыз гына китеп барганын әйткәч, Зәйтүнә Хикмәтовна аңа карамыйча гына сөйләнеп куйды:

— Зариф Салихович белән минем фикер бер.

— Монда, безнеңчә, янадан кул тыгарлык урын юк,— дип, бригадир Кузнецов үз фикерендә калганын әйтте.

Баш инженерның хатыны дәшмәде, артык юанмыйча китеп тә барды.

Икенче көнне прораб бу квартирга эшчеләр җибәрмәде. Чөнки Васил Сафинның кушуы шулай иде. Ул хуҗалардан соң квартирны үзе килеп карады, аннары катгый карарга килде.

Васил, әллә Никитинның үзе белән киңәшеп карарга микән, дип фикер йөртсә дә, сонра бу уеннан кире кайтты. Кайнар эздән Юлдашевка телефоннан шалтыратты, тавышы калтыраса да, тыныч сөйләшергә тырышты. Озак көтәргә туры килмәде. Дүрт катлы яңа йорт янына янадан кара җинел машина һәм иске, әрсез газик килеп туктады. Юлдашевлар ирле-хатынлы килгәннәр булып чыкты. Өчәүләп квартирны карарга керештеләр. Юлдашев саран гына елмайды:

— Сезгә кешеләр турында кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен рәхмәттән башлыйммы сүзне?

— Нинди рәхмәт? — дип гаҗәпләнә калды Васил.

Зәйтүнә Хикмәтовна инбашларын селкетеп куйды.

Алар бер бүлмәне карап, икенчесенә күчәргә өлгермәделәр, кемдер сак кына ишеккә шакыды һәм килеп тә керде. Аның өстендә язгы-көзге пальто, башында эшләпә, аягында резин итекләр булып, кара галстугы бер якка кыйгаеп тора, болай төсенә-битенә карап урта яшьләрдәге кеше икәнен чамаларлык иде. Әле яңа гына кырынган булса кирәк, иякяңаклары шоп-шома һәм үзеннән одеколон исе аңкый иде. Василлар аны кем дип тә уйларга белмәделәр. Алар белән тыйнак кына күрешеп чыккannan соң, документын күрсәтте. Юлдашев, аның үзенә сиздермәскә тырышып, бу кешене баштанаяк күзләре белән сөзеп чыкты. Сагая төшебрәк аңа сорау куйды:

— Йомышыгыз кайсыбызда иде?

— Һәр икегездә дә.

Юлдашевның күзләре зур ачылды, бармак очларына нииндидер салкын калтырау йөгерде. Аныңча, монда бу кешенең катнашып йөрүе артык, бер дә кирәк түгел иде. Шуны күздә тотып ул әйтә куйды:

— Без тиздән бушыйбыз. Сез конторага барып, бераз көтсәгез, ничек булыр?

Тегe бер дә исе китмичә генә үзенекен итте:

— Алай да ярар иде дә. Әйдә, бер очрашкач, сездән аерылмыйм инде.

Васил эндәшмәгән кебек, Юлдашев та аңа каршы килеп бер сүз әйтмәде. Инә-җептән әле генә төшкән затлы кием кебек һәр җире, һәр төше күңелгә куш килерлек квартирның бөтен җирен җентекләп карап чыккач, Васил Юлдашевка карап сүз кушты:

— Я, ничек, кабул итәрлекме?

Юлдашевлар ирле-хатынлы, ни әйтергә белмичәрәк, бер-берсенә караштылар да, сүз катырга батырчылык итә алмыйча, тынып калдылар.

— Минемчә, бу һәр яктан төгәлләнгән, янадан кул тидерәсе юк. Хуҗаларга күчәргә дә рәхәтләнеп торырга,— дип үз соравына үзе җавап кайтарды Васил.

Юлдашев сүзсез катып калды. Бу төз борынлы, зур соры күзле кеше — республика газетасының үз хәбәрчесе, монда аларны көлкегә калдыру өчен кем тарафыннандыр юри чакырып алынгандыр кебек тоелды аңа. Хәбәрче шунда кинәт кенә сүзгә кушылып китте:

— Мин сезнең соравыгызны аңлап бетермим, иптәш Сафин. Бу йорт бит инде тапшырылган. Һәр квартирда кешеләр тора. Ә сез бер квартирны кем кабул итәргә кирәклеге турында сөйлисез?

— Ничек әйтергә? — дип тукталып калды Васил. Юлдашев та, хатыны да, безне бәладән коткар, дигән кебек Василга карадылар. Ул исә башта ык-мык килебрәк торды. Аннары әкрен тавыш белән салмак кына тел тибрәтте:

— Бу квартирның дефектлары күбрәк иде. Шулай туры килде.

Хәбәрче тагы сорады:

— Димәк, монда сез күченәсез, иптәш Юлдашев?

— Әйе, мин күчәргә уйлыйм.

— Барлык квартирларны да шушылай бик яхшы сыйфатлы итеп эшләтсәгез, сезне мактап бетерерлек булмас.

— Билгеле, сыйфатны беренче планга куябыз,— диде Юлдашев.

Хәбәрченең зур соры күзләре хәйләкәр елмаеп кысыла төште:

— Ничектер мона ышанып бетәсе килми, иптәшләр.

Василга да уңайсызрак булып китте. Каян килеп юлыкты соң әле бу хәбәрче?! Әллә ниләр язып чыгаруы бар аның. Әмма ничек кенә булмасын, бу зур газетаның вәкиле алдында хәйлә корып сөйләшүнең файдасы бирмәячәген уена бик ачык китерде ул. Аннары, хәбәрченең тел төбенә караганда, аның дөнья күргән кеше булуын һәм төзү эшләре белән дә яхшы ук хәбәрдар икәнлеген абайлап алды. Үзен дә, Юлдашевны да кыенрак хәлдән чыгару нияте белән шулай әйтергә тиеш тапты:

— Билгеле, сыйфат өчен көрәш иң авыры. Кимчелекләргә килгәндә, алары житәрлек. Барсын да ал да гөл итәргә күп кирәк әле, күп...

— Шуның өчен һәркайсыбыз тырышабыз да,— диде хәбәрче.

Юлдашев, ничектер, әллә ачылып сөйләшергә теләмәде, әллә уңайсызлык кичерде, Васил белән хәбәрченең гәпләшүенә дә кушылмады. Хәбәрче моны аңлы һаваланувы, үзен эре тотуы дип санаса, Васил исә бу хәлгә әллә ни илтифат бирмәде. Инде эш беткән санап, квартирдан чыгып, коридор баскычыннан төшешли, хәбәрче түзелеш житәкчеләренә һич көтелмәгәнчә шулай мөрәҗәгать итте:

— Әйдәгез әле, берничә квартирны карап чыгыйк.

Мондый тәкъдимгә каршы килеп нишлисен инде? Каршы килеп тә, уңай яктан да сүз кыстыручы булмады. Васил юл өстендәге бер квартирның звонogына басты. Ул арада Юлдашевның хатыны бер сүз дә әйтми китеп барды. Озакламый ишек ачылды. Ишеге ярым ачык яшь кенә бер хатын: «Рәхим итегез»,— диде. Монда иң нык күзгә ташланганы — өй тулы балалар иде. Аларны балалар бакчасы дип үк атап булмаса да, саннары аз түгел иде. Хәбәрче квартир эчен карап чыккач, Юлдашев белән Василга текәлеп әйтте:

— Аерма зур. Монда инде идән такталары да «авызларын» ача башлаганнар. Буяулары да әллә ни түгел, юкарак. Стеналарга да матур накат төшерелмәгән. Тәрәзә рамнарында ялгаулы пыялалар да бар...— Ул барысын да әйтеп бетермәде.

Юлдашев аның әйткәннәре белән ризалашырга теләмәде:

— Бу хәтле бала-чага белән тәртип буламы соң? Нинди автомашиналар тәгәрәтеп уйныйлар, атлар, филләр, аннары ни хәтле тимер-томыр... Боларга тимер идән дә чыдамас.

— Эш анда гына микән? — диде хәбәрче.

Лəкин берсе дə аңа җавап бирергə ашыкмады. Тагы да ике квартирга кереп чыккач, хəбəрче башкача аларны борчымады. Ул төзелеш житəкчелəренə бик аңлашылырлык итеп, кулларын җəеп əйтте:

— Җир белəн күк аермасы...

Юлдашев кызарынды, бүртенде, ни əйтергə белми ык-мык килеп торды. Василга да уңайсыз, чөнки хəбəрче сүзлəрендə дөреслек, хаклык ярылып ята иде. Алай да сыйфат өчен тартышмыйлар түгел бит алар. Моннан күз йому шулай ук дөреслеккə туры килмəс иде. Шуны уйлап:

— Без бу йортны начар сыйфат белəн тапшырмадык. Торучылар, күчкəч, синең сыйфатыңа карап торамы соң? Тегесен кага, монысын элə, ышкый-кыра, һəркем үзенчə мөгез чыгара. Аннары үзе үк безне сүгə,— диде.

— Юк, мин ул тиклесен инкарь итəргə җыенмыйм,— диде хəбəрче. Суынып житмəс борын яңа эздəн Васил сүзлəрен Юлдашев күтəреп алды:

— Именно дөрес əйтə иптəш Сафин. Киемне генə алып карыйк, кибеттəн сатып алып бер киден, ике киден, инде анда азмы-күпме үзгəреш сизелə башлый: җыерыла, сəдəфлəре өзелə, төсе китə. Файдалануга тапшырылган башка нəрсəлəргə карата да бу шулай, хəбəрче иптəш. Ни генə булмасын, йортмы ул, складмы ул, машинамы яки киемме — һəркайсы көн үткəн саен үзгəрə, тузуга таба бара...

— Бəхəслəшмим. Лəкин сыйфат һəркайда бер тигез яхшы булырга тиеш,— дип өзеп əйтте хəбəрче.

Башкача сүз көрəштермəделəр, һəркайсы үз юлы белəн китте.

Васил кабинетына кайтып, агымдагы эшлəр белəн шөгыльлəнеп утырганда тагы да теге хəбəрче килеп керде, аның эшен бүлдерде. Хəбəрче төзелеш эшлəренə кагылышлы хəллəр турында бер-бер артлы сораулар яудырырга керешге. Васил саннар, фактларны урыны килгəн саен əйтə торды. Ул участокларда эшлəренең начар бармавын белə, шуңлыктан хəбəрче сорауларына кыю җавап кайтара һəм шуның белəн бер үк вакытта бу ят кеше алдында ниндидер каушаулы хислəрдəн дə бөтенлəйгə азат түгел иде. Хəбəрче аның янында шактый озак утырды. Эше бетте, күрəсең, ак тышлы блокнотын ябып куйгач, ул папирос кабызды да, һавага зəңгəр төтеннəр очыра-очыра, аерүча бер тəм белəн тарта башлады. Ул артык сораштырмый иде инде. Бер ара Васил, аның үзе белəн кызыксынып, сорап куйды:

— Безнең якларда озак буласызмы əле?

— Анык əйтə алмыйм, бер килгəч, əйбəтлəбрəк танышырга кирəк. Минем үземнең туган авылым да бу тирəлəрдəн ерак түгел. Бу урыннар мина яшь чактан ук танышка күрə, хəзер бигрəк тə кызыксындыра. Нинди зур үсеш бу якларда, нинди гигантлар калкып чыгачак! Мин шулар турында берничə очерк язарга җыенам. Шулай булгач, бирегə ешрак килергə туры килер. Ə хəзергə, между прочим... Кимчелекле яклар да житəрлек булса кирəк сездə. Аерым шəхеслəр мина охшап житми, бигрəк тə житəкче иптəшлəр арасында...

Кинəт телефон шалтырап, хəбəрче сүзеннəн бүленеп калды. Васил телефон трубкасын алып колагына куйды:

— Юлдашев əле бу...

— Тынлыйм сезне, Зариф Салихович...

— Бу эшнең сузылуы үземнең дə эчне пошыра башлады инде. Чик куярга бик вакыт кебек,— диде Юлдашев трубкадан.

— Нəрсəгə чик куярга?

— Күчү-күченү мəсьəлəсен əйтүем инде.

— Бергəлəп карадык ич. Рəхим итеп күченегез, Зариф Салихович.

— Эш бер миндə генə булса...

— Тагы нəрсə килеп чыкты?

Юлдашев бераз тукталып торды, кемгәдер нидер әйтте дә яналан үтенгән сыман әкрен тавыш белән дәвам итте:

— Кухнянын идәнен, коридорнын стеналарын тагы бер кат буяп чыгарга кирәк. Сабыр итегез, ни әйтәчәгегезне беләм. Мина калса, шул килеш тә ярар сыман да бит. Хатын каршы. Врач кеше бит, анын зәвыгына төшенеп житмәссен.

Василнын төсе күнелсезләнә баруы борын яфракларынын кинәюеннән үк сизелеп тора иде.

— Анламыйм мин сезне, Зариф Салихович, безнен белән бергәләп йөргәндә Зәйтүнә Хикмәтовна бер сүз дә әйтмәде ич. Мин инде аны яна квартирдан бик канәгать калгандыр дип уйлаган идем. Күрәсен...

— Күрәсен, оялгандыр,— дип ялгап алып китте Юлдашев.— Ана гына калгач, сатулашмыйк инде, тагы бер кат сылап чыгудан әллә ни булмас.

Васил телефон трубкасын колагына тоткан килеш тын калды, ни дип әйтергә ана? Ахырында:

— Хатынызгыз белән ничек тә уртак тел табарсыз,— дип трубканы куйды.

Болай да сиземләү һәм төсмерләү куәсе көчле булган хәбәрче бу сөйләшүнен нәрсәгә кайтып калуын өстәмә сораусыз да бик яхшы төшенде. Төсенә үк чыккан бер усаллык белән әйтә куйды:

— Бүтән йортларны кабул иткәндә мондый таләпләр куймый торгандыр бит иптәш Юлдашев?

— Әлегә андый хәлнен булганы юк шикелле,— диде Васил.

Ничәдер көн үткәч, инде бу йөрүләр, бу сөйләшүләр онытылып бетә язгач, республика газетасында әче телле фельетон басылып чыкты. Анда Юлдашевнын яна квартир алуы дәүләткә бик кыйммәткә төшүе турында каты тәнкыйть сүзләре әйтелгән, баш инженернын бармагы үзенә таба кәкре булуы турында тәфсилле рәвештә язылган иде. Бу вакытта Юлдашевлар яна квартирга күченгәннәр иде инде. Фельетон күзләренә күренгәч, гаиләдә каты тавыш купты, табак-савыт шалтырады. Ире хатынын гаепләде, хатыны ирен гаепләде.

— Барысы да синен капризларын аркасында килеп чыкты,— диде Зариф Салихович.

— Юк, син төп котыртучы. Монысы ярамый, тегесе начар, дип кем әйтә иде?

— Анысы башта, ә сонынннан? — диде ире.

— Сонынннан да син ошатмадын, мин синен әйткәннәренә кушылдым һәм шунын белән ялгыштым,— диде Зәйтүнә Хикмәтовна.

— Ярар, куйсана, хатыннарнын бер кайчан да гаепле булганнары юк. Һәрвакыт ирләр гаепле... Ана китсә, фельетонда сине телгә алучы юк. Бөтен гаеп минем өскә төшә,— диде Зариф Салихович.

Буласы булган, хәзер сүз кәрәштереп торудан мәгънә юк иде инде. Шулай да ир белән хатын шактый вакыт рәтләп сөйләшмичә бер-берсенә төсләрен бозып йөрделәр. Юлдашев фельетонны газетадан кисеп алып, куен кесәсенә тыкты. Ул, үзенен асылда гаебе бармы-юкмы икәнен уйламастан, бөтен күнеле белән хәбәрчегә ачуланды. Алай гынамы сон! Сафин... Хәер, фельетонда анын турында да берничә тешле генә жөмлә бар иде барын. Болар юри шомарту өчен, күзгә төтен жибәрү өчен генә булса кирәк, дип уйлады Юлдашев. Анынча, Васил, һич югында, хәбәрче анын кабинетында утырган чагында, телефоннан сөйләшмәскә, берәр хәйлә табарга тиеш иде. Димәк, Сафин да теләпме-теләмичәме, Юлдашевка каршы булып чыга. Ул шундыйрак нәтижәгә килде: ничек кенә булмасын, акланырга, үз өстенә төшкән тапны кырып ташларга теләде ул. Һәм көннәрдән бер көнне шул ниятен гамәлгә ашыру теләге белән партком секретаре янына китте.

Ул көнне Василның һич нәрсәгә кулы бармады. Ярый әле, әллә аның авыр кичерешләргә тап булып йөрүен белеп, әллә йомыш-юллары булмау сәбәпле, ул хәтле борчучы булмады. Төш авышып шактый вакытлар үткән иде инде. Ничек әле бу, күрше бүлмәләрдә шаулашып сөйләшкән авазлар да ишетелми, арифмометрның өзлексез текелдәве дә колакны тондырмый, коридорда да аяк тавышлары ишетелми. Нигә әле аның сәгатенә карарга да акылына килмәгән? Караса — сәгате туктап калган; ул аны иртән борырга оныткан икән ләбаса. Васил конторада гадәттәге шау-шуның басылуыннан хезмәт көненең узганын, хезмәткәрләрнең өйләренә кайтып киткәнлекләрен чамалады.

Басылып кына эшләп йөргәндә авылдан телеграмма килеп төште. Һава шартларының начар булуы сәбәпле, анда кичегеп кайтуы, ниһаять, гаилә башына төшкән авыр кайгы...

Ул кайтканда әтисе вафат булган иде инде. Васил әтисе картның соңгы сүзләрен ишетә алмады. Тик ана атаның ахыр сулышына кадәр сөекле улын көтүе, аның исемен телдән төшермәве турында ирештерделәр. Васил әгисен җирләшеп, соңгы юлга озатышып килде. Ике кич өйләрендә кунды.

Иртәгесен көн аяз иде. Кайчандыр үзе мал саклаган, уйнап йөргән чишмә тавы буйларын, яңадан кайтмас өчен артта калган үсмер чак эзләреннән йөрде. Әнисен үз янына торырга чакырса да, ризалата алмады, карчыкның туган авылыннан, йортыннан һәм күрше-күләннән аерыласы килмәде. Аннары: «Җеназамны укырга карчык-корчык та табылмас, анда гел җыен яшь-җилбәзәк арасында»,— диде.

Шәһәргә, хатыны янына да кереп чыкты ул. Нурзилә аны сагынып каршылаган кебек тоелды, мәгәр әллә ни янып торган кайнарлык һәм җылы хисләр белән озатмады. Һаман да бер балык башы. Васил урынында бәлки икенче берәү булса, гаиләдә килеп туган бу аңлашылмаучылыкны башкачарак чишәр иде, ләкин чишәр иде. Нигә соң әле ул, тормышның үз агымы белән килешеп яшәгән ваемсыз кеше сыман, булган хәл белән ризалаша? Үзенең алдына килеп баскан бу сорауга каршы Васил: «Түзик. Ашыкмыйк. Тормыш катлаулы нәрсә. Тик шунысы ачык — мине уңышлы кешеләр рәтенә кертеп булмый»,— дип исәп йөртте.

Кинәт кенә телефон шалтырап, Василны уйларыннан бүлдерде. Шалтыратучы Нәриманов иде.

— Бүген бит кыска көн,— дип сүзен башлады Нәриманов.— Ин элек сезнең квартирыгызны сорадым. Телефонисткалар Сафин фамилияле кешенең квартирын тапмадылар. Үзләре белеп аннан гостиницага шалтыраттылар. Анда да юк. Шуннан соң мин эшли торган җирегезне сорадым. Бу тиклесе сүз уңаеннан гына. Ниләр бетереп ятасыз, Васил Закирович?

Василның иреннәренә әкренләп елмаю яктылыгы чыга башлады, баягы сүрәнлек үзеннән-үзе югала барды.

— Әллә ни кырган эш юк дисәм, дөрес булмас. Картлар әйтмешли, сезнең фатихагызда хәрәкәт итеп ятабыз шунда. Үзегездә ниләр бар?

— Күченәбез.

— Озакка барырмы әле?

— Эшләр болай барса, яңа елларга хуҗалыкларның күбесе күченеп бетәр инде.

— Җәмәгать биналары төзү ничегрәк?

— Менә нәкъ өстенә генә китереп бастыгыз, Васил Закирович. Үзем дә шул турыдан сүз кузгатмакчы идем әле.

— Ничек алай?

— Шулай, килеп терәлмәсәк тә, шунар якынрак торабыз.

— Нәрсә, әллә материал җитмиме?

— Ул тиклесе дә бик ал да гөл түгел түгелен. Әмма безгә яхшы һөнәрле ташчылар кирәк иде.

— Алар безгә дә кирәк,— диде Васил.

— Сезнең икенче чут. Бәлки шефларыгыз янына килеп китәрсез. Анда ничегрәк итәргә икәнен сөйләшер идек. Барыбер иргәгә ял көне бит сездәге рабочий класс өчен. Бергә-бергә ял да итәр идек, балыкка барырга да була.

Иртәге көнне кайда һәм ничек уздыру турында Василның бертөрле дә исәп йөрткәне юк иде. Бәлки Зиннурларга барса гына инде. Аларны да хәтсез вакытлардан бирле күргәне юк ич. Хәер, ул аларга башка чакта да бара ала бит әле. Ул Нәриманов тәкъдиме белән ризалашты. Озакламый, әрсез газикка утырып, юлга чыкты.

Чыннан да ана бераз һава алмаштыру кирәктер дә. Сынык кәефе дә ялганмасмы, күңеле азрак тынычланмасмы? Ул гына да түгел, шефларның хәл-әхвәлләрен дә белеп торырга кирәк ич.

Акъярның яртысы күченгән иде инде. Шулай да механизаторлар һәм терлекчелек фермаларында эшләүчеләрнең өйләре үз урыннарында иде. Председатель үзе дә күчмәгән икән әле. Нәриманов өендә чәй эчеп, тамак ялгадылар да, колхозга авыл хуҗалыгы йөкләмәләрен уңышлы үтәгән өчен республика оешмаларыннан бүләк итеп бирелгән өр-яңа «Москвич»ка утырып, колхоз күченә торган авылга юл тоттылар. Якында гына урман. Аны тирә-яктан, мал-туар кермәсен өчен һәм яман күзләрдән саклау өчен булса кирәк, киртәләр белән әйләндереп алганнар. Әле монда әллә ни күптән түгел килүендә үзенең текә ярлары арасыннан ефәк тасма шикелле сузылган инешне күрә алмавына гаҗәпләнеп куйды Васил. Күп заманнар болыннар куенында яшеренеп яткан инешне буганнар, һәм көмеш төсле су ярлардан түгеләм-түгеләм дигән шикелле салмак кына тирбәлеп тора. Елгадан өстәрәк, үзенә бер аерым шәһәрчек кебек, яңа җәмәгать бинալары, терлекчелек каралтылары калкып килә.

Нәриманов Василны һәркайсы белән таныштыра, һәркайсы турында җанланып сөйләп бара иде:

— Менә монысында сыерлар асрарбыз. Монысында ике йөз баш, тегесендә йөз илле баш. Әнә тегесендә «роддом», ягъни сыерларга бозаулау урыны, аннан арырак сарыклар фермасы булачак. Менә монысы, хәзер без килеп кергәне, азык кухнясы...

Бу биналарның күбесе салынып беген килә, кайсыларының түбәләрен ябалар иде. Шуларны карап чыккач, Нәриманов үзенә генә хас бер елдамлык, яшьләрчә бер җитезлек белән Василга күз кысты:

— Кырмыскалардай кыймылдап яткан көнебез инде безнең.

Васил ирексездән көлеп җибәрде, аның куанганлыгын күзләренә чыккан очкыннар сөйли кебек.

— Оһо, сез кыймылдау дисез. Кыймылдау гына түгел бу, бик зурдан купкансыз! Һәркайсы таштан да кирпечтән, тимер-бетоннан, тәт-тәт-тә!

— Болар инде теге колхозлар оешкандагы колаклардан калган салам түбәле абзарлар түгел,— дип Василның әйткәннәрен җөпләде Нәриманов.

— Эшегез әйбәт бара бит, тагы ни җитми? — дип сорады Васил.

— Мин сезгә телефоннан сөйләшкәндә үк әйттем бугай инде.

— Ташчылармы?

— Әйе, яхшы квалификацияле ташчылар булса, адымнар кызулана безнең.

— Миңа калса, сез ашыгасыз кебек, иптәш Нәриманов. Әле киләсе елга көзен генә күчәчәк бит бу яңа урынга фермаларыгыз. Житешерсез ич?

— Житешүен житешербез дә, алданрак пошынмасаң, тун итәгенә ут капкач кына кузгалу кебек булып чыга ул.

— Ну, дипломат сез,— диде Васил һәм шушы көннәрдә Акъярга иң әйбәт берничә ташчы җибәрергә булды.

Иртәгесен балыкка барырга сүз куештылар. Бу тарафлардан ерак түгел Акчарлак күле дип йөртелгән, суы үз алдына зәңгәрләнеп, урын-урын кара кучкылланып торган, әкияттәге сыман матур, камышлы күл Василга таныш, аның анда җәй көне булганы бар иде. Шуны исенә төшереп, Васил әйтә куйды:

— Балык бармы?

— Балыкның ниндие генә әле, карп! — диде Нәриманов.

— Алайса иртүк шунда юл тотарбыз. Көндез җилли башласа, буш кул белән кайтырга туры килер.

— Анысы, баргач-баргач, буш кул белән кайтмабыз инде. Бер дә балык капмаса, балыкчылардан алырбыз. Безнең балыкчылар звеносы бар ич,— диде Нәриманов.

— Менә ничек, шәп! — дип гаҗәпләнде Васил.

— Безнең Акчарлак күлендә кыр үрдәкләре дә житәрлек. Булмаса, үрдәк атарбыз. Икебезгә бер мылтык, иске булса да, бик шәп минем бирдәнкә.

— Үрдәкләр киткәндер бит инде,— диде Васил.

— Юк әле, китеп бетмәгәннәр. Бер ишеләре китте, бер ишеләре калды, дигәндәй, нинди порода бит, ул шуңа карый.

...Авыл клубында яңа картина күрсәтелергә тиеш иде. Васил билет алып керде дә урта рәтләрдәге эскәмиягә барып утырды. Ана монда барысы да ят, бер генә танышы да юк, житмәсә кешеләр аңа әледән-әле карыйлар. Егетләр үзара шаяртып сүзләр әйтешәләр, кызлар чыркчырык көлешәләр. Нигә соң ул да шулар шикелле шаяра, уйный алмый, әллә андый чаклары үтеп киткәнме инде? Юк, аңа кызлар белән шаярырга ярамый инде. Ул — бала атасы.

Васил утыра торган рәт яртылаш буш диярлек. Халык әкренләп керә, эскәмияләрдә урыннар азая бара иде. Васил сабырсызланып кино башлануын көтеп утырганда, шул ук рәткә таныш төс, таныш гәүдә килеп керде. Василга калса, ниндидер саф җил, рәхәтлек сугылып үткән кебек булды, бөтен гәүдәсеннән ниндидер кайнар дулкын йөгереп үткән кебек тоелды. Каушаганрак бер хәлдә:

— Гөлзадә! — диде ул.

— Васил абый, сез ничек монда?

— Минем янда урын буш, килегез, утырыгыз.

Гөлзадәнең бит алмаларына куе алсулык йөгерде, ул башта ни әйтергә белмичә югалыбрак торды да аннары, кинәт үзен кулга алып булса кирәк, Васил янына килеп утырды. Ләкин ике арада шактый буш урын калды. Гөлзадә тарсына һәм ояла иде, күрәсең. Бер мәлгә икесе дә, каушап калгандай, тып-тын утырдылар. Ни дип башларга, нидән тотынырга? Васил моңа җавап таба алмады. Мәгәр, ничек кенә булмасын, ул ялгыз түгел һәм баштагы кебек ямансу да түгел иде. Гөлзадә исә, баштарак әллә ни кичерешләргә бирелмәсә дә, бара-тора бер янып, бер көеп утыра башлады. Әллә ничек кенә шунда: «Сез ничек монда?» — дигән сүз ычкынып китте аның теленнән. Дөреслектә, ул Акъярга башлыкларының килүен ишеткән, иртәгесен аның машинасына утырып төзелешкә кайту турында сорамакчы да иде кыз. Аннары ул бер үзе генә түгел бит әле бирелә... Хәзер менә кайту турында ничегрәк сорашырга, сүзне ничегрәк башлап җибәрергә? Аны ничек итеп искәртергә?

Гөлзадә артына борылып, күзләре белән кемнедер эзләгәндә, Васил кинәт әйтә куйды:

— Егыласыз бит, ул хәтле каерылып карамагыз!

— Күренми шул,— диде Гөлзадә.

Васил аптыраганрак бер тәстә кызга карагач кына Гөлзадә эшнең нәрсәдә икәнен абайлап алды һәм нигә пошынуы турында әйтте:

— Мин бит үзем генә түгел, Васил абый, кунак кызым да бар иде.

— Ул кем тагы?

— Мадинә.

— Ник килмәде соң ул клубка?

— Үзем дә менә шуңа аптырыйм инде, нигә тоткарлангандыр, әллә арттa утыра инде шунда?

Картинаны ничек кирәк алай карасалар да, гомуми тәэсир алай начар булмады. Кино беткәч, кешеләр һава алмаштырып, папирос көйрәтеп кергән арада эскәмияләрне стена кырыйларына урнаштырдылар, бию өчен урын әзерләделәр. Нигәдер Василның да аяклары өйгә тартмады, урамга чыгып папирос тартып алды да яңадан клубка керде. Кызлар бер якта, аларга каршы як стенада егетләр тезелешеп утырган. Берсеннән-берсе саф, берсеннән берсе матур киенгән, яшьлек һәм ялкын, кайнар хис сирпеп торган кызлар арасында Гөлзадәнең булуы Васил өчен ничектер яшерен бер шатлык иде. Озакламый кемнеңдер йөгерек бармаклары баян теләрен тибрәтте, һәм моңлы да, дәртләндергеч тә булып татарча бию көе яңгырады. Егетләр, кызлар бер-бер артлы биергә чыга башлауга, кемне сайларга белмичә аптырап торган шикеллерәк як-ягына каранган Гөлзадә Василга таба атлады. Васил шундук урыныннан торды, сак кына итеп кызның кулларыннан тотты. Башта ул бер-ике ялгыш адым ясады, ләкин бу хатасын тиз төзәтте, кыз белән бер тактка җиңел генә хәрәкәт итә, бии башлады. Аның бу халәтен Гөлзадә дә бик тиз сизенеп алды. Василның күптән биегәне юк иде. Шуңлыктан булса кирәк, башта аңа кыенрак шикелле тоелды, әмма кешеләр кайнашкан түгәрәкне әйләнә-әйләнә, ул тиз күнекте, тиз үзләште. Беренче турдан соң, бер кадәр ял иткәч, яшьләр тагы биюләрен дәвам иттерделәр. Васил белән Гөлзадә дә шул ук түгәрәк эчендә бөтерелделәр. Ләкин Василның күңелендә кинәт кенә ниндидер эчке бер тартыш уянды. Бер үк вакытта аның бу давыллдан, бу әйләнештән, бу күңеллелектән чыгасы килми. Әмма, җәйге чиллә вакытында урманга баргач сырып алган черкиләр кебек, борчулы уйлар аңа тынгылык бирми иде.

— Сезнең белән биюе җиңел! — диде һич көтмәгәндә Гөлзадә. Кызның йөрәк тибешен тойган, вакыт-вакыт аның тән ялкыны үз гәүдәсенә күчүне сизенгән Василга, бу сүзләрне ишеткәч, бер яктан, күңелле, икенче яктан, сәер иде. Алай да үзен борчый башлаган уйлар, кирәксез исәпләр таралган кебек булдылар. Биюнең икенче туры бетәр алдыннан Васил кызга үзенең китәргә теләгәнен, иртүк председатель белән Акчарлак күленә барасылары барлыгын әйтте. Васил җавап көтеп Гөлзадәнең күзләренә карады. Тик Гөлзадә бер сүз дә әйтмәде, дөресрәге, әйтә алмады. Кызның болай да янып торган яңакларындагы алсулык тагы да куера төште.

Васил ялгызы гына клубтан чыкты. Ниндидер көч аны шундук китеп барудан тыеп калды. Клуб капкасы төбендә арлы-бирле йөрергә тотынды. Бу Гөлзадә нинди җепләр белән үзенә тарта? Кызның очынып-талпынып биисе килә торгандыр, керсп карыйсы иде, хәзер кем белән әйләнә икән ул? Уй-исәпләренең очына чыга алмыйча, үзен билгесез бер халәттә хис иткән Васил, бер мәлне ишектән Гөлзадә чыгуын күреп, сөенеченнән чак кына кычкырып җибәрмәде. Кыз аны күрүгә, әллә шатлыктан, әллә гаҗәпләнүдән, кулларын җәеп туктап калды. «Менә аның җавабы шушы икән. Чыкты»,— дип куанды Васил. Чалт иткән ай яктысында сүзсез генә урамнан атладылар.

— Үземә генә күңелсез иде. Минем миңа юлдаш булдыгыз,— диде Васил.

— Сезгә әле безнең өйне узгач та барасы да барасы,— диде кыз.

Урам тын булса да, кайдадыр еракта, авылның икенче башында бугай, мотор гөрелтесе ишетелә иде. Гөлзадә тегермән тартуын абайлап алды. Авыл яртылаш йоклый, тәрәзәләрнең байтагында утлар күренми, төнге тынлык үзенең йокы пәрдәсен һаман саен күбрәк сара бара иде. Василның теленә нигәдер сүз килми, аңа калса, бу сөйкемле кыз белән сүзсез генә янәшә бару — үзе зур бәхет... Бу тынлык Гөлзадәгә ошап җитмәде, ахрысы, ул кинәт сүз башлады:

— Хәзер менә без йөргән бу урыннар су астында калачакмыни, Васил абый?

Кызның бу соравы Василны айнытып җибәргән кебек булды.

— Әйе, бу тирәләргә су күтәреләчәк.— Бераз тын баргач, болай диде: — Яңа урында нинди зур, матур авыл калка. Моңа сезнең Акъяр кешеләре үзләре дә таң калырлар әле.

— Мин бу төшләрнең су астында калачагын күз алдыма китерә алмыйм. Һаман да шушында кайтырмын сыман.

— Билгеле, башта ямансурак булыр. Әмма кеше дигәнең тиз күнегә ул.

— Авылда һәркемнең телендә су басу... Күчү дә күчену,— дип куйды Гөлзадә сузып кына.

— Авылыгызга бик еш кайтасызмы?

— Ял көннәрендә кайтмый калган чак бик сирәк.

— Кемнәрегез бар?

— Әти, әни, тагы бер энем дә бер сеңлем.

— Әтиләрең эшли торганнардыр бит?

— Әйе, эшлиләр. Әти тракторчы, әни төрле эшләрдә йөри.

Васил сораулар бирүдән туктагач, Гөлзадә дә телен йоткан шикелле тынып калды. Алар салмак кына атлыйлар. Үз өйләре турына килеп җиткәч, кызның йөрәге леп-леп тибә башлады һәм тәрәзәләрендә ут булуга ничектер кәефе кырылды төсле. Күрәсең, әле ятарга җыенмыйлар, радио тыңлый торганнардыр яки... кем белә? Мәдинә? Нинди сәбәп, ул ник килмәде икән, әллә югыйсә үпкәләдеме? Әллә Гөлзадәгә өйләренә кереп калыргамы? «Гафу итегез, мин кайтып җиттем»,— диярга дә капканы ачарга... Юк, алай диярга теле әйләнмәде. Киресенчә, ул үз турларына җиткәч, адымнарын сизелерлек кызулата төште. Васил кызның бу халәтенә төшенә алмады. Берәр тыкрык арасы узгач, Гөлзадә тагы салмак кына атлап бара башлады. Нигә соң сүзгә бик саран булып чыкты әле бу Васил абыйсы? Беләсе иде: башында нинди уйлар бар икән? Гөлзадә башлыкларының этисе үлү турындагы күңелсез хәбәрне ишеткән иде инде. Әллә ничек кенә шунда ул хакта сорау килешеп бетмәс, кешенең җәрәхәтен яңартыр кебек тоелды кызга.

Алар ашыкмыйча гына атладылар да атладылар. Күп өйләр, күп тыкрыклар артта калды. Ниһаять, авылның урта урамын үтеп, басу капкасына якынлаштылар. Аяк асты коры. Көзнең шәфкатьсез җиле каяндыр бакчалардан һәм ындыр артларындагы куаклыклардан коелган яфракларны чокыр-чакыр җирләргә китереп тутырган. Йомшакка басып бару рәхәт, яфракларның кыштырдавы хәвефле дә сыман. Авылдан шактый ерактагы күпергә җиткәч, кире борылдылар. Болай янәшә бару Василга ифрат күңелле иде. Нигә соң әле ул бу чибәркәйне култыклап алмый?!

Гөлзадәне шайтан котыртамы югыйсә, аның нишләве бу, әллә инде күңеле Васил абыйсына таба тартыла башладымы? Бу минутларда кыз үз-үзен аңламады. Тиле! Тирә-ягында әллә никадәр егетләр була торып, хатынлы кешегә йөрәген ачарга тиешме ул? Хатыны ни исемле икән, нигә ул аны төзелешкә алып килми икән, беләсе иде? Юк, юк, ул аның белән болай гына йөри, Васил абыйсына күңелсез булмасын өчен генә йөри...

Васил абыйсы бит монда япа-ялгыз, беркемне дә белми, аннары начар кеше дә түгел ул. Теге чакта хат салгач, шундук җавабы килеп төште. Кайтты Гөлзадә. И саташып бетә язды бит ул шул чакта. Ничек кенә эшләмәсен, тәки Рафисны акылга утыртты: ник бер генә бәйләнеп карасын хәзер. Ул аны нигәдер кызганып та куя. Ләкин нишләсен, аны сөйми ул, җанына ошамый ул аның. Егет хәзер Гөлзадәнең ул хисләрен аңлады шикелле...

Күк битендә болытлар куера иде. Көньяк офыкта аларны яктыртып, тулып килгән ай йөзә. Тирә-як тын, ә шулай да кабарынкы болытлар агылалар, мөгаен, өстә җилдер. Кинәт кенә казлар каңгылдашканы ишетелүгә, Васил әсәренеп китте. Кыр казлары каңгылдаган тавышлар бер ерагайды, бер якынайды, аннары талгын гына ишетелә башлады, тагы якынайган кебек булды. Василның күзләре болытларда, өстә иде. Нихәтле генә тырышып карамасын, ул киек казларны күрә алмады. Тик төньякта ай нурларыннан көмешләнә барган болытлар һаман ишәяләр. Сөйләшә китсәләр, Гөлзадә дә кыр казлары тавышын күнеле ямансылап тыңлаган икән.

— Нигә алар төнлә очалар икән? — дип сорады кыз.

— Бу кошларның үзләрен саклау инстинктларыдыр. Төнлә аучылардан куркыныч юк. Кыр казлары көндезләрен җайлы урыннар сайлап ял итәргә төшәләр. Туеналар. Төнен тагы сәфәргә...

— Ничек юлны ялгышмыйлар диген!

— Ялгышмыйлар,— диде Васил.— Араларында юл салып очучы карт каз — иярткүчеләре була. Ул инде бу озын юлларны әллә ничә тапкыр үткән.

— Аларның да, димәк, бригадирлары бар!

— Бар.

— Кызык кына бу табигать, кызык кына бу тормыш...— Гөлзадә әйтеп бетермәде, уйлары тагы кыр казлары тирәсендә чуалды. Аның өлкәннәрдән кыр казлары, кыр үрдәкләре очканда аларны санарга ярамавы, санасаң, җеп булып тезелгән өчпочмакларының таралуы, тагы әлләниләр турында ишеткәне бар. Шул хакта чак-чак кына тел тибрәтми калды. Чөнки соңыннан Васил абыйсы алдында үзенә уңайсыз булыр шикелле тоелды.

— Төзелешкә кайчан кайтасыз? — дип сорады Васил.

— Исәп иртәгә кичкә иде дә бит...

Кызның тел төбе нәрсәдә икәнен Васил әйтелеп бетмәгән ярты җөмләдән үк абайлап алды.

— Сезнең исәп минем исәп белән бер икән. Бергә кайтырбыз. Мин сезгә кичкырын сугылырмын,— диде Васил.

— Сез безнең өйне белмисез бит әле. Капка төбендә сиртмәле кое...

Васил серле генә елмаеп, ашыкмыйча гына әйтте:

— Беләм! Сезнең өйнең кайда икәнен Нәримановның күрсәткәне бар миңа.

Васил кызның бармак очларыннан саклык белән генә тотып алып, аңа татлы йокы, тәмле төшләр юрап саубуллашты.

Гөлзадә капкадан кергәч, үзләренең ишек алларының кинәт яктырганын күреп гаҗәпсенде. Күккә карады — ай, үз тирәсендәге болытларны куып тараткан шикелле, үзенең көмеш төсе белән кызга карап елмая. Өйдәгеләр ятмаганнар иде әле. Ак өйдә гөлләргә күмелгән олы якта Мәдинә китап укып утыра иде. Гөлзадәне күргәч, урыныннан торды да ишек катына килде. Мәдинәнең җиңелчә генә аксавын абайлады Гөлзадә.

— Клубка нигә килмәдең? Көтә-көтә гарык булдым сине...

— Баскыч төбеннән төшкәндә ялгыш басып үкчәмне авырттырдым. Бара алмый кире борылырга туры килде. Хәзер инде ничаваланып бара кебек.

— Менә ничек? — Гөлзадә иңбашларын селкетте.
— Васил Закировичны күрдеңме?
— Күрдем.— Гөлзадәнең кызарынуын Мәдинә сизмәде.
— Әйттеңме?
— Әйттем. Безне дә апкитә...
Кызлар икесе бергә түр яктагы йомшак киң караватка урын җәеп яттылар. Мәдинә, киноның ничегрәк тәэсир итүе турында сораштырганнан соң, үзе укый башлаган китап хакында сүз куертты. Ләкин Гөлзадә башына аның сүзләре керми, аның үз уе уй, үз исәбе исәп, Васил белән бию, аннары урамда йөрүләре, ниндидер татлы истәлек шикелле, аның күңел түрендә айкала һәм ул үзе дә аңлап җиткермәгән ниндидер алмашыну сизә иде. Мәдинә тигез сулыш белән тәмле йокыга киткәч тә, Гөлзадәнең күзләренә озак вакыт йокы эленмәде.

## 2

Васил бу тарафларга килгәндә әле җир эшләре дә бетмәгән, зур пулатларга нигезләр генә салына башлаган иде...
Бер язда һәм бер җәйдә нихәтле зур адымнар атланган: генератор һәм пар казаннарының нигезләре әзер, машиналар залының да стеналары исә һаман өскә калка бара. Тимер юл белән Жигули якларыннан әллә ничәшәр тонна авырлыктагы озын-озын тимер-бетон колонналар туктаусыз килә тора. Көчле краннар аларны күтәреп алалар да алдан хәзерләнгән бетон мендәрләргә утырталар. Аннан эретеп ябыштыру китә. Көндезләрен яшенне, кичләрен йолдыз атылганны хәтерләтә кебек алар.
Әле анда барып, әле монда килеп, арлы-бирле йөргәч, Васил прораблык будкасына керде. Анда Игнаттан башка кеше юк иде. Икәүләп кайбер сызымнарны карадылар. Васил сәгатенә күз төшереп алгач, салмак кына әйтте:
— Миңа китсәм дә ярар. Егетләрнең эшләрен үзең яхшылап карарсың.
— Фиргали абзыйлар бригадасына ышанырга була. Тәҗрибәле кешеләр,— диде Игнат.
— Болай да сынатканнары юк шикелле әлегәчә.
— Бригадир үзе монтажчы да ич.
— Беләм,— диде Васил.
Игнат, нидер уйлаган шикелле, башын кашып алды. Аннары сорады:
— Фиргали абый бер сүз дә әйтмәдеме?
— Әйткәне юк.
— Ул бездән китәргә йөри бит.
— Бу ни дигән сүз тагы?
— Әйе, шулай...
— Кая китәргә уйлый?
— Гидромонтажга.
— Җибәрмәскә кирәк.
— Ул әйтә, минем урынга, ди, я Викторны, я Рафисны калдырырга була, ди. Монтажчылар да бик кирәк бит. Какраз чоры башлана.
— Андый яхшы кешеләрдән аерылмаска тырышырга кирәк.
— Мин дә шулайрак уйлыйм да бит...
Бер кавым сөйләшеп утыргач, Васил чыгып китәргә җыенды.
— Мин беркадәр йөрим дә китәм. Калганын үзең карарсың,— диде ул.
Фиргалиләр бригадасы төп корпуста, генератор куелачак шахты биек урындагы тимер-бетон корылышта такта тышламаларны ала иде. Васил алар янына да тукталды. Бригададан күчүе турында Фиргали абзыйсы бер сүз дә әйтмәгәч, Васил да тел кыймылдатмады, агымдагы эшләр турында гәпләште дә китеп барды.

Бу көннәрдә Фарук житәкчелегендәге малярлар звеносы өч катлы яңа йортта эшли. Йортны бик тиз житештерергә кирәк булганлыктан, аларны төзелеш башлыгының махсус приказы буенча күчергәннәр иде. Фарук Фарукшиннын эшеннән мастерлар да, прораб та канәгать калдылар. Чыннан да коры мактанчык кына түгел, эшнең рәтен белә торган кеше булып чыкты, дип уй йөрттеләр аның турында. Ул гынамы соң әле, яшь эшчеләрне өйрәтү үзе ни тора! Шуны искә алып булса кирәк, прораб Игнат аны көн саен уздырыла торган бишминутлыкларда мактап телгә алды. Мондый чакларда Фарук үзе рәхәтләнеп тешләрен агартырга ярата, яңа көзге кебек, көнозын ялтырып йөри. Эшләре дә жырлап бара, һәркайсына күнелле. Ул инде башлыкларның килүләренә күнегеп беткән. Ялтырап торган сары идәннәргә, төрле бизәкләр төшереп акшарланган стеналарга, көлеп торган тәрәзәләргә сокланып карарлык! Фарук үзе белән бергә эшләүчеләргә һаваланып әйтә торган булып китте: «Васил Закирович безгә бик шәфкатьле күз белән карый хәзер. Болай барса, почет тактасына да эләгербез, аннары инде бүләкләрен-мазарларын көт тә тор. Упшым, сынатмаска кирәк, егетләр...»

Ләкин көннәрдән бер көнне ул бик кәефсез иде. Кашлары жимерек, бугаз төере уйнаклый, беркем белән дә рәтләп сөйләшми, иреннәре салынган, борыны чөгендер кебек кызарган иде. Ул көнне Фарук рәтләп эшли дә алмады. Үзе белән бергә эшләүчеләр аның еш-еш төчкеренүенә карап, грипп-фәлән эләктергәндер, дип уйладылар. Төш вакытлары житкәч, ул Виктор белән бергә буяулар саклана торган бүлмәгә керде дә ниндидер бер шешә табып алды. Кесәсендә стаканы да бар икән, ин элек үзе салып эчте, аннары Викторга сузды:

— Салып жибәр, аппетит тамчылары...

Виктор каршы килмәде. Аның эчкәне борыч аракысына охшаган, бугазны көйдереп ала торган ниндидер эчемлек иде. Аракы жылысы шундук егетнең кан тамырларына йөгерде. Икәүләп ашханәгә киттеләр.

Фарукның күнеле әкренләп күтәрелә барды. Йөзе дә яктырып, ачылып киткәндәй булды. Икенче көнне дә әлеге тамчыларны эчтеләр, өченче көнне дә... Кичләрен дә Викторның тамак төбе үзалдына кымыржап тора башлады, чыннан да бик әйбәт кеше булса кирәк бу Фарук дигәннәре...

Бер көнне Фарук абыйлары хезмәт хакы алыр алдыннан үз звеноларындагыларга әйтә салды:

— Инде чын малярлар булып життегез. Без яшь чакта мастерны сыйлау гадәте бар иде. Мин, кәничне, алай итәргә кушмыйм, моңа хакым да юк. Шулай да, мин әйтәм, дуслыкка берни дә житми, хәзер, беребез барыбыз өчен, барыбыз беребез өчен, дип куялар бит мәсьәләне. Ә без сезнең белән, мәсәлән, кемнән ким?

Хезмәт хакы алгач, алар жыелышып закусочныйга юнәлделәр. Төн урталары житкәч кенә таралыштылар. Иртәгесен Фарук күтәренке кәеф белән эшкә килде. Тагы тату гына эшләделәр. Ләкин бара-тора Фарук абыйлары яңа «әмәлләр» тапты. Бер көнне, смена беткәч, Фарук егетләрне «төшемле эш»кә чакырды. Виктор, тагы бер кылый егет аңа ияреп, поселок читенә юл тоттылар. Берәүнең капкасыннан керделәр. Ниндидер Африканмы, Американмы атлы кеше зур гына өй салган икән. Алар шул кеше өенең ишек борысларын һәм идәннәрен буядылар. Икенче көнне дә килделәр монда. Берничә көннән соң ул кеше Фарукларны кунакка чакырды. Өстәлдә нинди генә сый юк иде! Фарук, бик нык кызгач, «Дөмбердәтәбез генә»не жырлап жибәрде. «Менә ничек яшәргә кирәк бу дөньяда, сыт, пьян, нос в табаку»,— диләр бит руслар. Кешегә шуннан башка ни кирәк тагы?»

Виктор аның бу фәлсәфәсенә каршы төшәргә уйласа да, Фарук абыйлары башкалар әйткәнне аңларлык хәлдә түгел иде инде. Ул бүтәннәр-

дән күбрәк тә эчте, күбрәк тә ашады. Ниһаять, күзләре тәмам болганчык төскә кереп, аягыннан егылырлык дәрәҗәгә җиткәч кенә эчүдән туктады. Виктор белән кылый егет аны сөйрәп тә алып чыга алмадылар. Фарук идәнгә егылган килеш йокыга китте. Өй хуҗасы үзе дә курка калды. Ахырында Виктор белән кылый егет, Фарукны калдырып, үзләре генә китеп бардылар.

Икенче көнне Викторлар эшкә килгәндә, Фарук шунда иде инде. Кичтән адәм күзенә күренмәслек исерек булса да, аның шулай тиз айнуы гаҗәпләнерлек иде. Дөрес, аның йөзе шешенгән, күз төпләре капчыкланган, төсе-чырае бик сүрән иде. Әмма сүзендә, үзен тотышында артык үзгәреш сизелми кебек. Төш вакытында ул, Виктор белән кылый егетне буяулар саклана торган бүлмәгә алып кереп, берәр стакан кызылны салып бирде: «Агуны агу җиңә, башларны төзәтеп тотынсак, җиңелрәк булыр. Әле хуҗадан акчаның бөтенесен алган юк. Бу шешәдәге дә аның бүләге» — диде.

Берничә көннән соң шундый ук хәл тагы кабатланды.

Варвара карчык ара-тирә биләмгә чыга, белгән-күргән белән очрашырга, сөйләшергә ярата иде. Көннәрдән бер көнне ул үзләренең авылларыннан күченеп килеп, өй җиткергән берәүләрдә иркенләп, сөйләшеп, чәй эчеп утырганда кемнәрнедер ияртеп, озын борынлы, урта гәүдәле бер кеше килеп керде. Аның белән кергән егетләр ишек катында калдылар. Хуҗа хатын белән сүзне шул кеше башлап җибәрде:

— Җәгүр өйдә юкмыни? — дип сорады озын борын.

— Юк шул, кәзер кайтып җитәр,— диде хатын.

— Без аны көтеп тормадык инде, килеп тә җиттек, давай, эшкә тотынабыз,— диде бу.

— Тотыныгыз, Җәгүр үзе дә шулай әйтте,— диде хатын.

Ничектер Варвара карчыкка тиз генә китеп барырга туры килмәде. Авылдашларын күптәннән бирле күргәне булмаганга, карчыкның алар белән сөйләшәсе байтак кына сүзләре бар иде. Ул хуҗа хатын белән сөйләшкән арада теге килгән кешеләр төрлесе төрле якка таралып, ишек-тәрәзәләрне буярга керештеләр.

— Идәннәрегезне дә буятасызмы?

— Буятабыз,— дип җавап бирде хуҗа хатын Варвара карчыкның бу соравына каршы.

Варвара карчык нигәдер бу кешегә күз чите белән карап-карап алды. Аның бугаз төере гел йөреп торуга ул да игътибар итте. Кылыч борын астыннан нечкә генә калдырып кырылган мыеклы бу кеше, авыз эченнән генә нидер көйли-көйли, тәрәзә яңакларын буйый иде. Варвара карчыкка калса, анын мыеклары да әллә ничегрәк кенә, ни кара, ни сары түгел, ни җирән, ни көрән түгел, дигәндәй. Ахрысы, һәрбер төстән азмы-күпме өлеш тигән булса кирәк. Шуларны күреп һәм уеннан кичереп, карчык үз алдына мәзәк кенә итеп көлеп куйганын да сизми калды: «Мыекларын юрамалый буяган диярсең. И кодаем, була бит кешеләр дөньяда».

Бер арада малярлар тәмәке кабызып, ял итеп алдылар. Бу чагында аларның иң өлкәнenә — бугаз төере йөреп торганына — бер яшьрәге ниндидер сорау белән мөрәҗәгать итте һәм аны «Фарук абзый» дип атады. Варвара карчык, ала-болай йомышы-фәләне төшсә, аның исемен дә белде. Карчыкның ничектер теле кычытып китте. Иң башлап аның кайсы авылдан икәнен сораштырды. Аннары сүз бер җайга ялганып китте:

— Үзегез кайда эшлисез? — дип сорады карчык.

— Шушында, аста,— диде Фарук башын кагып.

Варвара карчык төпченә бирде:

— Башлыкларыгыз кушып йөри торгансыздыр инде буяу-бизәү эшенә, дигәндәй?

— И түтекәй, аларның кушканын көтеп торсаң? Без үзебез дә сознательни илиминт. Без нәкъ гәзит кушканча эшлибез...

Карчык, моның мәзәк кенә итеп сөйләшүен үзенчә аңлап, янә тел тибрәтте:

— Шулай да гел бушка йөрми торгансыздыр әле?

— Ничек әйтергә, таныш-белеш килеп ялынып сорагач, отказ итеп булмый инде. Һәркемнең культурный торасы килә бит хәзер.

— Үзең буйый башласаң, җырып чыгышлы түгел. Буявын-мазарын каян юнәтеп җиткерәсең, дигәндәй.— Варвара карчык шулай сүз кыстыргалап торды.

Фарук күзләрен түгәрәкләндереп карчыкка карап алды да бик гадәти сүз кебек җайга салып кына әйтте:

— Бездән корал да эш. Буявын-мазарын заказчик үзе таба и беттекитте...— Фарук, тәмәкесе янып-бетеп, кәгазь исе чыгара башлаган папиросын сүндереп ташлагач, башта әйткәннәренә өстәде:— Әллә өеңне буятып җибәрергә исәбең бармы, түтекәй? Булса — без әзер! Хакын да күп сорамыйбыз. Безгә ни — хак ярым хак, пот ярым борчак, сәке ярым как булса, шул җиткән.— Үзе авызын ерып, урт тешләренә кадәр күрсәтеп көлеп җибәрде.

— Юк, туган, юк, әркемгә дә җитешә алмассыз, дигәндәй.

— Җитешмәгән кая! Бер башыннан керәбез, икенче башыннан чыгабыз без аның — мондый кечкентәй өйләрнең. Күрәсез, җырлатып кына барабыз...

Тел дигәнең бер гибрәнсә, тиз генә туктый беләме соң. Фарук белән Варвара карчык күптәнге танышлар кебек сөйләшәләр иде инде. Үзе кайсы авылныкы икәнен әйткәч, Фарук бөтенләй җанланып ук китте:

— Сезнең авыл урман астындагы авыл булгач, бигрәк тә якын безнең күңелгә. Без бәләкәй чаклардан таныш миңа сезнең Таулар. Ни өчен дип әйткәндә, сезнең авыл дәдәйләре безнең Акъяр базарына гел суган алып килеп сата торганнар иде элек.

— Гөргери дәдәгез белән үземнең дә булганым бар сезнең авыл базарында,— дип, Фарукның сүзләрен хаклап куйды Варвара карчык.

— Булгандыр, булгандыр,— диде Фарук. Аннары пумаласын кулына алып, бик тәмләп һәм бөртекләп кенә эшенә тотынды. Варвара карчык кайчандыр үзе булгалаган Акъяр турында сөйләргә керешге:

— И, ул заманнарда бәк олы була торган ие сезнең авыл базары. Ниләр генә юк ие анда! Күгәрчен сөтенә катьле сатканнардыр ул чакларда. Ул сабан туйлары! Үземнең дә сабан туйларына айбагыр алып барган вакытларым булды.— Карчык, авыз суларын корытып дигәндәй, сүзен чүмечләп сала-сала сөйли бирде.— Казер бик күптән барганым юк инде ул тирәләргә. Базарлары шәп буламы соң?

Фарук җилкәсен сикертеп куйды.

— Иллә мәгәр, базар бәләкәен бәләкәй булса да, тегене төшереп алсаң, ярминкә булып күренә башлый...

Варвара карчык, аның соңгы шаярту сүзләрен ишетмәгән төсле, мәгънәле генә итеп, ирен читләрен бармагы белән сөртеп алды һәм әйтеп салды:

— Казер базарларның рәте китте шул. Нигә дип әйтеп әйтсәң, аларның кирәге дә шуның катьле генә. Казер ни жанына теләгәнне лапкадан барып аласың. Тавар-әйбер белән прилапкалар сыгылып тора, кодайның рәхмәте! Биштәр-чабата, киндер күлмәк заманнарын җир упты.

— Шулай шул, түтекәй,— дип, Варвара карчыкның сүзләренә печать басты Фарук.

Варвара карчык йорт хуҗасының кайтуын көтеп алалмыйча китеп баргач, Фарук хуҗа хатыннан сорашып, аның прораб Игнат Давилов-

ның әнисе икәнен белде. Үзенең артык чишелеп китмәвенә, кирәгеннән артык сайрамавына куанып куйды. Чыннан да, аларның болай йөрүләрен белсә, башлыкларның әллә ниләр уйлап куюлары бар. Бер яктан, ул шулай уйласа, икенче яктан, үз-үзен тынычландырып куярга ашыкты: «Эштән соң безгә кем бәйләнә ала, кемнең нинди катнашы бар бездә? Кемнең генә күбрәк акча аласы килми икән? Балык та суның тирәнен эзли ич...»

Көннәрдән бер көнне Карчыга да яңадан төзелешкә килеп чыкты. Ул яңадан тулай торакка килде. Ләкин үзенә иш-кушлар, сердәшләр таба алмагач, озак тормады, аскы урамдагы бер фатирга күчте. Кадрлар бүлегендә ничек уртак тел тапкандыр, аны тагын эшкә алдылар. Озакламый, ул Фарук Фарукшин звеносына килеп кушылды. Болар һәммәсе тиз арада үзләшеп тә киттеләр. Тамгалы агач ерактан күренә дигәндәй, куе сакаллы Карчыга әллә кайдан ук күзгә бәрелә, һәм аннан кала да Фарук звеносы ничектер кинолардагы геройларны хәтерләтеп, башкалардан бик нык аерылып тора иде. Берсе озын буйлы, берсе сакаллы, берсе кылый, берсе озын борынлы, неп-нечкә мыеклы... Берничә вакытлардан соң инде аларны үз йортлары белән торучылар урамында шактый кеше белә һәм «Чумарайлар» бригадасы дип йөртә башладылар. Үзләренең төп эшләренә зыян килүе сизелми, план-заданиеләре үтәлә иде аларның. Бригада кешеләре арасында аларның сулга каерулары турында сүзләр йөрсә дә, ул әле башлыкларга барып ирешмәгән иде.

Көннәр шулай үтә торды.

Рафис санаторийда ял итеп кайтты. Тазарды. Авырлыкка да артты. Әмма бара-тора дус-ишләрен, бергә эшләүче иптәшләрен күптән күрмәгән шикелле сагына башлады.

Тулай торакка якынлашуга, бу бина аны якты тәрәзәләре белән көлеп каршылый сыман тоелды. Менә үз бүлмәләре... Нигә әле аның ишеге шар ачык? Бүлмәдә беркем дә юк, аны танырлык та түгел — урын-җир җыелмаган, идәндә тәмәке төпчекләре, ниндидер ертык кәгазь кисәкләре; өстәлдә дә тәртип юк, һавасы суларга авыр иде. Рафис тиз генә барып форточканы ачты. Бүлмәнең нигә болай ташландык хәлдә булуына ул башта төшенми торды. Һәрвакыт үзенең төгәллеге белән аерылып торган Виктор ничек итеп шушындый хәлгә юл куйгандыр. Җитмәсә, Рафис урынында да кемдер йоклаган булса кирәк. Йоклавы йоклау, урынны җыеп киткән булсалар ни булыр иде тагы? Рафис бүлмәне беркадәр тәртипкә китерде дә ашханәгә китте.

Ашап чыккач, нигәдер аның аяклары тулай торакка тартмады, яңарак ачылган китапханәгә юл тотты. Уку залында кеше күп түгел иде. Рәхәтләнеп, яңа килгән газеталарны карады. Рафисның ничә тапкыр сынаганы бар; бер җиргә барырга туры килдеме, газеталар укып булмый дигән сүз. Аннары ил, дөнья хәлләренең җеп очын югалта башлыйсың. Кайбер газеталарны укып, кайберләрен өстән-өстән генә караштырса да, хәтсез генә вакытның үткәне сизелми дә калды.

Ул тулай торакка янә әйләнеп кайтканда сәгать теле яхшы ук алдырган, күптән караңгы төшкән иде инде. Ул бүлмәләрендә җырлаган, мандолина уйнаган тавышлар ишетеп сагая калды. Җырлаучыны тавышыннан шундук таныды: анысы Виктор булырга тиеш. Ә менә мандолинада кем уйный икән? Рафисның абайлавына караганда, монысы Карчыганы хәтерләтә сыман. Бүлмәгә килеп керүгә, үзенең ялгышмаганлыгын белде. Виктор белән Карчыга аны икесе ике яктан кочаклап алдылар. Өстәлдә берсе эчелеп бетә язган, икенчесе башланмаган аракы шешәләре тора, балык башлары, суган һәм икмәк телемнәре һәм тагы кайбер ашамлыклар бар. Бүлмә инде ул җыештырып киткәндәге кебек түгел, тагы асты өскә килгән иде.

Тегеләр икесе ике яктан тотып, Рафисны, гүя чит кешене үз өйләрендә сыйлаган сыман, өстәл артына утырттылар. Үзләренә яртышар, аңа тулы стакан аракы салдылар. Рафисның инде күптәннән бирле «шайтан сөте»н авызына алганы юк иде. Ул чыраен сытып, курка-курка гына ярты стакан аракы эчте дә суган кисәге һәм балык койрыгы капты. Су салып эчте, тамак төбен көйдереп торган әчелекне юып төшергән итте. Виктор аннан шәһәр яңалыкларын сораштырырга кереште. Сүз ничектер шунда үзеннән-үзе Рафисның укуына күчте. Виктор аннан көнләшкән сыман шулай диде:

— Синең түземлек житә. Югарыга үрмәлисең. Тик миңа миннән генә булмады. Өч тапкыр омтылып карадым, но институтка керә алмадым.

Карчыга исә борыннарын җыерып куйды, аның чәче-башы тузган, кием-салымының да рәте киткән иде. Ул да сүзгә кушылды:

— Рафисның үз ихтыяры. Ләкин... Бар кешегә дә институт бетерергә димәгән. Мин үзем, мәсәлән...

— Ничек алай? — дип сорады Виктор.

Теге куе җирән сакалын сыпырды, яхшы ук томанлана башлаган күзләрен түгәрәкләндереп, җавап кайтарды:

— Ничек дип, бик гади генә. Ике ел бер класска кадаклап куйдылар. унынчыны коридорда гына бетердем дисәм дә ярый. Аннан «тегендә» йөреп кайттым. Хәзер инде минем башка да керми, әлләни теләк тә юк.

Викторның башына аракы пары менеп җиткән иде инде. Ләкин ул, әллә Рафистан беркадәр тартынып, әллә гаүдәсе авырая барганга күрә, тып-тын утыра бирде. Карчыга исә, бүлмәдә үзен хуҗа итеп тойган шикелле, тагы стаканнарга аракы салып чыкты:

— Ягез, суытып җибәрик, һәр нәрсәнең үз юлында булуы яхшы, ди торган иде безнең бабай.

Карчыга, тамчысын да калдырмыйча, ярты стакан аракыны тагы каплап куйды. Виктор яртысын бушатты. Рафис стаканы да күзеннән тулы иде. Ул эчемлеккә иреннәрен генә тидереп алды, башкача авызына якын да китермәде. Эчкән кадәресе дә аның башына киткән иде инде.

Карчыга исерек күзләрен күтәреп Рафиска карады. Аның йокысы килгән кебек, күз кабаклары салынган иде. Үзе сүзсез утыргач, Рафис аңа башына килгән соравын бирде:

— Син бит мине чакырып язган идең.

— Язса?

— Барган булсам әгәр...

— Икәүләшеп яңадан кайткан булыр идек.

— Нигә?

— Анда суык.

— Монда да Ташкент түгел лә.

— Булмаса да, монда икенче төрлерәк хәл. Себердә инде кыш: тәрәзәләргә бозлар каткан. Монда әле җәйге пальто белән йөрерлек.— Карчыга өстәлдә яткан балык башын кабып суырды да янә сүзен дәвам иттерде:— Барыбер төзелеш ич, анныры төшем ягыннан да әллә ни артыклык юк, брат. Кешеләр килеп кенә торалар. Романтика, героизм, фәләнтөгән, имеш... Анда романтика эзләп туңып-бөкрәеп йөргәнче, монда Россиянең уртасында әйбәтрәк, минемчә.

Ул көнне Карчыга Рафислар бүлмәсендә йоклады, эшкә дә шуннан гына китте. Әмма бу хәлгә Викторның артык исе китмәсә дә, Рафиска калса, аның эче пошты. Икенче көнне аларның бүлмәләрендә гадәттәгечә тәртип урнашкан кебек булды. Виктор да ят кешеләр ияртеп кайтмады, өстәлдә шешәләр дә күренмәде. Берничә көн буе тынлык һәм гадәти бертөрлелек хөкем сөрде.

Әмма бу хәл озакка бармады.

Ул, күзләрен ачып җибәрүгә, төшенә алмыйча гаҗәпкә калды. Бу ни дигән сүз? Ничек итеп һәм кайдан килеп эләкте ул монда? Рафис үзенең бу соравына җавап таба алмады. Ул әле күптән түгел генә ачылган яңа больница палаталарының берсендә тар гына караватта ята иде. Торырга маташты, кая ул, буыннары, гәүдәсе аны тыңламады. Калкынып ятарга тырышты, бу тиклесе дә барып чыкмады. Рафисның сул кулы һәм муены гүя аның үзенеке түгел, бөгелми дә, сыгылмый да, үзәккә үтәрлек каты авырту кузгалырга да ирек бирми иде. Үзенең ни хәлдә икәненә төшенмичә, ул тагы күзләрен йомды. Хәлсезләнеп йокыга китте-ме, һушыннан яздымы — бу тиклесен дә әйтүе кыен иде.

Ул яңадан күзләрен ачканда аның караваты янында урындыкта ап-ак халатлы сестра утыра иде. Ничек соң әле ул аны беренче уянуында күрмәгән. Бәлки чыгып киткән булгандыр, бәлки аның янына очраклы рәвештә генә кергәндер. Рафис шул рәвешчә уй йөрткәндә сестра ягымлы гына әйтеп куйды:

— Хәлегез ничек? Менә аңга да килдегез. Хәзер...

Рафисның җавабын да көтеп тормастан, сестра сак адымнар белән тиз генә палатадан чыгып китте. Рафис, түшәмгә караган килеш, ни дә булса уйларга өлгергәнче, пыяла ишектән берничә кеше килеп керде. Бу ак халатлыларның икесеме, өчесеме ишек бусагасыннан ары узмадылар. Әмма башкаларга караганда озынрак буйлысы Рафис янына килеп, аның битенә карады, пульсен капшады, хәлен сорашты. Аннары авыруларны тынычландыра торган гадәти сүзләр әйтте дә, сестрага әкрен, салмак тавыш белән нindидер күрсәтмәләр биреп, чыгып китте. Аның төз гәүдәсе, куе кашлары, аннан да бигрәк калын, йомшак тавышы үзе чыгып киткәч тә Рафисның исендә калды.

Сестра Рафиска бер ак таблетка бирде, мензуркага салып ниндидер әчкелтем-төчкелтем тамчылар эчерде. Сестра дигәне инде бик яшь булмаса кирәк, аның сыек кына итеп кызартылган ирен читләрендә вак-вак җыерчыклар күренә, ияк асты да салына башлаган, әмма күзләре яшь, бик яшь иде сыман. Рафисның үтереп эчәсе килә, хәтта тамагы карлыгып хәлгә җиткән иде. Сестра аның соравына каршы:

— Сезгә күп эчәргә ярамый,— дип, ирен чылатырлык кына су китереп бирде.

Авыруның хәле көтелмәгән тизлектә арулана бару сестрага яхшы тәэсир итте булса кирәк, ул елмаеп сүз кушты:

— Әле кереп чыккан кеше — сезне караган врач — хирург ул. Һуштан язган булгач, бик курыккан иде. Ярый әле...

Рафис, сестрадан сорашып, үзенең авыр хәлдә больницага эләгүен, бары сигез сәгатьтән соң гына һушына килгән булуын һәм сул кулының беләк сөяге сынган икәнен белде. Кулы төзәлер, тик менә һуштан язуы... Аның башы әле һаман да авырта, әйләнебрәк тора иде.

Баштагы көннәрдә Рафис янына берәүне дә кертмәделәр. Аның авыр хәлдә ятуы турында тиздән хәбәр таралып та өлгерде. Бер атна узуга, Рафис урыныннан торып утыра, аз-азлап тамагына капкалый башлады. Ул ята торган бүлмәдә аннан башка да өч кеше бар иде.

Рафиска әледән-әле укол биреп торалар. Сестра, беренче көннәрдәге кебек гел янында утырмаса да, еш кына палатага күз сала һәм Рафисның хәлен, кәефен сораштыра иде. Аңына килеп, хәле бераз рәтләнә төшкәч, егет барысын да хәтерләде.

...Булачак төп корпуста төрле машина һәм агрегатларны кую, урнаштыру өчен эшләнгән нигезләрнең тышламаларын алуда бригаданың яртысы катнашты. Тышламалар аз түгел иде. Шуның өчен көне буе эшләсәләр дә, бөтенесен дә алып бетерә алмадылар. Башкалар киткәч тә, бригадир Фиргали, тагы берничә кеше арасында Рафис та калды. Соңгы

«калкулык»ка менеп такталарны алырга керештеләр. Инде эш күп калмады кебек. Рафис агач баскыч белән өскә менде дә тышламаларны саклык белән генә кубара башлады. Чөнки прораб барлык такталарның да төзек булуларын таләп итә, аларны икенче тапкыр тышлама ясаганда да файдаланалар иде. Озакламый Фиргали үзе дә өскә, аның янына менде. Ул корылманың икенче башына таба китте. Рафис бер төпне такталардан арындырып, икенчесенә күчте. Такталар балта йөзен тидерүгә җиңел генә куба, ныгыган тимер-бетон корылмаларда бары такта эзләре генә кала. Шулай бер корылманың соңгы такталарын кубарганда, уңайсыз җирдә аның аягы таеп китте. Куллары белән тотынырлык нәрсә күренмәде, һәм, аны-моны уйлап өлгергәнче, ул аска таба тәгәрәде... Бәла аяк астыннан килеп чыга икән шул, югыйсә техника хәвефсезлеге кагыйдәләрен дә белә, ул турыдагы журналга кул да куйган иде.

Бергә эшләүче бригадашлары Рафис янына килгәләп торалар. Фиргали абыйсы, Рафис егылгач, ашыгыч ярдәм күрсәтү станциясенә шалтыратса да, машина икенче җиргә чыгып киткән булганлыктан, тиз генә килә алмаган. Бригадир, йөк машинасы тотып, аны шуның белән больницага озаткан икән. «Бөтенләй төсең качкан иде, без сине исән калыр дип уйламаган идек», дип сөйләп торды бригадир, башын селкә-селкә.

Ял көне. Больницада гадәти ыгы-зыгы сизелми, сестралар да врачларның обходын көтеп каушап йөрмиләр, ары-бире чапмыйлар. Рафиска урында килеш кенә иртәнге аш китерделәр. Ул гомерендә ашамаган манный боткасына күзләрен түгәрәкләндереп карады. Шул төчерәк итеп пешерелгән ботка турында, детсад баласына әйләндек, дип күршесе белән сөйләшеп ятканда, сак кына итеп алар палатасының ишеген шакыдылар. Шундук сестра белән иңенә ак халат бөркәнгән Мәдинә килеп керде. Сестра, гафу итенгәндәй, тиз генә чыгып китүгә, Мәдинә караватн янында бераз басып торды да урындыкка утырды. Тегe-бу турында сүз алышкалагач, хәл-әхвәл белешергә килгән Мәдинә, тагы киләчәген әйтеп, китеп тә барды. Ул киткәч, Рафис кыз калдырган кара җимеш компотын кат-кат кулында әйләндереп карады. «Бу Мәдинә бик яхшы кеше булып чыга бит әле»,— дип куанды егет. Җимеше дә теленне йотарлык тәмле тоелды. Соңра ул, савыт бушагач та, аны ташламады, шуннан чәй эчте, гүя башка тәм, татлы тәм иде.

Берничә көннән соң инде Рафис урыныннан торып йөри башлады. Гадәттәгечә ул тәрәзә янына барып басты. Икенче кат. Урамда кешеләр йөргәләп тора. Больница ишек алдында кулларына төенчек-күчтәнәчләр, сумкалар тоткан хатын-кыз, ир-ат күренә. Бәлки аның янына да берәрсе килеп чыгар. Бүлмәдәше Виктор да әле бер генә мәртәбә күренде бит. Больница капкасыннан керүчеләр арасында үзенә таныш төсләрне күргәч, Рафис сөенеп куйды. Мәдинә, Лиза, тагы Диләрә... Элегрәк аннан көлеп йөргән, адым саен үчекләгән бу кызлар аңа ничектер бик якын, бик яхшыдыр сыман тоелды бу минутларда. Кызлар больница ишек төбенә килеп җиткәч кенә ул тәрәзә яныннан китте. Озак көтәргә туры килмәде, палатага Мәдинә килеп керде. Нишләп ул үзе генә икән, иптәш кызлары нигә кермәделәр икән? Мәдинә, аның уйларын белгән шикелле, үзе үк әйтеп салды.

— Без өчәү килгән идек, аларны кертмәделәр. Кире беткән дежурныйга эләктек.

— Кемнәрне кертмәделәр? — дигән булды Рафис.

— Лиза белән Диләрә дә килделәр минем белән.

— Ә, алай икән,— диде Рафис бер дә исе китмәгән шикелле.

— Бары да синең саулыгың белән кызыксыналар,— диде Мәдинә. Аның турында төрле сүзләр йөри икән. Имештер, аның акылына зәгыйфьлек килгән, имештер, әллә нинә җирдән сөякләре сынган. Рафис боларны ишетүгә ирексездән көлеп куйды. Мәдинә, башта килгәндәге кебек үк, карават янындагы ак урындыкка утырды. Рафисның да

урыныннан торып, аңа каршы утырасы килде, ләкин уңайсызланды, мендәрен калкытып, күтәребрәк кенә ятты. Аның башындагы җәрәхәтләре төзәлгән, маңгаенда җөй беленеп тора, бер кулы гипска катырылган хәлдә муенына асып бәйләнгән иде. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, алар мөмкин кадәр башка кешеләр ишетмәслек итеп, ярым пышылдап сөйләшүгә күчтеләр. Аларның шулай тартынуларын сизепме яки башка сәбәпләре булыпмы, авыруларның иң элек берсе, аннары икенчесе палатадан чыкты.

— Менә икәү генә калдык,— диде Рафис.

Мәдинә җавап кайтармады. Яшькелт-сорырак күзле, авыз читләре уймакланып торган түгәрәк битле, чия кебек тамарга торган калынрак иренле, бөтен торышында, үзен тотышында яшьлек дәрте һәм шаянлык кайнап торган Мәдинә, беркадәр калынрак гәүдәле булса да, үзенең кай ягы беләндер бик сөйкемле, бик ягымлы иде. Рафисның шулай сынап каравын сизенгән шикелле, Мәдинә иң элек күзен читкә алды, аннары, озын керфекләре белән күз төпләрен күләгәләндереп, аска карады, кызның бит алмаларына алсулык йөгерде... Мәдинә Рафисның баш очында китаплар күреп, аларның берсен кулына алды да озак тотмыйча кире урынына куйды.

— Дәреслекләр,— диде Рафис.

— Монда да укыйсыңмыни?

— Әле кичә генә китерттем. Караштырмыйча булмый, болай да артка калдым бугай инде.

Мәдинәнең чыраендагы кызару кайткан иде инде. Ул, әллә сүз югында сүз булсын дигәндәй, әйтеп ташлады:

— Хәзер кызларга бәйләнмисеңме инде?

— Мин бәйләнмим, кызлар үзләре нишләрләр тагы,— дип мәзәк кенә әйтеп куйды Рафис.

— Юк, Рафис, кызлар алар бер вакытта да бәйләнмиләр. Егетләр үзләре бәйләнчек була,— диде Мәдинә, яңадан кызарына башлап.

Рафис җавап кайтармады.

Палатадагы авырулар кергәнче, Рафис кызга ниндидер җылы, ягымлы сүзләр әйтмәкче иде. Тик әйтә алмады, озакламый теге авыруларның башта берсе, аннары икенчесе килеп тә керде. Кыз белән егет ничектер уңайсызлана башладылар. Ләкин бу хәл озакка бармады. Салмак кына итеп шулай сүз башлады:

— Мин хәзерлек курсларына кердем, Рафис.

— ВУЗгамы?

— Юк. Техникумга.

— Куптәнме?

— Әле укый башламадык.

— Димәк, электростанция үз белгечләрен әзерли.

— Шулай сөйләнәләр,— диде Мәдинә.

— Дәреслекләрең бармы соң, житәрлекме? — дип сорады Рафис.

Бу әйткәне белән ул Мәдинәнең иң эчен пошырган нәрсә турында сүз кузгатты. Аның китаплары юк диярлек иде шул. Ярый әле, Рафис урта мәктәптә укыгандагы дәреслекләрен җыеп барган икән. Ул кызга аларны бирергә булды һәм үзе белән бер бүлмәдә торучы Викторга язу язып, аны Мәдинәнең үз кулына тоттырды...

Мәдинә палатадан чыгып киткәч тә, Рафис, тәрәзә катына барып, күзләре белән аны озатып калды. Әнә ул бераз юантыграк, уртача буйлы, зәңгәр шәлле кыз, бөтен тирә-якка ямь кертеп, нинди җиңел атлап бара! Нигә ул ашыга, нигә салмаграк атламый, нигә ялт итеп, бер генә тапкыр булса да, Рафис басып торган тәрәзә ягына әйләнеп карамый? Рафисның уйлары яшен тизлеге белән алга да, артка да йөгерәләр. Ул узган яз көне урманда агач кисүләрен, бер көнне эштән кайтканда Мәдинәгә нинди тозсыз сүзләр әйтүен исенә төшерде. «Әй

тупас, әй, йомыркадан борын тәртеп чыккан чебеш», дип әйтәсе килде Рафисның үз-үзенә. Ул вакытта бер Мәдинә генә түгел, башка кызлар да аңа ахмак бер кешегә караган сыман мыскыллап карадылар ич. Үзе дә пешмәгән дисәң, пешмәгән инде, кызларга тора салып: «Мин сине сөям»,— дип кем әйтә инде? Аннары ул Гөлзадә артыннан тилереп йөргәннәрен хәтеренә китерде...

Шундук Рафисның уй-исәпләре тагы да Мәдинә тирәсендә әйләнә башлады. «Ничә тапкыр килде. Һаман хәл белә, сөйләшергә тели, ничектер үз итүе, якын итүе сизелә. Әллә укырга керү уңае белән аңа ярдәм кирәкме, әллә Рафистан бар кызлар да кул селтәгәнгә, аны кызгана башлаганмы? Әллә чыннан да Мәдинәнең күңеле аңа тартыламы?.. Ничек кенә булмасын, әле аның болай килеп хәл белешеп йөрүе үзе бер бәхет. Алдагы көннәр ни күрсәтер тагы...» Рафисның чыраендагы беркадәр моңсулыкны күреп булса кирәк, палатадагы озын буйлы, җеп мыеклы абзый әйтә куйды:

— Ул кызны бик яратасың, ахры? Тәрәзәне рамы белән күтәреп, артыннан чыгып китәр төсле күренәсең. Җитешерсең әле... Әйдә, домино сугып алыйк, энекәш.

Ах, харап итте. Бу кеше Рафисны татлы уйларыннан бүлдерде. Бу агайның үзенең дә яшь чагы, егет чагы булмадымы икәнни?..

## 4

Октябрь бәйрәмнәре узып, ике көн дә тормагандыр, ишеп-ишеп кар яуды. Олы кешеләрнең юравынча, беренче кар күренгәннән соң, бер ай вакыт узгач, чынлап кар төшә, кыш керә, диләр. Мөгаен, бу рас килә торгандыр. Беренче карның күренүенә бер ай узмаса да, егерме-егерме биш көн узган иде. Ул көнне эшчеләр юешләнеп, карга буялып кайттылар. Мәдинәнең бөтен гәүдәсенә салкын йөгерде, туңды. Иптәш кызлары юл өстендәге тулай торакка кереп калгач, ул йөгерә-атлый өйләренә кайтты. Әмма яңа пешкән икмәк исе чыккан җылы өйдә озак юанырга туры килмәде, тамак ялгап, бераз ял итте дә, җыйнак кына кара сумкасына китап, дәфтәрләр салып, укырга юнәлде.

Рафис та көндезге сменада эшли. Больницада ятып чыгуның беренче көннәрендә аңа ничектер күңелсезрәк тоелды. Буыннарында ниндидер калтырау һәм хәлсезлек сизде. Тик мондый хәл озакка бармады. Ул үзенә бирелгән биш көнлек бюллетененең бер көнен көч-хәл белән генә уздырды да, икенче көнне иртүк эшкә китте. Иптәшләре аны бик көткәннәр икән, ачык чырай белән каршы алдылар. Хәтта өчме-дүртме көн эшләгәч, Фиргали абыйсы бик якын итеп, үз итеп бер сер сөйләште аның белән. Фиргали абыйсына, үзе монтажчы булып китмәкче булгач, үз урынына кеше табарга кушканнар икән. Ул уйлаган-уйлаган да Рафисны тәкъдим итмәкче булган. Рафиска калса, нигәдер аның бер дә бригадир буласы килми. Аннары бу эшне ерып чыга алуына да ышанып җитми. Укыгач та, шундый җаваплы эштә эшләгәч тә, ничектер бик кыен булырдыр сыман тоела иде. Ул, бригадирының тәкъдименә каршы килеп, бу эшкә Алып батыр — Виктор кандидатурасы әйбәт булачагын әйтте. Ләкин монсы белән Фиргали абыйсы килешмәде. Ул соңгы вакытларда Викторның әллә ничек кенә, бөтенләй юлдан язмаса да, еш кына абынуы турында белә иде. Егетнең сәбәпсез-нисез эштән калган көннәре дә юк түгел икән. Әнә шуларны искә алып, Фиргали абыйсының соңгы көннәрдә бу егеткә карата карашы кире якка авышкан икән. Алай да Рафис бригадир тәкъдименә риза булуы турында әлегә өзеп бер сүз дә әйтә алмады. Уйланырга булды. Аннары бит әле Викторны да читтә калдырып булмый. Алар ни гомер бергә эшлиләр, бер бүлмәдә торалар.

Рафис энә шул турыда уйлана-уйлана тороктан чыкты. Урамдагы баганалар башыннан электр утлары җемелдәп күз кыса. Егетнең аякларында кышкы җылы ботинка булса да, өстендә көзге пальто, башында фуражка. Баштарак һава дымлырак кебек тоелса, бара-тора корытып һәм беркадәр суытып җибәрде. Урамда йөрүчеләр аз, тын, тик түзелеш ягыннан гына утлар күренә һәм моторлар шау-шуы ишетелә иде. Рафис, больницадан чыкканнан соң, кызны бер мәртәбә күргән булса да, аның белән генә күңеле канәгатьләнмәгән иде. Хәзер ул нишли икән, уйлары кай тирәдәрәк чуала икән? Рафисның һәммәсен дә беләсе килә. Ул поселокның төзелеш ягыннан беренче булып башлана торган киң урамына килеп керде. Чапаев урамы дип йөртәләр иде аны. Монда һәр ике яклап бараклар төзелгән, читтәрәк зур бер йортка нигез салынган иде. Рафис бер катлы шактый зур, киң йортның тәрәзәләренә йотылып-йотылып карады. Кайбер тәрәзәләргә пәрдәләр корганлыктан, анда кешеләрнең нишләве күренми. Хәер, пәрдәсез тәрәзәләр дә байтак икән. Аларыннан инде һәммәсе ап-ачык күренеп тора — әнә икешәр кешелек өстәлләр артына утырган студентлар лекция тыңлыйлар. Ул лекторны таныды. Озын буйлы, тар җилкәле бу кеше проектлар бүлегендә эшләүче инженер ич. Кызлар, егетләр аралашып та, ничек туры килде шулай да утырганнар. Рафис, шулай кызыксына-кызыксына тәрәзәләргә таба артык якынлашканын чамалап, беркадәр арырак китте. Янәшә генә берничә класс укый, күрәсең. Ул, нихәтле каранса да, Мәдинәне таба алмады. Кайда утыра икән соң ул, әллә килмәдеме икән? Шулай карап йөри-йөри, тәрәзә кырыенда утыручылар аның үзенә игътибар итә башладылар. Рафис, уңайсызланып, читкәрәк китте.

Егет яңадан әйләнеп килгәндә, студентлар соңгы дәрестән чыгарга яңа гына звонок булган иде. Аңа озак көтәргә туры килмәде, көләшә-көләшә үзенә таба килгән кызлар арасында ул Мәдинәне тавышыннан ук танып алды. Кызлар култыклашып баралар иде.

Алар Рафисны узып киттеләр. Бу нинди хикмәт? Әллә югыйсә Мәдинә күрмәдеме? Ул аның зарыгып көтүен белмиме әллә? Кычкырса? Сызгырса? Ләкин Рафис боларның берсен дә эшләмәде. Тиз генә иелеп, тапталмаган җирдән учлап йомшак кар алды. Шуны аз гына әвәләштерде дә кызлар артыннан куып җитте. Мәдинәнең аркасына кар йомарлагын — шап!.. Кызлар чәрелдәшеп таралдылар...

Икесе генә калгач, Мәдинә әкрен генә әйтте:

— И чудак та инде син, Рафис. Кайчан бетәр мәзәк гадәтләрең!

— Ул тиклесен киләчәккә планлаштырырбыз,— диде Рафис. Бераз тын баргач өстәде: — Мине күрми дә үтеп барасың ич...

— Мин сине баягынак ук күрдем лә.

— Ничек? Кайда?

— Тәрәзә төбендә йөргән чагыңда...

— Ә мин сине күрә алмадым.

— Мин теге як стена буенда утырдым шул.

Рафис күңелсезләнгәндәй әйтә куйды:

— Хәзер танцаларга йөрү бетә инде, алайса?

— Анысына житешербез, курыкма,— дип көлде Мәдинә.

Сөйләр сүзе күп иде Рафисның, кыз үзе очрагач, ничектер ул беркадәр югалыбрак калды. Бусы инде, аңа калса, шулай ук килешеп бетми. Әле узган яз гына очраган һәр кызга үзенең гашыйк икәнен әйтергә ашыккан Рафисның, әйтерсең лә, алыштырган шикелле, шулай тын калуы һәм оялчан күренүе Мәдинәгә, бер яктан, ошаса, икенче яктан, нигәдер бик сәер тоелды. Бәлки кызның үзенә сүз башларгадыр? Ничек кенә баш ватмасын, Мәдинә дә үзләрен якынайта, йөрәкләрен куша торган сәбәпләр турында әйтергә сүз таба алмый йөдәде. Теге-бу

рыда сүз кушып, ара-тирә тын калып барганда, һәр икесенең уйларын леп, күңелгә ятышсыз җыр тавышлары ишетелде:

Таллардин тартма ясап бирим
Сырлауларын үзең сырларсың.
Су буйларында бөдрә тал,
Башын кис тә суга сал...
Если любишь и веришь,
Все дороги ясны,
Океаны измеришь,
Долетишь до луны.
Я люблю тебя очч-ччень...

Җырлаучылар озакламый үзләре дә күренделәр. Болар төзелеш алкына яхшы ук таныш булган Фарук Фарукшин компаниясе егетләре де. Татарча ул үзе җырлый икән. Рус егетләре татар сүзләрен әйтә лмасалар да, Фарук җырлаган көйгә кушылалар, бераз бозып булса а, җырның яңгырашын көчәйтәләр иде.

Рафис белән Мәдинәне күргәч, Виктор, мөмкин кадәр туры атларга ырышып, урамның икенче ягына таба китте. Кылый белән Карчыга, ерни дә булмаган кебек, башлаган җырларын сузып, турыга килделәр. ик Фарук Фарукшин гына тыныч кан белән уза алмады. Ул аларның аршыларына килеп басты, үзе алпан-тилпән килә, чайкала иде.

— Ә, Рафис, асыл кошны аягыннан эләктердеңме? Сиздем эшегезне, юярмын тешегезне... Ха-ха-ха...— Фарук шулай диде дә, Рафислар узып итүгә, баштагыча чайкала-чайкала җырлавында дәвам итте.

Шактый вакыт тын бардылар. Инде Мәдинәләргә дә ерак калмаган иде. Әлеге исерекләр, үзләре килеп бәйләнмәсәләр дә, аларның икесенә дә ниндидер бик начар тәэсир итте. Башларындагы татлы уйларны чуалтып җибәрделәр.

— Атаклы маляр Фарук шушымы инде? — дип сорады Мәдинә.

— Нәкъ үзе.

— Шулай «культурный» ял итәме инде ул?

— Күрдең ич.

— Бигрәк сансыз кеше икән. Үзе лыгырдык җитмәсә, теленә тилчә чыккыры, карчыклар әйтмешли...

Тагы бераз сөйләшеп йөргәч, Мәдинәләр турына килеп җиттеләр. Инде урамны ничәнче әйләнүләре булгандыр, монысында Мәдинә йомшак тавыш белән хушлашты да капкадан кереп югалды. Рафисның күңеленә читен булып китте. Ул, әле һаман да үз янында Мәдинә булган кебек, бер мизгел капка алдында басып торды, аннары караңгы урам буйлап салмак кына атлап кайтып китте.

## 5

Шеш тула-тула да бер тишелә. диләр...

Моны киңәшмә дип тә, утырыш дип тә атап булмый. Тик шунысы бар — гадәти утырыш яки киңәшмә шикелле, барыбер өстәл тирәсенә, стена буйларына кешеләр утырган Васил эшли башлаганнан бирле кабинетка әллә ни үзгәреш кермәсә дә, аны әйбәтләп акшарлаганнар, яңа урындыклар китерткәннәр иде.

Васил Сафинның чыраендагы кырыслык, әйтерсең лә, башкаларга да күчә сыман. Бүтәннәргә ничектер, әмма Игнатка калса, нәкъ шулай тоелды. Аның болай да куе кашлары җыерылып бергә тоташкан кебек күренә иде. Ул сүзне башларга гына торганда, кемдер телефоннан шалтыратты. Васил Сафин телефоннан сөйләшкән арада, Игнат бер-бер артлы күз алдыннан үткәрде. Фарук Фарукшин звеносының намусын югалтуы хәзер инде һәркемгә ачык. Дер калтырап торган Фарукшин звеносы кешеләре авызларын ачкалап, нидер көтәләр кебек.

Болай тыштан тыныч күренгән Васил Игнатның башына шундый сүз белән китереп сукты: «Мин дә сукыр, Игнат, син дә сукыр... Без берни күрмибез. Безнең борын төбендә шабашниклар тамыр җәя. Атай малы — катай... принципыннан чыгып эш итүчеләрне күрмибез без». Билгеле, Сафиннан мондый сүз ишетү Игнат өчен күңелле түгел иде. Әйе шул, эштән соң да кешеләрнең нәрсә белән шөгыльләнүләрен белергә тиеш алар. Тормыш үзе шулай куша.

Игнат Данилов башын күтәрмичә генә кабинеттагылар өстеннән күз йөртеп чыкты. Фарук Фарукшин бүтән чаклардагы кебек кояштай балкымый, күзләрен ялтыратмый, колакларын авызына җиткереп елмаймый. Бүтән чаклардагы шикелле, «күлнең өстендә» дә калкып тормый. Аны күрмәсеннәр, аңа күз салмасыннар өчен, бүрәнә ярыгына кереп поскан тараканны хәтерләтеп, иң почмакка кереп сеңгән. Аның белән янәшә Кылый егет. Утырганнар арасында зур гәүдәле Виктор — басып торган шикелле күренә. Ләкин егетнең чыраенда гадәти яктылык һәм елмаю сызыклары чагылмый, аның йөзе көл шикелле агара, сорылана бара иде. Карчыганың гына кыяфәте әүвәлгечә, аны борчыла дип тә, борчылмый дип тә әйтерлек түгел иде. Кабинетта тагы да берничә мастер, бригадирлар, алар арасында Фиргали дә бар.

Васил Сафин, башта кызып, аннары салмак эзгә төшеп, сөйләде дә сөйләде. Шуны сизенгән Фарук Фарукшин да калкыныбрак утырды. Башлык малярлар бригадасының берничә йорттагы әйбәт эшләрен, башта аларның хезмәткә намус белән карауларын әйтеп үтте, шуннан соң кинәт тукталып калды. Барысы да аңа карадылар. Эшләрен уңай яктан телгә алганда, яшеренгән почмактан чыгарга, алгарак шуышып утырырга өлгергән Фарук «Менә мине күрегез» — дигән сыман тирәяктагыларга карап алды. Ләкин Васил Сафин аерым кешеләрдән кергән жалобаларны укый башлагач, Фарук тагы кечерәеп, почмакка сеңде. Сафин дәвам итте:

— «...Гагарин урамындагы утызынчы йортта, унберенче квартирада торучы Петровтан. Тәрәзә һәм ишек борысларыбызның әле һаман кибеп беткәне юк. Идән дә бик начар буялган. Урын-урын буяу куба». Яки менә тагы: «Егерменче йортта торучы... Тәрәзә борысларындагы буяуның сыйфаты начар. Буялган урыннар кубырчыклана. Күрәсең, буяучылар эшнең сыйфат ягына әһәмият бирмәгәннәр...»

Сафин бер-берсенә охшашлырак тагы ике-өч кәгазь укыды да туп-туры Фарукшинга карады:

— Сез моны ничек аңлыйсыз?

Фарук, җавап кайтармыйча, бераз вакыт башын кашып торды, аннары чыраен сытып:

— Ничек әйтергә, иптәш Васил Закирович, тәрәзә борыслары буяулары кипми дигәне... Форточкаларын ачмыйлар да кипми шуңа,— диде.

— Бәлки буяу артык сыектыр,— дип сүз кыстырды Васил.

— Буяуның таш кебек катысын күргәнем юк әле шушы гомергә хәтле яшәп бу дөньяда,— диде Фарук.

Васил Сафин да, башкалар да көлемсерәделәр.

— Ә буяган җирләр ник кубырчыклана соң? — дип сорады Васил.

Фарук Фарукшин, башлыгының карашы үзенә текәлгәнен сизенеп, күзләрен аннан яшерергә тырышты:

— Хатын-кызның билгеле инде аның, иптәш Васил Закирович, бер кер юа башласа, дөньясын туздыра. Кер юганда пар чыгаралар да буяулар кубырчыклана... и вәссәлам...

— Тагы нинди сәбәпләр булырга мөмкин?

Башкаларның тып-тын утыруларын күреп, Фарук Фарукшин тагы күтәреп алды:

— Тагымы? Андый хәл тәрәзә борыслары чи булудан да килергә мөмкин.

— Алар коры. Сез төрле сылтаулар табып акланырга маташмагыз,— диде Васил, кырыс кына.

Аның бу әйткәннәре дә Фарукшинны артык каушатмады, күрәсең, бу юлы ул үзе сорау куйды:

— Без йөзләгән квартир буядыкмы? Буядык. Идән-тәрәзәләр ялт итеп торамы? Тора. Шуннан китереп, мин әйтәм, нигә өч-дүрт кешедән генә шикаять кергән. Гаеп бездә түгел, хуҗаларда.

— Нинди хуҗаларда?

— Квартир хуҗаларында.

— Юк, Фарук абзый, гаеп сездә. Ул жалоба язган кешеләрнең квартирларын буярга тиешле буяулар каядыр «аякланган», тиешле җиргә тотылмаган. Менә бөтен бәла шуңа кайтып кала.

— Дөрес түгел,— дип кычкырды Фарук.

— Сез инде бу урында, тотылмаган карак карак түгел, дигән принциптан чыгып эш итмәкче буласыз. Индивидуаль өйләрне буярга буяу кайдан аласыз?

Фарукшин бу юлы да югалып калмады:

— Өй хуҗалары үзләре табалар.

— Кайдан табалар?

— Кибеттән.

— Анда ялан саен буяу булып тормый бит.

— Теләгән кеше таба,— дип тагы кырт кисеп әйтте Фарук.

Игнат Данилов Васил Сафинны бик кызып китәр, һәммәсен дә туздырып ташлар дип уйлаган иде. Аның бу рәвешчә салкын канлылык күрсәтеп сөйләшүенә гаҗәпләнеп утырды ул. Игнат үзе дә каты-каты гына сүзләр әйтмәкче булып сүз сорарга җыенганда, Васил Сафин кинәт кенә кызып китте:

— Җитте! Фарукшинның компаниясен таратырга вакыт. Шабашникларга тәртипсезлек ясап йөрергә башкача юл куелмас безнең идарәдә, моны бик ачык белеп торыгыз.

Фарук Фарукшинның чырае агара барды. Ул үзенең һәм иптәшләренең тырышып эшләүләре, инде сменадан соң бераз акча эшлиләр икән, аларны бу эштән беркем дә тыя алмавы, моның беркемгә дә зыян китермәве турында әйтеп, һаман үзләрен аклау ягын каерды. Моңарчы тын утырган Кылый да сүзгә катышты:

— Эштән соң без үзебезгә үзебез хуҗа, хөрмәтле Васил Закирович.

Васил Сафин, аның сүзен әйтеп бетерү-бетермәвен уйлап тормастан, үзенекен итте.

— Искедән калган яман гадәт... получка алгач, бригадирны сыйлау. Эштә макмыр төшкән баш белән нинди рәт булырга мөмкин?!

Башлык кеше, бераз тын торып, иң элек Карчыгага карады. Бу «сакалбай» башлыгыннан карашын яшерергә теләп башын читкә борды. Аннары Сафин Викторга карады:

— Сез ничек уйлыйсыз? Тайгак юлга басканыгызны сизмисезмени?

Карчыга кебек үк Виктор да карашын яшерде, кайтарып сүз әйтүче булмады. Васил папирос кабызды, бер-ике тапкыр төтен суыргач, соңгы сүзен әйтте:

— Ярый. Шушы урында точка куйдык. Шабашникларга капканы бикле дип саныйбыз. Аңлашылгандыр, шәт?

Аңарга каршы кайтарып җавап сүзе әйтүче булмады. Озакламый кешеләр таралыштылар.

Гадәттә бер юлдан, бер сукмактан йөрергә күнегеп беткән бу кешеләрнең бу юлы төрлесе төрле якка юнәлде. Фарук Фарукшин егетләренең әле берсенә, әле икенчесенә нихәтле күз салмасын, аңа борылып карауны булмады. Ул, кулларын җәеп, бу хәлгә аптырап калды.

Һәр көнне эштән соң гына кайтып китү Васил Сафинның гадәте булып әверелде. Көндезге ыгы-зыгыдан котылып, яңа килгән газеталарга күз салып утырганда, аның кабинетына озын гәүдәсен ия-сыга Виктор килеп керде. Ул, әле күптән түгел генә биредә булганга, эш киемнәрен дә алмаштырмаган иде. Ишектән керү белән нигәдер торааш кебек катып калгандай, бер урында тора бирде. Васил Сафин, газетадан карашын алып, салмак кына тавыш белән эндәште:

— Әйдә, утырып җибәр, Виктор.

— Басып торсак та ярар.

Шулай да ул ишек катындагы урындыкка чүкте.

— Бүген икенче тапкыр күрешәбез бугай...

— Шулай туры килде,— дип ялгап алып китте Виктор.— Мин гаепле...

— Ничек алай? Сине гаепләргә җыенучы юк бит әле.

Виктор озын кулларын җыеп тез өстенә салды. Болай карап торуга һич кирәге сизелмәсә дә, кулъяулык чыгарып, маңгаен сөртеп алды.

— Әйе, мин гаепле,— дип дәвам итте ул.— Фарукшин койрыгына тагылып йөрүем өчен гаепле мин.

Васил салкын гына елмаеп куйды:

— Нигә ул турыда бая бер сүз дә әйтмәдең?

— Уңайсызландым, ояллым.

— Хәзер?

— Сезнең белән ялгыз гына сөйләшсәм килде. Мин беркайчан да бу тайгак юлга басмам бүтәнчә. Комсомол линиясе буенча да шелтә чәпәделәр.

— Башта ни уйладың?

— Уйлап житкермәгәнмен шул. Шуңа тагылып йөрү аркасында эчәргә өйрәнеп китә яздым.

— Күкрәгеңә кулыңны куеп әйтә аласыңмы — Фарукшинның буяу чәлдергән чаклары булдымы?

Виктор җавап кайтармады, бурлат кебек кызарды, бүртенде. Шулай да мондый халәт озакка бармады:

— Үз күзем белән күрмәдем, әмма булгалагандыр дип уйлыйм... Мине Фиргали абзый бригадасында калдырыгыз. Бүтәнчә Фарукшин кул астында эшләргә теләмим,— диде егет.

— Фарукшин арбасын бүген ваттык. Баягы сөйләшүдән соң аңлагансыздыр.

Виктор кайтарып җавап сүзе әйтмәде. Салмак кына атлап кабинеттан чыгып китте.

Иртәгесен прораб Игнат Данилов Фарукшинның үзен дә, башкаларны да төрле бригадаларга кушты. Берничә көннән соң байтак кына буяуның әрәм-шәрәм ителгәне мәгълүм булды. Җитмәгән буяуның хакын Фарукшинның хезмәт хакыннан тотып калу турында тиешле документ рәсмиләштерелде.

## 6

Ул һич көтмәгәндә килеп төште...

Ишектән җыйнак кына чемодан күтәреп килеп кергән уртача буйлы, яхшы киемле, тәскә-биткә чибәр генә хатынны күргәч, юан вахтер апа гадәтенчә башта җентекләп карап торды. Теге хатын, чемоданын идәнгә куеп:

— СМУ начальнигы Сафин шушында торамы? — дип сорады.

— Шушында, шушында тора Васил Закирович,— дип җавап кайтарды вахтер. Үзе тагы бер тапкыр яшь чибәр хатынны баштанаяк сөзеп карап чыкты. Аз гына вакытка һәр ике яктан сүз кушучы булмый

торды. Вахтер хатын документ-мазар сорарга исәпләп торганда, килүче үзе әйтеп салды:

— Мина ул кирәк иде.

— Кайтмаган әле ул. Булмасе бикле.

— Вакыт соң бит инде, кайда йөри икән?

Нурзиләнең бу сүзләре җавапсыз калды. Вахтер хатын бераз чеметтерә торган бу сүздән шундук чамалап алды һәм җавап бирәсе урында үзе сорау куйды:

— Сез аның кеме буласыз соң?

— Хатыны,— дигәч, Нурзилә җиңелчә генә кызарып китте.

Шаянрак табигатьле вахтер хатын төсенә елмаю сызыклары чыгарып әйтә салды:

— Бәрәкәч, без аны тагы егет кеше дип йөрибез... Менә ничек икән!..

Хатынның бу сүзләреннән соң Нурзиләнең йөзе тагы да кызара төште, күзләрен челт-челт йомгалап алды. Күршедәге ишекләрдән кызыксынып караучылар күренә башлагач, вахтер хатын үзе тәкъдим итте:

— Ачкыч миндә, рәхим итегез.

Уртача зурлыктагы бүлмә, өстәл һәм берничә урындык, пөхтәләп җыештырылган ике кешелек караваты һәм ишек катындагы почмакта торган шифоньер Нурзиләне артык гаҗәпләндермәде. Ул чемоданыннан кайбер әйберләрен алды да юынып керде, чәчен-башын тәртипкә китерде. Өстәлдә яткан «Огонек» журналын актарып утырды. Шуның белән бергә, ул, сабырлыгын югалта барып, беләгендәге сәгатенә әледән-әле күз төшереп ала иде. Бераздан ул үз күчтәнәчләре белән чәйләп тә алды. Ләкин Василның һаман кайтмавы аны пошындырганнан пошындыра барды. «Башта ук шулай буласы билгеле иде. Әллә кемнәр белән сөйрәлеп йөри торгандыр әле, юньле хәл түгелдер»,— дип уйлады хатын. Китапларны, өстә яткан кайбер әйберләрне актарып карады: чит куллар эзе юкмы, янәсе... Шик-мазар сизелерлек нәрсә тапмады. Аннары коридорга чыкты. Вахтер хатын каядыр кухняга чыгып киткән иде. Нурзилә, шикле күз белән карана-карана, тар гына коридорда арлы-бирле йөренеп килде. Аңа мондагы ис тә, кешеләр дә ят иде. Вахтер хатын килеп үз урынына утыргач, Нурзилә янә түземсезләнеп сорады:

— Кайчанрак кайтыр икән бу Васил? Көтә-көтә гарык булдым бит инде.

— Кайтыр. Кайтмый син теге! — диде аңа карамыйча гына вахтер хатын.

— Һәр көн шулай соң кайтамы?

— Юк, һәр көн түгел,— диде вахтер.— Ул хәтле олы урындагы кешенең, берәр мәшәкатькә юлыккандыр. Аннары китереп бит аларның киңәш-уңашлары да гел булып кына тора. Клуб тирәсендә түгелме икән, әйләнеп килсәң? Ерак түгел ич.

Нурзилә, баш селкеп, үзенең риза булмавын белдерде. Аннары уйлангандай тын калып торды да күптән тел очына килеп, башын кайнаткан соравын бирми түзә алмады:

— Болай үзе ничек тота?

— Бик яхшы, әчеп-исереп йөрмәс. Теге ярамый, бу ярамый дип теңкәбезгә тимәс.

— Юк, мин ул яктан түгел?

— Ә нинди яктан тагы? — Вахтер хатын, шешенке кабаклар арасына яшеренгән кечкенә елтыр күзләрен зуррак ачарга тырышып, Нурзиләгә карады: — Безнең ҖКУ башлыгы Вазих Вафич үзе дә бик олылый сезнең ирегезне. Кайбер ирләр хатыннары янынннан читкә китү белән башкалар артыннан чаба башлыйлар. Васил Закирович хакында ул турыдан да сүз әйтеп булмый, йөгенә керешле түгел.

СОВВУХ РАФИКОВ ◆ ТЫШ ЕЛГА БУЕНДА ◆

Инде ул сорауларына хатынның төшенгәнен сизенеп, Нурзилә гүя үсеп киткәндәй булды. Алай да үзенчә сер бирергә теләмәде:

— Ай-һай, ирләргә ышансаң...

Ул арада кин урындыгына җәелеп утырган юан вахтер хатын, кулына инәсен алып, бияләй бәйләргә керешкән иде инде. Яңа танышы Нурзилә әйткәннәргә аның бер дә исе китмәде:

— Үз иреңнең ничеклеген белә торгансыңдыр инде. Миңа ни, хатыннар белән йөргәнен үз күзең белән күрмәгәч, ничек итеп кешенең йөгенә керәсең?!

Күрәсең, тышта суыта бара — ишектән керүчеләр артыннан буланып салкын һава керә иде. Ире турында нинди дә булса сер алу нияте белән, Нурзилә җылы йон кофтасын иңенә салып чыкты да вахтер хатын тәкъдим иткән урынга җайлабрак утырды. Аның нечкәләп сораштыруы бераздан вахтер хатынның үзен дә нигәдер сагайта калды.

— Балаларыгыз бармы соң үзегезнең? — дип сорады.

— Бер улыбыз бар.

— Бөтенләйгә килүегезме?

— Безнең шәһәрдә яхшы квартирабыз бар. Баланы тәрбияләү...

— Хәзер безнең монда да каладагыдан ким салмыйлар йортларны. Бараклардан нихәтле халык күчте ваннысы-ние булган, пар белән жылыткан квартирларга. Ирең шундый зур башлык була торып, каладагы квартирны саклап ятырга син теге, булмаганны. Картың белән бергә-бергә гөрләшеп торуга ни җитә донҗада!

Вахтер хатынның бу соңгы сүзләреннән Нурзиләнең чыраена күңелсезлек күләгәсе иңде. Аның сөйләшәсе дә килми башлады. Ул арада ишектән тагы бер төркем кеше кайтып керде. Ләкин алар арасында да Васил юк иде. Теге-бу турында теләр-теләмәс кенә сүз алышканнан соң, башта бик теләп сүз ачкан Нурзилә бөтенләй тынып калды һәм озакламый, монда суык дигән булып, бүлмәгә кереп китте.

Беренче кар күренгәнгә бер ай вакыт үтмәгәндер, ишеп кар яуды. Яуды да шул кар утырып та калды. Төзелешкә материал ташый торган юлларны даими рәвештә көчле бульдозерлар чистартып торалар. Быелгы кыш хәл кылгыч кыш булганлыктан, салкыннар башлангач та эш күләмен киметмәделәр. Көннән-көн үсә килгән төп корпус биналары белән янәшә башка корылмаларны да торгызырга керештеләр. Язгы айлар башланганчы, булачак электр станциясенә су кереп-чыгып йөрү өчен катлаулы су комплексы галереяләрен төзү дә киң колач алды. Вакыт үтү белән алар һәммәсе җир астында калып, өстән бетон һәм асфальт җәеләчәк, кай урыннарга агачлар утыртылачак.

Әлеге шул галереяләргә бетон салучы дистәләгән бригадалар арасында Васил Сафин да үзенең эш көнен уздырды. Дөрес, бухгалтерия документларына, төрле мәгълүматларга кул кую өчен ул конторага керергә тиеш иде. Әмма кешеләр арасында вакытның ничек үтүе дә сизелмәде. Төзелеш мәйданыннан китеп баргач кына, бу турыда исенә төште. Көне буе төзелештә йөргәнгә, калын киенмәсә дә, кышкы кием аның иңбашларын шактый баскан, гәүдәсен талчыктырган иде. Ашханәдән туенып чыгуга, ул саф һавада тәмләп папирос тартты да кайтып ял итү нияте белән урам буйлап китте.

Инде кайтып җитәргә ерак калмаган иде. Почмакны борылуга, аның күз алдында кинәт таныш сын — таныш кыз пәйда булды. Бу ничек әле — әллә күзләренә ялгыш күренәме? Юк, ялгыш түгел икән... Әле күптән түгел генә ул аны эштә — өстенә сырма, пиджак, тар гына чалбар кигән килеш күргән иде. Ул чагында күз карашлары белән генә сәламләштеләр дә, шуның белән эш бетте кебек. Электр лампалары янып торган якты урамда Василның каршысына ук килеп туктаган

Гөлзадә тирә-якны ямьләндереп җибәрде сыман. Килеп җитүгә кыз ниндидер күңелле тавыш белән кычкырып әйтә куйды:

— Васил абый!

— Әү!..

Кыз тотлыга-каушый дәвам итте:

— Сез клубка барасыздыр инде, иеме?

Ни дияргә? Булмасенә кайтып ял итү нияте шундук башыннан очты.

— Әйе, клубка...

Гөлзадә, аны ашыктыруын да сизмичә, гүя житәкләгәндәй, клуб ягына тартты.

— Анда чират бик зур. Миңа да билет алып бирә алмассызмы?

Клуб стенасына «Анна Каренина» фильмы күрсәтеләчәге турында игълан эленгән. Васил аны ничек күрмәгән соң? Һәрвакыт афишаларны хәтерләп-күзәтеп үтә бит югыйсә. Хәер, иртәнге якта игълан юк иде шикелле, төштән соң гына элгәннәрдер. Ике сериясен дә берьюлы күрсәтәләр икән. Кызның очравына әйтеп бетерә алмаслык куанды Васил! Ул администратор аша билет алдыртты. Кино башланганчы беркадәр урамда йөрергә дә җитештеләр. Гөлзадә перчаткасы эченә йомарланган акчасын бирү турында баш ватты. Ниһаять, бер арада кыюсыз гына акчаны Василга бирергә булды. Ләкин Васил алмады. Кыз бу турыда яңадан сүз кузгата башлауга, Васил аны йомшак кына ачуланган итте. Гөлзадә:

— Болай бер дә килешми инде,— дип, учындагы акчасын кесәсенә тыкты.

Клуб эче халык белән шыгрым тулы иде. Хәтта, урын житмәгәнлектән, стена буйларында басып торучылар да күп. Картинадагы вакыйгалар бик киеренке барганлыктан, кешеләрнең башларында бүтән төрле уйларга урын калмады. Тамашачыларга тик бер арада залда ут сүнеп торганда гына экрандагы каһарманнар тормышыннан аерылырга туры килде. Васил, кыз белән башка очрашуларындагы кебек, үзен бик тыйнак тотты. Ярым пышылдап, Гөлзададән:

— Ошыймы? — дип сорады.

— Ничек кенә әле, ошамаган кая! — диде Гөлзадә. Бу романны ул әле күптән түгел генә укыган икән. Шуны укып чыккан көнне төне буе рәтләп йоклый алмаган икән. Гөлзадә әйтә башлаганын әйтеп бетергәнче янә ут сүнде.

Өч сәгатьтән артык вакытның ничек үткәне дә сизелми калды. Халык төркеме беркадәр вакыт клуб тирәсендә умарта иледәй кайнашып торганнан соң, кешеләр әле парлап, әле төркемләп, әле берәмләп төрле урамнарга таралышып беттеләр. Васил белән Гөлзадә дә шул ташкын, шул агым эчендә иделәр. Гөлзадә култыклашып барганнарга сокланып, юк, алай гына да түгел, көнләшеп карады. Нигә инде Васил абыйсы аны да култыклап алмый? Әллә ул үзе култыкласынмы икән? Ләкин кыз күтәрелә башлаган кулларын янә төшерде. Болай килешеп бетмәс, үтә әрсезлек булыр, дип уйлады. Бүтән ир-ат белән шулай янәшә барсаң, көт тә тор, кыюлыкны күрсәтеп кенә торырлар иде. Ә менә Васил абыйсы андыйлардан түгел. Ул аның белән бер генә тапкыр очрашмады бит инде. Бераз баргач, кызның уйларын тагы да «Анна Каренина» биләп алды. Васил да фильмнан алган тәэсирләреннән айнып житмәгән иде, ахры. Азмы-күпме шулай тын баргач, Гөлзадә, түзмичә, сүз башлады:

— Картинаны карагач бөтенләй күз ачылды. Һәр герой күңел түрендә тора.

— Дөрес әйтәсең, дөрес,— дип башын какты Васил.— Аннаның һәлак булуы күңелдә авыр тойгы калдыра.

— Әйе шул. Анна Каренина исән калган булса, күңелгә җиңелрәк булыр иде,— дип өстәде Гөлзадә.

— Бер яктан шулай. Икенче яктан алай түгел...

— Ә нигә?

— Тормыш аны ерып чыга алмаслык сазлыкка ташлый. Ни өчен дигәндә, менә ничек килеп чыга — Анна ире Каренинны яратмый. Ләкин Каренин ул заманның кыргый, гаделсез законнарыннан бик оста файдаланып, аның белән никах җепләрен өзми. Инде Вронскийга килсәк, аның әнисе Аннаны өнәп бетерми. Башта Вронский Аннага гел сыланып йөрсә дә, тормышларын бергә кушкач, аның да карашы үзгәрә. Анна өй колы гына, ир хатыны гына булып кала. Тормыш аны шул хәтле әзәрлекли — Анна артка чигенергә теләми, ә алга барырга аңа юллар ябык. Шул хәлдә калгач, дөньяда яшәүнең ни мәгънәсе, ни кызыгы бар?

— Шулай шул,— дип авыр сулады Гөлзадә, аның әйткәннәре белән килешеп.

Фильмнан алган тәэсирләрне уртаклашкач, тагы тын калдылар. Икесенең дә телләренә сүз килмәде. Ара-тирә теге-бу турыда гына сөйләшкәләп бардылар, менә кызлар тулай торагына да килеп җиттеләр. Гөлзадә бик юка киенгән. Аның өстендә җәйге пальто, аякларында туфли генә иде. Һава тагы да салкынайтып, төньяк җиле исә башлаган иде. Василның кызны кочагына алып җылытасы, иркәлисе килсә дә, каядыр еракка яшеренгән бу тойгысы тышка бәреп чыга алмады. Бу саф күңел, бу яз карлыгачы белән бик озак урамда йөрергә теләсә дә, бердән, нигәдер кыенсынып, аннан да бигрәк, кызга салкын тию шигеннән күңеле кушмады. Шуннан соң ул Гөлзадәне тулай торакка кадәр озатып куйды да аңа тыныч йокы теләп китеп барды.

...Аңа йөкләнгән эш никадәр кыен, никадәр җаваплы булмасын — барыбер бөтен вакытыңны эштә генә үткәреп булмый. Эштән соңгы тормыш, гаилә тормышы да бар бит әле. Сине сагынып көткән хатының белән булган тормыш та бар бит әле. Василның андый тормыш иптәше бармы соң? Баштагы ике-өч ел бик күңелле үтте бугай. Ә аннан соң? Аннан соңгысы турында Васил ничек дип тә әйтә алмый. Башлыкүзле булып тора башлагач, дөньяга уртак шатлыклары — уллары тугач та, алар дөньясының түгәрәклегенә зыян килмәде шикелле. Бергә тора башлауның баштагы елларында ук Василга үзенең хезмәте буенча әледән-әле командировкаларга китеп йөрергә туры килде. Аннан соң да аның тынычсыз хезмәте шул ук хәлне таләп итте, шул ук чыгып йөрүләр кабатлана торды. Ир белән хатын бер-берсен күрми торырга дучар булганда нихәтле сагынышалар, йөрәкләре өзелеп бер-берсеннән хат көтәләр, телеграммалар сугалар. Ә менә Васил белән Нурзиләнең уртак тормышлары ничек соң? Үзенә гаилә йөкләгән бурычны искә алмаганда, Нурзилә аны ул хәтле исе-акылы китеп юксынмады, сагынмады кебек. Кешеләрнең бер-берсе белән сөйләшеп сүзләре бетми. Ә аларның? Васил берәр җирдән кайткач, ун-унбиш минутлык сүз була да, аннары һәркайсы үз шөгыле белән мәшгуль. Сөйләшергә сүз табылмый. Мондый чаклар алар тормышында бик еш була. Нурзилә генәме? Васил үзе дә аның өчен дөньясын бик онытмый бугай, ул хәтле янып-өзгәләнеп тормый. Тик аларны уллары Ринат кына бәйли. Әгәр дә ул булмаса, алар бер-берсен ихтирам итәрләр идеме икән? Дөресен әйткәндә, Васил белән Нурзилә бер-берсенә күптәнге танышлар кебегрәк. Танышлар күрешмичә озак тора алган шикелле, алар да бер-берсен озак күрми тора алалар. Аларның соңгы тапкыр аерылуларына менә берничә ай була инде. Дөрес, баштарак Василга кыен иде, аның бәгырен нидер кимерә иде. Ә менә бара-тора күнекте, гадәти бер хәлгә әйләнде

бу. Хәзер инде ул Нурзиләдән башка артык күңелсезләнмәгән кебек, аның белән очрашкач та башы күкләргә тиярлек булып куанмый.

Моңарчы әле аның мондый уй йөртеп караганы юк иде. Менә бүген үзенә ниндидер хөрмәт, ниндидер эчке ялкын сирпеп караган Гөлзадәне кызлар тулай торагы янына илтеп куйгач, аның башында шундый уй-исәпләр туды. Василның йөрәге, күнеле кемнедер эзли, кемнедер юксына, кемнедер гел үз янында күрәсе килә.

Кем ул? Аның Нурзилә белән уртак язмышы нишләр? Киләчәктә алар бергә тора алырлармы? Билгеле, бу катлаулы һәм каршылыклы тормышта бик күп гаиләләр бик күп төрле тормыш кичерәләр. Бер-берсен чын күңелдән яратып торган ир-хатыннар булган кебек, уртак тормышта «танышлар», гаилә тормышының рәвеше саклансын өчен генә торучылар да аз түгелдер. Мондый чакларда балалары булмаганнар эшне коры тоталар, һәркайсы үзе теләгән ярга таба йөзеп китә. Ә бала-чагалары булганнарга мәсьәләне хәл кылу авыррак. Андыйлар күбесенчә түзәләр. Тыштан бер-берсенә якты һәм көләч булырга тырышып та, эчтәгесен яшерәләр.

Ә тормыш дәвам итә. Гомер үтә. Картаялар. Һәм эчләрендәге ялкын, башка ярларга омтылып та, үзләренә юл таба алмаган килеш, бөтенләйгә сүнеп тә кала.

Васил шундый уйлар белән гостиница ишек төбенә килеп җиткәнен сизми дә калды. Үзен сырып алган җәйге чиллә черкиләрен куган шикелле, кулын бер селкеп алды да ишек тоткасын тартты. Вакыт шактый соң булганга гостиница ишеге бикле иде. Ишекне шакырга туры килде.

Васил ачкычны сорауга, юан вахтер хатын, йокы баскан кечкенә күзләрен кулы белән уа-уа, бер дә исе китмичә генә җавап кайтарды:

— Ачкыч миндә түгел.

— Кемдә?

— Хатыныгызда.

— Ә-ә-ә?

— Әйттем ич инде... ихлас менә!

Бу сүзне ишетүгә Василның тез буыннарына кадәр калтырау йөгерде. Йөрәге леп-леп тибә башлады. Ул, ишекне шакып-нитеп тормастан, тиз-тиз атлап бүлмәгә керде. Ашык-пошык кына өстен чишенде дә кочагын җәеп хатыны белән күреште. Нурзилә, аңа калса, әллә ни үзгәрмәгән, тәсе-бите элеккечә көләчлеккә саран, буянган-ясанган булса да, күз төпләрендә күләгәләнеп торган карасу төс күренә, чыраенда шәфкать нурлары да ул хәтле балкып, янып тормый кебек. Ә менә бүлмәдәге тәтен һәм әче ис бөтенләй сизелми, хушбуй исе, пудра исе күңелгә үзенә бер тәчелек биреп торган кебек иде.

Нурзилә дә иренә җентекләп карады. Аны баштан-аяк күзләре белән сөзеп чыкты. Нурзиләгә калса, Васил әллә ни үзгәрмәгән, элеккегә караганда бераз калыная төшкән, бите әллә җилгә, әллә кояшка каралып үз алдына карасу тимгелле булып тора. Ул аның күлмәк якалары карадыр, керледер дип уйлаган иде. Иренең өс-башы чип-чиста икәнен күргәч, бераз гаҗәпләнә һәм көнләшә куйды. Нурзилә, үзе дә сизмәстән, нигәдер иң элек аның керләрен кем ууы турында сорашты. Шушында эшләүче җыештыручы бер хатын юганын белгәч, гасабиланган шикелле, бармакларын өстәлдә биетеп алды. Васил исә Нурзиләдән: «Нигә хәбәр итмичә килеп төштең?» — дип сорамакчы. Ләкин әлегә сабыр итеп торырга булды, кинәт сораса, хатынының ачулану ихтималлыгы уена китерде.

— Килүе бик кыен булмадымы?

— Юк, бер дә кыен булмады. Самолет белән килдем. Аэропортка килеп төшкәч тә, машина очрады,— диде Нурзилә.

— Саулык хәлләрең ничек?

— Зарланырлык түгел. Күрәсең...
— Ринат ничек?
— Исән. Детсадка йөри.
— Аны ник алып килмәдең?
— Салкын тиюдән курыктым.
— Минем хатларны аласыңмы?
— Алам. Сирәк язасың бит...
— Әй син бер дә язмыйсың диярлек. Ике хатка бер җавап та кайтармыйсың,— дип төрттереп куйды Васил.
— Кайтармаса... менә үзем килдем ич,— дип акланырга теләде Нурзилә.
— Йорт-ил, күршеләр саумы?
— Бар да үз урынында.
Ара-тирә бер-берсенә ят, салкын караш ташладылар. Инде урынга яткач, Нурзилә җанын телгән уен әйтмичә түзмәде:
— Нигә бу хәтле соң кайттың, кайда йөрдең?
— Син киләсен белгән булсам, алдан ук кайтып көтеп торган булыр идем,— диде Васил көлеп.
— Әй шулай да кайда йөрдең соң? — диде Нурзилә.
— Кинода булдым.
— Нишләп бик озак?
— Фильм ике серияле иде.
— Анда кем белән булдың?
— Кешеләр белән, зал тулы халык иде.
— Берәрсен тапкансыңдыр әле...
— Әлегә берәүне дә эзләгәнем юк...
— Ирләргә ышансаң... алар барысы да бер чыбыктан сөрелгән.
— Ирләргә дә ышанмагач, кемгә ышанырга соң?
Василның бу соңгы сүзләре җавапсыз калды. Нурзилә, әллә ачуланып, әллә иренең ярым шаяртып әйткән сүзләренә артык игътибар итмичә, тынып калды һәм җылы куллары белән иренең муенныннан кочып алды.
Биш көн вакыт сизелмичә үтеп тә китте. Васил эштән кайту белән гел хатыны янында булды. Нурзиләнең төсе нурланып, яктырып китте. Ул үсеп килүче поселок белән дә танышып өлгерде. Хәзергә монда ул хәтле күңелле түгел түгелен. Шулай да поселокның киләчәге якты, өметле икәне аңа да аңлашыла сыман. Васил да бик күңелле йөрде. Бер көнне ул Нурзиләнең килү хәбәре төзелеш башлыгы Андрей Акимович Никитинга да ишетелгән булуын хатынына сөйләде. Аны шул уңай белән Андрей Акимович үк кабинетына чакыртып сөйләшкәнен, котлаганын һәм яңа йорттан квартир алып тора башларга киңәклеген әйткән икән. Бу хәбәрне әйткәч, Нурзилә, баштагы авыр һәм каршылыклы уйларын онытканшикелле, күңелле талпынып куйды. Һәм һич көтмәгәндә әйтеп ташлады:
— Бирәләр икән, ал квартирны. Мин тиздән отпускыга чыгам. Ялымны синең янда уздырырмын. Аннан тагы күз күрер. Бәлки иянәнеп тә китәрмен сезнең бу җирләргә. Ринатны ничек тә детсадка урнаштырырсың дип беләм.
— Әлбәттә,— диде Васил.
Шулай якын киләчәктә аеры-чаеры килеп йөрү мәшәкатьләреннән арынырга юл ачылыр дип исәпләде Васил. Ләкин ул хатынының башта бик нык каршы килеп тә, кинәт кенә үз янына күчеп торырга риза булуына ул кадәр ярсып шатланмады. Тик, ничек кенә булмасын, гаилә тормышы болай торуга караганда, күп мәртәбә яхшырак буласын күз алдына бик ачык китерде.
Нурзилә юлга чыгар алдыннан гына һавалар кинәт бозылып китте. Күк йөзен каплап алган аксыл көрән болытлар күпергәннән-күперә

бардылар. Башта ишелеп-ишелеп кар яуды. Аннары салкын җил уларга кереште, коточкыч буран күтәрелде. Бу әчпошыргыч һәм күңелсез буран күктән «юеш он» иләп, юлында очраган һәрнәрсәне үзенең ак кырпаклары белән сарды. Шулай итеп, бер басыла төшеп, бер котырынып шактый озак дәвам итте буран. Нурзиләгә самолетка алган билетын кире тапшырырга туры килде.

Төзелештән ерактагы тимер юл станциясендә дә берничә сәгать көтәргә туры килде. Әле поезд төнге унберләр узгач кына килэсе. Залда Василның күзләренә Фарук Фарукшин да чагылды. Аның бер улы шәһәрдә авырып ята икән дип ишеткәне бар иде Василның. Мөгаен, шуны алып кайтырга бара торгандыр. Игнат рөхсәт иткәндер. Әмма Фарук Васил белән килеп күрешмәде. Киресенчә, аннан читтәрәк, кырыйда йөрде. Шабашниклар тамырына балта чабылганнан бирле ул Василга ачулы, аны күрүгә җене котыра иде.

Васил төн урталарында Нурзиләне поездга утыртып, кул болгый-болгый озатып калды. Теге әрсез Фарук та аның хатыны белән бер вагонга утырды.

...Нурзилә озын кылыч борыны астыннан нечкә генә мыек калдырган, бугаз төере һәрвакыт йөреп торган кешенең карашы үзенә төбәлгәнен әллә ничә тапкыр шәйләп алды. Менә бераздан ул аның янындагы буш урынга килеп утырды. Нурзиләгә, күптәнге таныш шикелле, сүз кушарга да өлгерде:

— Казанга барасызмы?

— Юк, аннан да арырак,— дип, теләр-теләмәс кенә җавап кайтарды Нурзилә.

Фарук Фарукшин әрсез күзләре белән Нурзиләгә тагы бер кат сөзеп карап чыкты да сөйләнүен белде:

— Мин дә әле менә калага барам. Бер улымның тумыштан бер аягы кыскарак иде. Шуны озынайттылар. Бер баруымда гипска катырганнар иде. Хәзер килеп алырга тилиграм сукканнар.

— Алай икән,— диде Нурзилә аңа карамыйча гына, сөйләшәсе килмәгәнен сиздерергә тырышып. Ләкин Фарук андый нечкәлекләрне тоя торган бәндә түгел иде. Ул үзенекен итте:

— Васил Закирович җәмәгате буласыз, ахры?

Нурзилә эндәшмәде. Ләкин моңа карап кына Фарук башлаган сүзеннән туктамады:

— Ул бит безнең начальник. Мин дә төзелештә эшлим. Болай ярыйсы начальник. Ну кирәгеннән артык коры тота кайчагында.

Аның сүзләре Нурзиләне сагайта калды. Шунда инде ул, сөйләшергә теләге булмавын да онытып, иренең кешеләргә мөнәсәбәтен бик яхшы белгәнгә, тегеңә җавап бирде:

— Васил Закирович кешеләргә бик турылыклы ул...

Нурзиләнең әйтеп бетерүен көтмәстән, Фарук үзенчә сукалады:

— Юк, ашыкмагыз әле, сеңелем, мин дә аның яманатын сатарга җыенмыйм. Мин болай да бик изгеләрдән түгел, өстәп гөнаһа җыясым килми. Шулай да эштә төрлесе була инде. Аның тоткан урыны бәк олы, зерә дә дәү бит.

Шуның белән бу кеше сүздән туктар, шуның белән башлаган лыгырдавына нокта куяр дип уйлаган иде Нурзилә. Ләкин алай булмады. Фарук дәвам итте:

— Начальство ул бар кешегә дә тигез карамый. Һәр кайсыбызның якыннары булган кебек, аларның да якыннары, үз кешеләре була. Сез инде үз иреегезне миннән ныграк белә торгансыздыр...

— Я, белсә...— Нурзилә тагы иреннәрен турсайтты.

— Бер яктан беләсез, икенче яктан бик белеп тә бетермисез булыр, сеңелем. Васил Закирович та асыл кошларны аякларыннан элэктерә кай чакта...

Кемдер яңагына китереп суккан кебек, Нурзилә чыраен сытып куйды, иреннәреннән калтырау дулкыны тирбәлеп үтте, киемнәре тәнен кыса кебек тоелды:

— Сез ни әйтергә телисез, абзый кеше?

— Ни әйтим, кайбер начальниклар алар хатыннары алдында эт койрыгыннан да төз булып йөриләр, алар юкта... әйе, әһе... типтерәләр.

— Сез Василны да шундый кеше дип уйлыйсызмы?

— Шундый булмаган кая гына әле?! Мин әйткәнне сиздерә күрмәгез, сеңелем, ул монда бик яшь, бик чибәр бер кызны кармагына эләктерде инде.

— Сез ни сөйлисез? Нигә кешегә бер дә юкка пычрак атасыз?

— Атмый гына торсын әле,— дип дәвам итте Фарук.— Үз кул астында эшләүче Гөлзадә дигән кыз белән йөри синең ирең, әйттерәсең килсә. Шуның белән клубларда була, урамда йөри. Үз күзем белән ничә мәртәбә күргәнем бар...

Нурзилә бу кешене артык тыңламады. Поселокка үзе килеп төшкән көнне Василның бик соңга калып кайтуын, аннары тагы бер хатынның вахтер ахирәтенә сөйләгән гайбәтне хәтерләде. Ул чакта вахтерша теге биләмче хатынның Василны кызлар белән шаяра дип сөйләгән сүзләрен гел кире кага торып, имеш-мимешләрне ялганга чыгарып калдырган иде. «Димәк... дөрес сөйләгән икән...» Ә инде бугаз төере йөреп торган Фарук Нурзиләнең эчендә пыскыган шул күмерләрне кабындырып җибәрде.

## 7

Яңа йортка күченгәннәренә байтак вакыт үтте инде. Ләкин Нурзиләдән җавап юк та юк. Югыйсә, башта сөйләшенгәнчә, ул кайтып җиту белән иренә телефоннан шалтыратырга яки телеграмма сугарга тиеш иде. Ләкин Василга бернинди дә хәбәр килмәде, телефон да шалтырамады. Мондый хәбәрсезлек аны борчыганнан борчый бара иде. Инде нишләргә? Ахырында ул Нурзиләне үзе телефонга чакырды. Тик нихәтле көтсә дә, хатыны телефонга килмәде. Телефонистка аны эштә, вакыты юк дип җавап бирде. Аннары Васил Нурзиләнең эшли торган җиренә шалтыратты. Анысында аны эштән китте, өендә булырга тиеш, дип җавап бирделәр. Әмма бу өмет тә үзен акламады, Василга өеннән җавап кайтаручы булмады. Ул, аптырагач, уйлады-уйлады да, Нурзиләгә килергә җыенырга кушып, телеграмма сукты. Аннан җавап килү белән үзенең дә әйбер-әшәнчекләрне китерү өчен тиздән юлга чыгачагын әйтте. Кичтән шул телеграмманы тапшыргач, хәзер инде үзе берничә кич кунган квартирына кайтты. Ике бүлмә, бөтен уңайлыклар бар. Һәммәсе дә өр-яңа, энәдән-җептән генә чыккан яңа кием кебек. Беренче көннәрдә буяу исе борыннарны әчеттерде. Хәтта иртән Василның башы авыртып торды. Ләкин көндәлек эш ыгы-зыгысы белән барлык күңелсезлекләре онытылды. Ә менә эштән кайткач, аның башында тагы күңелсез уйлар айкала башлады. Нурзиләгә ни булды, нигә җавап бирми ул? Васил, өс-башын чишенгәннән соң, аягына йомшак туфлиләр киеп, ишекле-түрле йөренеп алды. Бүлмәләрне, кухняны, ванна бүлмәсен карады. Моннан бер көн элек кенә аның үтенүе буенча юан вахтер апа идәннәрне сөртеп киткән иде. Шуннан бирле Васил идәннең бер тактасына бер генә чүп тә төшермәде. Өй эче гаять чиста һәм җылы. Нурзиләнең тиздән киләчәген һәм шәһәрдәге квартирларыннан әйберләр китерәчәген уйлап, ул әлегә квартирны буш диярлек тота иде. Нибары бер карават, бер өстәл һәм берничә урындыктан башка мебель заты юк иде. Гостиницада монда караганда ничектер күңеллерәк кебек тоелды аңа. Ләкин ул, мондый халәтнең озакка бармаячагын уена китереп, үзен тынычландырырга тырышты.

Иртәгесен бик иртә үзенен шәхси эшләре белән йөрергә исәпләп куйган иде, мәгәр әле теге, әле бу эш чыга торды. Бераздан ул бу турыда бөтенләй онытты. Тик төш авышкач кына хатыны белән сөйләшергә заказ бирергә өлгерде, ул арада телефон шалтырады. Аны партком секретаре Сабиров чакыра иде. Секретарь: «Парткомга бер сугылып чыгыгыз әле»,— дисә дә, Васил анын тавышына ниндидер дулкынлану, ул гына да түгел, калтырау сизенгән кебек булды. Васил, үзе дә ныклап сизмәгән ниндидер эчке борчылу белән, урынында озак утыра алмады.

Бу араларда гына анын Сабиров белән очрашканы юк иде. Күрешкәч, бер-берсенең кулларын шактый кысышып тордылар. Сабиров гадәттәгечә конгырт чәчләрен кыеклап тарап юл ачкан. Нигәдер бу күрүендә анын маңгае тагы да текәләнеп калган сыман тоелды. Һәрвакыт сабыр холыклы бу кеше аны әле дә бик мөлаем каршылады.

— Бер сукмактан йөрсәк тә, сирәк күрешәбез,— диде ул мәгънәле генә елмаеп.

— Шулай туры килә шул,— диде Васил.— Безнен ни... тәүченен эше — тавык та чүпләп бетерерлек түгел. Гел мәшәкать чыгып кына тора.

— Мәшәкатьсез булса, тормышның кызыгы да булмас иде,— диде Сабиров.

Эшләрнен барышы, план-заданиеләрнең үтәлеше турында рәсми төстә сүзләр алышканнан соң, секретарь булачак өмәгә Сафиннар коллективының ничек хәзерләнүе белән кызыксынды. Бу турыда биш-минутлыкларда да телгә алынган, эшчеләр искәртеп куелганнар иде инде. Сабиров төзелештәге иң зур коллективнын сынатмаска тиешлеген тагы бер кат искә төшерде.

— Безнен кешеләр йөзгә кызыллык китермәсләр, оешкан төстә үткәрербез бу мөһим чараны,— диде Васил Сафин.

Сабиров нигәдер кул сәгатенә карап алды һәм тагы карашын Василга юнәлтте.

— Алдагы көннәргә прогноз ничегрәк?

— Һава шартларымы? Көннәрнең аязуы көтелә. Радио шулай хәбәр итә.

— Алай булганда ерып чыгып булыр төсле.

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде Васил.

Сүз су астында калачак әрәмәлекләрне кисү, чистарту турында бара иде. Әллә ничә мең гектар җир биләгән бу әрәмәләр Тын елганың бизәге булып торсалар да, зур сулык аларны читләтеп уза алмый иде. Табигатьне, бигрәк тә үзе туган як табигатен чын күңеле белән яраткан Солтан Сабиров тыштан бик тыныч сыман тоелса да, тирә-якның яме булып торган бу шомыртлыклардан анын һич тә аерыласы килми, әмма зур эшләр моны таләп итә, туган як табигатенең азмы-күпме үзгәрүе котылгысыз бер хәл иде. Солтан моны аңлый, ләкин үзендәге эчке әрнүне бетерә алмый иде. Тын елга буйлары моңарчы ата-баба уеня да китерә алмаганча үзгәрәчәк. Менә хәзер дистәләрчә километрларга сузылган соры бетон ярлар анын күз алдында барлыкка килделәр. Боларга карап куанмый мөмкин түгел. Киләсе язга инде бу бетон ярларны зур сулыкның дулкыннары юачак. Үзенә күрә бер кечкенә диңгез кебек булачак ул! Солтан Сабировның күңеленнән кичкән бу уйлар Васил Сафинга да барып тоташты кебек. Беркадәр вакыт икесе дә сүзсез генә, тын калып утырдылар. Васил бик күп санда кирәк булачак аркылы пычкылар, бер кеше кисешле пычкылар, балталар турында уй йөртте. Бу хакта ул тәэминатчыларга алдан ук задание биргән иде инде. Тик менә ничек үтәлә икән бу күрсәтмә — ул тиклесен тиздән тикшерәсе булыр.

Солтан Сабиров белән Васил Сафинның әледән-әле карашлары очраша, тик әле һаман да төзү идарәсе башлыгы партком секретареның аны ни өчен чакыруын белми һәм аның бу турыда сүз әйтүен көтә иде. Сүз өмә турында гына барса, аны телефон аша да шалтыратып әйтеп була бит. Бераздан соң Сабиров папкадан бер конверт алып, шуны кулында әйләндергәли башлады. Аннары Сабиров, сүзне икенчегә күчереп, Сафинның гаилә хәлләре, теге-бу турыда сорашты.

— Шулай да, хәтсез вакытлар үтеп бара бит инде бу төзелештә эшли башлаганыгызга. Семьягызны ник китертмисез? — дип сорады Сабиров.

Секретарь тарафыннан мондый сорауның биреләчәген күптән көтеп йөри иде Васил. Менә, ниһаять, колаклары ишетте хәзер. Әмма ничек кенә булмасын, Сафинга бу турыда сүз башлау җиңел түгел иде. Инде алдыңа шундый сорау куелгач, җавап бирми мөмкин түгел.

— Минем белән хатын арасында бу турыда бик күптәннән бирле тартыш бара. Башта аны һич ризалатып булмады. Киресенчә: минем үземнең шәһәргә кайтуымны таләп итте. Әле менә күптән түгел генә үзе килеп китте. Ул күчеп килергә риза булды шикелле.

— Димәк, ул килә?

— Килергә тиеш. Шулай сөйләшкән идек. Тик менә нигәдер тынып калды бу арада.

Сабировның төсендәге елмаюы сүрелә барды, чырае җитдиләнде. Алай да гадәти йомшак тавыш белән әйтте:

— Ул килергә җыенмый бугай...

Василның күзләре зур ачылды, төсенә гаҗәпләнү чыкты:

— Сез аны кайдан беләсез? Ул ничек инде, ягъни, килми?

— Шулай. Бездә хатыныгызның жалобасы бар.

— Жалоба?

— Әйе, Васил Закирович. Менә танышыгыз.— Сабиров берничә мәртәбә кулында тотып, куярга урын таба алмаган зәңгәр конвертны Василга сузды.

Әйе, Нурзилә кулы, ул язган. Шакмаклы дәфтәр битенә тигез юллар белән язылган сүзләрне укыгач, Василның маңгаена тир бөртекләре тибеп чыкты. Ул хатны өстәлгә куйгач, түземе җитмичә, тагы бер тапкыр алып карады. Нурзиләнең фикерен төйнәгән шикелле тоелган соңгы сүзләре аны бөтенләй тетрәтеп җибәрде: «...Аның мондый хыянәте беренче тапкыр гына түгел. Шушындый ике йөзле кеше белән киләчәктә нинди семья тормышы булырга мөмкин?!. Минем ирем үз кул астында эшләүче хатын-кызлар белән чуала икән. Ул моның белән хатыны һәм улы алдында җинаять эшләвен аңламый, күрәсең... Менә шуның өчен В. З. Сафинны, коммунист буларак, партия җәзасына тартуыгызны сорыйм».

Ике ирнең, ике коммунистның күзләре тагы очрашты. Васил Сафин секретарь алдында карашын яшермәде, аның үзе шикелле үк туры һәм куркусыз карады.

— Моны ничек аңларга, Васил Закирович? — диде Сабиров.

— Ничек аңлау — ул тиклесе сезнең эш,— диде Васил салкын гына итеп.

Солтан Сабировның Сафинны юлдан язуда һич кенә дә гаеплисе килми иде, билгеле. Ә ничек кенә булмасын, аның өстеннән үз хатыны шундый тешле, каты бәгырьле шикаять язган икән, моны инде, һич югында, ачыкларга кирәк. Шул теләктән чыгып, Сабиров дәвам итте:

— Ә мин сезнең иптәшегезне мактарга да, хурларга да җыенмыйм. Мин аны бөтенләй белмим. Белсәм дә, бәлки моңарга хакым булмас иде сыман. Тик шуларның берсенә дә карамастан, хөрмәтле Васил Закирович, утсыз төтен чыкмый диләр бит...

Васил кайнарланып урыныннан торды, папирос кабызды, тирән итеп сулады да тагын урынына утырды.

— Белмим... Кайчагында аяк астыннан очкан тузан да төтен булып күренергә мөмкин.

— Бу очракта сез шулай дисез инде алайса?

— Әйе, Солтан Сабирович.

— Димәк, сез Гөлзадә белән таныш түгел? Мәдинә?..

— Ничек инде таныш булмаска? Үз кул астымда эшләгән кешеләрне дә белмәскә, андый начальник кем була инде ул?

— Юк, мин ул яктан әйтмим.

— Кайсы яктан әйтәсез?

— Ул кызларның берәрсе белән дим дуслыгыгыз юкмы?

— Мин эшчеләрнең һәркайсы белән дус!

— Ну, чорт возьми, йөрмисезме, куертмыйсызмы, дигән сүзем инде!..— Солтан Сабировның чыраена кызыллык йөгерде.

— Әлегә андый хәл булганы юк,— диде секретарьның үзе кебек үк инде кызара башлаган Васил Сафин.

— Ә киләчәктә?

— Киләчәктәгесен әйтергә мин пәйгамбәр түгел. Гомумән, минем семья мәсьәләсе бик катлаулы... Белмим, Нурзилә күтәргән күсәк кем башына килеп төшәр? Уртак тел таба алырбызмы-юкмы,— ул хәтлесен дә киләчәк күрсәтер,— диде Васил.

Васил Сафин, бер папиросны тартып бетермичә, көл савытына батырып, икенчесен кабызды. Ахырында ул түзмәде, сорады:

— Әллә партком утырышына куеп тикшерәсезме?

Сабиров иңбашларын сикертте, аңа ничектер уңайсыз булып китте. Мондый сорауны көтмәгән иде ул.

— Минемчә, сезне утырышка куеп тикшерерлек бернинди нигез юк безнең кулда,— диде Сабиров.

Секретарьга ихтирамы никадәр зур, аңа карашы никадәр яхшы булуга карамастан, Васил партком бүлмәсеннән авыр тойгы белән чыкты.

Квартирда ялгыз башың гына тору күңелле түгел, әлбәттә. Васил, нихәтле кыен булмасын, түзәргә карар кылды. Нурзиләгә аның ничектер күңеле катты, башкача телефоннан да шалтыратмады, телеграмма сугарга да ашыкмады. Мәгәр, ничек кенә булмасын, барыбер аны күрергә, ныгытып сөйләшергә кирәк иде. Эх, Нурзилә, Нурзилә, нигә шулай әллә кайлардан ишетелгән гайбәт сүзләренә карап эчеңә кара сөрем җыеп йөрергә? Җитмәсә, ирең өстеннән шикаять язу... Монысы инде, йомшак кына итеп әйткәндә, һич тә акылга сыя торган хәл түгел. Шундый кара һәм ялган юлга басканнан соң, ул инде үзенең тормыш иптәше саналган Васил белән ничек сөйләшер, ничек итеп аның күзләренә карый алыр икән?

Аларга бик ныклап аңлашырга кирәк... Ярый әле, җае килеп чыкты. Эш буенча аңа шәһәргә барырга туры килде. Шуннан файдаланып, ул үзенең гаиләсендәге аңлашылмаучанлыкны да төзәтергә тырышыр. Бу юлы инде хезмәт командировкасына китәр алдыннан һич көтмәгәндә аңа хат килеп төште. Нурзиләдән иде бу хат. Ләкин хат Василның күңеленә бернинди дә шатлык салырлык түгел, боз кебек салкын һәм бер үк вакытта мәкерле, агулы иде. «...Миңа карата суынуыңны күптән сизәм. Шулай булмаганда син үзеңнең семьяңнан гел читтә йөрмәс идең. Моңа хәтле дә синең кемнәр беләндер сөберелүең миңа ишетелә торды. Инде соңгысын үз күзләрем белән күрмәсәм дә, шуңарга якынрак дип әйтергә була. Мин килгән көнне генә алыйк. Син төнге уникеләр үткәч кенә «эштән» кайттың. Гөлзадә атлы бер «фәрештә» белән төне буе салкын урамнарны «җылытып» йөргәнсең. Аның янында куныл кайткан чаклары да була икән. Шуның өстенә тагы Мәдинә атлы сәркәң дә бар

икән... Ярый, мин аларның барысын да санап тормыйм инде. Аларны санау һәм намусыңны югалтып йөрү — анысы синең эш.

Ләкин бел: мин дә төшеп калганнардан түгел. Инде эшләр алайга китә икән — мин дә чәчәк кебек вакытымны сиңа алданып үткәрмәм...»

Аларның болай да бик якын булмаган аралары һаман саен еракләша бара иде...

Шәһәргә кичкырын гына килеп төште ул. Менә тагы таныш юллар, таныш сукмаклар, таныш йортлар... Васил үз йортлары тирәсеннән ике-өч тапкыр уратып үтте. Кермәде. Аннары улы Ринат янына — балалар бакчасына кагылырга уйлады. Ләкин сәгатенә карагач, вакытның соң, инде балаларның өйләренә таралган булуларын уена китереп, кире борылды. Ярый әле, бәхетенә каршы, урын тиз табылды — ул шәһәр гостиницаларының берсенә урнашты. Иртәгесен сәгать тугызлар тирәсендә балалар бакчасына улын күрергә килде. Ләкин... Ак халатлы, ике күзе ике төрле: берсе зәңгәр, икенчесе соры күзле, озын нечкә буйлы тәрбияче апа Ринатны инде бишенче көн бакчадан әнисе алганлыгын хәбәр итте. Нурзилә бакчадагыларга чираттагы ялга китәсен, шунда үзе белән бергә улын да аласын әйткән икән.

— Соңга калмадыгыз микән? Хатыныгыз китеп баргандыр инде,— диде тәрбияче ханым, аны юатырга тырышкандай.

Васил, аптырашлы уйлар эчендә, шәһәр урамы буйлап атлады. Бу минутта аның моңарчы булмаганча улын күрү, кулына алып сөю теләге уянды. Ул кайларда икән хәзер? Васил Нурзиләнең усал сүзләре алдында тукталып калмаска, ничек тә улын күрергә исәп тотты. Аңгырайган кеше сыман, бер кызулап, бер әкренләп, таныш подъездның баскычыннан икенче катка менде. Гасабиланып звонокка басты. Ләкин эчтән җавап бирүче булмады, ишек тә ачылмады. Ул шәһәрдә чакта алар Нурзилә белән икесенә ике ачкыч йөртә торганнар иде. Шул гадәте буенча кесәләрен капшап карады. Ләкин кесәсендә кирәкле ачкыч юк иде. Васил кая барырга, нишләргә белми аптырап торганда, күрше квартирның ишеге ачылды. Васил күршеләрен яхшы белми иде. Ә ишек ачкан өлкән яшьләрдәге бу хатын аңа бөтенләй таныш түгел иде.

— Сезгә кем кирәк? — дип сорады әлеге хатын.

— Мин бу квартирның хуҗасы,— диде Васил.

— Күршеләр икәнбез. Без дә әле күптән түгел генә күченеп килдек.— Шундук, Василның аптырашта калганлыгын төсеннән укып белгән кебек, йомшак кына итеп әйтә куйды: — Бу көннәрдә сезнең ишеткән бер дә кереп-чыгып йөрүче күренми.— Хатын, шулай дигәч, ишекне кинәт ачкан кебек, кинәт ябып кереп тә китте. Соңгы баскычны төшеп килгәндә генә аңа таныш бер хатын очрады. Ул Нурзиләнең Кара диңгез буена ял итәргә киткәнен әйтте. Ринатны авылдагы әбиләрендә калдырган булырга тиеш, диде. Васил, башын чайкый-чайкый, коридор ишегеннән чыкты.

Аңа хәзер нишләргә?

Чыннан да туган авылына сугылмыйча булмас.

## 8

Тора-тора да югала — бу нинди кеше була инде?

Бүген өченче көн бугай ул аны һич кенә дә туры китерә алмады. Дөрес, прораб Кукушкинны эшкә чыкмаган дип әйтеп булмый. Аның участогында эшләүчеләр прорабның иртәнге якта кешеләрне тыкырдатып, арлы-бирле сугылып йөрүен һәм ниндидер йомышлар белән китеп баруын әйттеләр. Кичке якта ул тагы үз участогында күренми калмас. Тик менә аны Сафин гына очрата алмый. Нишләргә аңа бу адәм белән?

Васил Сафин инде стеналары салынып беткән гараж һәм төгәлләнү алдында торган ярдәмче биналар тирәсеннән йөреп кайткач, күңелсез уйларга бирелде. Аларның түбәләрен ябарга кирәк иде. Складларда

бернинди материал юк. Нәрсә белән ябарга? Шул турыда көн-төн яныпкөеп кайгыртырга тиеш булган Кукушкинны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый. Дөрес, булмаган материалны бер Кукушкин гына таба алмастыр. Ләкин турыдан-туры үз җаваплылыгындагы бу эш өчен кыл да кыймылдатмыйча кайдадыр югалып йөрү — монысы инде бер дә законга сыя торган эш түгел.

Тәэминатчылар төрле җирләргә чабалар, диспетчерлар төрле җирләргә шалтыраталар — ләкин моңа карап кына барыбер түбә материалы яки газобетон табылмый. Шлакны каяндыр ерактан, бик ерактан китертергә кирәк. Бердән, ул бик кыйммәткә төшә, икенчедән, аны да бик «өзек-өзек кенә» тартып алырга туры килә. Сафин, шул турыда кат-кат кайта-кайта уйлап, электр станциясен промышленность үзәкләреннән бик еракта төзи башлауларына тирәнтен пошынып та куя. Кайсыдыр бер җыелышта бу турыда сүз чыккач, төзелеш башлыгы Никитин бик дөрес әйткән иде әйтүен. «Ул промышленность үзәкләрендә дә кайчандыр безнең шушындагы шикелле берни дә булмаган. Кешеләр тырышлык салганнар. Әкренләп зур заводлар калкып чыккан. Биредә дә озакламый шулай булыр» — дигән иде. Сафин бу хакыйкатькә ышана. Әмма кайчан булыр әле ул? Бары тик иген кырлары, болын һәм әрәмәлекләр булган, язын тургайлар сайраган, кышын бураннар уйнап торган урынны тиз генә шәһәр яки завод төсенә кертеп кара син! Моның өчен мең тапкыр гасабиланырга, мең тапкыр кайнар тир агызырга кирәк әле!

Ә хәзергә шлак, бик күп шлак, бик күп газобетон кирәк аларга. Кукушкин ишеләр белән шлак урынына ком да таба алмасың?!

Кукушкинны ул барыбер дүрт көннән соң гына күрә алды. Анда да иртәнге якта. Прорабльк будкасына керделәр. Анда курнос борынлы, сипкелле учетчы кыздан гайре беркем дә юк иде. Васил Сафин якты йөз күрсәтүне уена да китермәде. Шулай булгач, аның төсендәге кырыслык, ачу билгеләре Кукушкинга да шундук сизелде. Кешеләр белән сөйләшкәндә салпы якка салам кыстыра торган гадәте булган бу кеше, билгеле, Сафинны хөрмәт итү йөзеннән түгел, барыннан да бигрәк үзенең гаебен йомшарту нияте белән, башлыгы сүз кушканчы әйтеп өлгерде:

— Әллә кәеф шәп түгелме, Васил Закирович? Авырып китә күрмәгез тагы...

Кукушкин шулай дигәч, Сафин ирексездән көлеп куйды. Ләкин шундук аның төсенә элекке кырыслыгы, җитдилеге кайтты. Турысын гына әйткәндә, өзгәләп атасы, ботарлап ташлыйсы килде аның Кукушкинны.

— Сезнең ише кешеләр ярдәмчең булганда, авыру гына түгел, үлеп китүең дә гаҗәп түгел...

— Нигә алай дисез, Васил Закирович?

— Молчать! — дип кинәт кычкырып җибәрде Сафин, үз-үзен тыя алмыйча.

— Тыңлыйм, Васил Закирович.— Кукушкин төсенә елмаюмы, гаҗәпләнүме яки куркумы чыккан бер кыяфәттә карашын аска төшерде, ни чектер җыерылып, кечерәеп калган сыман күренде.

— Шундый җаваплы момент, бер кешене ике итәрлек чаклар... Ә сез кайдадыр югалып йөрисез. Намусыгыз кайда сезнең?!

— Намусым үзем белән минем, Васил Закирович, гомергә үзем белән...

— Бармы икән соң ул сездә намус?

— Бик кызмагыз әле.

— Сез кайда югалып йөрисез уттай эш вакытында?

Кукушкин беркадәр ык-мык килеп торды да зәңгәрле-яшелле тавыш белән шулай җавап кайтарды:

— Минем эшкә чыкмаган көнем юк. Ышанмасагыз, эшчеләрдән сорагыз.

— Килеп күренәсез дә кайдыр юкка чыгасыз.

— Материал артыннан, теге-бу йомыш белән чабарга туры килә.

— Теге-бу!.. Именно теге-бу тирәсендә генә чуаласыз.

Кукушкин телен йоткандай тып-тын утыра бирде. Васил Сафин аңа югалып йөрү, гамьсезлек гадәтен ташламаганда, алдагы көннәрдә бергә эшләү кыен булачагын кат-кат кисәтте. Кукушкин еламсыраган мескен бер тавыш белән ялварып тел тибрәтте:

— Беренчесе дә, соңгысы да шушы. Бүтән китеп йөрмәм. Теге-ни... азрак булды инде. Ни әйтсәм дә сез миңа ышанмыйсыз. Югыйсә гел эш артыннан кайгыртып йөргән көнем...

— Сез эчәсезме?

— Бәйрәмнәрдә генә...

— Ышанмыйм.

— Мине исерек килеш кемнең күргәне бар?

— Була шундый кешеләр, аның эчкәнме-эчмәгәнме икәнен аеруы да кыен... Минемчә, сез гел төшереп йөрисез.

— Ике кулымны күкрәгемә куеп, ант итәм, Васил Закирович, мин андыйлардан түгел.

Чыннан да Кукушкинны исерек хәлдә берсенең дә күргәне юк. Үзеннән бер вакытта да аракы исе дә килмәс. Ә менә аның төсендә-чыраенда эчүчеләргә хас билгеләр ярылып ята: борыны кызыл, күз төпләре шешенке, күзләре болганчыграк, йөреше салынкы, куллары калтырый. Сафин аның аз-азлап кына өзлексез эчеп йөрүе турында элек тә ишеткән иде инде. Тик менә югалып торуы... Аш алдыннан гына «аппетитны ачарлык» кына эчә-эчә алкоголик булып киткән адәмнәр азмыни бу дөньяда. Бәлки Кукушкин да шундыйлардандыр... Сафин, бу уйларын эчендә йотып калдырып, катгый төстә кисәтеп әйтте:

— Соңгысы булсын, югыйсә үзегезгә үпкәләрсез.

Кукушкин бик мескенләнеп, урлап май ашаган мәче кебек күзләрен ялтыратып:

— Тыңлыйм сезне, Васил Закирович,— диде.

Сафин алда торган эшләр турында, материал житмәү сәбәпле түбәсе ябылмаган биналар хакында да сүз кузгатты. Шул турыда Кукушкинның фикерен белергә теләде. Бу бит турыдан-туры прораб Кукушкин җаваплылыгындагы объектлар.

— Материал булмагач, без ни эшли алабыз? — дип кулларын җәеп салды Кукушкин.

— Ә материал берничә ай булмый торса?

— Аңлыйм, Васил Закирович. Ләкин без ни эшли алабыз? Бу мәсьәләне Никитин, Юлдашев, сез — башлыклар гына хәл кыла ала, минемчә. Без винтиклар гына димәсәм.

— Һәркем үзенә тапшырылган эштә винтик түгел, чын хуҗа булырга тиеш. Хәзер шулай куела мәсьәлә.

— Аңлыйм, Васил Закирович.

— Аңлау гына җитми. Хәзерге кыен хәлдән чыгу юлын бергәләп уйларга кирәк. Безнең татарларда «Тырышып елаганда сукыр күздән дә яшь чыга» дигән мәкаль бар. Без, бердән, сукыр түгел, икенчедән, безнең мөмкинлекләр бар.

Кукушкин, башын селкеп, риза булган шикелле, тыңлап утыра бирде. Көннәр әкренләп үтә торды. Үзе белән Сафин тозлап-борычлап сөйләшкәннән соң, Кукушкин эш урыныннан китми башлады. Ул гына да түгел, Сафин аның кайчан карама — гел контора тирәсендә уралуын күрә башлады. Ул әле производство бүлегендә утыра, әле бухгалтериядә авыз ерып тора, әле секретарь-машинистка белән сүз куертып, тешләрен агарта. Ахырында Сафин бу хәлгә тыныч кына карый алмады. Кашларын җыерып сүз башлады:

— Сез нишләп һәрвакыт контора тирәсендә чуаласыз?

— Сезгә кирәгем булыр дип уйлыйм, Васил Закирович. Үзегез ачуландыгыз ич. Болай мине эзләп йөрисе булмый...
— Сезнең урыныгыз төзелештә...
— Билгеле, шулай. Алай да һәрвакыт күз алдыгызда буласым килә...
Бер тапкыр Кукушкин тагы баштагыча югалып йөри башлагач, Сафин бөтенләй түземен җуйды. Һәм, аны төзәлмәс кеше санап, эштән чыгару турында приказ язды. Ләкин участок начальникларын, прорабларны эшкә алганда һәм эштән чыгарганда төзелеш идарәсе баш инженерының визасы — килешүе кирәк иде. Кукушкин турындагы приказны Юлдашев расламады. Бу хәлгә Сафинның кәефе китте. Бу уңайдан Юлдашев белән телле-тешле сөйләшү булып алды. Соңрак Юлдашев аңа азмы-күпме теләктәшлек күрсәткән шикелле әйтте:
— Сез аңа шелтә бирегез, әлегә шул житеп торыр. Артык кайнарлану ярамас,— диде.
Кукушкинга өчме-дүртме мәртәбә шелтә бирелүе турында әйткәч, баш инженер тәлинкәнең икенче ягын әйләндерде:
— Минем исемгә рапорт язып бирегез.
Рапортлар Юлдашев өстәле тартмасында ята бирде. Кукушкинга карата берниндн дә чара күрелмәде. Шунда инде Сафин гомуми эш максатларына караганда Юлдашевның шәхси мәнфәгатьләрне өстен күрүен аңлады. Кукушкинның аңа тагылып әллә ничә төзелештә булганын ишеткән иде инде ул. Ләкин бу турыда Никитинга нигәдер белдермәде. Болай итү үзенең тешсезлеген, көчсезлеген күрсәтү булыр кебек тоелды. Ләкин, ничек кенә булмасын, Юлдашев белән аның арасында каршылык үсә барды. Бу нәрсә бигрәк тә төзелешкә кагылышлы зуррак мәсьәләләрне хәл кылганда яки килеп төртелгәндә баш калкыта, үзен күрсәтә башлады. Юлдашевның бик вак мәсьәләләрдә дә «калай әтәчләнеп» күрсәтмә бирүе, зуррак эшләрне хәл кылганда читтән күзәтүче кебек күренүе яки каушап калуы, аннары каршы килүе кебек хәлләр бер булмаса бер күренгәли торды.

Васил улының авылда әниләре кулында калу хәбәре дөреска чыкты. Ул, туган авылына кайтып, улын үзе белән алып китәргә карар кылды. Әнисе карчыкны да үзе белән барырга ризалатты. Шуңа күрә хәзер аның да үз гаилә кисәге бар иде инде.
Ринат яңа урынга бик тиз ияләште. Әтисе эшкә барганда һәр көн аны балалар бакчасына үзе илтә. Уйный, шаяра баралар. Улын бакчада калдырып, үзенең эшкә китүе ничектер күңелле була башлады аңа. Кичке якта инде Васил эштән вакытында кайта алмаганлыктан, малайны алырга бакчага әбисе бара.
Васил уйлавынча, Нурзиләнең отпускысы беткән, ул ялдан кайтып, эшенә керешкән булырга тиеш иде. Шуны күздә тотып, ул хатынына үзләренең тормышлары турында тәфсилле итеп хат салды. Ул аны бигрәк тә уллары өчен борчылыр дип уйлаган иде. Ләкин аның хат салганына атна узса да, унбиш көн узса да, җавап килмәде. Күрәсең, анасы улы турында ул кадәр борчылмый иде булса кирәк.
Йомшак күңелле, басынкы табигатьле әбисенә оныгы көннән-көн иялләшә барды. Илгәзәкләнде. Баштарак әнисен беркадәр юксынган сыман булса да, бара-тора малай бөтенләй тынычланды. Васил гаиләсенең киләчәге турында әледән-әле борчыла, башында шактый күңелсез уйлар туып тора иде.
Василның студент чагында тулай торакта яшәүдән бик нык туйганы бар. Моннан байтак еллар элек, зур шәһәр урамнарыннан узганда, ул: «Эх, кешеләр кебек шундый квартирларда яшисе иде»,— дип йортларда янган утларга карап, кызыгып үтә иде. Мондый хис Яңа Наратлыда да аның күңелендә килә иде. Әнисе һәм улы белән бергә яшәү нихәтле

күнелле, рәхәт булмасын, бу яшь иргә тулы гаилә тормышы барыбер җитми иде. Бу китеклекне ничек бетерергә — әлегә Васил бу сорауга җавап табудан гаҗиз иде.

Эштән кайтып беркадәр ял иткәч, ул тагы үзенең язу өстәле артына утыра. Бу зур төзелештә аны борчыган, аны уйландырган бик күп мәсьәләләр бар. Башындагы төрле авыр исәпләрне әлегә шул эш кенә оныттыра иде.

## 9

Баш инженер үзенең бик пөхтәләп яңартылган иркен кабинетында, үз теле белән әйткәндә, «төзелеш командирларын» җыеп сөйләшүне, киңәшмәләр үткәрүне ешайтып җибәрде. Бүген дә аның эш көне шундый киңәшмә белән башланып китте. Һәрвакыттагыча пөхтә киенгән Юлдашев гадәтенчә кешеләргә сирәк күз йөртә. Зур сөяк кысалы калын күзлеген ара-тирә төзәткәләп куя, аннары, канат астын чистарткан кош кебек, тырнак асларын казыштыргаларга керешә. Аның бу кыланышлары Сафинга ничектер сәер тоелды. Баш инженерның мондый гадәтләренә ул һич кенә дә күнегеп җитә алмый. Юлдашев гадәттәгечә иң элек үзе сөйләде. Аннары башкаларның кыскача информацияләрен тыңлады. Шуннан соң тагы сүз тегермәне аңа күчте. Стена буйларына һәм өстәл тирәсенә утырышкан прораблар, участок башлыкларының Сафинга һәркайсы таныш. Аларның күбесе белән эш максатларыннан чыгып тарткалашканы да, телгә килгәне дә бар. Кешеләр Юлдашев «нотыгын» теләр-теләмәс кенә тыңлап утырганда, төзелеш башлыгы Никитинның килеп керүе байтакларны сагайта һәм бераз каушата калды. Гадәттә ул баш инженер уздыра торган киңәшмәләргә бик сирәк катнаша иде. Никитинга түр яктагы култыксалы йомшак урындыктан урын тәкъдим иттеләр. Ул кергәч, Юлдашевның гадәти тигез аккан тавышында калтырау сизелде. Ул берничә тапкыр тотлыгып та алды шикелле. Никитин, кулын күтәреп, бүленмәскә, киңәшмәне дәвам итәргә кирәклеген аңлатты да, кесәннән дәфтәрен чыгарып, нидер яза башлады. Юлдашев башлаган сүзенең әзенә кайтып төште, ул инде гадәтенчә тыныч сөйли иде.— Социалистик ярыш... Әйе, иптәшләр, безнең төзелештә шактый кыен моментлар бар. Материал булмау яки җитмәү... юлларның промышленность үзәкләреннән ерак булуы зур кыенлыклар тудыра. Ләкин коллективның барлык көчен туплаганда, социалистик ярышны бөтен киңлеге белән җәелдергәндә, һәркем үз эшендә җаваплылык хисен көчәйткәндә, безгә бик күп моментларны шушында, урында хәл кылырга мөмкин, минемчә. Кадрлардан дөрес файдаланырга кирәк, аларны дикъкать белән карап, тәрбияләп үстерергә кирәк. Безнең күп кенә участокларда әнә шул җитми. Ул гынамы соң әле? Кайбер участокларда, хәтта идарәләрдә сыналган эшлекле кадрларны куалар, мыскыл итәләр. Моның мисалларын әллә кайларга барып эзләсе юк. Иптәш Сафин җитәкчелек итә торган төзүмонтаж идарәсен алып карыйк. Анда әле шушы көнгә кадәр безнең алтыннан да кыйммәтле кадрларыбызга дөрес карашның урнашып җиткәне юк. Димәк, безнең күп кенә җитәкче иптәшләрнең үзләренең игътибарлары җитенкерәми...

Баш инженерның чыгышын, аның соңгы сүзләрен тыңлап утыручылардан кемнәрдер җиңелчә генә көлеп тә куйдылар.

Кайсыдыр тавыш салды:

— Төзибез, төзибез, ә биналарның түбәләре ачык килеш тора. Аларга кайчан бүрек кидертербез инде?

Баш инженер бу сорауларга җавап бирмәгәч, кешеләр Васил Сафинга карадылар. Шул дистәләгән карашка буйсынган шикелле, ул урыныннан күтәрелде. Җиңел генә тамак кырып алды.

— Алма, пеш, авызыма төш, дип кенә көтеп ятып булмый,— дип башлады ул.— Минемчә, безнең үзебездә дә кайбер мөмкинлекләр бар.

Әйтик, бүгенге көндәге иң кыен, безне иң тоткарлаган түшәм-түбә ябу мәсьәләләре бик күпләрне борчый. Әмма без барлык мөмкинлекләрдән дә файдаланабызмы соң?

Юлдашев, бу сүзләрне ишетүгә, ашыга-кабалана реплика ташлады:

— Хөрмәтле Васил Закирович, төгәлрәк әйтсәгез икән, ничек һәм нәрсә белән япмакчы буласыз сез түшәм-түбәләрне?

Сафин, фикерен бүлдергәнгә кәефе киткәндәй, беркадәр уйланып торды да өзелгән сүзен ялгап җибәрде:

— Бар андый мөмкинлек бездә! — дип кистереп әйтте ул.

— Нindирәк икән ул? — дип көлемсерәп тагы сүз кыстырды Юлдашев.

Никитин да урынында тыныч кына утыра алмады. Ул, житдилеген саклаган хәлдә, кашларын җыерып, Васил Сафинга карады. Аның бу карашы нидер өмет итә, нидер көтә, нидер сыный кебек иде. Бүтәннәргә ничектер, әмма Василга шулай тоелды.

Васил техник китапханәдән нихәтле журнал, китаплар алды, ничә төн таң әтәчләре кычкырганда гына йокларга ятты. Ниһаять, бу эзләнүләр, бу интегүләрнең бер рәхәте, төзелеш һәм кешеләр өчен бер файдасы да булырга тиеш иде. Эзләгәненең табылуга якын бер хәлдә торганын исендә тотып, Васил дәвам итте:

— Дөньяда термопорит дигән нәрсә бар. Безне бәладән коткарса шул коткарыр. Нәрсә ул дисезме? Менә нәрсә ул...

Баш инженер кабинетындагы житәкче хезмәткәрләр Сафинны күңелле лекция тыңлаган шикелле тыңладылар. Ул үзенең сүзен шулай дип бетерде:

— Нәрсә ул термопорит дип сорыйсызмы? Ул цемент, известь һәм пычкы чүбе катышкан махсус измә. Һич икеләнмичә әйтә алам: безнең шартларда газобетон һәм шлакны алыштырачак ул. Мин әнә шуны куллануырга тәкъдим итәм.

Васил карашын кешеләр өстендә йөртә-йөртә урынына утырды. Кабинетта чебен очкан тавыш ишетерлек тирән бер тынлык урнашты. Юлдашев ашыгып папирос кабызды, авыз-борыныннан мул итеп төтен чыгара-чыгара, башын кашып алды. Сафинга борылып карады:

— Аны кем сынап караган — хикмәт шунда.

— Иң башлап без сынап карасак, ана карап айның бер чите кителмәстер, Зариф Салихович,— диде Сафин.

— Андый рискка барырга безгә кем хокук бирер икән, Васил Закирович?

Юлдашевның бу кисәтүе дә үз уенда нык торган Васил Сафинны туктатып кала алмады:

— Хокук безнең үз кулыбызда, мина калса...

Баш инженерның салынган сукмак буенча әзер юлдан баруын, яңалыкны үзе чыгаруга караганда чыккан яңалыкка, аны бүтәннәр хуплаган сурәттә генә нәрә торган кеше икәнен бергә эшләү дәверендә яхшы төшенеп алды Сафин.

Төзелеш башлыгы Никитин үзе бу киңәшмәдә катнаша бит әле. Баш инженер белән шулай килешә алмыйча килеп терәлгәндә, ул берничә тапкыр инде мәсьәләне уңай якка чишәргә булышты. Шуларны исенә төшереп, Сафин Никитинга карады. Бүлмәдә һава салкынча булуга карамастан, Никитин, кул яулыгы белән маңгаен сөртеп, калын тавышы белән әйтеп куйды:

— Мин экспериментка каршы түгел. Ләкин бу очракта каршы килергә туры килә. Нишлисең! Безнең шартлар шундыйрак. Моны исәпкә алмый булмый. Ләкин күзәнәкле бетон заводы житешкәнче, безгә шлакны Уралдан китерергә генә кала. Инде газобетонны әйткән дә юк, анысын хет җир читеннән кайтарырга да риза.

Шуларны әйтеп, Никитин кулларын җәеп җибәрде. Бу турыда башкача сүз көрәштереп торуның кирәге юк дигән кебек иде бу.

Юлдашев Никитин әйткәннәрне күтәреп алды: «...Яшьлек, романтика, күп мәсьәләләр теориядә ал да гөл булып күренсәләр дә, практикада үзләрен акламыйлар» — янәсе.

Дөньяга, тормышка киңрәк карашлы Никитинның да иң кирәк чакта аны якламавы Василны борчуга төшерде. Инде хәзер нишләргә? Шулай да ул үзен хаклы санап ныклы карарга килде: юк, ярты юлда тукталып калачак түгел ул. Аның фикерләрен яклаучылар да булыр әле...

Бәла аяк астыннан чыгып кына тора. Тәмам интекте Сафин бу Кукушкин дигәннәре белән. Чакырып сөйләшү, куркыту һәм янаулардан, баш инженер исеменә язылган рапортлардан соң, шактый вакыт тәртипле генә йөргән бу кеше, ниһаять, тагы да килеп абынды. Ул тикшереп-күзәтеп тормау аркасында, бер урында стена, проект таләпләрен бозып, ялгыш салынган булып чыкты. Дөрес, стена әллә ни биек күтәрелмәгән иде әле. Шул кимчелек ачылган көнне аны тагы таба алмыйча йөдәп беттеләр. Монысында инде Васил түзеп кала алмады. Кукушкинны эшеннән азат итү турында приказ чыгарды. Берничә көн үткәч, аның урынына икенче кеше алды, үзенең бу адымы турында төзелеш башлыгына аңлатма язды. Телефоннан сөйләшкәндә:— Кукушкин кебек балластлар белән бөтенләй адәм хуры булуың бар,— диде.

Бер атналап кеше күзенә күренми йөргәннән соң, Кукушкин тагы Сафинга килеп ялынды. «Ичмасам производстводан үзе теләп китте» дип язгыз, дип карады. Бу кешегә карата тәмам бәгыре каткан Сафин аның ялваруларын канәгатьләндермәде. Баштагы фикереннән бер карыш та чигенмәде.

Юлдашев, бу турыда ишеткән булса да, мәсьәләне үз бизмәненә салып үлчәгәч, әлегә белмәмешкә салынуны артыграк күрде. Ул тора салып гел юкка чыга барган бер бәндә өчен Сафин белән араны тагы да бозарга теләмәде. Әмма, икенче яктан, Кукушкин кебек кешеләр дә кирәк иде аңа. Ни әйтсәң дә, Кукушкин менә ничә ел инде аның белән бергә, бер юлдан йөри. Күңелсезлекләр була калганда аны вакытында искәртә, үз эшеннән ул бик канәгать, үзе һич югарыга үрмәләмәс, тегене-моны күрмәс, тәнкыйть-мазарны гомеренә читләтеп узар, үзенә тимәсәләр, бүтәннәрдә эше булмас... Кукушкин кебекләрдәге бу сыйфат нигәдер якын, үз иде Юлдашевка. Ул кызу канлы яшь начальнигы тарафыннан җәберсетелгән Кукушкинның үз янына килеп чыгуын көтеп йөрде. Инде тегесе һаман да күренмәгәч, Кукушкинны үзе чакыртты. Берсендә аны Иске Наратлыдан таба алмыйча кайттылар. Икенчесендә: «Хатыны больницада ята, килә алмый, өйдә балалар карап утыра» — диделәр. Алай да ничек булса да булды, бер көнне Кукушкин үзе Юлдашевның эш урынына түгел, квартирына килеп чыкты.

Юлдашев үзе җыйнак язу өстәле артына утырды, кунакны диванга утыртты. Кукушкинның ничек итеп Сафин тарафыннан җәберләнүе турында сүз ачканчы, Юлдашев аның гаилә хәлләрен, саулык-сәламәтлек якларын сораштырды.

— Шундый серьезный эш була торып та нигә күренмәдең? — дип сорады Юлдашев бераздан.

— Кыюсынмадым.

— Димәк, син гаепле?

— Түгел, Зариф Салихович, аңа беркем дә ярый алмас. Бара-тора барлык прорабларны да куып бетерер әле, менә күрерсез...

— Бетерә алмас, аннан да өлкәнрәкләр бар бит әле төзелештә. Аның приказын юкка чыгарып, сине яңадан үз эшеңә кайтарсак, ничек булыр, Кукушкин?

— Юк, юк! Мин аның кул астында эшләргә теләмим.

— Кая куярга соң сине?

Шушы соравыннан соң, Юлдашев Кукушкинны башка җиргә, башка урынга китәр дип уйлаган иде. Ләкин тегесе бу турыда авыз ачарга ашыкмады. Юлдашев башта ук әзерләп куйган соравын исенә төшерде:

— Нигә шундук минем янга килмәдең?

— Сәбәбе булды.

— Нинди сәбәп?

— Марфа авырды.

— Аңа ни булды тагы, бик таза дип сөйләгән идең бит әле.— Юлдашевның, көлемсерәгәнгә, күзләре елтырый башлады. Аны сизепме, сизмичәме, Кукушкин салкын гына әйтте:

— Каһәр суккан хатыннарның шул инде — аборт ясатты...

Юлдашев көлеп куйды:

— Үзең бер дә бала-чага яратмыйсың бугай?

Кукушкин иңбашларын сикертеп алды, болай да кысык күзләрен тагын да кыса төште.

— Юк инде, Зариф Салихович, чәчләрем коелып бетә язса да, әле һаман алимент түләүдән башым котылганы юк. Ходай сакласын, бу дөньяда балаларым болай да җитәрлек.

— Бу хатының белән дә торырга исәбең юкмы әллә?

Кукушкин, мәзәк бер караш ташлап, салкын гына елмайган итте:

— Эш миндә генәмени? Бәлки ул үзе теләмәс. Дөнья хәлен кем белеп бетергән...

Юлдашев авызын зур ачып, ниндидер ят тавыш белән, эчен тота-тота көләргә тотынды.

— Ай, плут, ай, Дон-Жуан...

Көлүеннән туктагач, өстәл тартмасыннан ниндидер кәгазьләр алып караган булды. Аннары җитди бер төс белән янә сүз кушты:

— Сине кая куярга соң? — Шул соравына җавап эзләгән бер кыяфәт белән ул урыныннан торды, арлы-бирле йөренеп килде.— Әлегә сине лабораториягә урнаштырып торыйк. Кем булып диярсең инде син. Урынбасар. Ризамы? Булды.

Васил, үзәк лабораториягә килгәч, Кукушкинны очратуына беркадәр аптырап калды. Ә тегесе, берни булмаган кебек, аны якты чырай белән каршы алды. Хәл-әхвәл сораштырган булды. Аннары, Сафин сорамаса да, үзенең кем булып эшләвен әйтте. Ләкин Василның аның белән сөйләшеп торырлык вакыты юк иде. Моннан берничә көн элек лабораториягә китерелгән термопоритның язмышы кызыксындыра иде аны. Менә аның рецепты буенча ничәнче көн инде сынау бара. Сынауның беренчесе уңышлы чыкмады. Термопорит ныклык ягыннан бик кайтыш иде. Инде менә бу соңгы рецепт, Васил уенча, аңсы һичшиксез яхшы нәтиҗә бирергә тиеш иде. Сары чәчле, сары кашлы хатын нәтиҗәнең иртәнге якта гына билгеле булачагын әйтте. Сафин ишектән чыгып барганда Кукушкин аңа тагы очрады.

— Шулай, Васил Закирович, безнең лабораториягә дә юлны онытып бетермәгез, килгәли торыгыз,— дигән булды.

Сафин, кайтарып әйтергә җавап тапмагандай, иңбашларын гына сикертеп алды, теленә сүз килмәде. «Урындык җылытып утырырга тагы бер кеше өстәлгән икән монда. Шул Юлдашев кулы, шул тарта үз нярченнәрен»,— дип уйлады.

Сафин икенче көнне дә үзәк лабораториягә барды, өченче көнне дә, нәтиҗә әле һаман юк иде. Лаборатория мөдире Касаткинны да очрата алмады. Бары тик дүртенче көнне генә термопоритның бик чыдамлы, производствода кулланырга яраклы булуы турында рәсми белешмә алды. Мәгәр бу соңгы килүендә дә Касаткинны очратмады. Югыйсә үзе-

нең уйларын бик тә уртаклашасы, фикер алышасы, рәхәтләнеп бер сөйләшәсе килгән иде аның.

Төзелештә термопорит бик тиз арада киң кулланыш тапты. Түбәләре ачык яткан зур-зур биналар өстендә күтәрү краннары хәрәкәткә килде. Термопорит ясый торган измә узелында бу көннәрне Васил Сафинны да, Игнат Даниловны да, башка прорабларны да бик еш күреп була иде. Алар, бердән, материалның күбрәк чыгуы белән кызыксынсалар, икенчедән, сыйфат ягын да әледән-әле тикшереп торалар иде. Эшнең иң кайнаган урыннарында икешәр сменага күчү белән канәгатьләнеп калмадылар. Хәтта профсоюз оешмаларын көч-хәл белән күндереп, ял көннәрендә дә эшләделәр. Түбә-түшәмнәрне ябу тәгәлләнгән биналарда эчләрен җиһазлау, монтажлау эшләре берсенен үкчәсенә икенчесе басып, көчәя барды.

Ләкин әле моның белән генә бөтен ачык-тишекләр ямалмый, хәл кыласы байтак мәсьәләләр бар, барсына берьюлы кул җитеп бетми иде. Соңгы көннәрдә Васил Сафин бинасы төзелеп бетеп килгән кислород цехында да күренгәли иде. Шуны күздә тотып булса кирәк, аны контрадан тапмагач, Игнат Данилов кислород цехына килде. Аның үз эшенә кагылышлы кайбер сорасы әйберләре бар икән. Шуларны тиз-тиз генә әйткәч, Игнат башка сүзгә күчте.

— Тәки җиңеп чыкты бит безнең термопорит.

— Барып чыкты, бәреп екты,— дип елмайды Васил Сафин.

— Атна-ун көн эчендә гараж түбәсе дә ябылып бетәчәк,— дип өстәде Игнат.

Васил, бик мөһим йомышы төшеп, Юлдашев янына барды. Секретарь хатын бүлмәсендә баш инженерның кабул итүен көтеп әллә ничә кеше утыра иде. Аңа кимендә бер сәгатьләп көтәргә кирәк булачак. Ул секретарь бүлмәсендә унбиш-егерме минут чамасы көтте дә, сабырлыгы бетеп, коридорга чыкты. Бер як стенада стена газетасы, матур-матур плакатлар, әйбәт-әйбәт карикатуралар. Рәссаме сизгер, хисле булса кирәк, дип уйлады Сафин. Аның күзләре кинәт стена газетасы белән янәшә элengән приказлар тактасына күчте. Әле шушы көннәрдә генә язылган бер приказ өстендә күзләре туктап калды:

«...Үзәк лаборатория хезмәткәрләре ип. Касаткин Ф. И. һәм ип. Кукушкин С. С. тарафыннан тәкъдим ителгән термопорит материалын киләчәктә түбә-түшәм ябуда киң кулланырга. Безнең үз төзелешебездә эшләүче белгечләребезнең бу рационализация тәкъдиме, бу уйлап табулары безгә миллионнарча сум экономия ясарга мөмкинлек бирәчәк. Бу материалны даими рәвештә җитештерүне измә узелының производство планына кертергә.

Уйлап табучы Касаткин, Кукушкин иптәшләрне кыйммәтле рационализаторлык тәкъдиме кертүләре өчен икешәр айлык хезмәт хакы күләмендә акча белән бүләкләргә.

Яңа Наратлы электр станциясе төзелешенең баш инженеры: Юлдашев».

Кайчакта кеше әйбәт кенә барган җиреннән абына да мәтәлеп китә яки күрмичә чокырга барып төшә. Әлеге приказны укыгач Сафин да шундыйрак тойгы кичерде. Ул үз күзләренә ышанмыйча приказны тагы бер кат укып чыкты. Ниһаять, аның каршында хәрефләр сикерә башлаган кебек булды. Ул тиз-тиз генә Юлдашев кабинетына таба китте. Ләкин, бераз атлагач, кире борылды. Хәзер ул аның белән ни сөйләшсен, ничек итеп теге яки бу мәсьәлә турында тыныч кына сөйли алсын?

Юлдашевның бу гаделсезлеге, бу дорфалыгы эштә вакытта да, квартирына кайткач та Василны гел борчып торды. Төрлечә уй йөртеп карады. Бәлки Юлдашев оныткандыр... Бәлки Юлдашевны үзәк лаборатория

хезмәткәрләре алдаганнардыр, Васил тәкъдимен үзләренеке итеп күрсәткәннәрдер. Бәлки... Ләкин, ничек кенә булмасын, лаборатория хезмәткәрләре эше генә түгел бу. Монда бөтен җепнең очы Юлдашев кулында. Тегеләре тик аның кубызына биюче ялагайлар һәм намусларын югалткан бәндәләр генә... карьеристлар... Бәлки Юлдашев үзе дә шундый ук сыек буынлы, вак җанлы кешеләрнең берседер. Аңа инде Василнең ышанычы бик нык какшады. Хәер, төзелештә Юлдашев ялгызы гына түгел бит әле, Никитин бар, Солтанов бар. Аларның кайсына булса да яки икесенә дә тишәр ул мәсьәләне. Аннары кемнең хаклы, кемнең гадел түгел икәнен күрерләр. Һәм тиешле нәтиҗәне дә ясамый калмаслар. Ләкин иң башлап кайсы белән сөйләшергә?

## 10

«Хөрмәтле Зариф Салихович!

Шушы хатым белән Сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым. Дөрес, Сез мине белмисез. Хәзер һәммәсен дә тәртибе белән сөйләп бирергә тырышам. Мин сезнең төзелештә төзү-монтаж идарәсе начальнигы булып эшләүче Сафинның хатыны булам. Дөресрәге, элекке хатыны булам. Ни өчен дисәгез, аның гаебе белән, соңгы вакытларда безнең семья тормышы бозылып китте.

Ул анда, семьялы кеше була торып, әхлакый яктан тотнаксызлык күрсәтә. Хатын-кызлар белән йөри. Бу турыда мин бер тапкыр сезнең парткомга язган идем инде. Аңа кисәтү ясалганмы яки берәр чара күрелгәнме, бу турыда миңа җавап бирүче булмады.

Ярый, бу хәтлесе калып торсын. Мин чираттагы ялымда көньякка киткәндә, аның әнисенә, ягъни миңа кайнана тиешле карчыкка, дүрт яшьлек улыбызны калдырып киткән идем. Билгеле, вакытлыча. Мин өйдә юклыктан файдаланып, Васил Закирович Сафин баланы урлап киткән. Минем әллә ничә тапкыр телефоннан хәбәр итүемә һәм баланы кайтаруны сорап хатлар язуыма карамастан, ул аны кайтармый. Бу эштә миңа ярдәм итүегезне сорыйм. Дөрес, мин эшне халык суды аша да хәл кыла алыр идем. Ләкин суд тикле судка житәсе килми әлегә. Ничектер уңайсыз. Администратор буларак, партком һәм профсоюз оешмасы белән берлектә Сафинга тиешле йогынты ясарсыз, чара күрерсез дип ышанып калам.

Сезне борчуым өчен бик гафу үтенәм. Нишлим? Минем өчен башкача юл юк иде.

Ихтирам белән — Нурзилә Сафина».

Шушы хатны алган көнне Юлдашев әллә нишләбрәк китте. Сафинны чакыртып сөйләшсә, ничектер аның үзенә генә бу мәсьәлә ят сыманрак тоелды.

Икенче көнне Юлдашев бер тапкыр Сафинны үзенең кабинетына чакыртып сөйләшү теләге белән телефон трубкасына да үрелде. Телефонистка кем кирәклеген сорагач, Юлдашев трубканы кире куйды. Аннары гына кискен карарга килде: «Әйдә, «асыл егетнең» кем икәнлеген башкалар да белеп торсыннар әле. Хат аның исеменә адресланган икән, аның төп нөсхәсе анда калырга тиеш...» Зариф Салихович Нурзилә хатының күчермәсен машинкада бастырып, шул ук конверт эченә тыкты. Ул яңадан телефон трубкасын алды:

— Ныклы саулык телим сезгә, Солтан Сабирович. Минем бер йомыш бар иде сездә. Ничек инде, мин барыйммы сезнең янга, сез киләсезме минем кабинетка? Ничек тә ярыймы? Авыр булмаса, бәлки сез...

Менә уңайлы, чиста, пөхтә кабинетта алар икәү генә. «Т» хәрефе рәвешендәге өстәл артында кабинетның хуҗасы, аның каршындагы йомшак урындыкта «кунак» утыра. Юлдашев тәкәллефле бер төстә өстәлгә конверт чыгарып салды. Яшен тизлеге белән Сабировның күз алдына килеп

басты: шундый ук конвертны күптән түгел генә ул үзе дә Васил Сафин алдына чыгарып салган иде. Ләкин Юлдашев, сүзне бу хат турында башламастан, бөтенләй икенче яктан китереп әйтте:

— Так... Язга Тын елга болыннары һәм әрәмәләре су астында калачак дип торабыз инде. Өмәне кайчанрак уздырырга планлаштырабыз, Солтан Сабирович?

Солтан Сабиров бу турыда көндәлек кайгырту алып бара, киләсе атнада өмә уздыру мәсьәләсен профсоюз оешмасы һәм комсомоллар белән сөйләшкән иде инде.

— Киләсе якшәмбегә дип торабыз.

Юлдашев ризалык билгесе күрсәтеп башын иде:

— Бик вакыт, бик дөрес, кичерергә ярамый.

— Әле бит бер өмә уздырып кына агачларны кисеп бетереп булмас. Анда тагы да эш калачак.

Юлдашев җиңелчә генә ютәлләп алды.

— Нигездә киселеп бетәр дип уйлыйк. Команданы шулай бирергә туры килер: барлык кешеләрне, барлык техниканы болынга, әрәмәгә. Ә аерым урыннарда «койрыклар»ны төйнәү өчен кайбер бригадалар чыга торырлар. Ярларны бетонлау да озакка сузылмастыр болай барса.

Юлдашев, каядыр барырга ашыккан шикелле, кул сәгатенә карап алды. Солтан инде баш инженерны шул өмә турында сөйләшү өчен очрашуны кирәк санагандыр дип китәргә җыенганда, Юлдашев аңа зәңгәр конверттан кәгазь чыгарып бирде. Сабиров гадәтенчә ашыкмый гына укып чыкты.

— Ничек? — дип кулларын җәеп салды Юлдашев.

— Таныш кул, таныш почерк бу.

Юлдашев шулайрак әйтүне тиешле тапты:

— Бу инде, бер яктан, әллә ничегрәк килеп чыга. Турыдан-туры производство мәсьәләләренә кагылмый. Шулай булгач, аны тикшерү минем вазифам түгел дә сыман. Ләкин һәр җитәкче работник үзенә буйсынган кешеләр өчен азмы-күпме җаваплы булу сәбәпле, бу хатка мин дә битараф булып кала алмыйм. Сез ничек уйлыйсыз, иптәш секретарь?

— Сезнең бу фикергә каршы килеп булмый, Зариф Салихович.

Юлдашев бер кавым тын калып торды да, фикерен туплап, күрәсең, янә телгә килде:

— Чакыртып сөйләшик, булмаса. Аннары мәсьәләгә тулы ачыклык керер. Хатынын болай мыскылларга күрә торып юл куеп булмый бит инде аңа. Юлдашевның төсенә әче елмаюлы ниндидер зәһәрлек чыкты: — Аның энергияле чагы шул әле, йөри торган чагы... Ләкин җитәкче кешегә тыйнак һәм тотнаклы булырга куша этика. Сафин, күрәсең, шул хакыйкатьне аңлап җитми торгандыр.

— Бу турыда ашыгып нәтиҗә ясарга ярамый, Зариф Салихович. Әлегә чакыртып сөйләшү дә әллә ни бирмәс.

Юлдашев тын калды, ләкин партком секретареның болай гамьсезрәк уй йөртүе аны гаҗәпләндерә иде, бәлки шуңа күрәдер, ул кулларын җәеп салды:

— Бәлки, бюрога куярсыз?

— Иң әлек аның белән мин үзем сөйләшеп карармын. Аннан фикеремне сезгә әйтермен. Ничек тә уртак тел табарбыз.

— Ярый, ярый,— дип килеште Юлдашев.— Ул чагында менә жалобаның бер данәсен рәхим итеп алыгыз.— Юлдашев конвертны үзендә калдырды. Сабиров ана нидер әйтергә уйлап авызын ача башлагач, «Шулай кирәк» — дигән сыман кул хәрәкәтләре белән аңлатты. Солтан аның бу кыланышына гаҗәпләнә калды.

Партком секретаре чыгып киткәч тә тиз генә тынычлана алмады Юлдашев. Зәңгәр конвертны нигәдер тагы әйләндереп-әйләндереп карады.

«...Хатын-кыз турыннан тикшереп караганда, бу тиклесе белән әллә ни алдырып булмас. Әмма бу кешене төзелешкә чакыртып ялгыштым мин. Үземә абынырга үзем киртә салдым түгелме?» — дип уйлады Юлдашев. Эш булгач, билгеле, һәммәсе дә шома гына бармый. Бу тиклесен Юлдашев бик ачык төшенә. Тик менә кирәгеннән артык арттырып җибәрүләр... Юлдашев уйлавынча, Сафинның «бу уйдырмалары» югары начальство каршында үз дәрәҗәсен күтәрү өчен кирәк. Алай гына да түгел, Сафин унае туры килгән саен баш инженерга тиешле вазифаларны үзенә йолкып ала. Бу инде Юлдашев өчен шактый куркынычлык тудыра. Кыю адым, новаторлык, инициатива дигән булып, беренче карашка шаккатырырлык могҗизалар тудырган төсле күренеп, әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән күңелсезлекләргә дучар булырга мөмкин ич. «Бөеклектән көлкегә калуның арасы — бер генә адым» — дигәнме әле Наполеон? Сине сагалап йөргән бәхетсезлеккә үз иркең белән капка ачып булмый бит инде. Ә була калса... Беренче чиратта кемнән сораячаклар, кем җавап тотачак? Ул, Юлдашев. Башкалар исә аның күләгәсенә ышыкланып качып калачаклар. Проект, норма, югарыдан күрсәтмәләр — алар юкка гына бирелми, юкка гына язылмый ич. Инде аларны бозу юлына бассаң, көт тә тор — сине аяз көн көтмәячәк...»

Юлдашев термопорит турындагы тартышны исенә төшерде. Хәзер инде файдасы ачыкланган бу материалга үзәк лабораториядә сынау барган көннәрдә Сафинга сиздерми генә ул гел күзәтеп торды. Мәсьәлә ачыкланып җиткәч тә нигәдер ышанып бетмәде. Касаткинга тагы бер кат бик нечкә һәм ныклы сынау ясарга күрсәтмә бирде. Инде материал производствога яраклы дип табылгач та, ниндидер шик-шөбһәләр аны тагы борчый башлады. Ниһаять, көннәрдән бер көнне аңа Казаннан шалтыраттылар. Яңа Наратлылар үрнәгендә анда да шундый материал кулланалар икән. Бары шуннан соң гына ул термопоритны производствода куллану турында приказ чыгарды.

Кайвакытта шулай була: кояш берничә көн тоташтан күренми-күренми дә кинәт бөтен дөнья яктырып, нурланып китә һәм синең кәеф-рухыңда күтәрелә. Телефоннан Дина шалтыраткач, Зариф Салихович та шундыйрак тойгы кичерде. Бу якты күзләр, бу көр һәм һич кенә дә картаймый торган тавыш, бу кыска, әмма күңелгә бары тик аязлык кына өсти торган сүзләр аны дәррәү яшәртеп җибәрде кебек.

— Мин бүген бер үзем дежурлык итәм.
— Ә иптәш кызың?
— Ул авырый.
— Килми?
— Килми. Вакыт табарсыздыр, шаять.
— Ничәгә?
— Төнге унберләргә...
— Киләм. Көт...
— Сезнең анда беркем дә юкмы?
— Юк. Үзем генә.
— Мин дә.
— Димәк, сүз куештык, Диночка.
— Әйе, хөрмәтлем.

Юлдашев, телефон трубкасын куйгач, иркенләп киерелде, рәхәт итеп сулу алды. Аңа бик тә рәхәт булып калды. Әйтерсең лә, аның бөтен борчулары, бөтен киеренкелеге берьюлы юылып төште, юкка чыккан кебек булды.

Кар тирән түгел әле. Шуңа күрә берәүләр автобусларга төялеп, икенче берәүләр үзләренең мотоцикллары, өченчеләре трактор һәм бульдозерлары белән, кайберәүләр җәяүләп әрәмәгә килеп төштеләр. Кая карама — халык. Күксел карā төстәге әрәмәлек... Агач, ботаклар, әйтерсең лә, ак тәнле Җирнең беленеп торган хисапсыз күп кан тамырлары. Монда түмгәклекләр дә күп очрый. Алар җиргә төшеп калган ак бүрекләрне хәтерләтәләр. Кышкы саран, салкын кояш, бер карaганда болытлар арасына качып, икенче карауда утлы күзен кысып, Тын елга буеның йокыга талган талларын, өянкеләрен, шулар тирәсендә кайнашкан кешеләрне күреп калырга ашыга сыман. Моторлар гөрелтесе һәм пычкы-балта тавышлары якынлашуны тоеп, тынычлыклары качкан саесканнар озын койрыклары белән күк гөмбәзенә нидер язарга теләгәндәй күтәрелеп китәләр. Биредәге көчле шау-шу эчендә аларның тавышы ишетелми, күмелеп кала. Кай ара яхшы ук көчәеп, кай ара тоныкланып дәртле җыр тавышлары яңгырый.

Өмә...

Тәннәр кыза, тамырларда каннар уйный, гомуми дәрт, гомуми ялкын һәммәсеннән өстен, һәммәсеннән куәтле. Киселгән өемнәр арта бара, аларны юл читләренә чыгара торалар. Вак чытырманлыкларны, учарлы куакларын өеп яндыралар. Әз генә дә җил исми, зәңгәр төтен багана-лары, берсен икенчесе узарга теләп, туп-туры һавага үрмәли.

Төзелеш башлыгы Никитин әле бер төркемгә, әле икенчесенә ашыга. Кулларын болгап, салмак кына нидер сөйли. Менә ул Акъярдан килгән кешеләр арасында тукталып кала. Колхоз председателе Нәриманов белән кул биреп күрешә дә өй, каралты-куралары яңа урынга ташылып беткән, бары тик урын-урын агачлыклар һәм ниндидер калкулыклар гына күренеп торган, күченгән Акъярга карашын ташлап сөйләнеп тора. Нәкъ шул чагында алар янына райкомның икенче секретаре Гусев белән Юлдашев та килеп туктый. Шаулашып сөйләшәләр, көлешеп алалар. Озак та үтми, Никитиннар төркеменә Солтан Сабиров, аннан Васил Сафин да бер-бер артлы килеп кушылалар. Председатель төзелеш начальнигына мөрәҗәгать итә:

— Андрей Акимович, безнең хуҗалыкка моннан бик күп утын запасы кала бит. Ачык-тишекне тыгарга шәп була әле бу.

— Нинди утын? Чыбык-чабык кына бит ул,— дип каршы төшә Никитин.

— Юк,— ди Нәриманов елмаеп.— Безнең колхозчылар әнә теге сыртланып торган калкулык тирәсеннән кисәләр. Агачның төрлесе бар анда. Ягардайларын читкәрәк ташып өяргә куштым. Барыбер утын бит. Акча түлисе түгел, ярап куяр шунда.

— Акча түләргә бер дә яратмыйсыз инде сез.

— Ә кем ярата?

— Бу сүздә дә дөреслек бар,— дип көлде Никитин.— Җәмәгать каралтыларын төзеп бетердегезме әле?

Нәриманов — янында басып торган Сафинга мәгънәле генә карап алды.

— Сезнең ярдәмегез белән эшебез бетү алдында тора. Тик көлтә җыясы гына калды да койрыкларны гына төйнисе бар.

— Сезнең көлтә җыясы гына калган. Ә безнең, төзүчеләрнең, орлык чәчү өчен җирләре генә эшкәртелә,— диде Никитин.

— Сезнең бер «урожай» булса шул житкән,— диде Нәриманов.

— Ничек кенә булмасын, эшнең уңышлы баруы хәерле,— дип җавап бирде Никитин.

Аннары сүз үз җае белән бүтән якка тәгәри башлады. Бераздан инде алар төрлесе төрле урынга таралышып та беттеләр. Үзара уртак сүз-

ләре бар, күрәсең, Солтан Сабиров белән Васил Сафинның сукмаклары бергә туры килде. Алар ашыкмыйча гына, кешеләр арасында туктал-галый-тукталгалый, әрәмә үзәнлекләре, болын тигезлекләре буйлап ат-лый бирделәр. Бераздан Васил, кычкырып килгән калын таныш тавыш ишетеп, артка борылып карады. Никитин, Нәриманов, тагы кемнәрдер шактый юан озын агачны күтәреп юл читенә, калкулыкка таба атлый-лар иде. Алар арасында Юлдашев кына күренмәде. Сафин аны-моны уйлап өлгерә алмады, күзе ничектер юлга төште. Такыр юл буйлап, по-селокка таба ана таныш, елкылдап торган кара ыспай машина әлде-репме әлдерә иде. Ул кая китеп барды, кая ашыкты икән?

Сабировның Василга әйтер сүзләре дә бар икән. Аны әлеге дә баягы Юлдашев биргән хат борчый иде. Сабировның бу турыда Юлдашевка да әйтәсе бар иң. Хәзер ачыклык кертәсе мәсьәлә әнә шул иде. Ләкин ул сүзне ничегрәк башлап җибәрергә белми йөдәде. Кешенең хәтерен калдырасы да килми, дорфаланып та хикмәт чыкмый. Алай да бу ту-рыда сүзне башламыйча булмый.

— Ничек соң, Васил Закирович, малай үсәме? — дип сорады Са-биров.

— Үсә. Ничек кенә әле! Көн үсәсен сәгать үсә, атна үсәсен көн үсә...

— Әнисен юксынмыймы?

— Анламыйм. Аның әнисе үлмәгән лә.

— Гафу итегез, ул читтә тора бит. Сагынмыймы дигәнем.

— Сагынса ара ерак түгел иң, рәхим итеп килеп тә чыга ала әнисе. Яки...

Сабиров Нурзиләдән баш инженер Юлдашев исеменә килгән шика-ятьле хат турында искәртте. Моны ишетүгә Васил бик нык әсәренде:

— Юк, мин малайны урлап китмәдем,— диде.— Әни карчык белән икесен туган авылымнан барып алдым. Бу — бер. Тагы... Нурзиләнең миңа хат аша да, телефоннан шалтыратып та берниндн дә хәбәр сал-ганы юк. Ул, киресенчә, качып йөри. Бу — ак эт бәласен кара эткә сыл-тау гына. Ялган!

Васил әйткәннәргә ышанмау мөмкин түгел иде. Шунлыктан Солтан бу турыда сүз куертмады.

Алар Тын елга үзәнлегенә килеп җиттеләр. Каршыда текә яр. Кар-лыгач оялары — санап бетергесез күп тишекләр. Бу тишекләр, бу оялар хәзер ятим калганнар. Кай төшләре беләндер алар хуҗалары читкә китеп, тәрәзәләре такта белән аркылы-торкылы кагылган ятим тәбәнәк өйләрне хәтерләтәләр. Тын елга, үзенең барлыгын да сиздермичә, өсте-нә зәңгәр юрган ябынып, кышкы салкыннардан яшеренгән. Җәйге көннәрдә башларын суга тыгып чайкый торган таллар, өянкеләр рәхим-сез җилләр алдында каушап калганнар да үзара тын гына кинәшәләр кебек. Шул күренешләр алдында хисләре нечкәргән Солтан таралган уйларын җыеп алганчы, Васил тагы дәвам итте:

— Семья турында беркем белән дә уртаклашканым юк минем. Уңышлы булып чыкмады минем семья тормышы...

— Шулай инде, ирләр хатыннарны, хатыннар ирләрне гаепләүчән булалар,— дип сүз кыстырды Солтан.

Васил, аны ишетмәгән бер кыяфәттә, салмак кына үз сүзендә булды:

— Килмәде. Язмый да. Җәкрене төзәйтү авыр икән. Киреләкнең дә бер чиге булырга тиеш инде югыйсә...— Ул соңгы вакытларда хатыны Нурзилә белән ике арада булган хәлләрне сөйләп бирде дә шулай дип төйнәп куйды: — Зарлану түгел бу. Үзенә бертөрле эчне бушату гына...

Бераздан аларның юллары аерылды, икесе ике якка юнәлделәр.

Солтан Сабиров Фиргалине күргәч сорамый түзмәде:

— Теге тәкъдим ни хәлдә?

— Әлегә ул сәнәк белән суга язылган сыманрак.

— Нишләп?

— Шулай. Васил Закирович барлык язуларның ибен китереп Юлдашевка тапшырган. Калганы аның кулында. Әле һаман карамый бугай.

— Ничава, карар, карамый нишләсен. Булырлык эш үзе үк төртеп чыга ул,— дип Фиргалине тынычландырып үтте Солтан.

Бу көннәрдә Фиргали белән Зиннурны пар казаннарын монтажлауга күчергәннәр иде. Фиргали абыйсын очратуга, шуны исенә төшергән Солтан сорый куйды:

— Яңа эшкә күнегеп буламы?

— Бара! Тәгәри! Әмма ликин минем өчен яңа эш түгел ул. Урал якларында әллә ни гомерләр монтажчы булып эшләгәнем бар минем.

— Ә Рафис?

— Яшь бригадирмы? — дип күтәреп алды Фиргали ышанычлы тавыш белән.— Егет грамотный. Абынса булышкалап торырбыз, без дә Каф тавы артында түгел.

Менә Зиннур янына да килеп житте ул. Күп вакытлар партком секретарен үзенең пәһлеван экскаваторы кабинасыннан төшеп каршылый торган бу кеше, пар казаннары монтажлауга күчкәч, аны сирәк күрә иде. Ә бүген һәркайсы ачык һавада, Зиннур бот төбеннән диярлек озын куньчлы киез итек, өстенә жиңелчә генә мех куртка кигән. Хатыны Хәмидә сырган чалбар, сырган пиджактан ничектер калынаеп киткән кебек. Бу озынча битле, тере карашлы, тигез вак тешле хатынны ул күбесенчә өстенә юка гына комбинезон кигән килеш кранда күрергә өйрәнгәнгә, аның бүгенге рәвеше ничектер ят сыман иде. Алар аерым «кишәрлек» алганнар да агачларны кырыпмы кыралар, егыпмы егалар. Күрәсең, бу үзәнлектә, агачлар ышыгында, кар тирәнрәк яткан иде. Зиннурлар янына якынрак килүгә, Солтан тезләре тиңентен карга батты.

— Күп кискәнсез, күп!

— Теләк кенә булсын. Теләк булганда эш чыдыймы соң? — диде Зиннур.

Солтан аларның әле берсенә, әле икенчесенә карап торды. Чыннан да артларында нихәтле киселгән агач. Төптән үк әйбәт итеп, тигез итеп кисәләр. Читтәрәк берничә юан-юан карама ята. Боларын ничек кискәннәр икән? Карама дигәннән, агачның киселгән башына күзе төшүгә, аның үрелеп-үрелеп үскән тыгызлыгын күреп таң калды ул. Шушы карама түмәрен яра алмыйча нихәтле интеккән чаклары булды аның малай чагында. Үтә тыгыз, әйтерсең, тимер жепсәләрдән үрелгән түмәргә чөйләр генә кысылып кала иде. Ярып кара син аны! Солтанның соравын көтмәстән Зиннур әйтә куйды:

— Хәзер, ни, тормыш көйләнә бара. Утын кисеп интегәсе юк. Барысы да әзер. Чыннан да, бик шәп квартир. Бар уңайлыгы да үзендә.

— Күпләр күчәләр андый квартирларга,— дип өстәде Солтан. Берәздән Хәмидәгә карап әйтте: — Сезгә чыкмасагыз да була иде. Бала-чагаларны карыйсы бар ич.

Хәмидә, вак ботакларны бер якка ыргыта-ыргыта, ризасызлык белдерде:

— Мондый көнелле эштән ничек каласың?

— Бүген балалар бакчасы эшләмидер ич. Ял көнне алар белән бергә булу яхшырак инде ул хатын-кыз өчен.

— Варвара әбиләре үзе иртүк килеп алды балаларны. Ял көне життеме — шунда барырга ашкынып торалар. Кесәләренә көнбагыш тутырып кайталар да күрсәтәләр: «Менә әби ни хәтле айбагыр биреп жибәрде»,— диләр.

*(Дәвамы бар)*

**Мөхәммәт Садри**

# КОЯШ КЫЗЛАРЫ

## Алтын көймә дулкыннарны яра...

*Гаиләмә һәм Армиядә хезмәт иткәндә полкта туган кызым Гөлнурга*

Алтын көймә дулкыннарны яра:
Ишкәкләрне каерып ишәбез,
Бала-чага койрык тотып бара,
Гомер юлын бергә кичәбез.

«Хәерчене фәкыйрь тапты» диеп,
Сөйләгәннәр, әйдә, сөйләсен.
Дуслык белән койдык янып-көеп
Яшь гомернен алтын көймәсен.

Син — ягимә, ятим идем мин дә,
Язны күреп карлы юлларда,
Башлы-күзле булдык кышкы көндә,
Язмыш эшен алып кулларга.

Без солдатка киттек туган яктан,
Гади биштәр иде — йөгебез.
Гөлнур туды армияда чакта,
Әти-әни булдык үзебез!

«Полкта бер медсестра артты,
Солдат кызы туды!» — диделәр.
Котлап аны дуслар бер-бер артлы
Котелок һәм кашык бирделәр.

Яшь интендант тынычлыгын җуйды,
(Әйбәт иде яшьлек дусларым):
Биләү өчен өеп-өеп куйды
Юган җәймә, мендәр тышларын.

Чал комиссар әти булды безгә.
Калды дуслар, солдат җырлары:
Казармадан цехка, бистәбезгә
Алып кайтты чуен юллары.

Солдат ашы, солдат боткалары
Безне таза, көчле иттерде.
Ил сакларга дәшкәч Идел яры
Берлингача мине җиткерде.

Тоям тагын илгә кайтып җитеп
Кин Иделдә саф җил искәнен.
Таң кояшы итеп, флаг итеп,
Күтәрдек без тормыш җилкәнен.

Гөлнур үсте,— шаһит Идел яры.
Инженер ул — таный солдатлар.
Җитештерә акыл, ихтыяры
Корыч кошлар, корыч канатлар...

Алтын көймә дулкыннарны яра,
Ел үтәсен айда үтәбез,
Көмеш җилкән әйдәп алып бара,
Гомер юлын бергә кичәбез.

## Ак болытлар, саф болытлар...

Карыйм ап-ак бөдрә болытларга,
Йомшак, нәфис берсе берсеннән,
Зәңгәр таңда охшап аккошларга,
Йөзә алар Идел өстеннән.
Ак болытлар, саф болытлар,—
Таңгы алсу аккошлар,
Сездән дәрман алсын безнең
Тынычлык сөйгән дуслар!
Карыйм ап-ак сихри болытларга,
Биек, яшел Ослан тавыннан,
Алар йөзә ерак-еракларга,
Сәлам алып Идел ярыннан.
Ак болытлар, саф болытлар,
Таңгы алсу аккошлар,
Сездән дәрман алсын безнең
Долорес кебек дуслар!
Идел күгенең зәңгәр һәр ягы да,
Идел үзе зәңгәр күк сыман,
Бетсен иде, бетсен җир шарында
Шомлы болыт, яшен, ут, томан.
Ак болытлар, саф болытлар,
Таңгы алсу аккошлар,
Сезнең аша дәрман алсын
Тынычлык сөйгән дуслар!

## Әҗәлгә дару юк диләр

Казан тимер юлчылар больницасы
терапевты, медицина фәннәре кандидаты
Фәридә ханым Ногмановага

Кайтты машинист өенә
Иркәсе кочагына...
Бүген ул юлда сөенә,
Оча да оча гына...

Таныш локомотив киткән,
Сагынып киткән посты,
Буранлы юллардан үткән
Аның өчен дә дусты.

Җылы җилләр инде көйләр:
Йөрәген, диеп, ару,
Әҗәлгә дару юк, диләр,
Шәп доктор үзе — дару...

Кем соң аңар дәрман бирде,
Әҗәлнең тартышында? —
Күзен ачкач кояш күрде
Үзенең каршысында.

Әйе, кояш!
— Исемегез?
— Фәридә,— диде доктор.
— Нур сипсен һаман йөзегез,
Бүген минем өчен сездән
Кадерле кеше юктыр!..

Кайтты машинист өенә
Иркәсе кочагына...
Бүген дә сафта, сөенә,
Оча да оча гына.

— Кояш күрәм, дөнья күрәм,
Нур ява, чәчәк ява...
Әҗәлгә дәва бар, беләм:
Доктор, сез икән дәва!

Чын йөрәгем хисен биреп
Яшим юлда һәм өйдә...
Кешеләр әҗәлен җиңеп,
Мең яшәгез, Фәридә!

## Әй чәчәкләр, чәчәкләр

Кондитер остасы, инженер-тех-
нолог Люция Лотфуллинага

Әй, чәчәкләр, чәчәкләр...
Танышу минутлары.
Бал аңкыткан чәчәкләр,
Чын мәхәббәт утлары.

Әй, тортлары, тортлары! —
Сүнмәс яшьлек утлары.
Чәчәкләр таныштыра,
Татлы торт кавыштыра.

Һәр чәчәк сина карый,
Лалә, нәркис, кашкарый..
Сезгә дуслык мәкләре,
Кондитер хезмәтләре!

Әй, тортлары, тортлары,
Шикәр белән бал гына,
Вак-вак кисеп ал гына,
Тел очына сал гына.

Телегез булса әче
Йомшартыр сүзегезне,
Яктыртыр йөзегезне
Осталар күчтәнәче!

Әй кызлар — алтын куллар,
Яшь инженер Люция,
Һәр табын сезне зурлап,
Хөрмәт белән баш ия!

## Кайнар хисләр

Ярга якын алма бакчасында
Күңел кайнар хискә күмелде.
Биек таудан зәңгәр Идел аша
Аллы-гөлле киң юл күренде:

Монсу баеп барган алсу кояш
Ярда танып газиз баласын,
Ялгыз булсаң, әйдә, кил, дигәндәй
Идел аша җәйде паласын.

Әйе, ялгыз көтәм сөйгән дусны,
Аның өчен яна хисләрем,
Аны көтеп кошлар җыелдылар,
Роза сибә иң хуш исләрен.

Җем-җем иткән аллы-гөлле палас,
Сихри күпер кебек күренде.
Очар келәм булып тауга менде,
Кояш белән янды, сүрелде.

Кара төндә нидер сөйли суга,
Мүкле ташлар Идел ярында.
Ташка учак ягып төнне куам:
Бәхет кошым балкыр таңымда!

## Китә балыкка яшь егет

Китә балыкка яшь егет
Теплоходка утырып,
Палубада моңа бер кыз
Карый күзен тутырып.

Әллә магниты бар индә,—
Тартып ала үзенә?
Егете дә әйтеп сала
Күзен төбәп күзенә:

— Минем янга күчеп утыр,
Карап күзең талмасын,
Кармагын, Идел дип уйлап,
Егет сиңа салмасын!

Ап-ак тешләр балкып китә:
— Хәтеркәең калмасын,
Өеңә кайтып бер кинәш,
Анаң ачуланмасын!

— Минем әни кояш йөзле,
Болытны да таратыр.
Үземне яраткан кәләш
Әнине дә яратыр.

— Син дә балыкчы икәнсең,
Әллә бергә барыйкмы?
Кармакларны синең белән
Бергәләшеп салыйкмы?!

Егет кучте кыз янына,
Сөйләштеләр. Күнделәр.
Осланда ук төштеләр дә
Ур өстенә менделәр.

Урдә — болынлык, чәчәкләр,
Сулдарак — алмагачлар,
Алмагач тармакларында
Хәл жыя сандугачлар.

Магнитлана бер-берсеннән
Йөрәкләре, күзләре,
Каплый алма бакчаларын
Иделнен энгерләре...

Ике йөрәк тибә бергә!
Балыклар су гизсеннәр.
Яшьләре уйнап йөрсеннәр,
Нәниләре үссеннәр...

Ирен — яшь гомер нектары,
Бал гына ла бал гына...
Үтмәсен иде җәй төне,
Атмасын тиз тан гына!

Кызнын иренен, ак күкрәген
Бизәделәр чәчәкләр.
Венок бүләк итте егет;
Уйнап калды кәлчәкләр.

Юлда да магнит җибәрми,
Кулы — кызнын билендә.
Кайнар кулын кулга алып
Болай диде өендә:

— Әни, менә Гөлчәчәген,
Минем тормыш йолдызым!
— Төкле аякларын белән,
Түргә рәхим ит, кызым!

## Ана сөте

Кем хәтерли икән әнкәсенен
Кайнар күкрәк сөте имгәнен,—
Тана сөте түгел, ана сөте! —
Бетмәс дәрт һәм дәрман биргәнен?!

Мәхәббәтен Ватан-ана өчен
Кайнап торсын өчен канында,
Ана биргән суырып йөрәгеннән
Сөте белән бергә барын да:

Хаят биргән кайнар йөрәгенә,
Миен биргән акыл, аңына,
Якты нурлар биргән күзләренә,
Карар өчен тормыш таңына.

Яшь анамы, әллә чал чәчлеме,
Балам! — диярөзелеп һәрчакта.
Ана сөте сине кеше иткән,
Онытма син, туган, шул хакта.



# *СӘРВӘР ӘДҺӘМОВАГА 70 ЯШЬ*

**Кыл күперләрне үтеп, оҗмахка кергән төслесен,**
**Юлга төштең, зур каршылыкларның үтеп иң көчлесен.**

*Ш. Бабич.*

Күренекле шагыйрь Шәйхзадә Бабич бу шигырен Сәрвәр ханым Әдһәмовага багышлап язган. һәм бу юкка түгел. Сәрвәр ханым үз тормышында сикәлтәле юллар да, кылдай нечкә күперләр дә үткән.

Ул Троицк шәһәрендә туган. 6—7 яшендә үк әнисеннән укырга-язарга өйрәнгән. 1911 елның көзендә Александровское училище дигән өч класслык кызлар мәктәбенә керү бәхетенә ирешкән. 1914 елда шул уку йортын тәмамлап, мактау кәгазе алган.

Яшүсмер чагында ике ел мегаллимәләр йортында да укырга туры килә Сәрвәргә. Анда укучылар язма рәвештә «Яшь көч» исемле журнал чыгаралар. Сәрвәр бу журналда редколлегия члены була. Булачак язучының беренче шигырьләре, мәкаләләре әнә шул журналда теркәлә башлый.

Февраль революциясеннән соң Сәрвәр рус кызлары ярдәмендә гимназиягә әзерләнә һәм май аенда, хосусый имтихан тотып, укырга керә. Шул вакытта Октябрь революциясе тудырган совет мәктәбендә укытучы булып та эшли.

1920 елда Сәрвәр Томскига китә, университетның медицина факультетына керә, уку дәвамында балалар йортында тәрбияче булып та эшли башлый. Биредә эшләү булачак язучыны яңа дөньяга, сабыйлар дөньясына якынайта, ул аларның психологиясен өйрәнә, рухи теләкләре белән кызыксына, алар өчен җан азыгы әзерли. Сәрвәр балалар көче белән спектакльләр куярга уйлый. Тик ул елларда балалар өчен язылган пьесалар булмый. Шуңа күрә тәрбияче бу эшкә үзе тотына. 21—23 елларда балалар йортында эшләгән Сәрвәр «Авыл тормышыннан бер күренеш» пьесасын яза. Тора-бара «Әптерәхим — добрахим» һәм «Хәзер бул» кебек әсәрләр иҗат ителә. Ул әсәрләр Казанда китап булып басылалар.

Ачлык елларында Идел тирәсендәге авыллардан җыелган йөздән артык баланы Казанга озатырга туры килә. 1923 елда Сәрвәр шул балаларны озата килә дә Казанда урнашып кала.

Сәрвәр ханымның укуы һәм хезмәте аның иҗади эшләре белән бергә алып барыла. Аның яшьлек энергиясе барын да күтәрә. 1924 елда күренекле татар язучысы Кави Нәҗми белән тормыш башлагач, аның иҗаты тагын да җанланып китә. Ул классик рус язучыларын тәрҗемә итәргә керешә. 1931 елда Г. Ибраһимов тәкъдиме буенча ул Н. Тихоновның «Сугыш» исемле повестен һәм В. Катаевның «Акча туздыручылар» исемле хикәясен татар теленә тәрҗемә итә. Аның бу хезмәте укучылар алдында уңай бәя ала. Шул ук вакытта ул «Крестьян гәзите», «Кызылармеец» газеталарында актив

катнашып килә. 1932 елдан башлап ул профессионал тәрҗемәче булып китә. М. Горькийның «Балачак», «Малайлыкта», «Минем университетларым» кебек әсәрләре аның тәрҗемәсендә басылып чыгалар, «Фома Гордеев», «Артамоновлар эше» кебек зур әсәрләрен дә Сәрвәр тәрҗемә итә. Гомумән ул М. Горькийның егермедән артык әсәрен татар теленә тәрҗемә итә һәм бу хезмәтләр матбугатта югары бәя алалар. Моннан башка Л. Толстойның татар телендә дөнья күргән «Алпавыт иртәсе», «Балдан соң» һәм «Кавказ әсире» кебек әсәрләренең тәрҗемәсе дә — Сәрвәр ханымның хезмәте. Укучыларга якын таныш булган «Робинзон Крузо»ны һәм чит илләр әдәбиятының тагын берничә үрнәген дә татар укучыларына ул җиткерде. Соңгы елларда М. Әуэзовның «Абай» исемле зур романын Сәрвәр ханым турыдан-туры казакъ теленнән тәрҗемә итте. Кыскасы, бүген 70 еллыгын хөрмәт белән билгеләп үткәндә, без аның бу хезмәтләрен зур горурлык белән искә алабыз.

Сәрвәр ханым Әдһәмова хәзер дә әдәбият бакчасыннан читтә яшәми, матбугат битләрендә аның исемен еш очратабыз. Аның әдәби җыентыгы хәзер нәшриятта басарга әзерләнеп ята. Җәмәгать эшләреннән дә читтә яшәми ул. Язучылар союзы, «Азат хатын» журналы һәм тынычлыкны яклау комитеты каршында оештырылган хикәяләр конкурсында ул жюри члены булып катнаша, яшь каләмнәргә актив ярдәм күрсәтеп килә. Танылган балалар язучысы һәм оста тәрҗемәче Сәрвәр ханым Әдһәмованы 70 еллык бәйрәме белән котлыйбыз һәм аңа тазалык-саулык, иҗади уңышлар теләп калабыз:

Г. БАКИР.

## Сәрвәр Әдһәмова

# НӘФИСӘ АПА

ХИКӘЯ



Нәфисәгә хәзер пенсиягә чыгарга бик вакыт. Бу хакта аңа киңәш бирүчеләр дә булмады түгел. Ләкин яшьтән үк өзлексез эшләп, кеше арасында гомер иткән Нәфисә кинәт кенә шул күнегелгән эшеннән, иптәшләреннән аерылуны берничек тә күз алдына китерә алмый иде әле. Улы Искәндәрне өйләндереп башлы-күзле иткәнче, тагы берәр ел эшләргә иде аның исәбе.

Искәндәр белән рәхәтләнеп сөйләшеп утырырлык та түгел, үтә аз сүзле анысы. Эшеннән кайтып керү белән, радиоалгычны тоташтырып, музыка уйната башлый.

Әнисе:

— Зинһар, шул чаклы акыртма әле. Эштә дә тавыштан колагым тонып бетә бит, улым! — дигәч кенә, радионы бераз акрынайта һәм, аны-моны әйтмичә, үзе ясаган телевизор каршына барып утыра. Берәр күңелле картинаны, спектакльне күрсәтсәләр, Нәфисә апа үзе дә карарга ярата яратуын. Тик футбол белән хоккейны гына аңламый. Искәндәрнең шуларны, авыз суы корып, бот чабып, кычкыра-кычкыра каравына гаҗәпләнә. Ә инде улы китап-журнал алып укырга тотынса,

аңа бер сүзне өч-дүрт тапкыр кабатларга кирәк. Әйтер сүзенне әйтергә аптырап торасың. Иркенләп сөйләшү кайда ул! Ничә әйтсәң дә, ир бала ир бала була икән. Ярый инде, эчеп, азып-тузып йөрми, авыр сүз әйтми. Шунысы зур бәхет. Мәнә өйләнеп тә куйса, Нәфисә апага бер иптәш булыр иде. Кече күңелле, әйбәт кыз күренә Сәлимәсе.

Нәфисә апа, шуларның төрлесен уйлый-уйлый, аш пешереп йөргәндә, ачык чырай белән балкып Сәлимә үзе килеп керде.

— Исәнмесез! Ни хәлләрегез бар?

— Әйбәт кенә әле. Гомерең озын булыр. Хәзер генә сине уйлап тора ием. Түрдән уз, Сәлимә. Берәр сәгатьтән Искәндәр дә кайтып житәр. Аңарчы чәй эчә торырбыз,— дип, Нәфисә апа чәйнеген газга утыртты.

Аннары:

— Әллә, мин әйтәм, яңа йортта фатир өлгергәнне көтмәстән, туй ясап ташлыйбызмы, Сәлимә җаным? — диде ул, икәүләп кара-каршы тәмләп чәй эчәргә утыргач.

Сәлимәнең бит алмалары кызарып китте. Искәндәр белән яратышып йөрүләренә, вәгъдәләшүләренә инде елга якын вакыт үтеп, бу өйдә бөтенләй үз кеше саналса да, булачак кайнанасы туй турында сүз кузгатса, бераз уңайсызлана иде кыз.

— Белмим шул...— дип, кыска гына җавап бирде ул, башын аска игән килеш ашъяулык читен бөтәрләп. Шуннан, берәр минут чамасы дәшми утырганнан соң, кыяр-кыймас:

— Сез дә Хәким абыйга барганда шулай, төрлесен уйлап, икеләнеп йөрдегезме, Нәфисә апа? Ничек таныштыгыз, ничек өйләнештегез сез? Шуны һаман сорыйсым килә...— диде.

— Безме? — Нәфисә, кинәт үзенең яшьлек көннәрен күз алдына китереп булса кирәк, елмаеп куйды.— Китапларда язылган күк кызык булды безнең танышу... Казанга килеп, яңарак эшкә кергән елым ие ул минем. Иялән алмыйм гына бит шәһәргә! Гел авылга күңел тарта. Атна саен диярлек Илһамия апа янына кайтып-килеп йөрим. Әнинең сеңелесе ул. Алмапай дип йөртә ием мин аны. Әни үлгәч, шул апам тәрбияләп үстерде мине.

Бер ял көнне шулай иптәш кызым Сәкинә белән, авылга кайтырга булып, иртүк вокзалга йөгердек. Карасак, поезд китәргә генә тора, билет алып өлгерерлек түгел. «Я, ярар, тикшермәсләр әле!» дип, кердек тә утырдык вагонга. Гөнаһ шомлыгы! Казаннан кузгалып озак та бармадык:

— Сезнең билетыгыз юк бит, сылукайлар, күзегез үк әйтеп тора,— дип, каршыбызга проводник килеп басмасынмы! Ут уйнап торган коңгырт күзле, коңгырт чәчле бу егет үзе сөйкемле генә күренсә дә, штраф түләтмәгәе дип, шүре тунын кидек без. Сәкинә бичара бөтенләй коелып төште. Шулай да мин сер бирмим: «Ник булмасын!» дип, сумкамны актарырга тотындым. И актарам, и актарам. Шабыр тиргә төштем. Башымны күтәреп егеткә карарга куркам үзем. Ахырда ул мине кызганды булса кирәк, хәйләкәр елмаеп:

— Ярар, мәшәкатьләнмәгез. Мин болай да ышанам,— дигән булды, үзе никтер безнең яннан бер дә китәргә ашыкмый. Уң аягын әллә ничек җайсыз итеп, алгарак сузып эскәмиягә утырып алды да: «Кайсы авыллыкылар сез, ерак барасызмы?» — дип сорады. Минем алай күрмәгән-белмәгән егет белән ачылып сөйләшә торган гадәтем юк ие югын. Тик бу проводник тагы билет турында сүз кузгатмагае дип шүрләп, соравын җавапсыз калдыра алмадым. «Шәһәрдә эшлибез. Авылга кунакка гына кайтуыбыз»,— дидем.

Ул арада Коркачык стансасына да барып життек. Проводник егет тә торып, ишеккә таба атлады. Шунда мин аның сизелер-сизелмәс аксавын абайладым. «Хәерле юл!» дип озатып калды ул, без вагоннан төшкәндә.

Нэфисэ апаның сүзен бүлдерүдән куркып, тының да алмый диярлек кызыксынып тыңлап утырган Сәлимә:

— Шул егет Хәким абзый булдымы әллә? — дип соравын үзе дә сизми калды.

— Ие шул! Тик мин аның исемен соңрак белдем. Башта Сәкинә белән без аны «теге аксак» дип кенә йөрттек.

Станса белән авыл арасы алты-җиде чакрым җир. Сәкинә мине юл буе шаяртып барды.

— Теге аксак сиңа күзен шундый тутырып карады, ахирәт, әллә гашыйк булды инде,— ди. Үзе шырык-шырык көлә.

— Китче! — дим, мин әйтәм.

— Юк! Ихластыр менә. Тагы очратсак, син аның башын-күзен әйләндерергә тырыш. Билетсыз йөрербез,— ди.

Сәкинә әйткәнгә түгел, үземнең дә никтер ул егетне янадан күрәсем килеп, күңелем ашкынып барган иçем икенче ялымда, очратмагач, нәүмизләндем. Ә инде аннан соңгы баруыбызда тагы аның вагонына туры килдек. Шунда башланды безнең чынлап танышу. Кара көзгәчә авыл белән ике арада килэп сардым. Ял көне якынлашу белән сабан туй аты шикелле алгысый башлыйм. Атна саен кабаланып вокзалга чабам. Уңсигез яшьлек исәр кыз түгел иçем бит инде ул чакта. Егерме бишкә чыккан иçем. Шулай да башымны җуйдым. Үзем йөгерәм, йөрәгем читлектәге кош төсле лып-лып итә. Очрашып сөйләшкән саен күңелемә якынрак була барды ул егет.

«Айналаен, Нәфисәм!» дип каршы ала башлады бу мине вагон ишеге төбендә. Павлодарда туып үсәнлектән, ара-тирә шулай казакъ сүзләре кыстырып сөйли иде ул. Күзен минем белән бергә авылга бәрәңге казышырга барганда, Алмапай да яратып калды үзен.

— Шуннан? Сөйләгез, сөйләгез, Нәфисә апа! — дип үтенде Сәлимә.

— Шул... Бәрәңге алганда булды бу хәл. Гаҗәп җылы аяз көн иде ул. Була бит кайчак сентябрь азагында шундый көннәр. Без икәү, арулуны белми, уйнап-көлеп эшләдек. Бер мәлне сулу алырга туктаган арада, Хәким миңа текәлеп карап торды-торды да: «Яратам, Нәфисә, синең елмаеп көлүеңне! Бит урталарың шундый матур чокырая! Үзеңне дә яратам никтер. Әллә барасыңмы миңа?» — димәсенме!

Мин, эчемнән сөенүемне сиздермәскә тырышып:

— Китче, мәхәббәтсез! Тузга язмаганны... Я, әйдә, тасма телләнеп торма, эшләвеңне генә бел, күз бәйләнгәнче бетерик,— дигән булдым.

Егетем, берсүз дәшми кинәт күңелсезләнеп, көрәген алып бураэнаны актарырга кереште. Ул казый, мин кәрзингә тутыра барам бәрәңгене. Ара-тирә башымны күтәреп аңа карап торам. Балтасы суга төшкән! Бик кадерле әйберен югалткан кеше төсле. Шул кыяфәтен күргәч, йөрәгем әллә нишләде. Мәхәббәтсез дигән булсам да, күптән күңел түренә кереп утырган иде бит инде ул минем. Аның вагонында йөрүче кызлардан да көнләшә башлаган иçем хәттә. Түзмәдем... Артыннан йөгереп барып кочакладым да, башымны аның иңсәсенә куеп: «Ярый алайса, Хәким. Әйтүең ихлас күңелдән булса, мин риза!» диюемне үзем дә сизми калдым.

Аның йөзе бердәм яктырып китте. Ул, капылт борылып, ике кулымнан тоткан килеш: «Ихлас! Ихлас!» дип, мине зыр-зыр әйләндерергә тотынды. Шул вакыт Алмапай чыгып:

— Әчәч! Нишләвегез бу, сантыйлар? Бәгыйдә әби хәзинәсен таптыгызмы әллә? Аш өлгерде, әйдәгез! — дип чакырмаса, дөньябызны онытыкан иек без. Хәким мине җилтерәтеп Алмапай каршына китереп бастырып: «Таптым, мин таптым ул хәзинәне, менә!» — диде.

Алмапай эшнең нәрсәдә икәнен аңлапмы, аңламыймы:

— Ярый, бик әйбәт! — диде дә кинәт кабаланып:— И аллам, ашым күерә бит! — дип кереп китте.

Без бит-кулларыбызны юып кергәндә анын ашы табында иде инде. (Авылда бәрәнге алган чак үзенә күрә бер бәйрәм була бит!) Алмапайның күнеле бигрәк күтәренке ие ул көнне. Фермадан эштән кайткач, өс-башын алыштырып шундый матур итеп киенгән. Кешелеккә кия торган күлмәк өстеннән бала итәкле кершәндәй ак алъяпкыч бәйләгән. Муенында сары гәрәбә. Ап-ак яулыгын артка чөереп бәйләп куйган. Гомердә илле яшь бирмәссен! Төскә-биткә дә чибәр, уен-көлке сүзне дә бик ярата ие ул.

Уен-көлке сөйләшә-сөйләшә озаклап утырдык без табын янында. Хәким белән икәү ара-тирә бер-беребезгә карап елмаешып куйган булабыз. Икебез генә белгән шатлыгыбыз бар, янәсе. Шулай да ул серне озак сакларга түземебез җитмәде. Чиштек Алмапайга. Ул бездән битәр куанды. Барысын да сөйли китсәң бик озак... Кышын без өйләнештек. Мин, кечкенә сандыгымны, мендәр-юрганымны алып, Хәким бүлмәсенә күчтем. Дус-ишләрне җыеп, кечкенә генә туй да ясаган булдык. Бәтенесен дә әлеге шул Алмапай оештырды инде. «Без кешедән киммени!» дип, суйган казларга чаклы алып килгән ие.

Хәким бик әйбәт кеше булып чыкты. Кулыннан килмәгән эше юк ие. Мин эштә чагында, үзе өйдә көнне ашларга тикле пешереп куя торган ие.

Холкы да бик әйбәт ие үзенең, юкка-барга борчылып бәрелеп-сугылмый, кечкенә генә нәрсәгә дә балалар төсле сөенә белә ие ул мәрхүм. Дөньяда һаман зур шатлык кына булып тормый бит. Кечкенәсенә дә куана белү үзе бер бәхет ул, Сәлимә кызым. Син ничек уйлыйсындыр?

— Бик дөрес әйтәсез, Нәфисә апа. Рәхмәт сезгә! Сезнең сөйләгәннәрне кызыклы кино карагандагы күк күз алдыма китереп тыңлап утырдым. Хәким абыйны да аермачык күргәндәй булдым. Бәхетле яшәгәнсез сез!

— Бик тә инде! Бер генә авыр сүз дә әйтмәде ул миңа. «Хәзинәм!» дип кенә йөртә ие. Беренче балам — Әлфиям үлгәч кенә бик кайгырдым. Тик ул чагында арка терәгем, юанычым Хәким бар ие. Ул исән ие...— дип, тирән көрсенеп, уйга талды Нәфисә апа.

Әле генә балкып торган йөзенә анын кинәт кенә сагыш сарды. Моны күреп Сәлимә дә яңадан сүз башларга кыймады. Ярый әле — Искәндәр кайтып керде.

— Ә-ә, Сәлимә, син биредә икән. Бик әйбәт булды, мин сезгә бармакчы идем. Киногa билет алып кайттым. Сиңа да алдым, әни. Бик кызык комедия. Ашың әзерме? — диде ул өс-башын салган арада.

— Әзер. Әйдәгез утырыгыз. Билет алуыңа рәхмәт. Тик мин барып тормам. Әллә нишләп бик арып торам әле,— дигән булды ул.

Чынлыкта анын күңеле купкан, сөекле кешесе белән үткән көннәр истәлеге күңелендә яңарган, хәзер бер үзе шулар иркендә калып, тулган күңелен юатасы килә иде.— Төчеткән баланым да бар бит әле...

— Әллем өлеш кенәсе,
Балан бәлеш кенәсе.
Иннек сөрткән, миңнәр төрткән
Кемнең җанаш кенәсе,—

дип җырлыйлар иде кайчандыр...

Яшьләр чыгып киттеләр. Нәфисә апа, пешерәсен пешереп, алар кайтуына дип, матурлап табын әзерләп куйганнан соң, караватына барып ятты. Ләкин ятса да, күзенә йокы килмәде. Күңеле белән тагын үзенең яшьлек көннәренә әйләнеп кайтты...

Хәкимнең һәлак булган көне... Ай, ул вакытлар... Йөрәктә төзәлмәс яра калдырган ул көнне әле хәзер дә, егерме елдан артык вакыт узганнан соң да, тыныч кына исенә төшерә алмый иде ул.

1943 елның август ахырында була ул фаҗига. Хәким гадәттәгечә иртәнге биштә үк торып киенә дә, караватында изрәп йоклап яткан нәни улы Искәндәргә бер мәл сокланып карап торганнан соң:

— Айналаен, чырагым! Шундый тәмле йоклый бу тишек борын! Исән-сау гына үсә күрсен. Ярый, мин киттем, җаным! Көнелле хәбәрләр белән каршы ал мине. Тагы нинди шәһәрләрне азат иттеләр икән? Менә кайда ул геройлар! Мин генә йөрим монда сөйрәлеп, юкны бушка аударып,— ди. Шул аягы аркасында үзенең фронтка китә алмавына бик офтана иде ул.

Нәфисә:

— Я, бар инде, эшенә сонга каласың,— дигәч, Хәким:

— Ярый, хуш. Бик сагынсаң, хат салырсың Арча калаларына,— дип җырлый-җырлый чыгып китә.

Бәхетсезлек буласын кешенең күңеле алдан ук сизенә, я ул нинди дә булса берәр хәерсез төш күрә диган булалар. Юк бит! Күңеле дә сизенмәде, төшенә дә кермәде Нәфисәнең. Шул китүдән ире әйләнеп кайтмас, бу аерылышу мәңгегә булыр дигән уй башына да килмәде аның.

Хәким исә, поезды белән Арчага барып, инде Казанга кире китәргә берничә минут калганда гына, күрше юлдагы ике шпал арасында ком белән уйнап утыручы кызчык өстенә ажгырып паровоз килгәнен күрә. Күрә дә, яшендәй атылып, кызчыкны читкә алып ташлый, ә үзе китеп өлгерә алмый. Аны паровоз бәреп үтә.

Көтмәгәндә өстенә тау-таш ишелеп төшкәндәй була Нәфисәнең.

Хәким үлемнән коткарган кызчык Ватан сугышы вакытында Украинадан Арчага килеп урнашкан укытучы Зоя Васильевна Морозованың кызы Нина булып чыга. Кызын җитәкләп, зур венок күтәреп, ул хатын да килә Хәкимне җирләгәндә. Ләкин Нәфисәнең ул көннәрдәге тирән кичерешләрен яхшы аңлап һәм аны юатырдай сүз таба алмаячагын белеп, аңа күренмәскә тырыша. Бердәнбер баласын әҗәл кочагыннан йолып калуы өчен мәрхүмгә күңеленнән чиксез рәхмәт укыганы хәлдә, Хәкимнең фаҗигале үлеме өчен ихтыярсыз үзен гаепле саный ул.

Хәкимен алып кайтып җирләгән көннәрдә Нәфисә, акылдан язган кешедәй, берни күрми дә, аңламый да. Ярый әле, Илһамия апасы, Нәфисәнең эшләгән җиреннән ике атналык отпуска юллап, Искәндәр белән икесен авылга алып китә. Шуннан Нәфисә бераз хәл алып кайта һәм яңадан эшли башлый. Кызу сугыш вакыты, үз кайгыңны кайгыртып утыра торган чак түгел. Искәндәрне Илһамия апасы: «Хәзергә миндә торсын әле. Монда тамагы да туграк булыр. Бәрәңге, сөт, йомырка бар, аллага шөкер»,— дип алып кала.

Ә вакыт үтә дә үтә. Җилле-яңгырлы көз җитә. Аның табанына басып, салкын кыш та килә. Эштә чакта эш белән юангандай булса да, бүлмәсенә кайтып керүгә Нәфисәне кара сагыш томаны чорнап ала. Кайбер көнне ул мичкә дә ягып тормый, ашамый-эчми түшәгенә барып ава. Ләкин, ике смена эшләп, арып кайтуына карамастан, тиз генә йоклап китә алмый интегә. Тик язын, Искәндәрне алып, Илһамия апасы килгәч кенә бераз җан кергәндәй була иде аңа.

Иртәгә май бәйрәме дигән көнне алар өчәүләп зиратка киттеләр. Анда Хәким күмелгән аллеяга керү белән ерактан ук аның кабере янында чүгәләп утырган кара жакетлы, кара яулыклы бер хатынны абайладылар. Якынрак барып карасалар... Кабер өсте шау чәчәк. Ак, кызыл, алсу маргаритлар утыртылган. Хатын үзе Нәфисәләргә аркан утырганлыктан йөзен күрерлек түгел, ә өстенә кыска гына кызыл пальто кигән түгәрәк йөзле биш-алты яшьләрдәге бик сөйкемле кызчык, юл читендә торган чиләктән нәни лейкасы белән чумырып су алып, тырыша-тырыша чәчәкләргә сибеп маташа иде. Бу хәлне күргәч, Нәфисә, ни уйларга да белми аптырап, тораташтай катып калды. Хатын-кызда

була торган ниндидер мәгънәсез бер көнчелек тә кузгалып куйды аның күңелендә.

Шул вакыт теге кызчык, боларны күреп, Искәндәр янына йөгереп килде дә, аны җитәкләп, кулыннан тартты.

— Идем, мальчик! Смотри какие красивые цветочки!

Инде өч яшен тутырып шактый оста тәтелдәргә өйрәнгән Искәндәр, бер дә ятсынып тормыйча, кызчык артыннан атлады:

— Иде, мячик?

Кызчык рәхәтләнеп көлде:

— Не мячик! Это ты — мальчик. Мала-ай.

Хатын аларның сөйләшкән тавышын ишетеп:

— Ни-на-а! Син...— дип нидер әйтмәкче булды, артына борылып караган уңайга, кинәт җинаять өстендә тотылган кешедәй, тәмам югалып, сүзен әйтеп бетерә алмый телдән язды.

Нәфисәне шунда ук таныды ул. Нәфисәгә дә алар турында сөйләгәннәр иде инде. Хатын белән кыз баланы әлегә кадәр күрмәгән булса да, хәзер абайлап алды. Берничә секунд ләм-мим сүз дәшүче булмады. Ниһаять, Зоя Васильевна чүгәләп утырган җиреннән, авыр йөк аркалаган кешедәй, көч-хәл белән аягына басып, юбкасындагы туфракны да сыпырып тормастан, Нәфисәгә таба атлады.

— Алла хакы өчен гафу итегез мине... Барсы өчен дә... Мин сезне яхшы аңлыйм. Шулай да үтенеп сорыйм...— диде дә, күз яшенә буылып, артык сүз әйтә алмый читкәрәк китте.

Нәфисә җавап бирмәде. Кинәт хәлсезләнеп, кабер янындагы эскәмиягә барып утырды. Хәкиме янына килгәндә ул, гадәттә, бөтен дөньядан ваз кичеп, уйланып утыра иде. Бүген шул көтелмәгән очрашу күңел тынычлыгын алды. Янында чүмәшеп утырган Алмапаеның шыпыртлап укыган догасының аерым сүзләре, әллә каян җир астыннан килгән өн төсле булып, колагына чалынып үтте.

Ул арада аллея буйлап бер-берсен куышып арыган Нина белән Искәндәр йөгерешеп килделәр. Зират ни дә, башкасы ни ул сабыйларга! Искәндәр йөгереп килгән уңайга әнисенең тезенә башын төртеп, бөтен гәүдәсе белән аңа сыенды. Нина исә, кинәт туктап, Нәфисәнең каршына баскан килеш, аңа балаларча кызыксынып карап торды да әнисен юксынып як-ягына борылды. Аннары, бер кырыйдарак агачка сөялеп торган Зоя Васильевнаны күргәч:

— Әнием, өйгә кайтыйк инде. Ашыйсы килә,— дип эндәште.

Әнисе урыныннан кузгалды.

— Хәзер кайтабыз, кызым. Чиләк белән лейканны ал әле. Хуш, сау булыгыз! — Монсы Нәфисәләргә әйтелгән сүз иде.

Искәндәр күз кырые белән бөтенесен күзәтеп торган икән. Нина кулына лейкасын алуга, уктай атылып барып аның чабуына ябышты.

— Китмә! Нәнәү!

Һәм Нина ычкынып киткәч, малай, бер әнисенә, бер Алмапасына карап:

— Китмәсен! Безгә барсын! — дип ялынып, җыларга ук тотынды.

Илһамия апасы да:

— Чыннан да апкайтып ашатып-эчертикме әллә үзләрен, Нәфисә җаным? Өйләренә кичсез кайтып җитә алмыйлар бит әле. Әйдә, шулай итик! Бер савап булыр,— дигәч, Нәфисә, бу тәкъдимне бик үк өнәп бетермәсә дә, апасының сүзен җиргә салырга кыймады.

— Ярар булмаса. Барсалар... Син аларны апкайта тор. Мин бераз утырам әле монда,— диде.

Илһамия, бердән, Нәфисәнең теле ачылуына, икенчедән, өйгә кунак алып кайтасына куанып:

— Искәндәр! Бар, улым! Артларыннан куып җитә тор тегеләрнең,— дип, малайны алдан йөгертте дә:— Шул тикле җирдән килгән кешене

бер самовар чәй дә эчерми җибәрергә! Булмаганны! — дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, кызу-кызу атлап китте.

Инде капка төбенә барып житкән Зоя Васильевна, Искәндәрнең нәрсә әйтергә теләвен аңлап житкерми, аптырап тора иде. Илһамия апа, авыр сулап, аның беләгеннән тотып алды да:

— Ты Арчадан утром поез ехал? Дибочка кушайт хатил, берно[1],— дип сорады, һәм Зоя Васильевна ихтыярсыз көлемсерәп:

— Әйе, апа! — дигәч, карчык бөтенләй эреп китте.

— Кара син аны! Мөселманча да сөйләшә беләсеңмени, рәхмәт яугыры?

Инде өч елга якын Арчада яшәп, татар мәктәбендә рус теле укыткан Зоя Васильевнаның татар сүзләрен байтак белүе болай караганда табигый булса да, Илһамия апа өчен көтелмәгән бер нәрсә иде.

Шулай итеп, аларга тылмач кирәк булмады.

Нәфисәләргә баруны Зоя Васильевна бик үк килештереп тә бетермәгән иде, уңайсызланып торды. Ләкин кызының ач булуын, кибетләрдә карточкасыз ашамлык әйбере табу мөшкел икәнлеген исәпләп, ахырында риза булды. Кеше өчен жанын ярып бирергә әзер торган изге күңелле Илһамия апа да:

— Юк, юк! Китмисез! Ризык ташлап! Бәйрәм ашларын авыз итми җибәрмим...— дип, ай-ваена куймады.

Трамвайда юл буе сөйләшеп кайттылар. Зоя Васильевна шуннан бер ай элек кенә иренең сугышта һәлак булуы турында кара хәбәр алганлыгын әйткәч, карчык аны чын күңелдән кызганып:

— И, Зуя! Бичаракаем! — дип, аркасыннан сөеп куйды.

Нәфисә кайтып кергәндә, Нина белән Искәндәр, бәрәңге пәрәмәче ашый-ашый, идәндә уенчыклар белән уйнап утыралар, Зоя Васильевна, терсәкләре белән урындык аркасына таянган килеш, балаларга карап тирән уйга чумган, Илһамия апа, бик кәефләнеп, тыз-быз чәй әзерләп йөри иде.

Табын янында шактый озак утырдылар. Белер-белмәс теле белән Илһамия апа сөйләште инде күбрәк. Нәфисә дә, артык ачылып китмәсә дә, кунакчыл булырга, караңгы чырай күрсәтмәскә тырышты. Зоя Васильевна китәргә җыенгач та, аңа мәнесез булып күренмәс өчен генә:

— Тагы килегез. Шәһәргә килгәндә кереп чыгыгыз,— диде.

Илһамия апа исә, кунакны капка төбенә чаклы озата чыгып:

— Миңа кунак булып кил, Зуя! — диде.

Күңеле тәмам тулышкан Зоя Васильевна:

— Рәхмәт сезгә, апа! Әниемне күргәндәй булдым. Шундый ялгыз бит мин! Бер үзем! Менә шул кызым гына, дип, карчыкны кочаклап, битеннән үпте.

Андый нечкәлекләргә өйрәнмәгән Илһамия апа аптырап калды.

— Што син! Што син!

Ул өйгә кергәндә, Нәфисә, тәрәзә янагына сөялеп, урамга карап тора, Искәндәр тәрәзә төбенә үк менеп утырган иде.

Әнә, кызын житәкләп, башын аска игән килеш акрын гына атлап килгән Зоя Васильевна күренде. Нина, чуар күбәләк рәсеме ясалган зәңгәр лейкасын селки-селки, сикергәләп килә. Аның кара чәчендәге алсу бантигы тере күбәләк төсле селкенә иде.

Аларны күргә, Искәндәр:

— Нәнә-әү! — дип кычкырып, бармагы белән тәрәзә пыяласына суккалап куйды.

Кызчык, гаҗәпләнгән сыман күзләрен зур ачып, тәрәзәгә күтәрелеп караган җиреннән Искәндәрне шәйләп, елмаеп кул болгады.

---

[1] Син Арчадан иртәнге поезд белән килдеңме? Кызның ашыйсы килгәндер.

Шунда гына Нәфисә кызның зәңгәр күзләрен абайлап алды. Аңарчы баланың йөзенә туры карый алмаган, аны маңгай күзе күрсә дә, күңел күзе күрмәгән иде.

Кинәт: «Гомеренең соңгы минутында Хәкимне күргән күзләр ләбаса бу!» дигән уй килде аның башына. Һәм ул күңелендә шул кызчыкка карата ниндидер бер җылылык тойгандай булды.

Йөрәк таш түгел. Вакыт үтү белән акрынлап Нәфисәнең йөрәгендәге боз да эреде. Бара-тора ул Зоя Васильевнаны хәтта якын күрә башлады. Ике тол хатынның уртак язмышы да шулай якынайткандыр, бәлки. Алмапасының тырышуы да кечкенә булмагандыр, билгеле. Җәй көне ул Арчага үзе барып, Зоя Васильевнаны эзләп тапты, Нина белән икесен авылына алып кайтып айга якын кунак итте. Искәндәр белән Нина уеннан туймадылар. Зоя Васильевнаның исә кул кушырып тик утырасы килмәде, Илһамия апаның бакча эшләренә булышты. Аңардан йон эрләргә, бәйләргә өйрәнеп, Искәндәр белән Нинага оек башлары, бияләйләр бәйләде.

Сугыш беткәч, Украинадагы туганнары Зоя Васильевнаны кире чакыртып алдылар. Шул көннән аерылган бу семья, барышып-күрешеп йөрмәсәләр дә, һаман хат алышып, хәбәрләшеп торалар иде әле. Хәер, хатларны хәзер күбрәк Нина яза. Ул инде педагогия институтын бетереп, әнисе төсле укытучы булган. Бик акыллы бер егеткә кияүгә чыгып, тормыш корып җибәргән. Үткән атнада килгән хатында, бик шатланып:

«...Ул таптым, Нәфисә апа! Саша белән икәү уйладык-уйладык та исемен Искәндәр дип кушарга булдык. Сез ачуланмассыздыр бит? Сашаның әнисе дә бик яратты ул исемне. Кай ягы беләндер Алмапайга охшатам мин аның әнисен. Бик әйбәт, киң күңелле карчык. Алмапайны, сезне һаман сагынып искә алам. Без хәзер Молдавиядә торабыз. Бик матур җирдә. Әни дә безнең белән яши. Ул олыгайды инде, сәламәтлеге дә какшау. Сезгә сәлам әйтте, кунак булып килегез, Нәфисә апа. Әнинең дә бик күрәсе килә»,— дип язган иде.

Кечкенә вакытында Искәндәр әйткәнчә, өйдәгеләрнең барсы да Нинаны «Нәнәү» дип йөриләр иде. Нәфисә апа да борчылып:

— Нәнәүнең соңгы хатына җавап язганым юк бит әле, бәбәй күчтәнәчләре дә җибәрергә иде үзенә, балалар кайткач әйтергә кирәк әле,— дип уйлап куйды.

Хатынның узган гомере бөтен шатлыклары, кайгылары белән күз алдыннан кичте бу кичтә. Уйлары аның станогындагы җепләр төсле тигез генә сузылып кызулап баралар-баралар да кинәт өзелеп куялар. Аларны тагын төйнәп, очын очка тоташтырып җибәрергә туры килә. Менә ул йөгерек уйлар, бер-берсенә ялганып очсыз-кырыйсыз бара торгач, ничектер сизелми генә киләчәккә күчтеләр: «Чыннан да, дус-ишләрнең киңәшенә колак салырга туры килер, ахры. Ялга чыгар вакыт житкән, бик житкән. Язга яңа йорт өлгерә, ди. Анда күчену мәшәкате дә булыр әле. Искәндәрнең туен да иркенләп үткәрермен. Беренче пенсиямне алгач, авылда, карчыклар җыеп, аш уздырырмын. Алмапайның кордашларыннан бер-икесе исән бит әле. Нәнәү дә хат саен диярлек чакырып яза. Барып, Зоя Васильевна белән дә күрешеп кайтырга кирәк. Нәни Искәндәрне дә сөеп кайтырмын, үзебезнен бала-чага булганчы. Искәндәр...»

Шунда аның уйлары тагын өзелде. Нәфисә апаның инде аларны ялгап җибәрерлеге калмаган. Ул тәмле йокыга талган иде.

Рафаэль Мостафин

# «ОҖМАХ»КА СӘЯХӘТ[1]

## Һинд океанын кичәбез




Капитан, Советлар иленең вәкаләтле кешесе буларак, чит ил вәкилләре белән сөйләшүләр алып барырга, туган һәм үлгән кешеләрне теркәргә, әгәр кирәк дип тапса, хәтта корабтагы теләсә кемне кулга алырга да хокуклы. Диңгездә йөзү турындагы Кодекста әйтелгәнчә, капитанның боерыкларына экипаж членнары гына түгел, ә пассажирлар һәм корабта булган башка кешеләр дә (хәтта ул кешеләр хезмәт урыны һәм дәрәҗәләре белән капитаннан өстен булсалар да) берсүзсез буйсынырга тиеш.

Четерекле һәм аеруча җаваплы очракларда капитан кораб советын җыеп киңәшә ала. Ләкин капитан азчылык ягында калса да, хәтта кораб советы аңа каршы булса да, барыбер аның сүзе үз көчендә кала. Кодекста бу турыда: соңгы карарны чыгару хокукы бары тик капитанга гына бирелгән,— дип әйтелә.

---

[1] Ахыры. Башы 2—3 саннарда.

Нәрсә бу? Ирекне кысумы? Юк. Гасырлар буенча килгән тәҗрибә күрсәтүенчә, диңгез шартларында шунсыз мөмкин түгел. Әгәр дә капитан һәр кыенлык саен җыелыш һәм киңәшмәләр үткәреп тора башласа, җаваплылыкны башкалар җилкәсенә аударып калдырырга тырышса, бу, әлбәттә, юньлегә алып бармас иде.

Кораб бата-нитә калганда аннан иң соңгы кеше булып капитан китәргә тиеш. Элек мин моны диңгезчеләр тормышындагы язылмаган закон дип уйлый идем. Хәзер инде аның диңгездә йөзү турындагы Кодексның аерым бер пункты булып торуын белдем.

Мин Роман Александровичның кешеләр белән ничек эшләвен күзәтәм. Ул үз кулы астындагы кешеләрнең шәхси эшләренә катнашмаска тырыша, аларга ышана. Корабтагы тормыш бер көйгә генә барганда капитанның бар икәнлеге сизелми дә: вахталар үз вакытында алышына, ремонт эшләре билгеле бер тәртип белән алып барыла, судно двигателе сәгать механизмы кебек төгәл эшли. Роман Александрович күперчеккә әллә нигә бер генә күтәрелә, узылган һәм узасы юлны билгели, һәм аңа сораулар булмаса, кают-компаниягә төшеп китә яки үз каютасына юнәлә. Ул үз кул астындагыларның инициативасын сүндермәскә тырыша.

Кечкенә генә бер мисал. Профсоюз җыелышларының берсендә баш ярдәмченең азык-төлекне «кысып яткыруы» турында сүз кузгалды. Кешеләр иртәнге ашларның бертөрле һәм аз калорияле була баруы, консервланган колбаса банкаларыннан киштәләрнең сынарга торуларына карамастан, баш ярдәмченең аларны менюга кертергә рөхсәт итмәве турында сөйләделәр. Баш ярдәмче корабта капитаннан кала икенче кеше, ул бөтен хуҗалык эшләре өчен җавап бирә. Мин Роман Александрович нишләр икән дип көттем: үзенең ярдәмчесен якларлмы, әллә аны бу эш өчен тиргәрме? Ләкин капитан иңбашларын гына җыерып куйды. Бу турыда нигә миңа әйтәсез, янәсе. Бездә әнә судком бар, менюны төзегәндә һәм аш бүлгәндә катнашырга тиешле махсус комиссия бар. Әнә шуларның эше турында мәсьәлә күтәрергә кирәк...

Чыннан да, җыелыштан соң бу комиссиянең эше җанланып китте. Миңа комиссия утырышларының берсендә катнашырга туры килде. Шунда баш ярдәмченең азык-төлекне нигә «кысып ятуы» ачыкланды: әле бит юлның икенче яртысы ничек буласы билгеле түгел. Ярый ла без тиздән берәр совет портына керсәк, ул чакта азык-төлекне иркенләп тотарга мөмкин. Ә инде үз портыбызга кереп тормасак, консервлар хәзергегә караганда да кирәгрәк булачак.

Озак кына бәхәсләшкәннән соң комиссия ике якның да фикерен искә алып карар чыгарды: консервланган азык-төлекнең бер өлешен ашый торырга, ә бер өлешен НЗга [1] сакларга.

Ләкин Роман Александрович кирәкле минутта беркайчан да җаваплылыктан качмый, ул ныклы һәм кискен карарга да килә белә. Диңгезчеләр аны нәкъ шуның өчен яраталар да.

Капитанның баш ярдәмчесе Станислав Николаевич Пуринов һәр яктан капитанга охшарга тырыша. Аның үз-үзен иркен тотып һәм бераз гына төрттереп сөйләшүендә дә, тышкы пөхтәлек һәм чисталыгында да, хәтта кул хәрәкәтләре һәм сөйләвендә дә «остасы» тәэсире сизелеп тора. Ләкин баш ярдәмченең әнә шулай капитанга охшарга тырышуы, аларның холык-фигыльләренең бер-беренә һич тә охшамавын тагын да кабартыбрак күрсәтә.

Роман Александрович — хискә бирелүчән кеше. Кәефе яхшы чагында ул матросларның хәтта шактый җитди гаепләрен дә кичерә ала.

[1] НЗ — кагылгысыз запас.

Ә инде кәефе көйсез чак булса — корабтагылар аның күзенә чалынмау ягын карыйлар. Сәяхәттәге бертөрле, гадәти көннәр аны шактый ялыктыра. Ачык диңгездәге вакытны ничек тә булса кызыклырак итеп үткәрү өчен, ул тропикларда үсә торган бик каты бакаут агачыннан кечкенә сыннар юнып ясый, сәгатьләр буе магнитофон язмалары тыңлый яки көннәр буе китап укый.

Станислав Николаевич исә сабыррак, кешеләр белән аралашканда үзен тынычрак тота. Ләкин капитанга караганда азрак белә, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрендә дә әллә ни иркен йөзә алмый, дөресрәге, алар белән бик үк кызыксынмый. Алар икесе дә Югары диңгез училищесы тәмамлаганнар, икесе дә еракка йөзү буенча капитан дәрәҗәсе алганнар, ләкин баш ярдәмче капитанга караганда берникадәр кайтышрак.

Роман Александрович бөтен нәрсәне дә бик ансат үзләштерә. Мәсәлән, ул кыска гына вакыт эчендә инглиз телен өйрәнгән һәм бу телдә әйбәт кенә сөйләшә. Аның каютасында инглизчә китаплардан җыелган тулы бер китапханә бар һәм капитан аларны, русчаны укыган кебек, җиңел укый. Ә Станислав Николаевич менә инде ничә еллар инглиз теле өстендә утыра, көн саен икешәр сәгать диярлек сүзлек ярдәмендә инглизчә текстлар укый һәм тәрҗемә итә. Көнгә бер-ике сәгать чамасы сүзләр ятлый. Ләкин һаман да әллә ни җимерә алмый. Ул һәр нәрсәне авыррак үзләштерә һәм үзенең тырышлыгы, түземлеге белән алдыра.

Әгәр дә капитанның бүген нәрсә эшләячәге алдан һич кенә дә билгеле булмаса, баш ярдәмченең көн тәртибен бөтен экипаж белеп тора һәм ул ифрат төгәллек белән үтәлә.

Иртәнге сәгать дүрттән сигезгә кадәр ул вахтада тора. Сәгать сигездә иртәнге ашны ашый. Тугызынчы яртыдан алып унберенче яртыга кадәр тавык та чүпләп бетермәслек хуҗалык эшләре белән шөгыльләнә. Уникенче яртыда төшке ашны ашый. Уникедән соң аның «адмирал сәгате», ягъни төшке аштан соңгы йокы вакыты. Бу вакытта аны беркем дә, хәтта капитан үзе дә борчымый. Нәкъ сәгать икенче яртыда ул урыныннан сикереп тора, дүртенче штурманны уята («чиф»ка охшарга тырышып, тегесе дә үзенә «адмирал сәгате» билгеләгән), һәм тышта һава торышы нинди генә булуга да карамастан, спорт киемендә яки трусиктан гына палубага йөгереп чыга. Йөгерә, буыннарын йомшарта, төрле күнегүләр ясый.

Сәгать ярымлык күнегүләрдән соң ул салкын душка керә һәм нәкъ сәгать өчтә эш кәгазьләрен тәртипкә китерергә утыра. Шул утырудан ул сәгать бишкә кадәр эшли — машинкада баса, менюга рөхсәт бирә, әртиләндәге азык-төлекнең күпме икәнен тикшерә. Сәгать биштә кичке аш. Кичке аштан соң сәгать алтыларга кадәр домино уйный, дусишләре белән сөйләшеп утыра. Корабта җыелышлар, политуку, техник уку, лекцияләр һәм әңгәмәләр (шул исәптән минекеләр дә) сәгать алтыдан сигезенче яртыга кадәр үткәрелә.

Сигез сәгать утыз минутта, кичке чәйдән соң, гадәттә, барысы да кают-компаниягә яки кызыл почмакка җыела. Берәүләр домино яки шахмат уйный, икенчеләр радио тыңлый, кайсы укый, кайберләре дуслары белән сөйләшеп утыра. Гадәттә Станислав Николаевич та шунда утыра, ләкин аның кулында һәрвакыт калын гына инглизчә-русча сүзлек була. Ул иреннәрен кыймылдата-кыймылдата бүген үзе өйрәнергә тиешле сүзләрне кабатлый. Капитан еш кына аңа төрттереп тә куя:

— Кем инде телне сүзлек белән өйрәнә? Көлке бит бу.... Күбрәк укырга гына кирәк...

Ләкин баш ярдәмче инглизчә китапларны уку өчен йокы алдыннан махсус вакыт билгеләп куйган. Ул, шаяртуларга һич кенә дә игътибар итмичә, бик тәфсилләп ятлый бирә.

* * *

Кичә китлар күрдек. Бездән бер миль чамасы ераклыкта аларның ялтыравык кара сыртлары күренеп-күренеп китте һәм әледән-әле су өстенә кечкенә фонтаннар бәреп торды. Хәтта шушындый ераклыктан да аларның гәүдәләре гаять зур икәнен шәйләп гаҗәпләнәсең, әйтерсең лә диңгез өстенә су асты көймәләре күтәрелә. Уен түгел: китларның буе 30 метрга, авырлыгы 120 тоннага җитә. Бер кит кына да мең ярым дуңгыз биргән кадәр май бирә.

Гаять зур гәүдәле һәм ифрат көчле булуга да карамастан, китлар гаҗәеп сабыр холыклылар: аларның күпчелек төрләре суүсемнәр белән туклана. Бары тик кашалотлар дип атала торган тешле китлар гына кальмар аулыйлар. Китлар, мыеклары арасыннан диңгез суын сөзеп, беркемгә дә кагылмыйча, көтүләре белән океан киңлекләрендә йөзеп йөриләр һәм аларга кешедән башка бер җан иясе дә һөҗүм итәргә батырчылык итми.

* * *

Китлар белән очрашу вакыйгасын искә алмаганда, безнең тормыш элеккегечә бертөсле ага. Ике-өч көн үткән саен кораб сәгатьләрен берәр сәгать алга күчереп куялар. Шул рәвешчә, безнең күп тәүлекләребез бары 23 кенә сәгатьтән тора.

Коры җирне сагыну хисе һаман көчәя бара. Киртә буйларында котырып үскән тузанлы кычыткан исләре, кыр ромашкасының ак таҗлары, авылдагы эссе көннәрдә карлыккан әтәч кычкыруы торган саен ешрак искә төшә. Хәзер мин кая да булса урман буена барып, рәхәтләнеп киерелеп, үлән салкынлыгын тоеп, бөтен тәнем белән юеш җир сулышын тыңлап ятар идем.

Океан, әлбәттә, матур, ләкин туган җир, гүзәлрәк тә, җанга якынрак та. Туган телемне, татар музыкасын, Академия театры спектакльләрен сагынам. Казан моннан гаять дәрәҗәдә ерак, эфирдагы сызгырулар һәм шытырдаулар аша хәтта Мәскәү дә көчкә генә ишетелә.

Ватан... Бу төшенчәнең кеше тормышындагы гаять зур әһәмияте аннан ерак киткәч кенә бөтен тирәнлеге белән аңлый башлыйсың.

Роман Александрович миңа бик кызык нәрсәләр сөйләде. Безнең пароход Австралия ярларына килеп туктагач, аның янына көтүләре белән рус эмигрантлары киләләр икән. Аларның совет кешеләрен күрәселәре, аз гына булса да Ватан һавасын сулыйсылары килә. Бервакыт бик купшы киенгәнниндидер карчык килде, ди капитан. Асылташлар белән бизәнеп, чәшке тиресеннән тегелгән тун кигән, үз машинасына утырган, ди. Корабтагылар аны берәр бай Америка туристыдыр дип уйлыйлар. Ә ул траптан өскә менә дә елап җибәрә. «Балакайларым, бер генә шынык руш ипекәе бирегежше...» ди, рус сүзләрен боза-боза. Баксаң, ул гап-гади рус карчыгы булып чыга. Аңа бер бөтен рус ипие биреп җибәрәләр.

Баштан «кунак» саен берәр бөтен ипи бирә торган булалар, соңыннан рус ипиен авыз итәргә теләүчеләр шул кадәр күбәя, ипине урталай кисәргә, тора-бара дүрткә бүләргә, ниһаять, берәр сынык кына бирә башларга туры килә.

Эмигрантларның кайберләре башта кирәгеннән артык мактанып ташлыйлар, үзләренең йортлары, телевизорлары, суыткычлары, машиналары һәм гаражлары белән күзгә төтен җибәрәләр. Аннан бераз гына эчеп алалар да, исерек баштан, бу әйберләрнең барысы да бурычка сатып алынганлыгы, чынында исә боларның берсе дә тулысынча үзләренеке булмавы һәм шифаханәгә ятарга туры килсә яки эш уры-

кын югалткан очракта, боларның барысын да, сорап тормыйча, тартып алачаклары турында сөйлиләр. Капитан әйтә, мондый чакта аларның күзләрендә шул кадәр сагыш була, ди, бу кешенең кайчандыр үзен-үзе рәхимсез рәвештә талаганлыгын аңлыйсың, ди...

* * *

Бүген мин үземнең элекке язмаларымны караштырып утыра идем — кайбер нәрсәләрне тулыландырасым килеп китте. Мәсәлән, мин кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы кайбер хакыйкатьләрне һәркем үзенең ачы тәҗрибәсе аша гына ачарга тиеш, дип язган идем. Бу фикер дөрес тә, дөрес тә түгел. Дөрес, чөнки һәрнәрсәгә үз акылың белән ирешергә тырышырга, һәрнәрсәне тормышта сынап карарга кирәк. Ләкин һәрчак алай эшләп булмый. Менә гади генә бер мисал. Галимнәр чебен гөмбәсен агулы дип әйтәләр. Инде шушы фикерне тормышта сынарга теләп, һәр кеше чебен гөмбәсен ашый башласа? Әхлак өлкәсендә дә шулай. Хатын-кызны хөрмәт итәргә өйрәнү өчен һич тә хатын аерып карау, үзеннең һәм кеше тормышын бозу, авыр рухи газаплар кичерү мәҗбүри түгел. Чөнки бу — күптән ачылган хакыйкатьне «ачу» булыр иде. VI—VIII класс укучылары Чехов, Горький, Толстой, Маяковскийларның тормыш һәм кеше турындагы бөек фикерләрен юкка гына истәлек дәфтәрләренә күчереп язмый торганнардыр, күрәсең.

Кайберәүләр бу эшкә авыз ерып карыйлар, ләкин, минемчә, монда бернинди дә көлке нәрсә юк. Тормышка яңа гына аяк баскан кеше алдына газаплы, бөтенләй чишеп булмаслык күренгән уннарча мәсьәләләр килеп баса, ә шәхси тормыш тәҗрибәсе әле шул кадәр аз, бу сорауларга җавап бирергә һич тә җитәрлек түгел. Менә шунда инде кеше олыларның тәҗрибәсенә таяна, атаклы кешеләрне ярдәмгә чакыра.

Кешене игелекле, әдәпле булырга бертуктаусыз, армый-талмый өйрәтергә кирәк. Әле дә хәтеремдә, җиде-сигез яшьлек малай чагымда мин бабайга ияреп тегермәнгә, утынга яки печәнгә йөрергә ярата идем. Кайчакта шулай юл буйлап тыныч кына барганда, бабай кемнеңдер арбасы пычракка батып, интегеп ятуын күреп ала. Безнең никадәр генә ашыккан чагыбыз булмасын, бабай атны шунда таба бора, тегеңә йөкле арбасын коры җиргә чыгарырга булыша. Аннары, әлеге бәлагә юлыккан кешедән ераккарак киткәч, үз-үзенә сөйләнгәндәй әйтеп куя:

— Бәлагә очраган һәр кешегә ярдәм итәргә кирәк. Бәлки син аны башка очратмассың да, бәлки ул синең изгелегеңә изгелек белән дә җавап бирә алмас, эш анда түгел. Бер мәлне син үзең дә шундый авыр хәлдә калсаң, моңарчы күрмәгән-ишетмәгән берәр узгынчы сиңа ярдәмгә килер...

Минем бабайның тулы бер үз фәлсәфи тәгълиматы бар иде — фәнни тел белән аны актив игелеклелек фәлсәфәсе дип атап булыр иде. Һәм бабай җае чыккан саен миңа да үзенең шул тәгълиматын сөйли иде. Олыларны хөрмәт ит, тыйнак бул, үзеннән алдан кешеләр турында кайгырт, бер генә минутны да эшсез үткәрмә — бабай җитди рәвештә мине әнә шуларга өйрәтергә тырыша иде. Бу хакыйкатьләрнең барысы да халыкның меңнәрчә еллар буе туплый килгән әхлакый тәҗрибәсенә нигезләнгән. Безнең боларны онытырга хакыбыз юк һәм яшьләр яңадан ачканны көтеп торырга тиеш түгелбез. Дөрес, без революциягә кадәрге крестьянның мораль кодексындагы бөтен нәрсәне дә кабул итә алмыйбыз, шулай да яңа әхлак нормаларын эшкәрткәндә халыкның мең еллар буена тупланган шушы тәҗрибәсенә таянырга тиешбез.

* * *

Әдәби, һәм бигрәк тә, әдәбият тирәсендә йөрүчеләр мохитыннан соң, монда, корабта, минем күзгә иң беренче ташланган нәрсә — диңгезче җанының сафлыгы, намуслылыгы. «Анда», коры җирдә, син берәүнең сөйләгәнен тыңлаганда ук эчтән нәрсә уйлаганын, күзгә күренеп торган начар, мескен китапны ни өчен чәпчеп-чәпчеп мактаганын сизеп торасың... Ә монда, диңгез стихиясе алдында, тәүлеккә егерме дүрт сәгать буе коллектив алдында һәркем үзенең чын йөзен күрсәтә. Кешеләр кайда да төрле булалар, һәм монда да, ярдагы кебек ук, берәү дә житешсезлекләрдән азат түгел. Ләкин беркем дә үз йөзен яшерергә, ниндидер битлекләр киеп, башкача булып күренергә тырышмый. Бу хәл корабта үзенчәлекле, сәламәт мохит тудыра.

Минемчә, кеше күңеленең иң әшәке, иң авыр төзәлә торган авыруы — икейөзлелек. Кайберәүләр болай тыштан караганда әйбәт кенә кеше булып күренә: эшли, анекдотлар сөйли, акылсыз да кебек түгел. Ләкин аның күңеленә кереп карасаң — анда бушлык, черек төп шикелле тотрыксызлык. Кагылып кына кара, шундук сасы тузан болыты күтәрелер. Мондый кеше синең белән пирәшләп тә утыра, дустанә кыяфәт белән җилкәңнән дә кага һәм шул ук вакытта артыңда синең турыда иң әшәке гайбәт сөйләүдән дә тартынып тормый.

* * *

Без янадан тропикларда. Янадан шәрап бирә, һава суыткычларны эшләтә башладылар. Ләкин бу инде Атлантикада мине шаккаттырган коточкыч эссе һәм бөркү тропиклар түгел. Суның җылылыгы — 27—28 градус тирәсе, һава чама белән 30 градуслар булыр. Бу — кышкы температура. Кышкы дигән сүзне куштырнаклар эченә алмыйм, чөнки хәзер көньяк ярымшарда чыннан да кыш.

Океанда вакыт шул кадәр акрын үтә, кичләре мәңгелек булып тоела. Океан өстенә сиздермәстән генә тыныч төн иңә. Ул чем-кара сөрем һәм ниндидер пошыну белән тулган кебек. Аның йомшак, дымлы җылылыгы сине төрле яктан чорный.

Кораб борыны белән урталай ярылган су инде башкача, сирәк якты очкыннар чәчеп торучы яшькелт фосфор төсләре чыгарып ялтырый. Тынлык. Кораб двигателенең тигез гүләве, оча торган балыкларның ара-тирә шап итеп палубага килеп төшүе генә ишетелә. Алар инде палубадан кире диңгезгә очып китә алмыйлар, чикерткәнекедәй канатлары белән пырылдый-пырылдыйлар да акрынлап тыналар.

* * *

Сәнгатьнең тормыштагы урыны турында уйланам.

Ул безне гүзәллекне тоярга өйрәтә — бу инде күптән билгеле хакыйкать. Беренче карашка гүзәллектән кием тегеп тә, йорт салып та, аш пешереп тә булмый иң, дияргә мөмкин...

Ләкин эш шунда ки, гүзәллек кешенең күңел түренә кереп урнаша да аның кылган һәр эшенә үз эзен сала бара — кием теккәндә дә, йорт салганда да, хәтта аш пешергәндә дә. Гүзәллекне бөтен тирәнлеге бе-

ләп тоя белгән кеше беркайчан да әшәкелек эшләми, чөнки әшәкелек аның аслына, эчке эстетик тоемына каршы килә.

Безнең Оренбург якларында шундый бер ырым бар: әгәр яңгыр аз гына булса да җирне чылатып үтсә, шул җир һавадагы болытларны үзенә янадан тартып тора, диләр. Ә инде кипшенеп, корып беткән җирне яңгыр болытлары әйләнеп узалар, ди.

Кеше дә шулай түгелмени?! Әгәр кешенең күңеле аз гына булса да сәнгать дымына «чыланган» булса, ул инде үзе үк һәр җирдә һәм һәркайчан комсызланып гүзәллек эзләячәк, аны үзенә сеңдерәчәк. Әгәр «чыланмаган» икән, аның күңеле гомер буена коры һәм ярлы булып калачак

* * *

Мәшһүр итальян рәссамы Рафаэльнең «Сикстин мадоннасы»н беренче мәртәбә күргәч, күңелемдә туган кичерешләрне гомергә онытасым юк. (Ул чакта Дрезден галереясы Мәскәүгә килгән иде.) Мине картинаның оста ясалган булуы һәм детальләрнең җентекләп эшләнүе гаҗәпләндермәде, мин аның никадәр кешелекле булуын күреп сокландым. Гаҗәп, ләкин мин «мадоннаның» йөзен үзебезнең татар хатынкызларыныкына охшаттым. Миңа нәкъ менә шундый ышанучан, уйга талган тирән карашлы, эчке бер яктылык сирпеп торган йөзле татар хатыннарын еш очратырга туры килде. Ләкин әле мин ул чакта аларның мондый гүзәл кешелеклелеген аңламаганмын, аларның сүз белән генә әйтеп биреп булмый торган үзенчәлекле рухи көчләрен тоймаганмын.

Соңыннан гына, күргәннәрем турында күп уйлаганнан соң гына, мин сәнгатьнең тормыштагы урынын тирәнрәк аңлый башладым: сәнгать безгә, көндәлек тормышның матурлыгын ачып бирү белән бергә, үзеңне кеше итеп тоярга да ярдәм итә икән.

* * *

Илдар Кашаев бу рейста безнең белән булмаса да, аның шушы коллектив кешесе икәнлеге сизелеп тора. Игътибар белән тыңласаң, экипаж членнары авызыннан әледән-әле аның исемен ишетергә була: «Илдар булса, ул болай итмәс иде...», «Илдар булса, ул моның өчен кирәген бирер иде...»

Әлеге сүзләрдән мин Илдар үзе әйтмәгән бер кызыклы детальне белеп алдым. Үзенең төп эшеннән тыш, җәмәгать эше тәртибендә һәм бер тиен дә өстәмә хезмәт хакы алмыйча, ул икенче механик вахтасында да торган икән. Юк, вакыты-вакыты белән генә түгел, ә көн саен тәүлегенә дүрт сәгать торган. Эш шунда ки, Илдар кайчандыр югары техник белем алган, хәтта бер фәнни-тикшеренү институтының конструкторлык бюросында да эшләгән. Илдар үзенең механик вахтасында торуын белгечлеген югалтасы килмәү белән аңлата торган булган. Бәлки монда күпмедер дөреслек тә бардыр. Ләкин төп сәбәп башка нәрсәдә. Илдар эшсезлекне яратмый, үзе дә бер генә минут та эшсез тора алмый. Үзе бу турыда күп сөйләмәсә дә, эш сөю аның канына сеңгән. Диңгезчеләр дә, үзләрен «тәрбияләп кенә» хезмәт хакы алучыга караганда, үзләре белән бергә тир түгеп эшли торган кешене яратарак төшәләр.

...Мин инде корабта яңа кеше түгел, шулай да, машиналар бүлегенә төшкәч, прексездән югалып калам. Анда тәмугтагы кебек. Тропик-

ларга кергәч, машина бүлегендә эсселек 45 градуска җитә. Безгә палубада да эссе кебек, ә майга буялып беткән, шыбыр тиргә баткан ярымшәрә моторыстлар өскә саф һава суларга чыгалар. Машина бүлегендә эшләүчеләрнең хезмәте юкка гына эссе цехлар белән тиңләштерелми, күрәсең. Мотористлар һәм механиклар күбрәк хезмәт хакы алалар һәм матросларга караганда алданрак пенсиягә чыгалар.

Шушы көннәрдә бу турыда баш механик белән сөйләшеп утырдык.

— Машина бүлегендәге кешеләрнең эшен җиңеләйтү өчен бер нәрсә дә уйлап чыгарып булмыймыни соң? — дим.

— Ә элеккеге пароход кочегарлары янып торган мичкә сигезәр сәгать буе күмер ыргытып торганнар. Алар ничек түзделәр икән соң? — дип, каршы төшә баш механик.— Сез, бәлки, бу хакта ишетеп кенә беләсездер, ә мин заманында үзем кочегар булып эшләдем. Элекке кочегарлар белән чагыштырганда, бүгенге мотористның эше бөтенләй җиңел. Дөрес, тавыш көчле, эсселек бар. Ләкин эшләр акрын-акрын моторист хезмәтен автоматика белән алыштыруга табан бара.

* * *

Повар ашханәдә җыелган калдык-постыкларны диңгезгә ташлый, мин шул чак борт янында басып тора идем. Кинәт океан төбеннән сыртындагы кара йөзгечен һәм ерткычларча ыржайган тешләрен ялтыратып орчык сыман бер нәрсә килеп чыкты. Акула... Ул комсызланып макарон, кичәге көннән калган котлет һәм ипи кисәкләрен кабып йота бара. Хәтта сыра әрҗәсе такталарына да килеп ябыша, буш консерв банкаларын да йотып җибәрә...

Акулалар гаҗәеп җан ияләре. Диңгезчеләр бер акуланы зур кармак белән тотарга уйлаганнар, ләкин теге чәнчә бармак калынлыгындагы капрон бауны тешләп өзеп качкан. Башта мин моңа ышанмаган идем, ләкин соңыннан акулалар турында язылган бер китап укып гаҗәпкә калдым. АКШның океанография институты океанариумында бер акуланың авызына махсус динамометр тыгалар. Шуннан күренгәнчә, акула үзенең корбанын ике мең атмосфера көче белән тешли икән! Ә акуланың йөзү тизлеген әле бүгенгә кадәр билгели алмыйлар, чөнки ул иң тиз йөрешле катерларны да бик ансат кына узып китә.

Акулалар безнең планетадагы иң карт җан ияләреннән берсе. Акула тешләре хәтта безнең республика җирләрендә дә табыла. Алар инде моннан күп миллион еллар элек үк яшәү шартларына менә дигән итеп яраша белгәннәр. Акуланың тәне беләү кебек каты, артка табан бөгелеп тора торган очлы мөгез тәңкәләр белән капланган. Игътибарсыз гына йөзеп баручы берәр җан иясенең бер кисәк ите умырылып чыксын өчен аның шушы тәңкәгә бер кагылып узуы гына да җитә.

Акуланың ашказаны сыекчасы теләсә нәрсәне диярлек эретә ала. Диңгезчеләргә консерв савытлары һәм башка төр металл әйберләр йоткан акулалар тотарга туры килгән. Берничә көннән инде акула ашказанында кәгазь кебек юкарып беткән тимерне көчкә эзләп тапканнар.

Гаять комсыз һәм куркыныч кыяфәттә булуларына карамастан, акулалар кешегә сирәк очракларда гына ташланалар. Ләкин диңгездәге бәхетсезлекләр вакытында суда аз гына кан күрсәләр дә, акулалар көтүләре белән җыела башлый. Баштан алар бәхетсезлек булган урынны уртада калдырып, суда зур түгәрәкләр ясап әйләнәләр. Түгәрәкләр һаман саен кысыла бара. Менә беренче акула яшен тизлеге белән корбанына ташлана. Аның артыннан башкалар да ияреләр. Тирә-яктагы су кан белән тула, акулаларның койрыклары селтәнүдән диңгез айка-

лып тора. Мондый чакларда акулалар тәмам акылларыннан шашалар, тирә-якта соңгы корбанны өзгәләмичә туктый алмыйлар.

Г. Марк-Кормик үзенең акулалар турындагы кызыклы китабында бу диңгез ерткычларының бәлагә очраган кешеләргә ташлануларын сурәтли. Ул шундый уннарча күренешне мисалга китерә. Узган сугыш елларында Япония су асты көймәсе Тын океанында «Кейп-Сан-Хуан» исемле транспорт корабына торпедалар җибәрә. Корабта 1 429 кеше була һәм алар барысы да диярлек суга сикерәләр. Ләкин монда кешеләр акулалар һөҗүменә дучар булалар. Ерткычлар яшен тизлеге белән диңгездә йөзеп йөргән кешеләргә ташланалар, аларны өзгәләп бетерәләр, су астына өстерәп алып төшеп китәләр. Акула тешләреннән бик аз кеше генә котылып кала. Командасы якынча шундый ук булган «Эрвин Мередит» дигән сәүдә корабының нибары 448 кешесен коткарып калалар. Аларны да әле вакытында килеп өлгергән ярдәм аркасында гына коткарырга мөмкин була. Хәтта коткару вакытында да кан исеннән котырынган акулалар көтүе һава тутырылган коткару салларына ташлана, багорлар белән сугуга һәм терәп атуга да карамастан, салга ябышкан кешеләрне урталай өзеп алып китә.

Менә ни өчен хәзер тропиклардагы күп курортларның пляжлары өстендә акулалар якынлашуын кисәтеп торучы махсус вертолетлар очып йөри, ә без бөтен рейс буена җылы океанда бер мәртәбә дә су коенмадык.



* * *


Сәяхәт барышында дүртенче штурман Валерий Кравченко белән дуслаштым. Ул 1942 елгы, сакаллы, мәһабәт гәүдәле егет. Әле өченче елын гына йөзә. Диңгезгә аны, капитаны шикелле үк, балачак хыяллары китергән. Һәм ул моңа аз гына да үкенми. Физиканы, электрониканы, радио эшен менә дигән итеп белә. Сәгатьләр буе төрле приборлар эчендә казына. Мондый чакта ул теге яки бу прибордагы төзексезлекне генә рәтләп калмый, ә приборны ничек тә булса камилләштерергә, үзеннән дә ни дә булса өстәргә тырыша. Аның каютасында нинди-дер кнопкалар, пультлар, реләләр. Шулар белән ул урыныннан тормыйча гына утны, радионы, җилләткечне кабыза яки сүндерә ала. Хәтта аның телефоны да кешеләрнеке кебек ачы тавыш белән чырылдамый, ә матур гына итеп кызыл күзен кыса.

Валерий музыка белән кызыксына, аккордеонда әйбәт кенә уйный. Ул сәяхәтче җырлары язылган магнитофон тасмалары җыя. Мин еш кына кичләрен аңа магнитофон тыңларга керәм.

Ул сувенирлар да җыя. Аның каютасы стенасына бамбук йомычкасыннан ясалган төрле төсләрдәге Кытай келәмнәре, Япон акварельләре эленгән. Киштәләрдә Куба кабырчыклары — караколалар, кокос чикләвекләре. Иллюминатор астында Япониянең кәрлә нараты үсеп утыра. Аның биеклеге нибары 35 сантиметр, ә үзе 50 яшьтә. Язу өстәлендә әле кызыл, әле ак яктылык бирел, маяк кебек итеп ясалган төнге лампа янып тора.

Валерий домино һәм шуңа охшаш уеннарны һич тә яратмый, ул аларны бушка вакыт үтерүчеләр дип кенә атый. Күп укый, шигърияте, бигрәк тә яшь шагыйрьләрне ярата. Аның авызыннан әшәке сүз ишетмәссең. Кыскасы, Валерий яңа буын диңгезчеләренең типик вәкиле.

# Индонезиянең зөбәрҗәт муенсасы



Сине кайнар нурлар иркәли,
Көннәр сиңа чәчәкләр суза.
Синең гүзәл ярларың буйлап
Төз пальмалар йөгереп уза.

Без Һинд океанын көнбатыштан көнчыгышка таба кисеп чыктык та хәзер Индонезия ярларына якынлашып киләбез.

Зәңгәр океан өстендә, су астыннан калкып чыккан шикелле, пальмаларның яшел җилпәзәләре күренә башлый. Якын ук килгәч кенә аларның тәлинкә кебек кечкенә, түгәрәк һәм тип-тигез мәрҗәнле утраучыкларда үсүләрен күрәсең. Бу утраучыклар тирә-яктан су астындагы мәрҗән рифлары белән әйләндереп алынган. Ачык диңгездә күзгә дә чалынмый торган яссы океан дулкыннары су астындагы каршылыкларга килеп бәреләләр дә, ак күбекләр чыгарып, өскә ургылалар. Ә утраучык белән су асты кыялары арасындагы су тыныч, җылы һәм фирүзә төсләре белән ялтырап ята.

Офыкта болытлардан да югары күтәрелгән, куе зәңгәр төстәге очлы башлы бүрәнкә күренә. Бүрәнкәнең бер ягы пычак белән кисеп алынган кебек. Бу — атаклы Кракатау вулканы. Ул урнашкан утрауны да Кракатау дип атыйлар. Вулкан үзенең бер ягын 1883 елдагы атуы вакытында югалткан. Ул вакытта утрауның яртысы, балыкчы поселоклары, җирле халыкларның алачыклары, кырлар һәм урманнар белән бергә су астына киткән. Кракатау җир шарындагы хәрәкәттәге вулканнарның иң көчлеләреннән санала. Шул ук 1883 елгы вулкан атылу вакытында аның авызыннан бәреп чыккан ташлар 2500 чакрым ераклыкка очканнар. Җир асты тетрәүләре аркасында илле метрдан да югары күтәрелгән океан дулкыннары Ява һәм Суматра утраулары яр буйларыннан меңнәрчә кешеләрне юып төшергән.

Менә без бертуктаусыз ничә сәгать буена вулканга таба йөзәбез һәм ул зурайганнан-зурая бара. Ниһаять, Кракатау утравы сул якта кала һәм безнең алда зөбәрҗәттәй яшел куе үсемлекләр белән капланган таулы Ява утравы ярлары ачыла. Дөге басулары, пальма һәм бамбук куаклары, үтеп чыккысыз үрмәле үләннәр белән чорналып беткән мангро урманнары... Океан яр буйларында шикәр кебек ап-ак

комлы пляжлар. Бөдрә агачлар белән капланган очлы башлы зәңгәрсу тау түбәләре өстендә алсу болытлар эленеп тора. Чип-чиста һавадан бу якларда гына була торган чәчәкләр һәм череп баручы мәрҗән исләре килә. Ә алда берсе артыннан икенчесе тезелеп киткән яңа утраучыклар күренә. Алар бөтенесе бергә зөбәрҗәт муенсага охшыйлар.

Су сизелерлек болганды һәм коңгырт-соры төскә керде. Анда караеп беткән ботаклар, соры яфраклар, озын чәнечкеле ниндидер җимешләр йөзеп йөри. Әле анда, әле монда куе соры төстәге дүрт почмаклы җилкәнле балыкчы көймәләре үтеп китә. Яр буендагы яшеллек арасында түбәләренә саргайган пальма яфрагы ябылган кечкенә алачыклар күренгәләп китә. Алар су эчендәге субайлар өстендә утыралар. Тирә-якларына киптерү өчен җәтмәләр эленгән, яннарында күмәч кебек янган шәп-шәрә балалар йөгерешеп йөри.

* * *

Шактый ерак ара калдырып, Вьетнам ярлары буйлап барабыз. Әледән-әле баш очыннан гына үтеп киткән АКШ реактив истребительләренең коточкыч гүләве ишетелеп кала. Биектә-биектә Окинава утравындагы Америка хәрби базасыннан күтәрелгән авыр бомбардировщиклар оча. Алар артыннан сызылып калган эз күк йөзе буйлап сузыла. Иртән офыкта Америка хәрби корабларының соры шәүләләре күренеп калды, ә көндезен вахтенный безнең кораб тирәсендә генә су асты көймәсе күреп калган.

Бу — безнең планетаның иң хәвефле урыны. Кичә кояш кызгылт төтен сыман болытлар арасына кереп баеды, һәм мин вакыт-вакыт янган джунгли исләрен сизгәндәй булдым. Ләкин бу хыялый алдану гына иде булса кирәк...

Бу тирәләрдә табигать гаять матур — җылы зәңгәр диңгез, мәңгелек җәйләр, күңелгә ятышлы гүзәл төсләр. Һәм бездән якында гына, үрмәле үләннәр үскән мәңге яшел джунглилар эчендә, пулеметлар тырылдый, бомбалар гөрселди, адәм каны коела, бамбук өйләр һәм дөге кырларына Американың кара козгыннары һөҗүм итә...

Сугышның күпме кайгы-хәсрәт һәм газаплар китергәнен без яхшы беләбез. Безнең әтиләребез Бөек Ватан сугышында җирдә башкача сугышлар булмасын өчен дә корбан булдылар. Ә сугышлар әле һаман җир шарының әле бер, әле икенче почмагында кабынып торалар.

Татарстан Вьетнамнан гаять ерак. Ләкин халык яхшы белә: сүндерелми калган бер генә төпчектән дә бөтен авыл янып бетәргә мөмкин. Ә монда инде ничәмә еллар буе джунглилар эчендә ялкын уйный, империалистлар һаман да ут белән шаярудан туктарга уйламыйлар...

* * *

Рюкю исемле япон архипелагы тирәсеннән үтәбез. Архипелагның иң зур утравы булган Окинавада Америка хәрби базалары урнашкан. Монда корал, шул исәптән атом-төш шартлаткычы куелган өр-яңа типтагы ракеталар һәм химик корал тутырылган баллоннар да саклана.

Монда Вьетнам патриотлары җимергән хәрби самолетлар, кораблар һәм башка төр техника төзәтелә. Моннан үлем йөге төягән авыр бомбардировщиклар күтәрелеп китә. Вьетнамдагы ярты миллионлы Америка армиясе Окинава утравыннан бөтен кирәк-ярак белән тәэмин ителеп тора: напалм бомбаларыннан алып үлгәннәр өчен пластик табутларга кадәр.

Капитан кичә үк безнең өстән Америка козгыннары очарга мөмкин дип кисәтеп куйган иде. Бүген төшке аш вакытында көчәя барган

мотор тавышлары ишеттек. Ашларыбызны ташлап, палубага йөгерег чыктык. Канатларына Америка хәрби һава көчләре билгесе төшерелгән разведка самолеты туп-туры безнең корабь өстенә төшеп килә. Ул якынайганнан якыная бара. Мачта очларына җитәргә берничә метр гына калгач, самолет, безгә сасы газ исе сирпеп, кинәт кенә югары күтәрелде. Аннары ашыкмыйча гына борылып яңадан түбән төшә башлады. Бу юлы инде ул корабның борыны түгел, ә койрыгы турыннан очып килде. Әйтерсең, Америка очучысы шушы кыланышы белән безнең түземлегебезне сыный иде. Аннары ул тагын түгәрәк ясап әйләнде дә безнең корабның уң ягыннан да, сул ягыннан да берәр мәртәбә очып үтте.

Минем фронтта булганым юк. Шуңа күрә булса кирәк, американың шулай оятсыз рәвештә безне эзәрлекләве миңа аеруча авыр тәэсир итте, гарьлек, ачу хисе тудырды. Ләкин диңгезчеләр тыныч иделәр. Доктор хәтта бу һава хулиганын кино тасмасына да төшереп алган.

## Иртәнге сафлык иле




...Безнең Латакиядән алып Корея Халык Демократиясе Республикасына кадәр булган кырык көнлек сәяхәтебез тәмамланып килә. Егетләрнең кәефе күзгә күренеп яхшыра. Кичә Кара диңгез пароходчылыгыннан радиограмма килде. Анда йөкне Чхонджин дигән Корея портына бушатырга да, шул ук илнең Хыннам портына барып, магнезит төяргә, аннары үзебезнең Находка портына кереп ягулык һәм азык-төлек запасын тулыландырырга кушылган. Бу — без якынча өч айдан соң кире кайтып җитәбез дигән сүз. Сентябрьдә Одессада булачагыбызны белгәч, барысы да шатланды... Мин генә бераз күңелсезләнеп куйдым — Япониядә буласым килгән иде. Узган рейста алар Борнео утравына һәм Италиягә дә тукталганнар. Ә бу юлы инде өч ил белән чикләнергә туры килә.

Радист Корея властьларына безнең корабның кайсы ноктада икәнлеген өч сәгать саен хәбәр итеп тора. Американың «Пуэбло» шпион-корабы белән булган хәлдән соң монда хәлләр шактый киеренке тора әле.

* * *

Куе урман белән капланган сопкалар томан арасыннан зәңгәрләнеп күренә. Аксыл-яшькелт дулкыннар иренеп кенә соры кыяларга бәрәләр, ватык кабырчыкларны, краблардан бушап калган кабыкларны кузгатып кыштырдаталар. Ташлы борын артында кара, сары һәм соргылт төтен бөркеп торучы бик күп завод торбалары калыккан, яңа төзелешләрдәге краннар торнадай муеннарын сузганнар, урамнарның юеш яшеллеге эченнән күп катлы ак биналар ялтырап күренә. Без Чхонджин портының тышкы рейдында торабыз. Безнең корабның сайга утыру куркынычы булганга күрә, причалга ук бара алмадык, хәзергә безнең йөкне кечкенә баржаларга бушатып алалар, ә аннары инде, кораб бераз калыккач, без причалга барып туктаячакбыз.

Ай ярымга беренче мәртәбә двигателебез тынып калды. Корабта гадәти булмаган тынлык. Мин инде туктаусыз гүләүгә шул кадәр күнегеп беткән идем, хәтта аннан башка ничектер ямансу булып китте, күңелгә нидер җитешмәгән кебек.

* * *

Чхонджинда өченче көн торабыз. Кояшлы якты иртә. Безнең яннан, бердәнбер ишкәк белән ишеп, балыкчы корейлылар ауга китә. Буксирчыклар күмер һәм чуен түмәрләре төялгән баржалар сөйрәп баралар. Бушату әлегә бик акрын бара, чөнки кораб чыгырлары гына эшли. Диңгезчеләр, тукталыштан файдаланып, суга агач сал төшерделәр дә, күгәрек чистарталар, кораб гәүдәсен буярга әзерлиләр. Машина командасы двигательгә профилактик ремонт ясый. Штурманнар карталарда кайтасы юлны билгелиләр.

Һавалар монда гаять үзенчәлекле. Иртәләрен диңгез өстеннән зәңгәрсу томан күтәрелә. Сәгать тугызларга ул таралып китә һәм бөтен тирә-як иртәнге зәңгәр сафлыкка күмелә. Ләкин көннең икенче яртысында сопкалар өстендә кара-кучкыл болытлар куера башлый. Алар акрын гына тауларны кичәләр, тизлекләрен һаман арттыра барып, түбән шуышалар да озакламый бөтен күк йөзен кургашын элпә каплап ала, вак кына җылы яңгыр ява башлый.

* * *

Асфальт җәелгән, яшеллеккә күмелгән киң, чиста урам. Урамның ике ягында дүртәр һәм бишәр катлы панель яки кирпеч йортлар тезелеп киткән. Нәкъ бездәге Әлмәт кебек өр-яңа шәһәрләрдәгечә. Йортларның төзелешләре генә бераз бүтәнчәрәк — түбәләр яссы, тәрәзәләр киң, йорт кырыйларында пыяла верандалар. Күп кенә биналарга Ким Ир Сенның зур портретлары эленгән. Урамнарда халык күп түгел. Барысы да эшлекле кыяфәттә, барысы да каядыр ашыгалар. Ирләр бердәй итеп зәңгәр, кара-көрән яки яшел киже-мамык тукымасыннан тегелгән чалбар һәм пиджак кигәннәр. Киемнәрнең бөтен төймәләре дә каптырылган. Хатын-кызлар да шундый ук караңгы төсләрдәге киже-мамык тукымасыннан тегелгән юбкалар һәм ак блузалар кигән. Хәрбиләр еш очрый. Араларында хатын-кызлар да бар.

Каршыбызга кәс-кәс атлап ярым хәрби киемле, сылу гәүдәле, нәфис йөзле бер кыз килә.

— Мин монда каш сикертер идем дә,— дип тел озайта матрос Неведомский,— җилкәсендә автоматы бар. Берәр нәрсә ошамаса баскан урынында тегеп тә куяр, матрос Неведомскийның исемен дә ишетми калырсыз...

Кызый елмаеп торган дүрт дистә күзне бөтенләй күрмәмешкә салышып үтеп китә һәм җилкәсеннән шуып төшеп барган автоматын гына рәтләп куя.

— Хәлләр мөшкел синең,— дип шаяртабыз без Неведомскийны,— бер эш тә чыгара алмыйсың бит әле...

Безнең гаҗәпләнеп каравыбызны сизеп булса кирәк, тәрҗемәче аңлатырга тотынды:

— Гаҗәпләнмәгез, болар халык ополчениесендәге кешеләр. Мондый ополчениеләр бездә кайбер предприятиеләрдә складларны, тимер юлларны, промышленность мәйданчыкларын саклау өчен төзелде. Алар эшлиләр дә һәм хәрби осталыкка да өйрәнәләр. Корея икегә бүленгәннән соң бездәге хәлләрнең киеренке булуын онытмагыз. Күптән түгел Американың «Пуэбло» шпион-корабы белән булып үткән хәл моны тагын бер кат раслады. Без империалистларның теләсә нинди тыкшынуларына җавап бирергә хәзер булырга тиешбез...

Без автобуска утырабыз һәм тәрҗемәче безгә шәһәр турында сөйли башлый.

Чхонджин — КНДРның Япон диңгезе буендагы иң зур порты һәм промышленность үзәге. Совет белгечләре ярдәме белән төзелгән Чхонджин металлургия комбинаты ил экономикасында әһәмиятле роль уйный. Күптән түгел ул совет инженерлары җитәкчелегендә яңабаштан үзгәртеп корылган. Моннан соң комбинатның куәте тагын да арткан. Чхонджинда шулай ук хәзерге заман машиналары белән җиһазландырылган кораб төзү верьфе, завод һәм сәүдә гаване, байтак кына башка төр промышленность предприятиеләре бар икән.

Шәһәр, нигездә, халык власте елларында үсә һәм ныгый. 1905—1945 еллардагы Япон оккупациясе чорында, бөтен Корея шикелле үк, бу шәһәр дә басып алучыларның чимал чыганагына әверелдерелгән. 1945 елның августында монда Совет диңгез пехотасы десанты төшә һәм үзенең кыю һәм көтелмәгән һөҗүме белән японнарның зур гарнизонын хәлсезләндерә. Аннары ул түгәрәк оборона ясап Совет гаскәрләренең төп көчләре килеп җиткәнче әһәмиятле плацдармны саклап тора.

1953 елда бөтен Чхонджин хәрабәләрдә ята иде, ди тәрҗемәче. Бер генә төзек бина да калмый. Америка авиациясенең бомбага тотуы шул кадәр көчле булган ки, буш вакытларда без рәхәтләнеп туп куа торган футбол кырында гына да берничә мең бомба шартлаган. «Сез күргәннәрнең барысы да соңгы 15 елда гына төзелде»,— дип сөйли тәрҗемәче. Бу елларда шәһәр тулысынча төзекләндерелеп кенә калмый, ә шактый үсә дә. Ул хәзер дә үсүен дәвам итә әле. Анда яңа төзелешләр чыннан да бик күп. Бөтен урамнар буйлап төзелеш басмалары тезелеп киткән. Ә җимереклек эзләре бөтенләй күренми диярлек.

Безнең автобус шәһәр уртасындагы шаулы урам чатына куелган биек таш һәйкәл янына килеп туктый. Ул демократик Корея бәйсезлеге өчен көрәшләрдә һәлак булган Совет сугышчыларына куелган. Без аңа тере чәчәкләр куябыз һәм һәйкәл итәгендә берничә минут тын гына басып торабыз.

Төньяк Кореяда халык саны Көньяк Кореядагыга караганда ике мәртәбә азрак. Шуңа да карамастан, Төньяк Корея Көньяк Кореяга караганда күмерне ике тапкыр, электр энергиясен биш тапкыр артыграк җитештерә, ә промышленностьның гомуми үсеш дәрәҗәсе буенча аны дистәләрчә тапкыр узып китә. КНДРда хәзер Советлар Союзы ярдәмендә төзелгән атом реакторы бар, авыл хуҗалыгына зур тизлек белән үсәргә ярдәм итүче көчле сугару системасы төзелгән.

Ләкин болар барысы да Төньяк Корея халкыннан искиткеч күп көч сарыф итүне сорый. Мәсәлән, төп азык культурасы булган дөге халыкка хәзергә кадәр үзәкләштерелгән ысул белән бүленә (карточка систе-

ласына охшаш ысул). Бу хәл дөге бәясен кыйбатлатмаска ярдәм итә. Башка төр азык-төлекнең күбесе сатылуда бар.

Ким безгә 37 нче параллельдә туктаусыз провокацияләр булып торуы, Көньяк Корея властьлары ягыннан хәлнең һәрвакыт кискенләшерелүе турында сөйли. Һөҗүм итешмәү турындагы килешүгә кул куелганнан соң үткән 15 ел эчендә бу килешү Америка гаскәрләре тарафыннан 67520 тапкыр бозылган. Ләкин Төньяк Корея халкы, бу провокацияләргә дә карамастан, ышанычлы рәвештә социализм төзи. Ким культура һәм халык мәгарифе өлкәсендәге уңышлар, КНДРдагы һәр дүрт кореялының берсе укуы турында горурланып сөйли.

Бу уңышларның барысында да Советлар Союзының һәм башка социалистик илләрнең ярдәме зур. Безнең илебез Төньяк Кореяга автомашиналар, тракторлар, станоклар, прокат, запас частьлар, кабель, нефть һәм мамык чыгара. Үз чиратында Корея безгә кургаш, цинк, югары сыйфатлы корыч, карбид кальцие һәм башка материаллар сата. «Муса Җәлил»нең Төньяк Кореяга килүе дә әнә шул дусларча экономик ярдәмләшүгә матур бер мисал булып тора. Без алып килгән марганец концентраты югары сыйфатлы корыч эшкәртү өчен бик кирәкле чимал, ә без алып китәчәк магнезит шулай ук бик кирәкле тау токымы. Магнезит табу буенча КНДР дөньяда күренекле урыннарның берсен алып тора.

* * *

Чхонджиндагы бушату ун көн вакытны алды. Хәзер Хыннамда йөк төйибез. Шушында ук причалда немец (ГДР һәм ФРГ), Польша, грек, Куба кораблары һәм ике Совет корабы (Ленинградтан һәм Владивостоктан) торалар. Очрактан файдаланып, кинофестиваль уздырырга уйладык. Күрше кораб белән тасмалар алмашабыз да көн саен өч-дүрт нәфис фильм карыйбыз — башлар әйләнеп бетә. Алмашу вакытында мәхәббәт турындагы, ковбой һәм детектив фильмнар аеруча үтемле санала.

Волейбол һәм футбол буенча халыкара ярышлар үткәрдек. Кубалылар белән булган бик авыр уенны безнекеләр 4 : 3 исәбе белән оттылар. Аның каравы көтмәгәндә һәм бик аяныч хәлдә грекларга 2 : 1 исәбе белән оттырдылар.

Корабка көн саен кунаклар килә. Кубалылар һәм поляклар башкаларга караганда ешрак киләләр. Совет диңгезчеләре турында әйтеп торасы да юк: алар безгә, без аларга теләсә кайчан йөреп торабыз.

Кичә кубалылар безне үзләренә кунакка чакырдылар. Башта фильм күрсәттеләр — испан телендәге кызыклы комедия. Аннары концерт карадык. Аларның менә дигән үзешчән джаз-оркестрлары бар. Каракучкыл негр барабанда могҗизалар күрсәтә — бармаклары белән дә, уч төпләре белән дә, терсәкләре белән дә, аяклары белән дә уйный. Саксофонда уйнаучы тәне шоколад төсендәге мулат гәүдәсе төйнәлер дәрәҗәдә бөгелә-сыгыла сумаладай сузыла торган озын көй уйный. Ак йөзле, кәкре борынлы ике егет электрогитараларда уйнадылар. Гарсон безгә мороженое, кара кофе һәм боз салган әфлисун согы бүлде. Кайберәүләр биеде. Күбесенчә кул хәрәкәтләре белән генә сөйләштек, ләкин бер-беребезне бик яхшы аңладык.

* * *

Кичә безнең корабка яр буе хезмәткәрләре һәм интерклуб дирекциясе вәкилләре килде. Капитан аларны кораб белән таныштырды, йөзү җиһазларын күрсәтте. Кызыл почмакта кунаклар «Виргиния» исемле

нәфис фильм карадылар. Ләкин фильм алдыннан күрсәтелгән «Днепр» хәрби өйрәнүләре турындагы документаль фильм аларга ныграк тәэсир итте.

Аннары кают-компаниядә кечкенә генә кабул итү мәҗлесе оештырылды. Пешекчебез бик каты тырышкан: рус борщы, кыздырылган бәрәнге белән дуңгыз ите, күп төрле салкын ашлар. Башта кунаклар әдәп саклап кына утырдылар, бер-ике рюмка «столичный»дан соң телләре чишелде. Озакламый, кечкенә генә төркемнәргә бүленеп, кызыпкызып әңгәмә куерта башладык. Шунсы яхшы, кореялыларның күбесе рус телен әйбәт кенә беләләр, ә кайберләре Советлар Союзында укып кайткан.

Мондый очракларда еш кына сүз милли мәсьәләләргә кереп китә. Минем белән бер өстәлдә утырган күршем Корея һәм рус халкы дуслыгы өчен тост тәкъдим иткәч, мин, совет халкы дисәң дөресрәк булыр, чөнки безнең корабта гына да биш милләт вәкилләре йөзә, дидем. Шуннан соң ул минем нинди милләттән булуым турында сорады.

«Татар»,— дип җавап бирдем мин. Күршем шунда ук җанланып китте. «О, татар, татар, беләм, минем татар музыкасы тыңлаганым бар, кореяныкына бик охшаган». Күршем, белеме буенча инженер, Советлар Союзында булып кайткан, безнең халыклар культурасы белән таныш кеше булып чыкты. Татар язучыларыннан Гадел Кутуйны («Тапшырылмаган хатлар») һәм Муса Җәлилне укыганы бар икән. Хәер, кунакларның барысы да диярлек Муса Җәлилне яхшы беләләр, чөнки аның «Моабит дәфтәрләре» корея теленә тәрҗемә ителгән һәм аерым китап булып басылып чыккан.

Күршем татар культурасы турында зур хөрмәт белән сөйләде, аннары халыкның рухи байлыгы кешеләр саны, чуен яки корыч коюкүрсәткечләре белән генә билгеләнмәве турында сүз башлады. «Хәтта кечкенә генә халыкның да,— дип сөйләп китте ул,— бөтендөнья культура хәзинәсенә бәһасез өлеш кертүе мөмкин. Әлбәттә, ул үзенең үзенчәлеген югалтмаса... Безнең атомлы-электронлы егерменче гасырыбыз,— дип дәвам итте ул,— гаять зур техник үсеш һәм фәннең күз күрмәгән гаҗәеп уңышлар гасыры, кайберәүләр күзаллаганча, милли мәсьәләне автоматик рәвештә генә алып ташламады. Әле, киресенчә, нәкъ менә XX гасыр урталары изелгән һәм колониаль халыкларның милли азатлык көрәшенең иң киң колач җәйгән чоры булды. Моны ничек аңлатырга соң? Минемчә, ди ул, техник үсешнең тигезләүгә омтылуы, соңгы елларда ачык чагыла башлаган космополитик тенденцияләр үзләренә капма-каршы хәрәкәтне көчәйтәләр, шуңа күрә дә үз милли әдәбиятына һәм культураңа тартылу көчәя».

— Ә бәлки соңгы унъеллыклар эчендә дөньяда булып узган зур социаль-сәяси үзгәрешләр үзләрен сиздерәдер? — дип куям мин.— Мәсәлән, социалистик лагерьның барлыкка килүе, Советлар Союзының башкаларга үрнәк булып тора торган мисалы, аның экономик һәм сәяси көченә таяну мөмкинлеге.

Әңгәмәдәшем моның белән дә килешә.

— Күрәмсез, милли горурлык һәм милли үзаңны искә алмау һич кенә дә мөмкин түгел икән,— дип дәртләнеп китә ул.— Колонизаторларга карата булган тирән нәфрәтнең бер сәбәбе шунда ки, алар үзләре басып алган халыкның культурасына мыскыллап карыйлар. Алар, Көнбатыш цивилизациясе рухы белән тәрбияләнгән кешеләр буларак, башка халыкларның культурасы белән дә, сәнгате белән дә, теле белән дә кызыксынмыйлар. Ул гына да түгел, аларның иҗатка сәләтле һәм чын кеше булуларына ышанмыйлар. Менә ни өчен изелгән милләтләрнең гади халкы гына түгел, буржуаз, өстен катлау даирәләре дә, колония

орында да әйбәт кенә яшәүчеләре дә, бер көн килеп, үзләренең килмешәк хуҗаларына каршы чыгалар.

Көнбатышта шундый бер ялгыш фикер таралган: имеш, Көнчыгыш үлгән, ул инде үзендә булганны биреп бетергән, ул ялкау һәм иҗатка сәләтсез. Ә менә, мәсәлән, Японияне, фәне, техникасы, культурасы, әдәбиятының гаять тиз үсеше белән безнең күз алдыбызда бөтен дөньяны шаккатырган илне кая куясын? Без, Көнчыгыш халыклары вәкилләре, Көнбатыш цивилизациясе казанышларын игътибар белән өйрәнәбез, аның көчле һәм йомшак якларын ачык күрәбез, шуңа күрә аңа сукырларча баш имибез, ләкин аны тулаем кире дә какмыйбыз. Ә Көнбатышның иң тирән ялгышларының берсе шунда, ул Көнчыгышка өстән генә карый, аннан өйрәнергә теләми, аның гасырлар буена тупланып килгән рухи һәм әхлакый байлыгын күрми. Менә сез, мәсәлән, XII гасырда ук, дөньяда беренче мәртәбә буларак, Кореяда китапларны җыелма металл шрифт белән баса башлаганнарын беләсезме?

Мин моны белмәвемне әйттем.

— Менә, күрәсезме?! Ә бит сез үзегез дә Көнчыгыш халыкларының вәкиле!

Күршем үз фикеренә нык ышанып һәм аны үстерә-үстерә бик озак сөйләде. Дөрес, мин кайбер урыннарда аңа төзәтмәләр кертергә тырышып карадым, абстракт Көнчыгыш белән абстракт Көнбатышның булмавын, ә билгеле бер җәмгыять строе булган аерым илләрнең генә булуы һәм моны һич кенә дә онытырга ярамавы турында әйттем. Ләкин мин төп мәсьәләләрнең берсендә аның белән килештем: һәр милли культураның тулысынча чәчәк атуыннан башка дөньядагы интернациональ культура да үсә алмый; һәм үз милләтенеке була алмаган кеше бөтен кешелек дөньясыныкы да була алмый.

* * *


Хыннам тирәсенә урнашкан элекке будда гыйбадәтханәсендә булдык. Гаҗәеп матур, җиңел һәм купшы бина. Ул урманлы тау түбәсендә утыра һәм бу тирәдәге табигать күренешенә шул кадәр тәңгәл килә, аннан башка бу яшел тау араларына, тауларны ярып төшкән үтә күренмәле елгаларга нидер җитмәс иде кебек. Безне йөртүче гид КНДРда диннең бетә баруы, ә бу бинаның архитектура истәлеге буларак кына саклануы турында сөйләде.

Дөрес, уенчык кебек гүзәл бу бинага карагач, без үзебез дә һич кенә дә алла һәм дин турында уйламадык. Безне бинаның үзенә генә хас мәһабәт күренеше, аны эшләгән билгесез корея ташчыларының осталыгы гаҗәпкә калдырды.

Мин Истамбул һәм Латакия мәчетләренең матурлыгына сокланганда да ислам һәм Мөхәммәт пәйгамбәр турында түгел, ә Көнчыгыш культурасының борынгы традицияләре, халык вәкилләренә үзләренең даһилыгын дини формадан башка күрсәтә алу мөмкинлеге булмаган чорлар турында уйланган идем.

Без әле хәзер генә, егерменче гасырның алтмышынчы һәм җитмешенче елларында гына, диннең бер нәрсә, ә халык арасыннан чыккан осталарның бөек иҗаты, аларның күп гасырларга сузылган архитектура традицияләре, таланты һәм осталыгы бөтенләй икенче нәрсә икәнлеген аңлый башладык бугай. Юк, без Василий Блаженный храмын да, Рублев иконаларын да, Әҗем мәчетен дә динчеләргә бирә алмыйбыз. Болар дин байлыгы түгел, ә халык байлыгы.

# «Оҗмах»ка тиң Сингапур



Малакка ярымутравының көньяк чите буйлап барабыз. Котырып үскән тропик үсемлекләре җирдән яшел фонтан бәреп торган сыман утыралар. Үтеп чыккысыз джунглилар белән капланган очлы түбәле калкулыклар кытай эшләпәләренә охшый, ә аларның түбәсендәге зонтик сыман ябалдашлы агачлар бик нәфис итеп эшләнгән акварель рәсемнәрне хәтерләтә. Джунглилар яшел стена булып бөтенләй яр кырыена ук килеп терәлә. Мангроның соры тамырлары еланнар өере кебек булып судан күренеп тора.

Ярдан искән җил чәчәк атып утыручы тропик агачларының шул кадәр куе һәм татлы исен алып килә ки, бу истән хәтта җилчә генә баш әйләнеп тора.

Бәрхет сыман яшел үсентеләр белән капланган, өстенә су җибәрелгән дөге басулары кояшта ялтырый. Эшкәртелгән, ләкин әле чәчелмәгән басулар яндырылган кирпеч төсендә. Менә шуның өчен дә Кытай елъязмачылары бу тирәләрне яшел джунглилар һәм кызыл туфрак иле дип атаганнар. Борынгы малайя легендасы болай ди: Малакка ярымутравының туфрагы моннан сигез гасыр элек рәхимсез үзара сугышлар вакытында «язгы ташу вакытындагы су кебек кан акканнан» кызарган. Әмма галимнәр әйтүенчә тропик җиренең кызыл төсе туфракта тимер катнашмаларының күп булуына бәйле.

Көн эссе, бөркү. Яшькелт-зәңгәр төстәге җылы диңгез күкрәген бөтен яклап кәкре борыннарын югары күтәргән моторлы балыкчы джонкалары, мәһабәт гәүдәле прахауслар ярып үтә. Тропик кояшы һәм диңгез тозы ашаган, уңып беткән җилкәнле көймәләр төбендә көмеш сыман балыклар тулы зур кәрзиннәр өелгән.

Сингапур — Малакка ярымутравының көньягына урнашкан кечкенә утрау. Аның мәйданы 500 квадрат километрдан чак кына артыграк, халкы ике миллион кеше чамасы. Үзе кечкенә генә булса да, бу утрау гаять зур стратегик әһәмияткә ия. Чөнки ул Тын океаннан Һинд океанына чыга торган бердәнбер уңайлы урынга урнашкан. Сингапурны кайчандыр көньяк-көнчыгышның Гибралтары дип йөрткәннәр.

Хәзер инде бу исем искергән, чөнки Сингапур озак вакытлы көрәштән соң сәяси бәйсезлеккә ирешә. 1963 елда Бөекбританиянең гомерлек колониясе инглиз империализмы кул астыннан чыгып, Малайзия федерациясе составына керде. Ә 1965 елның августында ул аерым дәү-

лэт булып оешты (лэкин анда эле һаман көчле инглиз хэрби базасы саклана).

Сәүдәгәрләрне һәм сәүдә капиталын үзенә тарту өчен Сингапур порто-франко, ягъни пошлинасыз сәүдә порты дип игълан ителә.

Сингапурга керү юлында кыялар, зур-зур мәрҗән ташлары, сайлыклар һәм су асты агымнары күп. Кайчандыр шулардан дингез пиратлары бик оста файдаланган. Алар кеше күзенә күренми торган кечкенә култыкларга кереп яшеренгәннәр дә шуннан һөҗүмнәр оештырганнар. Хәзер инде алар турында легендалар гына сакланып калган. Ләкин без җирле лоцманнан башка портка керә алмыйбыз һәм лоцман катеры килгәнне көтәргә мәҗбүр булабыз.

Тышкы һәм эчке рейдларда төрле илләрнең флагларын таккан йөзләрчә кораблар тора. Еллык йөк әйләнеше буенча Сингапур Көньяк-көнчыгыш Азиядә беренче, дөньяда дүртенче урынны били. Йолдызлар төшкән буй-буй Америка флагы һәм уртасына чыгып килүче кояшны чагылдырган кызыл түгәрәк төшкән ак Япон флагы ешрак очрыйлар. Ак океан лайнерлары арасында киндер түбәле кечкенә көймәләр күзгә чалына. Аларның берсе безгә дә иярә. Кара чәчле ябык малаялы көймә койрыгына баскан да учларын авызына куеп капитанга нәрсәдер кычкыра, тырыша-тырыша кулларын болгый. «Корабка менеп сәүдә итәргә рөхсәт сорый»,— дип аңлаталар миңа дингезчеләр. Капитан рөхсәт итми: «Шайтаныма кирәкләре бармы, бөтен корабны пычратып кына бетерәләр»... Ә безнең белән рәттән баручы япон корабын көймәдәгеләр шунда ук басып алалар: ярымшәрә җитез сатучылар астан арканга бәйләнгән тимер ыргак ыргыталар, аркан буенча, маймыллар кебек, корабка күтәреләләр, шул ук җеп белән товарларын өскә күтәрәләр дә кораб портка кергәнче үк кызу сәүдә оештырып җибәрәләр.

Гаҗәпләнүдән минем күзләрем шар була, ә дингезчеләр көләләр генә. Сингапур сәүдә белән яши, монда барысы да сату-алуга корылган, бүтәннәр өлгергәнче кулдагы товарны тизрәк сатып калырга кирәк, диләр. Менә тагын бер көймә күренә. Аңа каратут йөзле кызлар төялгән. Көймә борынында басып торучы кытай карты сораулы карашы белән үтеп баручы корабларга текәлгән. «Ә монысы тере товар»,— дип аңлаталар дингезчеләр һәм, минем гаҗәпләнүемне күргәч:

— Тукта әле, Сингапурда моннан да кәттәрәк хәлләрне күрерсең,— дип куялар.

* * *

Сингапур причалында үзенчәлекле, татлырак, бераз гына яңа чабылган кыяк үләне исенә охшаган, ләкин аннан көчлерәк бер ис тора. Бу ис копра һәм кокос мае складларыннан килә.

Һавада яшенле яңгыр алдыннан була торган бөркү эсселек. Яр буендагы кокос пальмаларының кытай җилпәзәләре кебек яфраклары селкенеп тә карамый. Кояш нурлары зурайткыч пыяла аша төшкән кебек кыздыра. Менә-менә дөрләп кабынып китәсең дә яна-яна көлен генә калыр кебек. Мин игътибарсызланып баш киемсез генә причалга чыккан идем, озакламый үземне баш чүмечемә эрегән кургаш коелгандай итеп сизә башладым. Шушы көйдергеч нурлар астында ярымшәрә йөкчеләр тукталмыйча диярлек корабларны бушаталар һәм төйиләр. Аларның шоколад төсендәге тәннәре, зәйтүн мае белән майлангандай, кояшта ялтырап тора.

Ярты башы кырылган кытай карты ананаслар, бананнар, кокос чикләвекләре тутырган әрҗәсе алдында йокымсырап утыра. Пластик түбәле склад бинасы өстеннән рәшә булып кайнар һава күтәрелә. Причал буйлап кызгылт тузан каплаган капчык өемнәре, ачы исләр таратып торучы кызыл агач әрдәнәләре, ак тальк сибелгән каучук төргәкләре тезелеп киткән.

Порт капкасы төбендәге склад ышыгында такси шоферлары карта сугып яталар. Берсе, капитан белән мине күреп ала да, рәхим итегез, дигәндәй, машинасының ишеген ача. Машина эчендә сандыктагы кебек бөркү.

Сингапурда хәрәкәт урамның сул ягыннан, шуна күрә моңа күнеккәнче гел каршы килгән машинага бәрелерсең шикелле тоела. Ә таксист илтифатсыз кыяфәт белән машинасын бер куллап кына йөртә. Ул каршыдагы көзгедән безгә хәйләкәр караш ташлап, буш кулы белән кесәсеннән бер төргәк фоторәсем чыгара да җәеп безгә күрсәтә. Рәсемнәрдә төрле кыяфәтләрдә төшерелгән шәрә хатыннар.

— Мадам кирәкме?

— Кесәгезгә тыгып куегыз,— ди капитан тыныч кына, инглизчәләтеп.— Без Россиядән.

Таксист, аңладым дигән сыман, баш кага һәм фоторәсемнәрен кесәсенә салып куя. Капитан миңа русча аңлата башлый: «Аларда һәрвакыт шулай. Бозыклыктан бигрәк материаль кызыксыну. Махсус йорт тотучылар белән договор төзиләр дә һәр клиент өчен акча алалар».

Ак таш җәелгән яр буеннан барабыз. Төсләр байлыгыннан күзләр камаша: диңгезнең чекрәеп тора торган сыек яшеллеге, әллә ниткән төсләргә кереп балкучы тропик чәчәкләре, кеше башы зурлык ялтыравык яшел һәм саргылт җимешле төз пальмалар.

Бераз баргач без Сингапурның үзәгенә килеп җитәбез һәм бәйләнчек таксисттан аерылабыз. Шәһәрнең бу өлешенә банклар, отельләр, төрле фирмаларның, транспорт агентлыкларының, страховой компанияләренең конторалары урнашкан. Ялтыратылган агачтан эшләнгән авыр ишекләр. Аларның һәрберсендә арыслан башы сыны. Инглиз һәм малайя телендә банк яки фирма исеме язылган сап-сары җиз такталар, гранит баскычлар һәм зур-зур мәрмәр баганалар. Көзгеле пыялалар артындагы киң холларда рәхәт ярымкараңгылык һәм чистартылган салкынча һава. Урамнарда ак күлмәкле зур портфельле хезмәткәр малайялылар җәяү һәм велосипедларда йөреп тора.

Сингапур президентының һәм премьер-министрының резиденцияләре дә шунда урнашкан. Колледж бинасы буендагы яшел стадионда ак майкалы яшүсмерләр регби уйный.

Менә викториан стилендә төзелгән өч катлы ак йортның капка төбенә бик шәп җиңел машина килеп туктый. Актан киенгән шофер тиз генә сикереп төшә дә ашыгып машина ишеген ача. Ак гольфалар, җиңнәре сызганган күлмәк кигән озын таза гәүдәле әфәнде машинадан ашыкмыйча гына чыга. Ул бик горур гына атлап йортның чуен коймалары артындагы мең төрле чәчәкләр үсеп утырган бакча эченә кереп югала.

Ә якында гына кибеп беткән, саргайган йөзле рикша кеше ташый торган арбасының тәртәсенә утырган да агач күләгәсендә сулу алып тора. Аның сеңерле, төерле аяклары агач тамырларына охшаган.

Безнең игътибарыбызны күреп, ул кинәт торып баса, баш иеп елмая. «Пли-из, сэр»,— ди ул арбасының утыргычына күрсәтеп. Без рәхмәт әйтеп баш тарткач та әле байтак вакыт артыбыздан ияреп килә.

...Сусыл үсемлекләр белән капланган кечкенә генә Эмпресс-плейс мәйданы. Аның уртасында шәһәр ыгы-зыгысыннан тәбәнәк чуен койма белән аерып куелган, яшелләнеп беткән бронза һәйкәл. Бу — Сингапурга нигез салучы, инглиз Көнчыгыш-Һинд компаниясе хезмәткәре Томас Стэмфорд Рафльзга салынган һәйкәл. Сингапурның экономик һәм стратегик яктан бик файдалы урын икәнен аңлап, бизгәкле сазлыклар һәм үтеп чыккысыз джунглиләр арасына британ ныгытмасы салуны дәгъвалаучы беренче инглиз әнә шул кеше инде. 150 ел элек бу урында 150 кеше чамасы җирле халык яши торган кечкенә генә балыкчылар авылы булган. Хәзер бу шәһәрдә миллионнан артык кеше яши.

Таба төбе шикелле тип-тигез Паданг мәйданы кыска итеп кыркыл-
ан сусыл үлән белән капланган. Уртада купшы гладиолуслар ялкын-
ланып утыра. Безгә таныш булмаган агач ботаклары янып торучы
кызгылт-сары чәчәкләргә күмелгән. Аларның юан кәүсәләре артында
шәһәр суды һәм муниципалитет бинасының ак колонналары һәм зур
гөмбәзе күренә.

Шәһәрнең бу купшы-житди эшлекләләр үзәгеннән соң ук шаулы
сәүдә урамнары башлана. Монда хисапсыз машиналар, мотороллер-
лар, велосипедлар, велорикшалар һәм чуар, тынгысыз халык төркеме
агыла. Бер-бер артлы тезелеп киткән купшы кибетләр, кафетерийлар,
төнге барлар, кинотеатрлар. Һәр витринада, белдерүдә яки реклама
плакатында диярлек арыслан рәсеме күрергә була. Ләкин бу арыслан
Британ хакимлеге калдыгы гына түгел, бәлки шәһәрнең символы да.
«Синга-пур» дигән сүз үзе дә «арыслан шәһәре» дип тәржемә ителә.

Бетоннан эшләнгән янгыр канаулары буйлап тар, биек тротуарлар
сузылып китә. Тротуарларга урыны-урыны белән кояштан саклану өчен
тыгыз киндердән яки бетоннан түбәләр корып куйганнар. Монда кем-
нәр генә юк! Юбка кигән ирләр, маңгайларына миң гөрткән, ачык төс-
ләрдәге озын тукыма — сарига төренгән һинд хатын-кызлары, жәлпәк
сары йөзле, кыска буйлы ябык малайялылар... Кайберләре өсләренә
әллә ниткән рәсемнәр — пальмалар, маймыллар, океан кораблары тө-
шерелгән күлмәк кигәннәр.

Жирле халыкның иң күп өлеше — кытайлар. Малайялылар, индус-
лар, пакистанлылар, индонезиялеләр, цейлонлылар, филиппинлылар да
аз түгел монда. Сингапур урамнарында төп-төз мәчет манаралары да,
күккә омтылган бизәкле готик собор шпиле дә, түбә читләре өскә кай-
тарылып торган кытай гыйбадәтханәсе дә, бөтен ягына таштан уеп
ясалган жанвар сыннары тезеп куелган будда храмы да очратырга
була.

Оча торган еланнар һәм аждаһалар рәсемнәре төшерелгән, кытайча
итеп салынган биналар белән рәттән генә Америка һәм Япония компа-
нияләре төзегән күп катлы пыяла һәм бетон эрҗәләр, вак һинд кибет-
ләре янәшәсендә бүгенге көннең менә дигән зур отельләре, чәчәк атып
утыручы бакчалар һәм парклар янында ярым жимерек алачыклар...

* * *

Шәһәрнең бу районы бернинди реклама белешмәсендә дә юк. Мин
ярлыларның субайлар өстендәге поселогында. Пычрак сулы култык-
ның сасы, бизгәкле сазлык өстендә бамбуктан, пальма яфракларыннан,
күгәргән калай, толь, сырлы алюминий кисәкләреннән һәм кока-кола
эрҗәләре ватыкларыннан корыштырылган алачыклар. Тротуарлар да
субайлар өстенә корылган.

Алачыкларның ачык ишекләреннән ярлы өй эче күренә — идәнгә
пальма яфракларыннан ясалган паласише нәрсәкәй ташланган, учак
алдында — берничә балчык чүлмәк. Ревматизмнан кәкрәеп калган,
карт маймылныкы кебек жәлпәк битле, күзләреннән бертуктаусыз яшь
агып торган карчык учак тирәсендә кайнаша. Зур корсаклы, кәкре аяк-
лы ярымшәрә яки бөтенләй шәп-шәрә бала-чага, шау-гөр килеп, такта-
лар өстеннән йөгерешә. Сүүткәргеч тә, электр да, канализация дә юк...
Пычрак суда чүп-чар, ачы исле калдык-постыклар ага, шул суны нин-
диләр хуҗалык кирәк-яракларына да алалар. Әгәр «Пан Амэрикэн»
авиакомпаниясенең колак тондыргыч тавыш белән өстән очып үткән
көчле реактив самолетлары булмаса, монда үзеңне таш гасырга килеп
эләккән итеп тоярга мөмкин.

Туристлар өчен чыгарыла торган белешмәләрдә Сингапур көньяк-
көнчыгыш Азиянең чәчәк ата торган почмагы итеп күрсәтелә. Әмма шул

ук белешмәләр түбәндәгеләрне дә хәбәр итә: Сингапурда рәсми рәвештә исәпкә алынган кырык мең эшсез кеше бар, ярлы халык арасында әле бүген дә бизгәк, дизентерия, трахома, туберкулез, махау авырулары киң таралган.

Урта хәллеләрнең тормышы да бик җиңелдән түгел. Бервакыт корабка кайтканда миңа такси шоферы белән сөйләшергә туры килде. Таксист эше төшемле һөнәр санала — бай туристлар йөртергә туры килә, кайчакта чәйлек тә биреп куялар. Әмма бу эштә дә, шоферның зарлануына караганда, тормышның очын-очка көчкә генә ялгап барып була икән. Аның айлык хезмәт хакы өч йөз сингапур доллары чамасы (йөз сум тирәсе). Шоферның дүрт баласы бар, шуларның әле олысы гына үз көнен үзе күрә башлаган. Хатыны кер юып бераз акча таба, ләкин бик аз, ул акча алдан күренмәгән вак-төяк чыгымнарга гына җитә.

Айлык хезмәт хакының яртысы ашау-эчүгә китә, ягъни көнгә уртача 5 доллар. Нигездә дөге, яшелчә һәм балык белән тукланалар. Сөт һәм сөтле азыклар бик кыйммәт, аларны балаларга гына алгалыйлар. Итне (күбесенчә, дуңгыз итен) атнага бер мәртәбәдән артык алмыйлар, ә туйганчы ит зур бәйрәмнәр вакытында гына эләгә.

Акчаның икенче төп чыгымы фатирга түләргә китә. Көнгә 2 доллар исәбеннән айга 60 доллар түлиләр. Фатиры зур түгел, бездәгечә әйтсәк, уңайлыклары булмаган ике бүлмә. Калган 90 долларны тарта-суза кием-нергә, балаларны укытырга һәм дәваланырга җиткерергә туры килә. Балаларга башлангычтан артык белем биреп булмый, бары тик иң сәләтле дигәнен генә шәһәр колледжына кертү бәхетенә ирешкәннәр. Дәвалану аеруча кыйммәт. Бервакыт аның кече баласы бер атна шифаханәдә яткан һәм моның өчен шоферның бер айлык хезмәт хакы — 300 доллар киткән. Ярый әле, аның бераз гына җыйган акчасы булган. Шоферның сүзләренә караганда, кара көнгә дип туктаусыз рәвештә акча җыя торырга туры килә. Авырып китсәң, яки гаиләдәгеләрнең берәрсенә бәхетсезлек килсә, беркаян да ярдәм көтеп булмый.

Менә шушы хәлләрне күргәннән соң мин бездәге кайбер мещаннарның чит илләрне оҗмах итеп күзаллаулары турында уйладым. Әйе, чит илләр турында реклама журналларындагы купшы рәсемнәргә һәм чит ил кинотасмаларына карап кына хөкем йөртергә ярамый. Дөрес, анда гаять тә уңайлы һәм матур отельләр һәм бик тә шәп машиналар бар. Ләкин алар бик аз сандагы кешеләр өчен генә, ә халыкның күпчелеге икмәкне бик авырлык белән таба һәм иртәгәге көн өчен һәрвакыт куркып яши.

Мин безнең корабта каучук төяүче йөкчеләрнең ничек эшләвен күзәтеп тордым. Сүз юк, монда эшләр шәп куелган. Автокаралар бер генә секунд вакытны да әрәм итмичә складлардан ак тальк сибелгән һәм кысып бәйләнгән каучук төргәкләре китереп торалар. Һәр төргәк 100 килограмм авырлыкта. Ике йөкче шуларны тиз генә җәтмәгә төйи, чыгыр аны трюмга төшерә. Йөкчеләр кайнар кояш астында эшли, ләкин җитәкчеләренең рөхсәтеннән башка берсе дә, авырткан билен турайту өчен генә дә, тукталмый. Төшке ялга барысы берьюлы туктыйлар һәм шунда, каучук төргәкләре өстендә үк, кайсы берничә кашык дөге боткасы, кайсы балык яки кабартма ашап ала. Ярты сәгатьтән яңадан баягы тизлек белән эшкә тотыналар. Смена беткәндә инде алар салмак кына, шаярмыйча һәм елмаймыйча гына әйберләрен җыялар да өйләренә таралалар. Алардан бүген инде бар булганы сыгылган, иртәгәгә кадәр алар беркемгә дә кирәкми. Берничә минуттан инде берникди ыгы-зыгысыз һәм сөйләшүләрсез генә икенче смена эшкә тотына.

Йөкче үзенең шушындый авыр хезмәте өчен такси шоферына караганда ике мәртәбә ким ала. Ләкин бу эшкә дә теше-тырнагы белән

ябышып ятарга туры килә, чөнки аның эштән чыкканын берничә эшсез көтеп кенә тора.

* * *

Кечкенә кибетләрнең берсенә керәбез. Бу савыт-саба кибете булып чыга. Киштәләргә кытай фарфорыннан ясалган бик матур савытлар тезелгән. Кабарынкы рәсемнәр төшерелгән чынаяклар, төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге тәлинкәләр, шулпа һәм кофе савытлары, лакланган поднослар, гаҗәеп әйбәт чәй, аш-су, кофе сервизлары. Исемсез халык осталарының бу иҗатларына сокланмау мөмкин түгел.

Кибет хуҗасы, чуар халат кигән олы яшьләрдәге кытайлы, почмактагы конторкада нәрсәдер саный, безгә дустанә елмая һәм товарын көчләп такмый.

Монда һава суыткыч җайланма юк. Түшәмгә эленгән җилпәзә акрын гына әйләнеп тирә-яктагы куе бөркүлекне бераз гына болгаткандай итә. Хуҗа торган почмак өстендә җитез соры кәлтә еланы баштүбән басып чебеннәр һәм бөҗәкләр аулый. Монда бөҗәкләр белән көрәшү өчен йорт саен диярлек шундый кәлтә еланнары тоталар.

Озакламый без яшелчә-җимеш сатучылар урамына килеп чыгабыз. Урам буйлап җиләк-җимеш, яшелчәләр өелгән озын өстәлләр тезелеп киткән. Бомбага охшаган сусыл ананаслар, ялтыравык сары эре кокос чикләвекләре, ипи агачы, папайя, гуава җимешләре, торо җиләкләре, һиндидер яфраклар, тамырлар, әллә ниткән җимешләр һәм җиләкләр. Боларның күбесенең исемнәрен безнең арада берәү дә белми.

Чуар күлмәгенең җиңнәрен сызганган, һәрвакыт елмаеп торучы яшь кытай егете озын пычак белән кокос чикләвегенең өске өлешен кисеп җибәрә һәм стаканга сөт сыман ак сыеклык агыза. Сөт җылы, ачкылт һәм бик үк тәмле дә түгел. Аннан бераз эремчек суы тәме килгән кебек. Соңыннан белүемчә, яңа өзелгән чикләвектән генә салкын сөт алып була икән. Өзгәннән соң берничә сәгать үтүгә ул җылына, куера, ачый башлый һәм үз тәмен югалта. Шуңа күрә дә кокос чикләвеген хәзергә чит илгә чыгармыйлар.

Җирле халыкның туклануында исә ул әһәмиятле урын алып тора. Кокос сөтендә витаминнар, аксымнар һәм майлар күп. Ул сусынны гына басып калмый, ә туклыклы да. Малайялылар кокос сөтен ачытып, кымызга һәм ачы балга охшаш исерткеч эчемлек ясыйлар. Чикләвекнең куе, бераз гына ачкылт йомшагыннан кабартма пешерәләр, кабыгы савыт хезмәтен үти. Төшне урап алган йонтәс киездән тукымалар, идән паласлары, себерке ясыйлар. Пальма агачы менә дигән төзү материалы бирә, ә яфраклары түбә ябуга китә.

Хәрчәүнәләрнең ачык ишекләреннән янган май һәм бу якларда кулланыла торган әллә ниткән аш тәмләткечләр исләре чыга. Кайбер хәрчәүнәләрнең кухнялары тышта ук, анда пешекчеләр көнчыгышта гына була торган төрле аш-су тәкъдим итәләр. Монда буар елан ите, кыздырылган сигезаяк, кан колбасасы һәм акула йөзгечләреннән пешерелгән шулпа ашап карарга була.

Сөйләүләренә караганда, кайдадыр, бу урамнар артында яшерен притоннар китә. Аларда әфьюн тарталар, контрабанда белән шөгыльләнәләр, корал һәм тере товар белән сату итәләр, акчалы уеннар уйныйлар. Ләкин без анда баруны кирәк тапмыйбыз. Сулга борылабыз да пычрак сулы, тар гына, ләкин шактый тирән булган Сингапур-ривер елгасы ярына чыгабыз. Елга өстендә яшәүчеләр коры җирдәгедән ким түгел. Суда кытайлылар һәм малайялылар ясаган моторлы һәм җилкәнле көймәләр тирбәлә. Шунда, көймәләрдә үк, тимер мичләр төтенли, балалар уйнап йөри, хатын-кызлар кер чайкый, ирләр тропик кояшыннан качып карта сугалар яки йокы симертәләр.

* * *

Һәр шәһәрнең холкын һәм йөзен билгели торган бер төп шөгыле була. Сингапурда ул — сәүдә. Дөрес, монда каучук һәм кокос мае эшкәртүче предприятиеләр, консерв фабрикалары, төзү материаллары һәм кечкенә генә металлургия заводлары бар. Портта судно ремонтлау һәм төзү верьфе дә эшли. Ләкин болар шәһәрнең чын йөзен билгеләми. Соңгы елларда хөкүмәт үз промышленностен үстерергә тырышса да, әлегә сатып алынган товарны сатудан, порт җыемнарыннан, туризмнан һәм сату-алучылар арасында арадашчы булудан алынган керемнәр Сингапур тышкы сәүдә балансының 80 процентын тәшкил итә.

Бу һәркайда сизелеп тора. Порт капкалары төбендә өсләренә төрле төсләрдәге киемнәр кигән җиң сакаллы, кояшта янган индуслар акча алыштырып утыралар. Алар алдындагы кечкенә әрҗәләрдә, долларлар, фунт-стерлинглар, рупийлар.

Акча алмаштыручылар бертуктаусыз: «Чендж мани! Акча алмашам!» — дип кычкыралар һәм каяндыр безнең руслар икәнлегебезне танып, рус һәм инглиз телләрен гаять дәрәҗәдә бутап: «Гагарин — мани бармы? Мал-мал чендж бир!» — дип сорыйлар.

«Гагарин-мани» дип алар совет акчасын йөртәләр. Безнең акчаны аерата ялынып сорыйлар.

Сәүдә рәтләре буйлап барганда сатучылар урамга йөгереп чыгып, җиңеңнән тотып диярлек товарлары янына алып баралар. Дөрес, монда да, Сүриядәге кебек үк, нәрсә генә алырга уйласаң да бик нык сатулашырга кирәк.

Портка килеп туктаган көнне үк безнең корабка комиссионерлар — төрле кибетләр һәм фирмалар вәкилләре — килә башлады. Алар үз товарларының үрнәкләрен һәм реклама-белешмәләр алып киләләр, бик тырышып үзләренең кибетләренә барырга үгетлиләр. Кибет хуҗалары күршеләрен узып киту һәм рәхимсез конкурентлык көрәшендә җиңеп чыгу өчен нәрсәләр генә уйлап чыгармыйлар! Берсе причалдан кибеткә кадәр һәм кире кайтырга транспорт бирергә вәгъдә итә. Аңлашыла ки, кибеткә кадәр бушлай транспорт белән баргач, коры кул белән кайту уңайсыз булачак. Икенчесе, әгәр без аның кибетеннән товар алсак, дингезчеләр өчен шәһәр буйлап бушлай экскурсия оештырачагын әйтә. Өченчесе сатып алучыны орандж[1] һәм кока-кола белән сыйлый, янәсе теге дусларын да алып килсен.

Совет суднолары Сингапурга моннан берничә ел элек кенә керә башладылар. Ләкин шул арада ниндидер бер җитез эшкуар монда «Мәскәү» исемле кибет тә ачып өлгергән. Бу кибеттә рус телендә хезмәт күрсәтәләр. Ләкин аның да инде үз көндәше бар. «Париж» кибете рус телендә махсус карточка бастырып чыгарган. Анда: «Кибетебез индусныкы булса да, русча сөйләшәбез. Моны үзегез кереп күрүегезне үтенәбез».— дип язылган.

Синең кем икәнең, кайсы илдән һәм ни өчен монда килүең беркемне дә кызыксындырмый — акчаң гына булсын. Акчаң булса сиңа елмаялар, түбәнчелек белән баш ияләр, ишекләрне ачып-ябып торалар. Ә инде акчаң юклыгын сизделәрме, барысы да битараф. Урамда ачтан үлеп ят, борылып та карамаслар.

Сәүдәнең иң кызган җире Клиффорд пристане янындагы «Малайбазар» дигән урында. Бу — гаять зур ябык базар. Аның түбәсе астында уннарча кибет, лотоклар, сату өстәлләре, җәяүле сатучылар урнашкан. Монда ни генә юк! Эчке яклары алсуланып янып торган гаять зур океан кабырчыклары: ал, ак, соргылт-зәңгәр төстәге мәрҗән куаклары; эшкәртелгән һәм бераз гына буялган матур су асты үсемлекләре;

---

[1] Орандж — апельсин суы.

эрзиннәр, келәмнәр, пальма яфрагы һәм бамбуктан эшләнгән палас-ар, боларына гаҗәеп зәвык белән төрле табигать күренешләре, оча орган еланнар, аждаһалар, юлбарыслар, кошлар төшерелгән һәм һәр-ерсендә сәнгатьчәләп иероглифлар язылган; киптереп лак белән буял-ан, тешләрен ыржайткан крокодил карачкылары — 30—40 сантиметр-ы кечкенәләре һәм метр ярымга житкән зурлары бар; төрле төстәге абырчыклардан, жимешләрдән, төшләрдән һәм шомартылган чуер ашлардан ясалган муенсалар; кокос чикләвегеннән юнып эшләнгән іентәс маймыллар; кызыл һәм сандал агачыннан уеп ясалган мәзәк ыннар; ташбака кабыгыннан эшләнгән чәч каптыргычлары, тараклар, бизәнү әйберләре, крокодил тиресеннән ясалган билбаулар, чемодан-нар, сумкалар, галстуклар һ. б., һ. б.

* * *

Бүген бездә кунакта — судовой агент һәм яр буе вәкилләре. Башта алар, гадәт буенча, корабны карап чыктылар. Аларга барысы да оша-ды. Һава суыткыч җайланмага бигрәк тә күзләре кызды.

Кунакларның берсе:

— «Муса Җәлил» кебек пароходлар сездә әлегә күп түгелдер? — дип кызыксынды.

— Нигә күп булмасын? Киресенчә, бу гадәти совет судносы,— диде капитан. Ул кунакларга, совет сәүдә флоты тоннаж буенча дөньяда алтынчы урынны алып торса да, составының яңалыгы буенча беренче урында икәнлеген аңлатты, СССР диңгез флоты тоннажының 80 про-центы соңгы ун ел эчендә генә төзелүен истән чыгармаска киңәш итте.

Кунаклар капитан каютасының ясалма климатында рәхәтләнеп уты-ралар: бозлап сок эчәләр, кызыл балык һәм ысланган колбаса ашый-лар, аз-азлап кына рус аракысын да тотып куялар, ләкин күп эчмиләр.

Капитанның шушындый очраклар өчен генә дип саклаган бер бан-ка кызыл уылдыгын да күргәч, алар бөтенләй шаккаталар.

Бер кунакның күзе минем көзгеле «Зенит» фотокамерасына төшә. Ул рөхсәт сорап, камераны җентекләп карый, бәясе белән кызыксына һәм үтереп мактый. Аның әйтүенчә, американыларның шушындый ук класслы фотоппаратлары күп мәртәбә кыйммәтрәк тә, начаррак та.

— Сезнең сәгатьләр дә әйбәт, кыйммәт тә түгел,— ди икенчесе.— «ВЭФ» транзисторы да.

Болар — бизнес дөньясы вәкилләре, әйберләрне аера беләләр. Ку-накларыбызның бераз йомшарып китүләре һәм безнең күңелебез бул-сын өчен тырышулары сизелсә дә, күңелдә ирексездән горурлык тойгы-сын уята. Без еш кына үз товарларыбызга тәнкыйть белән карыйбыз, хәтта начар сыйфатлы дип хурлыйбыз да. Әлбәттә, тәнкыйть булырга тиештер һәм кирәк нәрсәдер. Ләкин читкәрәк китеп, ерактанрак кара-ганда, мәсьәләнең икенче яклары да ачык күренә. Есенин әйтмешли, йөзне йөзгә терәп басканда кешенең йөзен күреп булмый, ерактанрак карарга кирәк. Һәм менә меңнәрчә миль ераклыкка китеп карагач, тән-кыйтьнең мещаннарча вак зарлану дәрәҗәсенә төшмәскә тиешлеге, безнең алга баруыбызда горурланырлык һәм ышанып таянырлык нәр-сәләребез күп икәнлеге аеруча ачык күренә.

Мәсәлән, мин монда үзем өчен көтелмәгән бер ачыш ясадым. Азия илләрендә бездә эшләнгән парфюмерия әйберләре француз ислемай-лары белән беррәттән йөри икән. Безнекеләрне хәтта теләбрәк тә ала-лар. Ә бит, минем белүемчә, Казандагы байтак кыз-кыркын үзебездә эшләнгән бизәнү әйберләрен бик ук өнәп бетерми, чит ил этикеткасы ябыштырылган теләсә нинди чүп-чар өчен җанын бирергә әзер тора. Казан талчугындагы кайбер спекулянтлар шуңа барып җиткәннәр ки, чит ил этикеткаларын иплән кенә кубарып алалар да Чистайда эш-

ләнгән йон кофталарга тагып куялар икән. Дөрес, йөз процентлы йоннан эшләнгән Чистай киемнәре иң яхшы чит ил әйберләреннән һич кенә дә калышмый, ләкин спекулянтларның әнә шундый «эшкәртүеннән» соң аларның бәясе икеләтә арта.

Дөньяны аркылыга-буйга инләгән һәм әйберләрне таный башлаган дингезчеләр үзебездә эшләнгән драп пальто һәм үзебездәге йон тукымалардан тегелгән костюм киюне чит ил киемнәреннән бик күпкә артык күрәләр. Бездәге байтак көяз яшьләр әле бүген дә җан тирләрен чыгарып эзләп йөри торган чит ил синтетикасына караганда, табигый тукымалар шул ук чит илләрдә әллә никадәр кыйммәтрәк тора.

Дөрес, безнең байтак предприятиеләргә өлгерлек, соңгы мода үзгәрешләрен исәпкә алу җитми, еш кына бездә товарның тышкы күркәмлеге дә килеп җитми. Бу турыда безгә кунаклардан да ишетергә туры килде. Шулай да безнең товарлар гомумән алганда әйбәт, алар дөнья базарында лаеклы уңыш казанды.

Мин инде монда совет мехы, күне, агачы, бодае, чөгендер шикәре, нефте, рудасының бик зур кадердә булуы турында әйтеп тә тормыйм. Әйе, читтән караганда Ватаныбызның никадәр бетмәс-төкәнмәс байлыкка ия икәнлеген күреп, тагын бер мәртәбә сокланасың.

* * *

Сингапур белән танышып йөргәндә сәер бер тойгы кичердем: әйтерсең, мин боларны кайчандыр күргәнмен инде — кинодамы, төштәме, хыялымдамы. Чыннан да, хәзерге заманда туристлык сәяхәтләре шул кадәр гадәти эш ки, үзәк һәм җирле журналларның һәр санында диярлек юлъязмалар басылып чыга. Шуңа күрә дә без чит илләр белән очрашуга күпмедер дәрәҗәдә әзерлекле булабыз. Ләкин монда, чит илләрдә, безнең ил турында никадәр аз һәм начар беләләр!

Бер генә мисал:

Бервакыт дингезчеләр белән Сингапур урамында йөргәндә бер кибет тәрәзәсендә Мәскәүдәге Василий Блаженный чиркәвенең зурайтылган рәсемен күреп, кибет хуҗасы чыгышы белән Россиянеке түгел микән, дип кызыксындык. Юк, кибет ниндидер бер һинд сәүдәгәренеке икән, ә чиркәү рәсемен «экзотика» өчен, сатып алучыларны җәлеп итәр өчен генә элеп куйганнар. Советлар Союзыннан икәнлегебезне белгәч, безне тәннәре кояшта янган, ак тешле, сайлап куйгандай зифа, сылу гәүдәле индус приказчиклары урап алды. Алар бездән Советлар иле турында сөйләвебезне үтенделәр. Мин, үз чиратымда, аларның Россия турында нәрсә белүләре белән кызыксындым. Ә алар Россиядә бик салкын булуыннан башка бер нәрсә дә белмиләр икән. Казан һәм Татарстан турында ишеткәннәре дә юк. Сөйләүләреннән аңлашылганча, аларга мәктәптә Россия тарихын бераз гына укытканнар, ул да булса 1917 елга кадәр генә.

Ялтыравык кара күзле бер яшүсмер бездән карның нинди булуы турында сорады, суыткычтагы бозга охшаганмы, янәсе, Россиядә нинди салкыннар булуы турында сорап интектерде. Мин бездә кышларын 25—30 градус салкын булуы турында әйткәч, аның хәтта бераз күңеле кайтты:

— О-о-о, узган февральдә бездә дә 25 градус салкын булган иде.
— Салкынлыкмы? — дип сорадым мин ышанмыйча.
— Әйе, салкынлык.
— Цельсий беләнме?
— Цельсий белән.

Шуннан соң мин, инглиз телен аңлавыма ышанып ук бетмичә, бер бит кәгазь алдым да эре хәрефләр белән: « — 25?» — дип язып куйдым. Приказчик минем кулдан каләмне алды да, аз гына да елмаймыйча,

минусны плюска төзәтеп куйды. Шунда ук кибеттә эшләүчеләр, барысы да беравыздан, чыннан да былтыр кыш аларда плюс 25 кә кадәр «салкыннар», булуы турында сөйли башладылар. Сирәк очрый торган хәл буларак, бу турыда хәтта газеталарга да язганнар.

* * *

Кичә безнең корабта Сингапурдагы совет сәүдә вәкиллеге хезмәткәре булды. Ул шәһәр, аның гореф-гадәтләре, җир шарының бу үзенчәлекле почмагы турында байтак нәрсәләр сөйләде. Безнең туган илгә кайтуыбызга кызыкты, Сингапурдагы авыр климатик эш шартларыннан, һәм аннан да бигрәк, авыр әхлакый климаттан зарланды. «Монда бөтен нәрсә дә акча белән генә үлчәнә,— дип сөйләде ул.— Гади генә бер мисал: безнең бер хезмәткәрнең кинәт кенә сукыр эчәге авырта башлый. Тиз генә әйбәт врач чакыралар. Врач авыруны карау белән операция ясарга кирәклеген һәм моның өчен күпме акча тиешлеген әйтә. Безнең күзлектән караганда байтак кына сумма була бу. Ул гына да түгел, врач акчаны алгач кына операциягә тотыначагын әйтә һәм чыннан да акчаны кесәсенә салмыйча эшкә керешми. Безгә моны күз алдына китерүе дә кыен; кеше авыртудан нишләргә белмичә ята, аның тормышы кыл өстендә, ә врач, иң игелекле белгечлек вәкиле булырга тиешле кеше, сүзне акчадан башлый. Бу хәл мондагы эшкуарларны һич тә гаҗәпләндерми, киресенчә, бик гадәти күренеш дип исәпләнә.

Корабка килгән иптәшнең әйтүенә караганда, безнең сәүдә вәкилләренә кайчакта туган илдән качып, империалистик пропаганда тырнагына эләккән кешеләр белән эш итәргә дә туры килә икән. «Кешеле булгач,— диде ул — кибәге дә була дигәндәй, бездә дә бит әле сирәк булса да чит илләрне тулаем оҗмах итеп караучылар табыла. Мондыйлар белән беренче чиратта империалистик державаларның разведкалары шөгыльләнә. Бу Сингапурда гына түгел, ә бөтен капиталистик илләрдә дә шулай. Мондый кешеләрдән мөмкин булганның барысын да сыгып бетерәләр, әгәр алар берәр эшкә яраса, үз кирәкләренә файдаланалар. Ә инде эшкә ярамыйсың икән, теләсәң ничек яшә, яши алмасаң дөмек шунда! Минә шул чакта инде кеше ике дөнья арасындагы аерманы үз җилкәсендә татый. Әгәр әле аның намусы бөтенләй үк пычранып бетмәгән икән, ул безнең илчелеккә килә, үзен илгә кайтарсалар, теләсә нәрсәгә дә риза икәнлеген әйтеп елый».

* * *

Мине тропик үсемлекләренең төрлелеге һәм байлыгы белән бөтен дөнья ботаникларына билгеле булган Сингапурның ботаник бакчасы. Пальма һәм ипи агачы аллеялары, араухари, агава агачлары, кызыл һәм сары чәчәкле хибикус куаклары. Гаҗәеп эре һәм ачык төсләрдәге көньяк чәчәкләре. Шулар арасында мин ниндидер таныш хуш ис сизеп алам. Игътибарлап карасам, янгырдан соң рәхәтләнеп утыручы хуш исле тәмәке гөле икән, чәчәкләре генә эрерәк һәм ачыграк. Бамбук чытырманлыкларында маймыллар кайнаша. Аларның кайсылары үрмәле үләннәргә тотынып атына, кайсылары чиный-чиный бер-берсен куыша, кайберләре гаять битараф кыяфәттә тәннәреннән борча эзли. Соргылт төстәге кечкенә генә гаять әкәмәт бер җитди маймыл нәкъ кеше шикелле итеп кулындагы баласын тирбәтә.

Бакча капкасы төбендә без көнбагыш һәм чикләвекләр сатып алган идек. Балалы маймылга бер уч көнбагыш сузам, ә ул алмый, артка чигенә, үзе кылый күзе белән генә зур гәүдәле, чыраен сыткан баш маймылга карый. Маймыллардагы тәртип буенча, иң әлек башлыкны сыйларга кирәк, аннары гына ул сыйны башкалар белән бүлешәчәк икән. Ләкин башлык үзен артык эре тота, аның янына барып торасым

килми. Маймыл гадәтләрен санга сукмыйча агачлар арасына керәм дә баягы маймылга көнбагыш сузам. Теге, башлык күрми микән дигәндәй, як-ягына карап куя. Ләкин көнбагышны ала, тәмләп кенә ярырга да тотына. Ләкин шул мизгелдә үк янына ачулы башлык килеп житә, шап итеп тегенен йомшак жиренә китереп суга, көнбагышны талап ала. Ләкин, үзе тук, ахры, ашамый, көнбагышларны жиргә сибә. Тәртип саклау өчен генә кыланган икән. Хәзер инде башкаларга да ашарга мөмкин.

* * *

Капитан белән икәүләшеп милли музейга да бардык. Йөз миллионга якын кешесе булган халыкның сәнгатен без әле бик начар беләбез икән. Музейга Малайя милли архитектурасы үрнәкләре, бамбуктан, сөяктән, кабырчыктан ясалган кием-салымнар, тукымалар, көнкүреш әйберләре куелган. Һәр халык үз тарихында дөнья үсешенең бер кан тамыры булырлык рухи байлык туплый. Негр музыкасы менә ачык мисал булып тора ала. Соң чиккәчә киеренке шартлылык, югары хисси тойгы, тыйнаклык — бүгенге сәнгатькә хас бу кичерешләрне малайя халык осталары инде моннан берничә гасыр элек үк үзләрендә булдырганнар. «Көнбатыш цивилизациясе» дип аталган нәрсә бүгенге көнгә кадәр берьяклы гына үсеп килде. Ул бары тик борынгы грек һәм борынгы рим үрнәкләрен генә канун итеп алды. Ә үзенчәлекле фәлсәфәсе, бетмәс-төкәнмәс рухи байлыклары булган Көнчыгыш әле һаман сер булып кала бирә, культура алмашу эшендә аз файдаланыла.

* * *

— Палуба командасына аврал!

Шалтыр-шолтыр килеп юан якорь чылбыры күтәрелә. Судан берничә тонналы зур чуен якорь күренә.

— Якорь чиста! — дип кычкыра боцман. Ә кая инде чиста булу — ул бөтенләй зәңгәрсу күк төстәге ләмгә һәм пычракка буялып беткән. Диңгезчеләрдән берәү бранспойдтан атып торган көчле су агымы белән ләмне юа.


Буксирчык безне акрын гына причалдан алып китә. Шул арада кораб двигателен дә кабызалар. Яр буендагы йөкчеләр, безнең сәүдә вәкиле һәм шипшандлер мистер Генри безгә кул болгыйлар.

Сау бул, Сингапур!

Без, жиңелчә сагыш һәм моңлы хисләр белән, океан исе аңкып торган һәм тропик кояшы астында кайнап торган бу үзенчәлекле һәм чуар шәһәрдән аерылып китәбез.

*1969 ел.*

*Кыскартылып басылды.*





Ильтани Илялова

# ЭЗЛӘНҮЧӘН, ТЫНГЫСЫЗ АКТРИСА

Юлия Тугина беренче тапкыр сәхнәгә чыга: зифа буйлы, шат күңелле, үзе шундый сылу. Шатлыгы эченә сыймый, мәхәббәт хисе тулып ташыр чиккә җиткән аның, һәм ул моны яшерер хәлдә дә түгел. Бертуктаусыз көлә, шаяра. Я ходай, бу кадәр дә бәхетле булыр икән кеше. Менә ул Дульчин белән очраша. Ихтыярсыздан аның күзләреннән яшь ага, үзе елый, үзе көлә, күкрәк төреннән чыккан бәрхеттәй йомшак тавышы соң чиккә тартылган кыл кебек.

Икенче пәрдә башлана. Һәм безнең алда гүяки бөтенләй башка кеше. Ул бәрешеп-боегып калган. Кайчандыр нур бөркеп торган күзләре тоныклана төшкән. Тугина Прибытков янына акча сорарга килгән. Йөзендә — үзенең нинди хәлгә төшүен аңлаудан туган гаҗизлек, шул ук вакытта өметсезлек һәм тәвәккәллек хисе. Аклы-каралы күлмәк кигән озын буйлы Юлия, ничек сүз башларга белмичә, аптырап басып тора. Аннары, тотлыга-тотлыга, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән акча хакында сүз кузгата. Прибытковның: «Булмый» дигән сүзен ишеткәч, Юлия борылып чыгып китә башлый... Ләкин тукталып кала, газаплы йөз белән яңадан Прибытковка таба борыла, акрын гына үтенечен кабатлый. Тагын тискәре җавап. Һәм шунда ул, соңгы чарага ябышкандай, көҗәләнеп аяк тибәргә, акча таләп итәргә тотына. Алай да эш чыкмагач, байны кочакларга, аның алдына менеп утырырга омтылыш ясап карый. Никадәр хурлык, түбәнлек... Бигрәк тә Юлия кебек мул тормышта үскән хәйләсез-мәкерсез кеше өчен...

Нињаять, без аның белән соңгы, өченче тапкыр очрашабыз. Безнең алда кабат



*Әсфәндиярова — Юлия Тугина*

башка кеше. Ул каралып, ямьсезләнеп беткән. Бу рәхимсез дөньядан бөтенләй туйган, үзенең намусын һәм кешелек горурлыгын югалткан мәрхәмәтсез бер кешегә әйләнгән.

Татар академия театрының сәләтле артисткаларыннан Шәхсенәм Әсфәндиярова башкаруында Островскийның «Соңгы корбан» пьесасыннан Юлия Тугина безнең күз алдына әнә шундый катлаулы бер образ булып килеп баса. Бу — аның соңгы рольләренең берсе. Купчелекнең уртак фикеренчә, уңышлы башкарылган роль. Әсфәндиярова уйнаган рольләр хакында сүз чыкканда, «уңышлы, кызыклы, шәп» кебек мактау сүзләрен, гомумән, еш ишетергә туры килә. Һәм ул сүзләр берәүне дә гаҗәпләндерми. Чөнки дөресе шулай. Әмма артистка адресына шундый җылы сүзләр әйтелсен һәм алар гадәти бер күренешкә әйләнсен өчен, Шәхсенәмгә күпме тырышырга, күпме көч куярга туры килгәндер.

...Актер язмышы. Кеше язмышлары кебек үк, күп төрле һәм бер-берсенә охшамаган алар. Берәүләр кече яшьтән сәнгать дөньясында театр һавасы сулап үсәләр, театрдан башка тормышны күз алдына да китерә алмыйлар. Икенче берәүләр театр дөньясына очраклы рәвештә килеп эләгә... Татар театрының кызыклы, үзенчәлекле актерларыннан Ш. Әсфәндиярова беренче төркемгә, ягъни аңлы тормыш юлларын театрдан башлаган, тагын да гадирәк итеп әйткәндә, театрда туып-үскән актерлар рәтенә керә.

...Урта Азия. Үзбәкстан. Борынгы мәшһүр Бохара, әмирнең зиннәтле сарайлары, искиткеч матур итеп салынган мәчетләр, аларның биек манаралары... һәм янәшәдә үк тар, кәкре-бөкре, тузанлы тыкрыклар, пычранып, кортлап-сасып беткән су ала торган урыннар — хаузлар. Менә бу контраст күренешләр үзләре үк театраль декорацияләрне хәтерләтәләр һәм сине дә үзгә бер театр дөньясына алып кергәндәй булалар.

Биредә, шушы шәһәрдәге үзбәк театрында, Шәхсенәмнең әнисе эшли. Мөкәррәмә ханымның бәләкәй кызы үзе дә, куның-төнеп дигәндәй, театрда яши, шунда аңа «театр җене» кагыла. Андагы кабатланмас атмосфера, сәхнә һәм сәхнә артындагы үзгә бер һава, чит кеше өчен аңлаешсыз, әмма сәнгатькә чын-чынлап гашыйк кешеләр йөрәген ешрак тибәргә мәҗбүр иткән сихри бер көч, кыскасы, театр дигән төшенчәгә нәрсәләр керсә, шуларның һәммәсе Шәхсенәмне гомерлеккә әсир итә.

Бохарадан соң Ташкент. Бирегә килгәч, ул кечкенә генә «хыянәт» эшләп ташлый. Гомумән театрга түгел, юк. Бары аның драматик төренә карата гына. Ни өчендер, аны балет үзенә тарта. Ул хореография училищесына керә. Анда хәзер те атаклы биюче, СССРның халык артисткасы Галия Измайлова белән бергә укый. Бергәләп Үзбәк опера һәм балет театры спектакльләренә йөриләр, сугышка кадәр үк куелган «Гөләндәм», «Ләкләк бәбкәсе» кебек спектакльләрдә хәтта үзләре дә катнашалар.

1941 елның июне җитеп, җәйге каникуллар башлангач, Шәхсенәм Львовтагы апасына кунакка китә. Ләкин готик стильдәге шәһәрнең архитектура истәлекләре белән озак хозурланып йөрергә туры килми. Сугыш башлана. Кечкенә кыз көч-хәл белән генә шәһәрдән чыгып китә. Әмма Ташкентка кайтып җитә алмый. Казанда туктап кала. Күп тә үтми, Татар опера һәм балет театрының кордебалетында эшли башлый. Ахырдан шушы ук бинада (хәзерге Татар академия театры бинасында), шушы ук сәхнәдә ул үзенең иң яхшы рольләрен башкарды, ләкин бу чагында Шәхсенәм драма театрына күчкән иде инде. Балерина булып эшләгән елларда кайчан да булса эш

урының үзгәртергә туры килер дип уйлап та бакмый. Ул биергә ярата, музыка ярата һәм тормышыннан канәгать була [1].

...Шулай, сугыш елларында биюче була. Бервакыт, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, кан койгыч сугыш әле дәвам иткән 1944 елның җәендә, татар артистлары әзерли торган студиягә студентлар сайлап алу өчен, Казанга махсус комиссия килеп төшә. Драма артистлары әзерли торган студиягә, ГИТИСка. Шәхсенәм озак уйлана. Дөресен әйткәндә, башкала үзе дә, алар укыячак мәшһүр институт та бик кызыктыра. Шул ук вакытта балетны да ташлап бетерәсе килми. Ахыр килеп, Мәскәүгә укырга бару теләге җиңеп чыга. һәм менә Казаннан килгән яшьләр актер осталыгы дәресендә утыралар. Дәресләрне исә талантлы актер, тәҗрибәле педагог, Станиславскийның иң якын укучысы Ольга Ивановна Пыжова алып бара. Дживилегов, Мокульский, Алперс кебек бөтендөньяга мәшһүр профессорлар лекция укый.

һәм курс үзе дә тырыш, эш сөючән, талантлы яшьләрдән оеша. Студияне алар 1949 елда ук тәмамладылар. Аннан бирле егерме елдан артык гомер узды. Ә ГИТИСта алар хакында бүген дә сагынып сөйлиләр. Прозат Исәнбәт, Рәфкать Бикчәнтаев, Гәүһәр Камалова, Шәхсенәм Әсфәндиярова, Асия Галиева, Асия Хәйруллина һәм Делюс Ильясовларны яхшы хәтерлиләр, яратып, үз итеп искә алалар. Дөресен әйтергә кирәк, студиячеләр үз укытучыларының ышанычларын тулысы белән акладылар. Хәзер алар Татар академия театрының таза, ныклы урта буынын тәшкил итәләр.

Башта аларның һәммәсе дә яшьләр театрында эшли, аннан академия театрына күчәләр. Билгеле, иҗат эшендәге уңышлар җиңел генә бирелми, беренче елларда шактый кыен була. Хәер, Әсфәндиярованың гомергә килгәндә, аның эшләре баштан ук җайлы бара шикелле. Академия театрына күчеп бернчә ел эшләгәч, аңа төп рольләрне ышанып тапшыра башлыйлар. Алар арасында аеруча игътибарга лаеклысы — Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» әсәреннән Луиза роле. Шушы беренче эшендә ук актриса мөстәкыйль юл белән барырга, Луиза образын үзенчә, үзе аңлаганча уйнарга омтылыш ясый. Аның Луизасы балалык беркатлылыгыннан аерылмаган аксөяк түгел. Ә акыллы, барысын да аңлый, кайгыра һәм борчыла белә торган җанлы кеше. Аның лирик персонажларга шул рәвешчә якын килүендә үк Әсфәндиярова иҗатының характерына хас бер сыйфатны, хәзергә әле ярлгы хәлендә генә булган, әмма киләчәктә тулы көче белән ачылачак сыйфатны төсмерләргә мөмкин иде. Сүз аның иҗатының асылын билгели торган төп сыйфат — тирән драматизм турында бара.

Театрга килгән беренче елларда аны төрле характердагы рольләрдә сынап карыйлар. Актриса туктаусыз үз йөзен, үз темасын, үз-үзен эзли. Шуңа да аның репертуарында без еш кына берсе икенчесенә бөтенләй охшамаган, хәтта капма-каршы характерда булган рольләр очратабыз. Луизадан соң М. Горькийның «Соңгылар» әсәреннән әдәпсез һәм оятсыз чая хатын Надежда килә. Әһәмиятсез генә берничә рольдән соң, 1953 елда дөнья драматургиясенең иң югары казанышы В. Шекспирның «Отелло»сы белән очрашу. Дездемона роле. Мондый рольне уйнау турында кайсы тәҗрибәле артист, кем генә хыялланмады икән. Әсфәндиярова аны труппага килеп дүрт ел эшләгәч үк уйный.

Мәсьәләгә объектив тәстә якын килеп, Шәхсенәм башкарган Дездемонаның уңышлы һәм кимчелекле якларын тикшерә башласак, ихтимал, кимчелекле яклар күбрәк тә булыр. Бу аңлашыла. Әлегә осталык җитәрлек түгел. Тик шуны онытмаска кирәк: чын сәнгать әсәрләрен куйдан курыкмаган театр гына иҗади үсә, авыр рольләрдән курыкмаган артистлар гына чын сәхнә осталары булып җитлегә алалар. Актрисаның үзе өчен Дездемона зур вакыйга, осталыкка ирешү юлында бер баскыч була.

Иҗади тынгысызлык, даими эзләнү, туктаусыз хезмәт итү — Ш. Әсфәндияровага хас төп сыйфатлар менә шулар. Шулар ук аңар беренче уңыш та китерәләр. 1954 елда Н. Исәнбәтнең «Зифа» комедиясе куела. Әсфәндиярова Эсмеральданы башкара. Аның иҗатындагы комедиячел, хәтта сатирик характердагы образлар галереясы Эсмеральдадан башлана. Күпмедер вакытка актриса үз темасын, үз йөзен тапкандай була. «Җилкәнсезләр»дәге Дилбәр, Островскийның «Котырган акчалар» әсәреннән Лидия

[1] Академия театрына күчкәннән соң да, Шәхсенәм биюне онытып бетерми. Башта күп кенә спектакльләрдә биюләр башкаручы буларак катнаша. Казан театр техникумында сәхнә хәрәкәте буенча дәресләрне бүген дә Ш. Әсфәндиярова алып бара.

шул ук тəркемгə карыйлар. Алар барысы да — кəеф-сафа корып, типтерəп яшəргə яратучы җилбəзəк мещанкалар.

Аларның уң флангысында яшь, чибəр, кыланчык Эсмеральда басып тора. Күзə төшкəн кешесе алдында нилəр генə эшлəми ул: күз-каш сикертү дисеңме, бишкə-унга бөгелеп кыланчыкланып сөйлəшү дисеңме. Кеше ирен кулга төшерү өчен, бөтен көчен, хəйлə-мəкерен эшкə җигə кызый.

Эсмеральданы иҗат иткəндə табылган алымнар Дилбəрне уйнаганда да файдаланыла. Тик соңгы əсəрдəге гимназист кыз тагын да кыланчыграк, кирəрəк һəм ертлачрак күренə. Иреннəрен турсайтып үпкəлəргə генə торa, ул да түгел, дөнья тотырып талашырга керешə.

Лидия Чебоксарова да Дилбəр белəн Эсмеральданың кан кардəше булып чыга. Əммa əлеге элгəрлəреннəн аермалы буларак, ул усалрак, акыллырак, үз максатына ирешү юлында бер төрле чарадан да тартынып тормый торган кеше. Бу инде каты күңелле, əшəке чытлык, кияүгə чыкмый йөрүе дə яраткан кешесе булганга, шуны көткəнгə түгел. Юк, акчалы кеше, миллионнар иясе кирəк, ул бай кияү эзли. Бу җəһəттəн Лидиянең Телятевны аулавын сурəтлəгəн күренеш аеруча характерлы. Менə алар диванда утыралар. Лидия үз карамагындагы бөтен чараларны эшкə җигə. Ул, назлы тавыш белəн, Телятевны (Г. Шамуков) никадəр көчле яратуы хакында сөйли, аңа сырышып бетеп, үзен үбəргə, кочарга рөхсəт итə. Гаҗəплəнүдəн аптырап калган Телятев башта сокланып Лидиягə төбəлə, аннары тиз-тиз бүлмəдəге утларны сүндерергə тотына. Шул чак Лидия иргə чыгу турында сүз кузгата. Телятев бер мəлгə югалып кала, аннан, сикереп торып, яңадан утларны кабыза башлый. Əле һаман яртылаш яткан хəлдəге Лидия аның кулларына ябыша, кабыздырмаска тырыша...

Əлеге рольлəрдə, дəрəсрəге, шушы рольлəрдəн башлап, Əсфəндиярова үзе алган һəр образын зур төгəллек белəн хəл итə, һəр образга бик нечкə акцентлар сала башлый. Шуңа да гаҗəп үзенчəлекле һəм кабатланмас образлар тудыра. Хəтта хəзер генə без тукталган, берсе икенчесенə охшаган геройларны башкарганда да, ниндидер эчке уртаклыклары булуга да карамастан, аларның һəрберсен индивидуаль шəхес итеп коя. Һəр персонажның үз йөзе, үз характеры бар. Дилбəр образындагы төп нəрсə аның эчке асылы бернигə яраксыз буш кеше булуында гəүдəлəнсə, Лидиянең эчке асылы — ерткычлыгында. Шуның белəн бергə һəр икесе җилбəзəк мещанкалар. Актриса аларны эчке дəрт һəм зур ышаныч белəн фаш итə.

Театрда эшли башлавына 10 еллап вакыт узгач, инде мəгълүм бер тəҗрибə һəм осталык туплаганнан соң Əсфəндиярова да үз көчен башкарак характердагы рольлəрдə сынап карау телəге туа. Җилбəзəк хатыннар туйдырып бетерə, аның чын мəгънəсендəге драматик рольлəр башкарасы килə. Күпме генə гаҗəп тоелмасын, шундый роль белəн ул беренче мəртəбə 1962 елда Ш. Шəһгалиевнең «Без аерылышмабыз» исемле сəнгатьчə йомшак кына эшлəнгəн əсəрендə очраша. Əсəрнең сюжеты яңа түгел. Сүз коммунистик хезмəт коллективы дигəн исемне алу өчен көрəшкəн бригада тормышы турында бара. Шунда ук ал-ялны белми эшлəп йөргəн бригадир образы. Соңыннан ачыклана, ул шəхси дан өчен генə тырышкан икəн. Тик ахырга таба əсəрнең производство белəн бəйлəнешлə ягы күмелеп кала, алгы планга Хупҗамал исемле хатынның язмышы килеп чыга. Мондый хəл катлаулы язмышлы əлеге персонаж образын Ш. Əсфəндиярованың оста уйнавы аркасында мөмкин була.

...Хупҗамал нефтьчелəр станында буфетчы булып эшли. Əсəрдə сөйлəнгəн сүзлəрдəн аңлашылганча, данга, ялтырапыклы бизəккə кызыгып, ул үзенең чын мəхəббəтен югалткан. Ул герой исеме алган бер егет белəн мавыгып китə, ахырдан шуңа кияүгə үк чыга. Əммa бу аңа бəхет китерми. Хупҗамал үзенең беренче, чын мəхəббəтен оныта алмый, ул иреннəн аерылып китəргə мəҗбүр була. Ə тормыш инде җимерелгəн булып чыга. Илдар (яраткан егетнең исеме) аның үзен ташлап кайчандыр кияүгə чыгуын гафу итми. Шуннан тормышның яме калмый. Хупҗамал мораль яктан череп таркала башлый. Ул əрсез, əдəпсез бер вульгар хатынга əйлəнə. Беренче мəртəбə сəхнəдə без аны əнə шундый итеп күрəбез. Ирлəр тупас рəвештə шаярта, Хупҗамалның моңа да исе китми. Əммa шиксез кабыкка төренгəн бу хатында нечкə тойгылы, җəрəхəтлəнгəн йөрəк яшеренгəнен тамашачы баштан ук сизеп тора. Үзе кыланган булып маташа, ə күзлəре тулы моң. Əсфəндиярованың Хупҗамалы — борчыла, кайгыра белə торган тере кеше. Актриса тамашачыга рольнең «икенче планын», героиня-



*Ш. Әсфәндиярова Хәдичә ролендә.*

ның фаҗигале үлеменә хәтле булган бөтен тормыш юлын китереп җиткерә алды. Хупҗамал үзен әдәпсез тотарга, нинди дә булса тупаслык эшләргә, талашырга мөмкин. Әмма асылда ул искиткеч юмарт күңелле, тормышны, хезмәтне ярата торган кеше.

Баштарак аңа карата уянган җиңелчә яратмау тойгысы тора-бара гаҗәпләнү хисе белән, аңа ышану һәм аны ярату хисе белән алмашына. Көннәрнең берендә стандагы электр чыбыгы өзелә, югары көчәнешле ток бер эшчене куырып ала. Анымоны уйлап тормастан, Хупҗамал коткарырга ташлана. Коткарам дип, үзе һәлак була. Аның үлеме йөрәктә сыкрау һәм кызгану хисләре уята.

Хупҗамалдан башлап, тормыш тарафыннан кыерсытылган, кимсетелгән, әмма бирешмәгән хатын-кыз йөрәге темасы Әсфәндиярова башкарган күп рольләр буенча кызыл җеп булып сузыла. Э. Альтның «Сукыр»ы кебек әсәрендәге Дианаы һәм башкаларны алыйк. Инде шушы рольләрдә үк, аннан соң үзе башкарган иң уңышлы образлардан «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Хәдичә (бу роль өчен аңа Тукай премиясе бирелде), Клея («Кол»), Тугина («Соңгы корбан») рольләрендә Шәхсенәм камил осталыкка ирешә. Әлеге рольләрдә актриса соң дәрәҗәдә табигый һәм төгәл. Аларны уйнау өчен ул артык көчәнми дә кебек. Әмма менә шул тышкы табигыйлек артында күп хезмәт, йокысыз төннәр тора. Актрисаның барлык образлары сәхнәдә уйлый беләләр. Әсфәндиярова һәр рольнең «икенче планы»н сизәргә булыша, бу исә ул башкарган образларны күп мәртәбә баета төшә. Аны психологик кичерешләр мәктәбенең күренекле бер вәкиле дип санарга мөмкин. Шуңа да ул башкарган рольләрне караганда тамашачы битараф утырмый, актрисага кушылып кайгыра, дулкынлана.

Авыр язмышлы, катлаулы, каршылыклы характерлы Хәдичә образына карата Әсфәндиярова тамашачыда тирән теләктәшлек хисе уята. Әсфәндиярованың иң яраткан героиняларыннан Хәдичә — язмыш тарафыннан кыерсытылган, бәхетсез, әмма туктаусыз рәвештә үз урынын, үз бәхетен эзли торган кеше. Кайгысын эчкә йотып, кеше алдында тыныч, хәтта гамьсез күренергә тырыша торган хатын. Аның күңел төбендәниләр барын соң дәрәҗәдә моңсу күзләре генә сөйли.

Хәдичәнең мәхәббәтендә дә шатлык һәм шигърият юк, бары ялгыз хатынның драмадан трагедиягә әйләнеп барган язмышы гына. Тормышның бөтен мәгънәсен Хәдичә Ильяста, аңа булган көчле мәхәббәтендә күрә. Ул инде мәхәббәтнең ләззәтен беренче кат татый торган яшь җилбәзәк түгел. Юк, ул күпне күргән, ниһаять, үзенең бәхетен очраткан ялгыз хатын. Бәхете — Ильяс аның. Аның өчен ул барысына әзер, бөтен нәрсәгә риза. Ильясның өйләнү хәбәре аңа никадәр авыр һәм никадәр нык тәэсир иткәнен белсәгез иде. Бу хәбәрне китергән Җантайны ул көлеп кенә тыңлый. Ул әле

ышанмый, моңа ышану мөмкин түгел. Шуннан, хәбәрнең раслыгына ышангач, кинәт катып кала, күзләре тонықланып китә һәм ул кычкырып көләргә тотына... Көлү тавышы тора-бара авыр, басынкы үксүгә әйләнә. Ул тормышта беренче тапкыр яраткан кешесен югалта. Берәр ел яшәп, Әсәл белән кычкырышканнан соң, Ильяс өеннән китә, Хәдичә кабат аны үз канаты астына ала.

Ике хатынның очрашу күренеше искиткеч көчле. Әсәл, баласын күтәреп, автобазага, Хәдичә янына килә. «Дөресме?» — аның бары шуны гына беләсе килә. Бу чандыр, бәләкәй хатында күз яше дә, ялыну-ялвару да юк. Ул баласын кочаклаган хәлдә күзләрен тутырып Хәдичәгә карап тора-тора да китеп бара, бөтенләй китә. Әүвәл каушап калган Хәдичә: «Ильясны барыбер бирмим», дип кычкырына башлый, әмма аның бу тышкы батырлыгы астында күпме ялыну, күзләрендә күпме кайгы һәм хәсрәт яшеренгән. Тик шулай да, Әсәл чыгып киткәч, инәлеп-ялварып Ильясны куа, бар, ди, хатыныңны тотып кал, ди. Ильясның чын-чынлап бары Әсәлне генә яратканын ул сизеп тора. Шул ук вакытта бәхетле булырга теләү хисе аны әрле-бирле ташланырга, бер — хатынның артыннан йөгер дип, бер — китмә дип Ильяска ялынырга мәҗбүр итә. Бу рәвештә икеләнү, нишләргә белми азаплану Хәдичә күңелендәге яраның тирәнлеген ныграк аңларга ярдәм итә. Тышкы яктан Хәдичә тыныч кебек, вакыты-вакыты белән хәтта бәхетле дә кебек, асылда ул гаять бәхетсез кеше. Ике хатын — Әсәл һәм Хәдичә бер үк кешене яраталар. Берсенең мәхәббәткә тулы хакы бар, икенчесенеке бөтенләй юк кебек. Тик сөю хисләре һәм газапланулары икесенеке дә шундый көчле, тамашачы аларның икесенә дә теләктәшлек күрсәтергә мәҗбүр була. Хәдичәгә исә, Әсәл белән чагыштырганда, теләктәшлек хисе уяту күп читенрәк. Әмма Әсфәндиярова үз ролен тиешле югарылыкта башкарды. Бик катлаулы һәм каршылыклы образдан ул авыр язмышлы, ирләрчә нык хатын-кызның күркәм образын иҗат итә алды.

Әсфәндиярованың соңгы еллардагы иҗатында аерым урын тоткан образларның тагын берсе, мөгаен, Клеядыр. Бу образда актриса иҗатына хас ике тема, ике буяу бергә кушыла. Без Дилбәр, Эсмеральда рольләре белән бәйле комедиячел линияне һәм актриса яраткан икенче теманы, драматик язмышлы образларны күздә тотабыз. Клеяда бу мотивлар бергә кушыла, һәм безнең алда күп кырлы, катлаулы характер туа. Ксанф һәм Эзоп белән булган мөгамәләләрендә ул төрле яктан ачыла. Ире янында ул иркә патрицианка, ярыйсы ук кыланчык, назлы бер хатын, хәтта уенчык дияргә була. Ихтимал, Эзоп белән очрашканга кадәр ул күпмедер күләмдә, чыннан да, шундыйрак булгандыр, тормышның мәгънәсе турында да әллә ни баш ватмагандыр. Эзоп белән очрашу аның моңарчы йоклаган миен уятып җибәргәндәй була. Эзоп белән аңлашу күренешендә аның характеры аеруча нык ачыла. Башта Клея аның мәхәббәтен гадәти алымнар белән яуларга тели. Шуңа да, икәү генә калгач, Клея чытлыкланып аңа сырышкан була, кыланчык-иркә тавыш белән аңа гашыйк булуы турында сөйли. Баксаң, әндый корал биредә яраксыз икән. Аның кыланышларын Эзоп шактый салкын һәм битараф каршылый. Үзе теләгән табигый аңлашу килеп чыкмавын күреп, Клея нервыланырга тотына. Ул кинәт аңлап ала: Эзоп бөтенләй башка, ул аңламаган кеше икән. Аңа яраклы ачкыч эзләп, үз арсеналындагы чараларның һәртөрлесен сынап карый башлый. Ул әле киреләнә, капризлана, йомшак күңелле иркә хатын булып кылана, ул да түгел, зәһәр, усал кешегә әйләнеп карый. Һәм менә зур саклык белән генә Эзоп Клеяның башыннан сыйпый, аның башын үз җилкәсенә сала. Бер мәлгә тынып калалар. Менә шунда гына Клея тыштан ямьсез бу кешедә никадәр зур мәхәббәт булуын аңлый. Уйнап маташуның эзе дә калмый. Клея акыллы хатын, ире кулында уенчык кына булуын аңлаган хатын булып кала. Һәм шул моменттан башлап үзе теләгән кешене сөяргә хакы булмаган, тормышта уенчык урынына йөртелүче драматик язмышлы хатын белән очрашабыз. Шушы моменттан башлап без Әсфәндиярова башкарган образда берьюлы ике кеше яшәвен сизәбез, аларның берсе — тыштан чибәр, шат күңелле кыланчык хатын, икенчесе — уйлый-кайгыра белә торган нечкә күңелле, яралы күңелле нәфис җан иясе.

Бу һәм кайбер башка рольләрдә Шәхсенәм безнең алга чын милли татар артисткасы булып килеп баса. Бу сыйфат ул башкарган образларның үз-үзләрен тотышларында, аларның аеруча тыйнак һәм оялчан булуларында нык сизелә. Әйтик, Юлия Тугина белән Прибытков очрашкан күренешне рус актрисасы, мөгаен, башкачарак



*Әсфәндиярова Клея ролендә.*

уйнар иде. Әсфәндиярованың Юлиясе — шактый тыйнак, ирләр белән кыланырга ояла торган, үзенең хурлыклы хәлдә калуыннан уңайсызлана торган кеше.

Әсфәндиярова уйнаган рольләр турында сөйләгәндә, без берничә тапкыр актриса сәхнәдә уйлый белә, үз рольләренең «икенче планын» җиткерә ала дип кабатладык. Мондый сыйфатлар аны бүгенге көн, заманча артисткалар белән бер рәткә куя. Мәшһүр рус режиссеры Г. Товстоногов бик дөрес яза: «Артист сәнгатен заманча иткән төп сыйфат дип мин интеллектны, фикер киеренкелеген саныйм. Әгәр элегрәк бу сыйфат чын-чыннан зур берничә художникка гына хас сыйфат булса, хәзер исә ул һәр башкаручының стилендә төп һәм хәлиткеч нәрсә булырга тиеш. Сәхнәдә кичерешле итеп уйлый белми торып, актер сәнгате заманча була алмый». Дөрес, биредә төрле яссылыктагы төшенчәләрне үзара бутарга ярамый. Әгәр син уйлый беләсең икән, син инде шәп актер булдың дигән сүз түгел. Талант һәм интеллект бергә кушылып кына актерны заманча итәләр. Ш. Әсфәндиярованы минем шундыйлар рәтенә кертәсем килә. Без актриса башкарган төрле рольләргә тукталдык. Аның иҗатына хас берничә төп сыйфат хакында сөйләдек. Әмма Әсфәндиярова өзлексез эзләнә торган иҗат кешесе. Ул үз сәләтенең яңа якларын эзли. Мәрҗан Даянова («Гөлҗамал») һәм картаеп, корышып беткән Карчык образларын («Бәйрәм кичендә») шул эзләнү юлындагы рольләрдән санарга кирәктер.

Бу актрисаның тынгысыз характеры турында, төрле характердагы рольләрне башкаруыннан тыш, тагын бер нәрсә сөйли. Һәр яңа рольдән соң ул алҗытып бетерә: начармы, әллә яхшы чыктымы, ди. Премьерадан соң да күп көннәр буена ролен шомарту өстендә эшли. Шуңа да мин үзенең кителмәгән рольләре белән Әсфәндиярова безне бер генә мәртәбә сокландырмас әле дип уйлыйм. Чөнки хәзер ул шундый яшьтә, талантының иң югары ноктасында. Озаккарак сузылсын иде ул югары нокта!

## Гасим Лотфи

# УНИКЕНЕҢ БЕРСЕ

XIX гасырның соңгы чирегендә, бигрәк тә XX гасыр башларында татарлар арасында да яңару хәрәкәтенең шактый көчәеп китүе һәркемгә билгеле. Бу чорда күп кенә шәһәр һәм авылларда дини белемнәр бирү өстенә, аларда дөньяви фәннәр дә укытыла башлаган яңа төр мәдрәсәләр («Галия», «Хөсәения», «Буби») ачыла. Матур әдәбият үсеш ала, газета-журналлар чыга башлый. Менә шушы яңалыклар, никадәр генә тыярга тырышмасыннар, яшь күңелләргә үтеп керә, аларны борчылырга, уйланырга мәҗбүр итә. Укучы яшьләрнең аңлырак өлешендә муллалыкка, муллалар гына хәзерләргә сәләтле булган мәдрәсәләргә нәфрәт уяна. Алар моннан котылу юлларын эзләргә керешәләр.

Элекке Лаеш өязенең Теләче волосте Югары Кибәхуҗа авылында унике бала атасы Госаметдин хәзрәт корган үтә тар рамкаларда тәрбияләнгән Гаяс та, качып-посып булса да, газета-журналлар алдыра, матур әдәбият укый, яңа фикерле яшьләрнең сүзләренә колак сала башлый.

1904 елда (аңа әле ни бары 13 яшь була) Гаясны да атасы Кышкар мәдрәсәсенә илтеп тапшыра. Ләкин күзләре инде яхшы ук ачыла төшкән үсмер бу мәдрәсәдә артык калырга теләми. Язга кадәр бәйдәге эт кебек яши дә җәен моннан ничек тә таярга ниятли. Кая да булса китү өчен исә аз булса да акча кирәк. Ул кулына эләккән акчаны, тиенләп, җыярга тотына. 1905 елның көзендә, бик кыенлыклар белән булса да, Гаяс Оренбург шәһәренә барып җитә. Анда «Хөсәения» мәдрәсәсен эзләп таба.

Гаясны мәдрәсәгә кабул итәләр. Ярты елдан интернатка тиешле акчаны кертеп, бик тырышып укый башлый. Әлбәтә, яхшы өлгерүче укучылардан берсе була. Ул, башлыча, иң кыен саналган риазият (математика) дәресләреннән яхшы өлгерә. Шуны исәпкә алып, уку елының икенче яртысында аны интернатта бушлай торучылар исемлегенә кертәләр.

Ул чордагы татар шәкертләре, җәй буе төрле кара һәм авыр эшләр эшләп, кышлык акча хәзерләргә тиеш булалар. Шәкерт, Мәкәрҗә ярминкәсенә барып, повар, официант булып эшли, тиречеләргә ялланып, тире киптерә, диңгез буйларына китеп, балык промыселларында эшли, пристаньнарда грузчик, носильщик булып җәйне үткәрә. Иң яхшы дигәндә, казакъ далаларына барып, укытучы булып эшли, ит ашап, кымыз эчеп кайта. Татар шәкертләренең бу ачы язмышын Гаяска да шактый татырга туры килә.

1905 елгы революция тәэсирендә шәкертләр хәрәкәте шактый көчәеп китә. Аның шифалы җилләре заманының алдынгы мәдрәсәсе саналган «Хөсәения»гә дә барып җитә: шәкертләр мәдрәсә администрациясе алдына байтак таләпләр куялар. Идарә ул таләпләрне тулысынча канәгатьләндермәгәч, шуңа протест йөзеннән, 1907 елда 40 лап шәкерт мәдрәсәне ташлап чыга. Гаяс бу хәрәкәтне башлап йөрүчеләрнең берсе була. Мәдрәсәне ташлап чыккан шәкертләр, оешкан рәвештә, хәзерге Әгерҗе районы Иж-Буби авылындагы мәдрәсәгә барып керәләр. Мәдрәсә, авыл җирендә булуга карамастан, төрле фәннәр, рус теле һәм башка телләр укытылу ягыннан заманына күрә бик алдынгы санала.



һәр төрле яңалыкка бик каршы Госаметдин хәзрәт Буби мәдәррисләренә тагын да начар карый, аларны «Буби поплары» дип кенә атый торган була. Үз улының шул мәдрәсәгә барып керүе аны бөтенләй шаштыра, ул хәтта улының исемен телгә алырга да теләми. Гаяс, гозере төшеп, атасы каршына кайткач (укуын дәвам иттерү өчен, ул чит илгә китәргә уйлый, чит ил паспорты алу өчен исә атасыннан язу кирәк була), күңеле тәмам бәрчәеп каткан ата улының сәламен алмый, гозерен тыңламый. Гадәттә иң ачуы килгәндә дә кулына ирек бирү гадәте булмаган Госаметдин хәзрәт егетнең яңагына нык кына итеп берне кундыра да, шуның белән бөтен ара өзелә...

Ләкин үз көченә таянырга күнеккән яшь егетне бу хәл генә юлыннан туктата алмый. Киңәшчеләр, ярдәмчеләр табыла: 1909 елда 18 яшьлек татар егете, Кара диңгезне кичеп, Төркиягә барып җитә, Истамбул шәһәрендәге бер лицейда укуын дәвам иттерә..

Кайчакта көтмәгәндә сәртенеп китәргә, шуның белән бөтен тормыш юлыңны бозып ташларга мөмкин. Шулай бер вакыт, лицейда укуның икенче елында, әдәбият дәресенә ниндидер бер ят әфәнде кереп утыра. Андый вакытта, билгеле инде, укытучылар яхшырак исәптәге укучыларга таяналар. Әдәбият укытучысы Гаяска мөрәҗәгать итә:

— Әйтегез әле, Гаяс әфәнде, «истигарә» дип нәрсәгә әйтәләр, аңа нинди мисал китерә аласыз?

Гаяс истигарә (метафора) бер әйберне икенче әйбергә охшату икәнен әйтә. Мисалга «Госман әфәнде көлебдер» (ягъни эт — Г. Л.) дигән җөмләне китерә. Кунак әфәнде шунда ук урыныннан сикереп тора да чыгып китә. Чөнки Мәгариф министрлыгыннан килгән бу кеше үзе дә Госман исемле икән! Гаяс, әлбәттә, аны күздә тотмаган була. Шулай да, бу вакыйгадан соң укытучыга да, уку йорты җитәкчесенә дә шактый борчылырга туры килә. Укучы исә лицейдан аз гына очмый кала...

Гаяс, лицейны уңышлы тәмамлап, Бельгиянең Льеж университетына аның фәнни факультетына барып керә. Ләкин бу уку йортын тәмамлый алмый: 1917 елда Европа сугышы башланып, шәһәрне немецлар оккупацияли. Гаясны берникадәр вакыт гражданский әсир итеп тоталар, аннан Бельгиядән китәргә кушалар. Туган илгә кайту мөмкин түгел: Россия сугыш хәлендә. Ул кире Истамбулга кайта һәм, анда университет тәмамлап, лицейда һәм укытучылар семинариясендә математика укыта башлый.

Бу чорда Төркиядә иҗтимагый-политик атмосфера шактый кыза. Истамбул союзниклар гаскәрләре тарафыннан оккупацияләнгәч, студентлар һәм интеллигенциянең сул канаты кискен протестлар ясый. Еш кына җыелышлар, митинглар үткәрәләр. Гаяс та бу көрәшләрдән читтә калмый. Төрле юллар белән Россиядән революцион әдәбият һәм Ленин әсәрләре үтеп керә. Шуларны пропагандалау буенча да күп көнә эшли. «Чит илдә күп авырлыклар баштан кичте. Дөрес, университетны тәмамлап, эшли башлагач, тормыш болай яхшы гына тәэмин ителгән кебек тә булды. Шулай да Төркиядә каласым килмәде, туган илгә кайтырга омтылып яшәдем»,— дип сөйли торган иде Гаяс.

Безнең илебездә Бөек Октябрь революциясе булу хәбәрен ишеткәч тә, ул үзенең шушы теләген тормышка ашыру чарасына керешә. Ниһаять, 1919 елда Одессага кайта. Ләкин бу вакытта әле Одессада деникинчылар хөкем сөрә. Аннан китү мөмкинлеге күренми. Ул 1 татар мәктәбенә мөдир булып урнаша, һәм шушы аны Деникин гаскәрләре сафына мобилизацияләнүдән коткара. Монда Гаяс Кырым подпольесы членнары белән аралаша. Безнең гаскәрләр Одессаны дошманнан азат иткәч, губерна партия комитеты тапшыруы буенча, ул шәһәрдәге барлык мөселманнарның (татарлар, төрекләр, иранлылар) митингларын оештыра, Кызыл Армия сафына ирекләләр туп-

лау буенча эшли һәм, шулар белән берлектә, 1920 елның июнь аенда Мәскәүгә кайта. Аннан озакламый Гаясны Казанга җибәрәләр. Бу нәкъ Татарстан республикасы төзелгән чор була. Кайтуына бер ай тулганда, 1920 елның 16 июлендә, инде ул РКП(б) сафына член итеп алына.

Шулай итеп, иске интеллигенциянең бер өлеше, ничек кенә булса да җаен табып, эмиграциягә качарга омтылган, калганнары саботаж белән шөгыльләнгән бер чорда Гаяс Максудов Совет Татарстанына кайта һәм, һич икеләнеп тормастан, коммунист булып, җиң сызганып эшкә чума. Бу — аның биографиясендәге иң якты сәхифәләрнең берсе дип уйлыйм мин.

Татарстан республикасы яңа гына төзелгән ул елларны күздә тотып, профессор Хәмит Мөштәринең Галимҗан Ибраһимов турында язган истәлегендә: «Ул вакытта математиклардан югары белемле кеше Гаяс Максудов белән мин генә идек», дию бик хаклы. Ә татарлардан чит телләрне яхшы белүчеләр гомумән юк дәрәҗәсендә иде. Чөнки иске җәмгыять безгә бик ярлы мирас калдырды.

Гаяс Максудов, югары белемле математик булу өстенә, күп кенә чит телләр дә белә иде. Ул, үз профессиясе буенча тар белгеч булып кына калмый, ә киң колачлы, күп кырлы совет белгече буларак, партия тапшырган эшләрнең барысына да зур теләк һәм инициатива белән алына. Бу елларда ул башкарган эшләрне санап кына чыгу өчен дә күп урын кирәк булыр иде[1].

Гаяс Максудов төп эшләреннән аерылмыйча, Казан дәүләт университетының математика факультеты профессоры И. М. Гагаев җитәкчелегендә аспирантура үтә, «Дифференциаль тигезләмәләрне академик Чаплыгин ысулы белән якынча интегрировать итү» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Бу хезмәт чит ил журналында да басылып чыга.

Фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәле Гаяс Шәрык педагогия институтында, Казан төзүче инженерлар институтында, Казан дәүләт университетында математикадан дәресләр бирә.

Гаяс агай җәмәгать эшләрендә дә актив катнашты: ул Казан дәүләт университетында һәм аның физика-математика факультетында Совет члены, Мәгариф эшчеләре союзының президиум члены, фән эшчеләре секциясенең председателе, «Татарстан» газетасында редколлегия члены, Татарстанны өйрәнү һәм Татар педагогия җәмгыятьләрендә председатель урынбасары булып эшләде, Казан шәһәр Советы члены, партия оешмасы тапшыруы буенча, комсомоллар һәм Вахитов заводы эшчеләре арасында аңлату эшләре алып баручы иде...

Шул ук вакытта Гаяс Максудов төрле газета-журналларда басылган күп санлы мәкаләләр авторы да. Аның педагогика-методика, мәгариф системасы, әдәби тел, орфография һәм башка темаларга караган күп мәкаләләре бар. Аның татар урта мәктәпләре өчен бастырып чыгарган алгебра һәм тригонометрия дәреслекләре, оригинал хезмәт буларак, үз вакытында тиешенчә бәяләнде һәм Татарстан математика тарихында билгеле урынны алды.

Гаяс агайның Мәгариф комиссариаты системасындагы эшчәнлегенең кайбер якларына тукталып китү дә кирәк булыр. Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендәге Гыйльми үзәк, үз тирәсенә татар һәм рус галимнәрен җыеп, ашыгыч хәл ителергә тиешле күп төрле проблемалар өстендә ныклап эшкә керешә. Ә андый проблемалар җитәрлек: Октябрь революциясеннән соң бик киңәеп киткән эш мәктәпләре челтәрен укытучылар белән тәэмин итү, яңа мәктәпләр өчен программа һәм дәреслекләр төзү, фәнни терминологияне рәткә салу, күптән үк башланган, ләкин әле һаман хәл ителмәгән хәреф, имла мәсьәләсен хәл итү һ. б.

---

[1] Белүебезчә, ул Казанда түбәндәге урыннарда эшләде: Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә матбугат бюросы начальнигы; «Кызыл Армия» газетасының вакытлы редакторы; Шәрык академиясе каршындагы эшчеләр факультетын оештыручы һәм аның мөдире; Татарстан Мәгариф комиссариатында тәрҗемәчеләр секторы начальнигы; «Мәгариф» журналын 1921 елда яңадан оештыручыларның берсе һәм берничә ел буена аның редакторы, редколлегия члены; Г. Ибраһимовтан соң Гыйльми үзәк җитәкчесе һ. б., һ. б.

Гаяс Максудов Гыйльми үзәктә терминология комиссиясенең председателе булып эшли башлый. Шундый җитәкче рольләрне башкару асылда математика белгече булган Гаясны мәгариф өлкәсенә кагылышлы башка мәсьәләләр белән дә актив шөгыльләнергә мәҗбүр итә. Терминология комиссиясе председателе буларак, аның иң беренче эше элек бездә кулланып килгән цифрларны хәзерге һәм барлык халыклар өчен уртак гарәп цифрлары белән, ә математика, физика, химия һәм башка фәннәрдә кулланыла торган тамгаларны латин хәрефләре белән алмаштыру булды. Бу мәсьәлә башта мәгариф эшчеләре тикшерүенә куела, анда Гаяс Максудов доклад ясый. Бу доклад 1921 елда «Мәгариф»нең 1—2 нче санында басылып та чыга.

Озакламый терминология комиссиясенең икенче зур хезмәте — математика терминнары эшләнде. Бу уңай белән фикер алышу тамгалар, терминнар мәсьәләсе белән генә чикләнеп калмый, гомумән татар әдәби теле һәм аның компонентлары турында сөйләшү төсен ала. Гаяс Максудов үз чыгышларында иң җитди мәсьәләләрне алга сөрә. Телдә «саф татарчалык» ягында торучылар, мәсәлән, татар әдәби теленә башка теллләрдән сүзләр алуга каршы булалар. Алар карашынча, халык телендә йөреп тә моңарчы әдәби телгә кермәгән сүзләр, шулай ук борынгы татар телендә булып та хәзер онытылган сүзләр, (мәсәлән, мөдир урынына — узаман, секретарь урынына — язгын, документ урынына — бәти) гражданлык алырга тиеш.

«Мәгариф»нең шул елдагы 3—4 санында Гаяс Максудов, боларга җавап рәвешендә, «Караш аермалары» дигән мәкалә урнаштыра. Мәкаләдә фәнни тамгалар мәсьәләсенең гомумән язу, бигрәк тә тел мәсьәләсенә катнашы юклыгы әйтелә, «катгый ихтыяҗ аңлашылып җитсә, язу өчен дә латинча алырбыз, бу киләчәк өчен бер хәзерләк булыр» диелә.

Татар әдәби теле ничек булырга тиешлек мәсьәләсенә тукталып, Гаяс агай бер генә культуралы телнең дә үз сүзләре белән генә чикләнеп кала алмавын әйтә. Гаяс Максудов чыгышлары, нигездә, «Әдәби һәм фәнни бөтен бер татар теле»нең төп принципларын аңлатуга, киң массага аңлаешлы татар әдәби теле булдыру юлындагы практик чараларга багышланган. Ул әдәби телнең башка телләр йогынтысыннан изоляцияләнгән булуын мөмкин санамый. Телебезгә халыкара сүзләрнең һаман күбрәк керә баруын, рус һәм башка халыклар теле йогынтысын да таный. Әмма башка телләрдән сүзләр алуда билгеле принциплардан чыгып эш итәргә, башбаштаклыкка юл куелмаска тиеш, ди.

Гаяс Максудов орфография мәсьәләсендә дә киң халык массасы өчен уңайлыкны беренче планга куйды. Ул, мәсәлән, орфография мәсьәләләре буенча 1929 елның 20 маенда үткәрелгән конференциядә чыгыш ясап, орфографиянең тар лингвистлар өчен генә булмавын, халык куллануы өчен уңайлы орфография эшләнергә тиешлеген әйтте, фонетик принцип белән кирәгеннән артык мавыгуны тәнкыйть итте, күп кенә практик тәкъдимнәр ясады. Аның бу чыгышы язма рәвештә хәзергәчә сакланган.

Гаяс агай үз фәне математиканы гаять тирәнтен белүче, таләпчән укытучы, оста методист та була. Ул физика-математика кебек төгәл фәннәрне яхшы белмәүче кеше (бигрәк тә техник уку йортларында) уңышлы укый алмый, шунлыктан аннан яхшы белгеч хәзерләнеп чыгуга исәп тотып булмый дигән карашта була. Имтихан вакытларында бу фәннәрдән аеруча таләпчәнлекне алга сөрә. Шуңа күрә аның укучылары математика дәресләрендә үзләрен бик киеренке хис итәләр. Педагогия техникумында Гаястан дәрес алган һәм шигырьләр язу белән дә шөгыльләнгән бер укучының үз көндәлек дәфтәренә:

> Гаяс абзый Максуд җырын җырлап,
> Үз җырымның көен онытым,—

дип язып куюы очраклы хәл булмаска охшый. Гомумән алганда, ул бик күп укучыларының һәм кордашларының хәтерендә җылы хисләр калдырган.

● ● ● ●

Юрий Белостоцкий

# КОРЫЧ КАНАТЛАР

*Республикабызның рус язучыларыннан Юрий Белостоцкий укучыларга үзенең «Төнге кунак», «Текә вираж», «Самолет басулар өстендә оча», «Кыска шырпы» исемле әсәрләре белән таныш.*

*Язучы күптән түгел «Корыч канатлар» исемле яңа китабын тәмамлады. Ул бу китабында Кызыл Байраклы, Суворов орденлы, Татарстан АССР Верховный Советы исемендәге 202 нче Урта Дон бомбардировщиклар дивизиясенең сугышчан юлын сурәтли. Бу дивизия ул вакыттагы иң камил бомбардировщиклар белән тәэмин ителгән була. Алар Татарстан хезмәт ияләренең шәхси хезмәт акчаларына ясала.*

*Түбәндә без укучыларга шул китаптан бер өзек тәкъдим итәбез.*

## I

Һавага чөелгән ракетадан тирә-якка утлы тәңкәләр чәчелде.

— Самолетларга!

Моторларның дәррәү гөрелтесе аэродром читендә изрәп йоклаган яшь имәннәрне сискәндереп уятты, самолет винтлары кузгаткан көчле җил сарутлы яланда вак-вак җитез дулкыннар йөгертте. Очлы борынлы пикировщиклар бер-бер артлы һавага күтәрелделәр һәм, «тугызлы» рәткә тезелеп, көнбатыш якка карап юл алдылар.

...Фронт сызыгы. Биредән, өч мең метр биеклектән, караганда аның бернәрсәсе дә сызыкны хәтерләтми. Ул тар гына елганың ике як яры буйлап уза. Яр буйлары бомба, снаряд чокырлары белән шул кадәр чуарланган, әйтерсең, ул күптән түгел генә чәчәк авыруы белән каты авырып, шулай шадра булып, каралып, котсызланып калган кеше бите. Ә елга, шул хәвефле ярлардан тизрәк котылырга, качарга теләгәндәй, әле уңга, әле сулга бормалана, кинәт кенә бер якка тайпылып, урман эченә чума; аннан чыгуга янә шул ук шыксыз күренешкә юлыга.

Әлегә зениткалар телгә килми. Эскадрилья, анда-санда күренгән өем-өем болытларга ышыкланып, әлеге елга кебек үк бормаланып оча.

Алда — зур тимер юл станциясе. Шул станция аша фронтка бертуктаусыз танклар, туплар, бомбалар, снарядлар төягән үлем эшелоннары агыла.

Кызыл йолдызлы тугыз очкыч, табышын күргән җитез лачыннар кебек, болыт

артыннан атылып чыктылар. Әмма ике мең метр биеклектә инде аларны көчле зенитка уты каршылады, әле уңда, әле сулда, йонтәс бүрекләргә охшаган кара төтен гөмбәзләре ясап, снарядлар ярыла башлады.

Эскадрильядәге иң тиз атучылардан саналган ике экипаж, шунда ук сафтан аерылып, атылган уктай, түбәнгә ташландылар, фашист зенитчылары башына бомба яудырып, кургаш яңгыры сибеп уздылар. Ә башка самолетлар, шул форсаттан файдаланып, «уң пелленг» рәтенә тезелделәр һәм бер-бер артлы станциянең нәкъ үзәгенә ут яудыра башладылар.

Аста, түбәндә, мәхшәр давылы уйнады. Корыч рельслар дугадай бөгелеп, ягулык тутырылган цистерналар, снаряд, бомба төялгән вагоннар утка, ялкынга чорналып һавага очтылар. Көл, тузан, кара төтен болыты тирә-яктагы урман-болыннар өстенә җәелде, кызарып кына чыгып килгән кояшны каплап китте. Шул сөремгә тончыгып, зениткалар да бөтенләй тынып калдылар. Эскадрилья, инде тәмам иркенләп, икенче кат станция өстенә атылды. Яңадан җир тетрәде, яңадан көл, туфрак, тимер-чуен кисәкләре һәм фашист сөякләре бергә аралашып, һавага чөелделәр. Яңадан ялкын телләре үрләде, яңадан кара болыт актарылды.

Шул вакыт кинәт очкычлар рәте буйлап көчле электр тогы узгандай булды.

— Сак булыгыз! Сулда «мессерлар!»

Самолетлар «тугызлы» сафка тезелеп бер-берсенә сыендылар, канатка канат, иңгә иң орынып диярлек дошманга йөз белән борылдылар. Пилотларның куллары штурвалны кысып тоткан, укчы штурманнарның бармаклары һәр мизгелдә пулемет гашеткасын басарга әзер. Пулеметлар, туп көбәкләре, керпе энәләре кебек, төрле юнәлешкә тырпайган. Әйдә, кодрәтеңнән килсә, якынлашып кара!

Һәм чыннан да, алдын-артын уйламастан, тилереп һөҗүмгә ташланган беренче «мессер» искиткеч көчле ут өермәсенә эләгеп, шунда ук читкә тайпылды, ә аның артыннан килгән икенчесе, борылыш ясарга өлгерә алмыйча, утның нәкъ үзәгенә килеп эләкте. Тагын берничә секундтан ул, артыннан кара эз калдырып, аска мәтәлде.

Тик шулай да әле фашистлар чигенергә уйламадылар. Безнең очкычлар рәтен таркатып, аларны берәмләп чуку нияте белән, әрсезләнеп, котырып кат-кат һөҗүмгә ташландылар. Зәңгәр һава гөмбәзен утлы кайчы белән тураклагандай, һәр юнәлешкә пуляләр, снарядлар эзе сызгаланды.

Арадан бер «мессер», хәйләле оста маневрлар ясап, кинәт кенә штурмовиклар янына ук килеп чыкты. Тагын бер секундтан бу тәҗрибәле фашистның утлы кайчысы безнең лачыннарның тыгыз сафын урталай кисеп, хәвефле хәл тудырачак иде. Әмма, ни сәбәпледер, ул ут ачарга ашыкмады. Бер секунд, ике, өч... Менә инде немецның озын кабак кебек какча сары йөзен дә аермачык күрергә мөмкин. Ә ул әле һаман атмый... Ник суза шулай? Нәрсә булды?.. Соңгы секундта гына каушап калдымы? Пулеметы, тубы ватылдымы? Я булмаса, безнең самолетларның канатындагы ниндидер язуларны күреп, шуңа бик сәерсендеме?..

Әйе, шулай булуы да ихтимал. Һәрхәлдә, бу ассның совет самолетлары белән беренче очрашуы түгел. Әмма аларның канатларында кызыл йолдыздан һәм машина номерларыннан тыш бернәрсә дә булмый торган иде. Ә боларда исә фюзеляжның буеннан буена ниндидер язу! Әмма прицел сеткасы аша караганда тиз генә танып булмый...

Әллә шул язуны укырга тырышып соңарды фашист, әллә башка бер сәбәп тоткарлады, ни булса да булгандыр, әмма ул үзе өчен иң уңай мизгелне уздырып җибәрде. Кызыл йолдызлы очкычлар алданрак ут ачтылар. «Мессер», яшен суккандай, кинәт тетрәнеп китте һәм бер яккарак янтаеп, түбәнәя башлады. Бераздан аны кара төтен чорнап алды.

Калган ике «мессер» кабаттан һөҗүм итәргә кыймадылар. Бомбардировщикларга нинди дә булса зыян китерү өметеннән бигрәк, күңелләрен бушату өчен генә тәзәми-нитми тагын бер-ике очередь бирделәр дә тизрәк таю ягын карадылар.

Эскадрилья бернинди югалтусыз, кыр казлары кебек тигез, матур сафка тезелеп кайтып китте. Урманнар, янып көйгән далалар өстеннән инде шактый югарыга күтәрелергә өлгергән коньяк кояшы көмеш канатлардагы язуларны фашист очучысы укый алмый калган әлеге ике сүзне җылы нурлары белән сыйпый иде: «Совет Татарстаны!»

«Совет Татарстаны»...

Куәтле бомбардировщикларның канатларында немецларны гаҗәпкә калдырган бу ике сүз 1943 елның 1 маенда күренә башлады. Ул көнне салкын җил исеп, яңгыр пыскаклап торуга карамастан, Казан аэродромында 202 нче авиация дивизиясе сугышчылары тигез сафка тезелделәр. Әле моннан унике генә көн элек, 19 апрельдә бу дивизиягә Оборона Халык Комиссары приказы белән яңа исем — Татарстан Верховный Советы исеме бирелгән иде...

Самолетлар төзү өчен күп миллион сумнар акча җыйган хезмәт ияләренең теләге шундый иде: Татарстан Верховный Советы исемендәге авиация дивизиясе булдырыл!

Бу вакытта инде дивизия сугышчан тәҗрибә алган иде. Ул Мәскәүдән Донга кадәр утлы юл узды, Минск һәм Бобруйск, Смоленск һәм Вязьма тирәләрендә дошман башына яшен ташы булып атылды. Богучар районында немецларның катлы-катлы ныгытмаларын көл-талкан итеп, пехотага һөҗүм юлы ачты. Әмма бу сугышларда дивизия үзе дә күп кан койды. Идел—Дон арасындагы далалар өстендә күп кызыл лачыннарның канатлары көйде.

Һәм менә шул авыр көннәрдә Татарстан хезмәт ияләре дивизиягә ярдәмгә килделәр. Казан аэродромына тезелгән 102 дәһшәтле машина «ПО-2» («Поликарпов-2») бомбардировщиклары халкыбызның дошманга нәфрәт, үз беркетләренә тирән мәхәббәт билгесе иде. Көч, куәт һәм җитезлек ягыннан ул авыр елларда әле боларга тиңләшерлек бомбардировщиклар дөньяда юк иде. Кабинасының һаваны һәм җирне күзәтү өчен бик уңай булуы очучылар күңеленә аеруча хуш килде, күп һава сугышларында хәтта истребительләрне җиңеп чыгарга мөмкинлек бирде.

Хәтта менә хәзер җирдә, аэродром бетонында тезелеп торган вакытта да, бу машиналар түземсезләнеп һавага омтылгандай тоелалар.

Аэродром өстендә ал байраклар җилферди. Данлы дивизиянең каһарман егетләре байраклар астына тигез сафка тезелеп тын калганнар. Аларга каршы якта кызыл комачка уралган кечкенә генә трибуна. Трибуна тирәсендә республиканың төрле районнарыннан килгән вәкилләр — эшчеләр, колхозчылар, партия-совет җитәкчеләре. Татарстан Верховный Советы Президиумы председателе Динмөхәммәтов та, ВКП(б) өлкә комитеты секретаре Гафаров та шунда, халык арасында.

Әнә Динмөхәммәтов трибунага күтәрелә һәм көр тавыш белән сүз башлый:

— Иптәшләр! Дошман мәкерле рәвештә безнең Ватаныбызга басып керде. Совет кешеләре бердәм булып ил сагына, изге яуга күтәрелделәр. Руслар, украиннар, белоруслар, грузиннар һәм башка милләт кешеләре белән бер сафта Ватан сугышы фронтларында татар егетләре дә үз-үзләрен аямый көрәшәләр. Ә без биредә, тылда, сугышчылардан калышмаска ант итәбез. Сезгә, ил батырлары, өс-башыгызга җылы кием, ашарыгызга туклыклы аш, кулыгызга көчле корал биреп торырбыз. Азыр һөҗүмнәргә барган чакларыгызда һәрчак сезнең турыда уйлаучы, һәрчак сезне кайгыртучы тугандаш татар халкы барлыгын онытмагыз. Без бу машиналарны Сезгә зур ышаныч белән тапшырабыз. Очыгыз, кыю лачыннар! Кансыз дошман өстенә яшен уты булып очыгыз! Бу канатлар сезне кара болытлар аша кояшка, аяз күккә, тыныч һаваларга алып чыксын. Җиңеп кайтыгыз, исән-имин туган җиргә әйләнеп кайтыгыз, ил уллары!

Гомерләре буе завод-фабрикаларда эшләп, куллары сөялләнеп каткан карт эшчеләр, җылы мич башларыннан төшеп, яңадан сабан башы тоткан ак сакаллы игенче агайлар, ирләре урынына тракторга, комбайнга утырган хатын-кызлар бер-бер артлы чыгып сөйләделәр, ут эченә китүче егетләргә хәерле юл, озын гомер теләделәр. Кайнар сүзләр генә түгел, күзләрдә кайнар яшь тамчылары да булды. Әмма өмет өзү, төшенкелеккә бирелү галәмәтләре сизелмәде.

Сугышчылар бу изге сүзләрне йотардай булып, мәңгегә истә калдырырга тырышып тыңладылар... Кем белә, бәлки, шушы минутта шул сафта торган бер очучының күз алдына әле күптән түгел генә үзе эшләп йөргән завод цехлары килгәндер... Цехлар, станоклар. Хәзер инде ул цехларның якты тәрәзәләренә кара пәрдәләр эленгән. Станоклар янына унбиш-уналты яшьлек малай-шалай баскан. Әлеге сугышчының галстуклы энесе дә шунда... Кайчандыр бу станокта аларның әтиләре эшләгән. Ул хәзер

иле яшенә житкәч, кайдадыр еракта, Белоруссия сазлыкларында сапер булып, утлар-сулар аша юллар салып йөри. Заводта аның урынын алган өлкән улы менә бүген дошман өнен туздырырга фронтка оча... Галстуклы малай, буе житмәгәч, станок янындагы агач тартма өстенә баса. Икешәр смена буе шул тартмасы өстеннән төшми, куз кабакларын йокы басып төшә башласа, иреннәрен канатканчы тешләп, йокысын куа. Ник дисәң, шулай кирәк. Ил өчен, фронт өчен кирәк. Ут эчендәге әтиләргә, туганнарга корал кирәк, снарядлар, патроннар кирәк, яңа самолетлар, танклар кирәк. Кирәк! Хезмәтең белән генә түгел, эшләп алган акчаң белән дә фронтка ярдәм итәргә кирәк... Һәм галстуклы малай, агач тартма өстендә ай буе икешәр смена куган чандыр малай, үзенең бер айлык хезмәт хакын «Совет Татарстаны» эскадрильясе фондына бирә.

Казан аэродромында «Совет Татарстаны» эскадрильясе сугышчылары — очучылар, радистлар, укчы-штурманнар, техниклар тезелгән. Алар, тын да алмыйча, якташларының кайнар сүзләрен, изге теләкләрен тыңлыйлар.

Кем белә, бәлки, шунда арадан берсе күптән түгел генә үзе иген игеп йөргән киң колхоз кырларын күз алдына китергәндер... Инде күптәннән солы, печән күрмәгән арык атлар көчәнеп-тырмашып буразна яра. Сабан артында әлеге сугышчының бабасы — Япон сугышында ук ике-өч яра алып кайткан ак сакаллы ветеран. Аңа инде җылы мич башында карт сөякләрен җылытып кына ятасы. Тик ул ятмый. Ул сукага чыккан... Ник дисәң, шулай кирәк. Игә икмәк кирәк, ут эчендәге улларны, оныкларны ач итмәскә кирәк, Туган җирнең игелекле туфрагын, уңдырышлы кара туфрагын бертексез калдырмаска кирәк.

Ак сакаллы ветеран, сугыш һәм кырлар ветераны арып, хәлдән таеп сукадан кайта. Кайту белән, тамагына да ашамастан, сандык актара башлый. Сандык төбеннән, иске оек кунычыннан бер төргәк акча чыгара. Озак еллар тиенләп җыйган, «кара көнгә» дип саклаган акча. Үлемтеккә дип, гүр сәдакасына дип җыйган акча... Менә инде ул кара көннәр. Әмма хәзер үләргә ярамый. Яшәргә, көрәшергә, җиңәргә кирәк! Ерткыч фашистлар үлсен, алар дөмексен. Бу акча — самолет төзелешенә, «Совет Татарстаны» эскадрильясенә!

...Казан аэродромында 102 дәһшәтле самолет. Самолетлар алдында сугышчылар сафы. Сафлар каршында кызыл комачлы трибуна. Трибунада дивизиянең политотдел командиры полковник Шалимов... Трибунада дивизия командиры урынбасары полковник Шевченко... Трибунада 18 нче полкның укчы-радисты старшина Касыйм Насыйров, эскадрильяда кораллар төзәтүче кыз бала — сержант Сәгадәт Сөнгәтуллина...

Аэродромда байраклар җилферди. Аэродромда саф күңеллардән чыккан кайнар сүзләр яңгырый:

— Кыю булыгыз, лачыннар. Кыйнагыз, куыгыз дошманны. Без сезгә ышанабыз!..

— Советлар иленә хезмәт итәбез! Ышанычыгызны акларбыз!

Икенче көнне иртә таңнан «Совет Татарстаны» очкычлары, бер-бер артлы һавага күтәрелеп, канлы көрәш барган якка — Курск дугасы ягына очтылар.

■

Воронеж һәм Дала фронты гаскәрләре бу көннәрдә авыр оборона сугышлары алып барды. Гитлерчылар астыртын рәвештә зур һөҗүмгә әзерләнделәр: Совет — Германия фронтындагы пехота һәм танк көчләренең өчтән икесен шушы фронтларга тупладылар, 2050 самолеты булган 4 нче һәм 6 нчы армияләрне шулай ук бирегә күчерделәр. Алар барлык төр кораллары белән кинәттән һөҗүм итеп, безнең армиягә җимергеч удар ясамакчылар иде. Һөҗүм башлану көнен тирән сер итеп сакладылар. Әмма безнең разведчиклар аларның бу мәкерле планнарын, алдан белеп, хәрби командованиегә җиткерделәр.

5 июль... Кара тәреле танклар иртә таңнан һөҗүмгә хәзерләнеп, фронтның алгы сызыгына төзелделәр, фашист очучылары бомбалар төягән самолетларына карап утырдылар, авыр орудиеләр үзләренең кара авызларын безнең якка бордылар. Әмма шул чак кинәт җир тетрәде. Фашистларның үз башларына бомбалар, снарядлар яуды. Кызыл йолдызлы самолетлар дошманнан алдарак күтәрелеп һөҗүмгә кит-

теләр. Беренче ташкын артыннан икенчесе, өченчесе... Фашистларның зур өметләр баглап хәзерләнгән операциясе үз канына буылып тончыкты.

Канатларына сөер сүзләр язылган очкычлар беренче мәртәбә нәкъ әнә шул көннәрдә немецларга үзләрен таныттылар. Алар, зур-зур төркемнәр булып, һич көтмәгән юнәлештә килеп чыгалар, һич көтмәгән яктан ут ачалар. Күз ачып йомган арада корал складларын, автомашина, танк колонналарын яндырып-туздырып, тиз арада юкка да чыгалар. Белгород, Тамаровка, Грайворон юнәлешендә һәм Прохоровка тирәләрендә «Совет Татарстаны» бөркетләре немецларга аеруча шәп сабак бирделәр. 12 июль көнендә алар, 2 нче һава армиясе частьләре белән берлектә, Гитлерның дүрт йөзгә якын танкысын юк иттеләр. Әмма көрәш корбансыз булмады. Бу көннәрдә һавада «мессер»лар, «фокке-вульф»лар саранча кебек кайнап тордылар. Дәһшәтле һава сугышларында кайчак һәр ике яктан йөзәрләгән самолет катнашты. Бу сугышларда бик күп яшь лачыннар туган ил өчен утка кереп, атылган йолдыз булып яндылар. Сугышның беренче көннәрендә үк очучы Джулай, Косарев, Шерстюк һәлак булды, Писарев, Беркутов экипажлары дуслары сафына әйләнеп кайтмады...

## IV

Гади бер кыр аэродромына «Орлик» дигән исемне кем кушкандыр. «Бөркет оясы» исеме җисемгә күбрәк туры килгән булыр иде. Чөнки бу аэродромнан тиз йөрешле бомбардировщиклар, бөркетләр ояларыннан күтәрелеп киткән кебек, төркеме-төркеме белән төрле сугышчан заданиеләргә оча тордылар.

Икенче августта «Орлик»та да, дивизиянең башка аэродромнарында да көн гадәттәгечә башланды: самолетлар очтылар һәм төштеләр, тукталышларга бензин, су, май тулы цистерналар йөреп торды, машиналарга бомбалар, сугыш кирәк-яраклары төялде. һәм, ниһаять, күптән көтелгән хәбәр: иртәгә һөҗүм. Һөҗүм башланырдан унбиш минут элек дивизия полклары дошманның алгы сызыгын бомбага тотарга тиеш.

...Көнчыгыштан алсуланып таң беленде. Яшел агач ботакларына күмелгән самолетлар тирәсендә инде ыгы-зыгы. Экипажлар кабат-кабат очыш маршрутын, бомба ташлау ысулларын, дошман өстенә килү, зенит тупларына каршы маневр, фашист истребительләре атакасына каршы тору тәртипләрен тикшерәләр; техниклар һәм мотористлар машиналарның частьләрен, детальләрен, борт җиһазларын күздән кичерәләр; корал осталары бомбалар нык эленгәнме, пулеметлар әзерме икәнлеген карый.

Иң беренче торган самолет янында — Сәгадәт Сөнгәтуллина. Ул яшел төстәге пилотка һәм җиңел комбинезон кигән. Сәгадәтнең хәрби дәрәҗәсе — кече сержант, ул авиация кораллары остасы. Күптән түгел ул хөкүмәт бүләгенә тәкъдим ителде.

Сөнгәтуллина янында А. Ватинский, экипажның укчы-радисты старшина Касыйм Насыйров. Алар икәүләшеп пулеметларның төзеклеген тикшерәләр. Ә «ПО-2» самолетында алар икәүләп: берсе — эре калибрлы, тубың бер якта торсын; икенчесе — шкас — тиз ата торган, күчереп йөртмәле пулемет. Димәк, самолетны, дошман истребительләреннән саклану мөмкинлеге ышанычлы. Алай гына да түгел, пулеметлар, әгәр биеклек мөмкинлек бирә икән, дошманның җирдәге хәрби көчләренә: солдат һәм офицерларына, автомашиналарга, тимер юл эшелоннарына да кургаш яңгыры сиптерә.

Самолетта радиостанция дә тәртиптә, команда пункты белән элемтәдә тоткарлык булмаячак.

Сәгадәт читкәрәк китә, һәм шул вакытта бомбардировщикларның моторлары үкерергә керешә, пропеллерлар җиленнән аэродром өстендәге үләннәр җиргә иелә.

Менә самолетлар бер-бер артлы күккә күтәрелә. Күптән түгел ВКП(б) өлкә комитеты секретаре С. Гафаров һәм республика Верховный Советы Президиумы секретаре Г. Шәмсиева җитәкчелегендәге Татарстан хезмәт ияләре делегациясе дивизиягә тапшырып киткән Кызыл Байрак, аларны озатып, иртәнге талгын җилдә йомшак кына җилферди.

Касыйм утырган самолет беренче «тугызлык»та. «Тугызлык» өчпочмаклы булып төзелгән сугышчан сафта оча. Биеклек зур түгел — 1500 метр. Бу биеклектән җир өсте ачык күренә. Әнә тузан туздырып пехота бара, туплар таккан тягачлар ашыга, урман-

нан бер-бер артлы танклар чыгып, дошманның алгы сызыгына ашыга. Дошманның алгы сызыгы да ерак түгел инде, хәзер үзен белдерә башлаячак ул. Дөрестән дә, Менә аның зениткалары телгә килде. Ләкин дошман бомбардировщиклар алай түбән очып килерләр дип уйламаган булса кирәк, снарядлар бик югары ярыла. Дошман аңына килеп дөрес исәп-хисап ясаганчы, самолетлар бронетранспортерлар, автомашиналар тупланган урыннарга, артиллерия позицияләренә бомбаларын ташларга өлгерделәр. Җир өстен төтен һәм ут каплап алды, солдатлар һәм офицерлар, бронетранспортерлардан, машиналардан төшеп, төрле якка сибелделәр. Касыйм Насыйров һәм башка экипажларның пулеметчылары алар өстенә кургаш яңгыры сиптерделәр.

Эскадрилья икенче тапкыр әйләнә, бу юлы уң якка, «тигр»лар, «фердинанд»лар, «пантера»лар тупланган урынга һөҗүм итә. Алар фашистларның Курск тирәсенә әле генә китерелгән яңа сугыш машиналары иде. Бу машиналарга, аларның бронясына, кечкенә Гитлер һәм аның нәрченнәре зур өмет баглаганнар. Шуңа күрә экипажлары да аларның машиналарында калдылар: имеш, мондый калын броняга һични куркыныч түгел. Әмма безнең самолетлар алар өчен махсус «көчтәнәч»ләр китергәннәр иде. Бер ярым, ике ярым килограммлы бомбалар, кечкенә булсалар да, һәртөрле броняны яндыруга сәләтле бомбалар, яңгыр булып ява башлагач, «тигр»лар, «фердинанд»лар, коры ботак өеме кебек, утка төренде, якындагы урманга да ут капты.

Әмма хәзер инде дошманның зенитчылары да аңнарына килеп өлгерделәр, самолетлар утлы ташкын эчендә калды.

Команда — кайту ягына борылырга! Бу бик вакытлы булды, бер самолет зарарланырга да өлгергән иде инде. Бәхеткә каршы, штурман да, очучы да яраланмады. Яшь очучы Петр Москальчук самолетына да снаряд тиде, аның сул як моторы сафтан чыкты, тизлеге кимеде.

— Аэродромга юл тот! Без синең арттан тезеләбез.

Шлемофон наушникларында шул ук боерулы тавыш тагын яңгырады:

— Бөтен төркем белән Москальчукны томалыйбыз...

Сигез самолет Москальчукның зарарланган машинасын камап алды. Тизлек сәгатенә 250 километр гына булса да ярты сәгатьтә аэродромга исән-сау кайтып җиттеләр. Беренче Петр Москальчук самолеты утырды. Бомбардировщикны ике моторы эшләп торганда да әле утырту бик җиңел түгел. Петр бер мотор белән дә менә диген итеп утыртты. Ул кабинадан сикереп төште дә, парашют бауларын чишә-чишә, малайларча келеп җибәрде. Көлмәскә ни: аның сугышчан дуслары менә дигән, ышанычлылар. Андыйлар белән утка да, суга да керергә була.

Касыйм Насыйровның да күңеле күтәренке: очыш уңышлы узды, югалтулар булмады, ә фашистларның астын-өскә китерделәр.

Оэакламый барлык самолетлар да үз аэродромнарына кайтып утырдылар. Ләкин озакка түгел. Тагын ягулык алдылар, тагын бомбалар тактылар, тагын дошман өстенә очтылар.

Ә бер көннән соң, кичен, землянкада дивизия очучылары радио аша Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдән Белгород һәм Орел шәһәрләрен азат итүче сугышчылар хөрмәтенә ясалган артиллерия салюты авазларын тыңладылар.

Шул ук айда Харьковны азат иткән өчен, ноябрьда борынгы Киев шәһәреннән дошманны куган өчен Ватаныбыз башкаласы алар хөрмәтенә салют бирде. Дивизиянең Украина башкаласын азат иткәндә күрсәткән батырлыкларын хөкүмәтебез Кызыл Байрак ордены белән бәяләде.

Шуны да әйтергә кирәк, Киевны алыр алдыннан Татарстан хезмәт ияләре делегациясе тагын бер кабат фронтка килде. Делегация үзе белән бергә бик күп бүләкләр, хатлар алып килгән иде. Аларның яхшы теләкләре, бу хатлар һәм бүләкләр сугышчыларны яңа батырлыкларга рухландырды.

## VI

Умань...

Фашистларның андагы аэродромнары безгә һич кенә дә тынгылык бирми. Штурмовиклар яки бомбардировщиклар ул тирәгә килеп чыгуга, «мессершмит»лар котүләре белән безнең самолетларга ябырылалар. Берничә самолетыбызны бәреп тә төшер-

деләр. Алай гына да түгел, төннәрнең берендә зур бер төркем бомбардировщиклары килделәр дә, безнең Лебединда урнашкан полк аэродромы өстен парашютка тагылган яктырткыч белән яктыртып, бомба коярга тотындылар. Аэродромда, бик табигый, ыгы-зыгы купты. Берничә сугышчы һәлак булды. Дөрес, капонирларга яшерелгән самолетларга зыян килмәде. Шулай да аларны икенче төннә дә килеп бомбага тотулары мөмкин иде бит. Шуңа күрә дивизия командиры генерал С. Нечипоренко, Лебединны калдырып, Прилукига күчәргә боерык бирде.

Умань тирәсендәге аэроузәк безнең җир өсте гаскәрләренә дә җитди куркыныч тудыра иде. Ә алар бу вакытта фашистларны Корсунь-Шевченко боҗрасына урау операциясен тәгәлләп киләләр иде инде.

Бу аэроузәкнең урнашкан урыны кайда соң? Әмма моны белү кыен, чөнки фашистлар ул тирәгә бик күп ялган аэродромнар төзегәннәр иде.

Бу көннәрдә дивизия командиры бик борчулы йөрде. Ул берничә тапкыр штаб начальнигы Н. Никитин һәм флаг-штурман Н. Бурако белән киңәште. Ниһаять, бер нәтиҗәгә килделәр: разведка самолеты җибәреп карарга! Әлбәттә, уңышка ирешү мөмкинлеге бик чикле, самолетның әйләнеп кайтмавы да бик мөмкин иде. Шулай да тәвәккәлләмичә һич ярамый.

Ләкин кемне җибәрергә?

Дивизиядә үзләренең батырлыклары, кыюлыклары белән танылган экипажлар күп. Ләкин бу заданиене үтәү өчен кыюлык кына җитми, тимер ихтыяр, түземлелек, салкын канлылык, хәйләкәрлек кирәк. Бу эшкә яраклы итеп, бертавыштан, 18 нче полкның эскадрилья командиры капитан А. Важинский экипажы сайланды.

...Александр Важинский, аның сугышчан дуслары штурман — Юлиан Кудрявцев, укчы-радист Касыйм Насыйров исемнәре күптән инде дивизиядә генә түгел, бөтен һава армиясенә билгеле. Аларның батырлыгы бөтен фронтка шаулады.

Мәсәлән, менә шундый бер хәл булды. Безнең командование немецларның бик нык маскировкаланган объектлары[1] янында аэродром барын белеп алды. Бу аэродромдагы истребительларнең ни эшләүләре, нәрсәне яки кемне саклаулары безнең өчен сер иде. Аэродром шул кадәр нык саклана, аңа якын килү һич мөмкин түгел диярлек иде. Бер болытлы көнне бик астан, агачларга тиярлек дәрәҗәдә биеклектә Важинский экипажы юлга чыкты. Бик җаваплы һәм катлаулы очыш иде бу. Әмма Важинский белән Насыйров тыныч иделәр, чөнки алар ышандылар: штурман Юлиан Кудрявцев югалып калмаячак, самолет тиешле вакытта тиешле урынга барып җитәчәк.

Бер сәгать очканнан соң, Кудрявцев болытларны тишеп чыгарга команда бирде. Важинский штурвалны үзенә тартты. Прибордагы ук 300 метр турысына килеп җиткәч, аста җир күренде. Тиздән — аэродром. Шул арада булмады, самолетны дүрт «мессершмит» камап алды. Димәк, чыннан да бик мөһим аэродром булырга тиеш. Әмма үзләре бик кыен хәлдә калдылар бит әле. Ычкыну мөмкин түгел. Борылырга да, югарыга менәргә дә мөмкинлек юк, качып кара — урталай киселәсеңне көт тә тор. Шулай итеп, бу бетү микәнни инде?

Ике яктан канатларын канатка терәп диярлек ике «мессер» оча. Менә берсе үз артыннан баруны таләп итеп канатларын чайкап куйды. Димәк, үз аэродромнарына утыртмакчылар. Берни эшләп булмый, ризалашкан булырга туры килә. Важинский, җавап итеп, самолет канатларын җиңелчә генә чайкатты... Фашистлар тынычландылар. Икесе хәтта, үзләрен артык санап, биеккә күтәрелделәр дә болыт эченә кереп югалдылар. Мөгаен, тагын бүтән самолетлар юкмы икән, дип карыйлардыр. Калган икесе дә, безнең самолетка якын ук килеп, үзләрен маневрлау мөмкинлегеннән мәхрүм иттеләр. Менә аста дошман аэродромы: вакыт! — штурман Кудрявцев Важинскийның тезенә төртте. Ә Важинский кнопкага басты, шунда ук бомбалардан арынган самолет, җиңеләеп китеп, югарыга омтылды һәм, болыт арасына кереп, күздән югалды!..

...Менә бу юлы да дивизия командованиесе заданиегә шушы экипажны җибәрергә дигән карарга килде. Важинский, Кудрявцев һәм Насыйров бу заданиене менә дигән

---

[1] Бу объект, соңыннан билгеле булганча, Гитлер ставкасының Винница янындагы җир асты оясы («Бүре оясы») булып чыкты.

ктеп утәделәр [1]. Алар ике аэродромны фотоларга төшерделәр. Бу аэродромнарда дошманның 130 га якын бомбардировщигы һәм истребительләре барлыгы беленде.

...Христиновка торак пункты янындагы беренче аэродромга алты истребитель сагында 797 нче полкның капитан Семен Ермак командалыгындагы эскадрильясе очты. Дошман зенитчиклары аларны көтмәгән иде. Бер минуттан аэродром танырлык та түгел иде инде: туфрак, ут, төтен, самолет ватыклары бергә аралашып, күккә очты. Дошман истребительләре һавага күтәрелә дә алмадылар.

Шул ук вакытта 18 нче полкның Петр Псурцев, Александр Морозов, Петр Перлукин һәм Иван Воробьев командалыгындагы эскадрильяләре Умань янындагы икенче аэродромга һөҗүм итте. Ләкин бу аэродром һәр төрле калибрдагы орудиеләр белән бик нык сакланган иде. Безнең самолетларны тоташ ут стенасы каршы алды. Петр Псурцев үзләрен саклап килүче истребительләргә, аскарак төшеп, дошман батареяларына пулеметлардан һәм туплардан ут ачарга боерды. Дошманның ут системасы какшады. Эскадрильяләр алдан билгеләнгән вакытта тиешле урынга барып җиттеләр һәм аэродромга яңгыр урынына бомба яудырырга керештеләр. Биредә дә дошманның бер генә истребителе дә күтәрелергә өлгерә алмады.

Уманьда да, Христиновкада да дошманның барлык самолетлары диярлек, складлар һәм корылмалар юк ителде.

Бу безнең пехотага һәм танкларга юл ачты, һәм дүрт көннән соң, 1944 елның 28 январенда, дошманның зур каршылыгын җимереп, Беренче һәм Икенче Украина фронты гаскәрләре Звеногород янында дошманның зур группа гаскәрләрен боҗра эчендә калдырдылар. Ә анда фашистларның ун дивизиясе, бер бригадасы, бәрнчә танк, артиллерия һәм инженер частьләре бар иде.

Идел буенда Паулюс армиясен җимергәннән соң, Бөек Ватан сугышында бу немец фашист гаскәрләрен икенче зур камалышта калдыру иде.

---

[1] Бу очышта күрсәткән батырлыгы өчен Касыйм Насыйров Икенче Дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнде. Соңрак Беренче Дәрәҗәсенә дә лаек булды. 1944 елда Львов шәһәре янында ул һәлак булды.

Җәүдәт Фәйзи

# ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ[1]

## 97. Кара карлыгач микән




Сандугачым, әйт үземә,
Кайсы талга кунасың?

Кушымта:

Кара карлыгач микән,
Сары сандугач микән
Аны үстергән әнкәсе?

Күзем йомсам, күз алдымда
Торган кебек буласың.

Кушымта.

Сандугачлар басып сайрап
Сындырды гөлләремне.

Кушымта.

Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган күңелләремне.

Кушымта.

[1] Ахыры. Башы журналыбызның 1970 елгы 1 санында.

Сандугачлар иләшкән
Су эчәргә миләштән.

Кушымта.

Кайгыларым бетәр иде,
Сине күреп сөйләшсәм.

Кушымта:

Кара карлыгач микән,
Сары сандугач микән
Аны үстергән әнкәсе?

* * *

Бу кушымталы җырны кайсы төркемгә кертү хакында күп уйланырга туры килде. Моның берничә сәбәбе бар.

Мин аны беренче мәртәбә 1925 елда Казанда ишеткән идем. Һәм ул «Наган көе» дип атала иде. Бары 30 нчы еллардан соң гына «Кара карлыгач микән» дигән исем белән яңгырый башлады.

Хәтерлим, җырның мин ишеткән беренче вариантында кушымта:

Атма, бәгырем, наган,
Йөрәгем яна
Шул наганның тавышына,—

рәвешендә иде. Кушымтаның моннан башка вариантлары да булган икән. Арадан берсе, мәсәлән, түбәндәгечә:

Атма мылтык-наган,
Куркам ла яман
Шул наганның тавышына.

Димәк, көй ниндидер фаҗигале вакыйгага уңае белән чыгарылган. Ләкин нинди вакыйгага ул!

Үзем бу турыда шуны ишеткән идем: имеш, 23 нче елларда бер егет Кабан күле буендагы ниндидер йортта туйда була. Шунда кәләшне дә, кияүне дә һәм үзен дә атып үтерә. Икенче версия буенча, бу хәл гражданнар сугышы вакытында була. Бер хәрби кеше, көнләшүдән, үзенең сөйгәненә наганнан ата. Өченче версияне революция ветераныЛәтыйф ага Гомәров сөйләде:

«22—23 нче еллар тирәсе. Мин Мамадыштан ат белән Казанга кайтам. Кучерам бик моңлы кеше булып чыкты. Гел җырлап кайта. «Наган көе»н мин беренче мәртәбә аңардан ишеттем. Көйнең тарихы турында да нәрсәдер сөйләде. Тулысынча хәтерләмим инде. Ниндидер бер начальник хатынынмы, сөйгәненме аткан, имеш».

Халык арасында җырның тарихына бәйле башка риваятьләр дә йөри икән...

Шуларның кайсысы дөрес! Әйтүе кыен. Һәрхәлдә, «Наган көе» (хәзерге «Кара карлыгач микән») гади җыр түгел, ә конкрет бер фаҗигага уңае белән чыккан совет чоры бәете булырга тиеш. Бәет булуын аның кушымтасы ук раслый. Бәлки:

Кара карлыгач микән,
Сары сандугач микән
Аны үстергән әнкәсе? —

дигән юллар кушымта да булмагандыр, ә бәетнең бер строфасы гынадыр. Көйдәге бер үк мотивның кабатлануы да «Кара карлыгач микән»нең бәет булуын раслый. Чөнки музыкаль алымнарның кабатлануы бәетләр өчен хас күренеш.

Кызганычка каршы, бәетнең тулы тексты безгә мәгълүм түгел. Монда китерелгән сүзләр бу көйгә соңгы вакытларда ясалма рәвештә генә беркетелгәннәр һәм аңа куплетлы җыр формасы биргәннәр.

Бу популяр бәетнең нотаrange салган көе хәзергә хәтле матбугатта чыкканы юк иде. Г. Сөләйманова һәм Р. Ваһаповлар репертуарында күренекле урын биләп торды. Мин исә җырчы Флера Сөләймановадан язып алган вариантны китердем.

# 108. Зәңгәр күз




Зәңгәр күзең, күз керфегең
Тибрәндерәп карама.

Кушымта:

Бөдрә чәчкәй, зәңгәр күз;
Әйтмә лә, бәгырькәем, авыр сүз.

Күз каравың уклы уттай,
Йөрәгемә кадала.

Кушымта.

Зәңгәр күзең охшатамын
Зәңгәр таң йолдызына.

Кушымта.

Иркә гәүдәң охшатамын
Диңгезнең дулкынына.

Кушымта.

Җилбердәп искән җилләрдә
Бөдрә чәчең таралган.

Кушымта.

Яр булып син яралмаган,
Җан көйдерергә яралган.

Кушымта.

Зәңгәр күзләр, бөдрә чәчләр
Алар безгә тиң түгел.

Кушымта.

Тиң түгеллеген дә беләм,
Өзелеп сөя яшь күңел.

Кушымта:

Бөдрә чәчкәй, зәңгәр күз;
Әйтмә лә, бәгырькәем, авыр сүз.

* * *


Утызынчы елларның башында ук бик популяр булып киткән бу «Зәңгәр күз» җырын мин 1936 елда Казан шәһәрендә яшәүче Исхак Камалов иптәштән язып алган идем. Кыска көйләрнең кушымталы төренә кергән әлеге җырда дүрт юллык строфаның ике юлы гына җырланып кушымтага күчелә. Кушымта исә ике тапкыр кабатлана. Дүрт строфа 8 куплетка бүленеп, кушымта 16 тапкыр кабатланса да, көй ялыктырмый. Чөнки көйнең башлам өлеше белән кушымтасы арасында метро-ритмик һәм мелодик контрастлык бар.

...Казан елга техникумын тәмамлаган Исмәгыйл Вәлиев исемле егет Казан музыка техникумында укучы Р. Ф. гә гашыйк була. Егет туганнарына үзенең серен ача. Бик күпләрнең күңелен үзенә тарткан, чыннан да зәңгәр күзле, бөдрә чәчле бу чибәр кызны Исмәгыйлнең туганнары да якын итәләр. Егет музыкага сәләтле икән: гармунны да, пианинонны да килешле генә уйный, тавышы да матур була. Уйнавын, җырлавын яратса да, кыз аның мәхәббәтен уртаклашмый. Кичләрнең берендә Исмәгыйл Р. гә багышлап үзе чыгарган көйне җырлый. Җыр ифрат көчле тәэсир итә. Туганнары Исмәгыйлне кызганып җылашалар, ә Р. исә хурланып мәҗлесне ташлап ук китә. Бу хәл 1935 елның язында була. Яшь белгеч И. Вәлиев капитан ярдәмчесе булып пароходка эшкә урнаша. Тик Агыйдел буйлап Уфага барган чакта беренче рейста ук үз-үзен үтерә. Сәбәбе мәхәббәтме, әллә башкамы! — Анысы билгеле түгел... Ә бу вакытта аның җыры «Зәңгәр күз» Казан халкы арасында таралып өлгергән була инде.

Сүзне шунда тәмамларга да ярар иде. Ләкин бу җырның тарихына карата булган ялгыш карашларга тукталмыйча булмый. Иптәш И. Надиров үзенең «Татар халык җырлары» китабында «Зәңгәр күз» җырын «Себер татарлары фольклорының бер үрнәге» ди (433 бит, 56 искәрмә). Үз сүзләрен раслау өчен, А. С. Ключаревның «Татар халык көйләре» китабына мөрәҗәгать итә. Ә ул китапның 42 битендә, ноталар өстенә: «Г. Мөхәммәтова тапшырды. Омск өлкәсе, 1940» дип язылган. Көйне җырлап карыйм. Бик күп үзгәрешләр һәм ялгышлар бар. Әлбәттә, бу Ключарев хатасы түгел, җырлаучы шулай тапшырган. Аны да гаепләп булмый. Чөнки Омск өлкәсенә барып җиткәнче җыр шактый үзгәргән булуы да ихтимал.

«Зәңгәр күз» җыры, һичшиксез, Казан фольклоры. Шуны да әйтеп китәргә кирәк. 1936 елда мин бу җырны гармониялаштереп Мәрьям Рахманкуловага биргән идем. Ул аны бер-ике генә җырлап калды. Ләкин халык авызыннан ул төшмәде һәм хәзерге көндә дә яратылып җырлана.

## 114. Әлфия




| | |
|---|---|
| Бите алма, ирене чия,<br>Колхоз кызы Әлфия;<br>Ахры, акылым җуям инде,<br>Әлфия, Әлфия дия-дия. | Кызыл бәйли, кызыл кия,<br>Колхоз кызы Әлфия;<br>Йөрәгемә ут кабыздым,<br>Әлфия, Әлфия дия-дия. |

Тырышып эшли, хезмәт сөя
Колхоз кызы Әлфия;
Ахры, Мәҗнүн булам инде,
Әлфия, Әлфия дия-дия.

* * *

Утызынчы елларның ахырында чыккан һәм Рәшит Ваһапов репертуарыннан төшми җырланып килгән бу җыр күп яклары белән игътибарга лаеклы. Катлаулы көйләрнең эндәш сүзләренә төренә кергән бу җырда ритмик төрлелек тә, кисәкләр арасындагы контрастлык та, киң колачлылык та бар.

...Бөек Ватан сугышының башы гына иде әле. Безне Госман һәм Рәхилә Галиевләр кич утырырга чакырдылар. Башка кунаклар арасында Рәшит Ваһапов та бар иде. Музыкага, җырга күчелде. Бар да Р. Ваһаповтан «Әлфия»не җырлавын үтенделәр. Ул җырлады, ә Госман рояль уйнады. Кул чаптык. Шуннан Рәшит, тыңлаучыларга мөрәҗәгать итеп:


— Бу җырның авторы безнең арада. Ул...,— дип, хәйләкәр генә елмаеп, сүзен өзде. Янәсе, үзегез белегез. Бар да миңа караш ташладылар. Ә мин бераз аптырап җилкәмне җыердым. Рәшит минем уңайсызлануымны күреп:

— Юк, ул түгел. Аны менә безнең хуҗабыз Госман Галиев чыгарган. Сүзләрен дә үзе язган,— диде.

Чынлап та, музыкаль сәләте зур булган Госманның шундый матур көй чыгаруына беребез дә шикләнмәдек. Ул вакытта Госман Галиев Минзәләдә эшли иде. Ялгышмасам, театрда бугай. Берничә елдан соң аның фаҗигале үлеме турында хәбәр алынды...

Композитор М. А. Юдин Кави Нәҗми либреттосына язган «Фәридә» операсында бу көйне бик урынлы файдаланды. Аны без Маһирә җырында ишетәбез.

## 135. Рамай




Төнгә каршы берәү моңлы итеп, Рамай,
Аерылышу көен җырлады.
Тынга калды урман буйлары да, Рамай,
Чишмәләр дә акмый тыңлады.

Агыйделкәй алкын, суы салкын, Рамай,
Салкын диеп басмый калмадым;
Сөйдем сине, бәгърем, чын күңелдән, Рамай,
Аңлашырлык сүзләр тапмадым.

Сахраларга чыгып бер сызгырдың, Рамай,
Чапкан печәннәрең кипсен дип,
Безгә кемнәр теләк теләде икән, Рамай,
Гомерләре аерым үтсен дип.

Сандугачлар сайрый, ай очканда, Рамай,
Кояш чыгып, кояш батканда;
Мин уйлармын синә шул вакытта, Рамай,
Матур таңнар сызылып атканда.

Сахраларга чыктым, бер гөл күрдем, Рамай,
Бөгелә-сыгыла җилгә буйсына;
Кайда барсам, бәгърем, кайда йөрсәм, Рамай,
Күңелләрем сине юксына.

Агиделкәй алкын, суы салкын, Рамай,
Дәрья суларыннан ким түгел;
Кеше кешеләрдән артык түгел, Рамай,
Тик бәхеткәйләр тиң түгел.

Агыйделне буйлап аккош йөзә, Рамай,
Дулкын чыкса, ярга ташлана;
Яшьли сөйгәнеңне ятлар алса, Рамай,
Бәхетсезлек шуннан башлана.

Сандугачлар талга басып сайрый, Рамай,
Җәй көннәре җылы, ямьлегә;
Нинди авырлыклар үткәрсәм дә, Рамай,
Мин онытмам сине мәңгегә.

Урманнарга керсәң, сызгырып кер, Рамай,
Селкенмәгән агач калмасын;
Сахраларга чыксаң, чәчәкләр җый, Рамай,
Сокланмаган кеше калмасын.

Чигелгән лә сөлге матур була, Рамай,
Сабан туйларында эләргә;
Минем теләкләрем якты иде, Рамай,
Бергә яшәп, бергә үләргә.

Нигә шулай кача икән балык, Рамай,
Агыйделдә яткан ак таштан.
Синең гыйшык утларында янып, Рамай,
Салкын гүргә кердем яшь баштан.

Китәм инде, бәгърем, дөньялыктан, Рамай,
Ай каласың, бәгърем, аерылып.

Гел карамасаң да бер карарсың, Рамай,
Каберем өсләренә каерылып.

Сугышлардан кайткан ялгыз атны, Рамай,
Ак каенга бәйләп куйсыннар.
Дөньялыкта, бәгърем, кавыша алмадык, Рамай,
Каберебез бергә булсыннар.

* * *

«Рамай»ның сүзләре моның белән генә бетми, билгеле. Фольклорчы И. Надировның әйтүенә караганда, аның егермегә якын варианты җыйнелган, һәм ул үз китабына җырның 9 строфадан торган җыелма текстын урнаштырган. [Татар халык җырлары. 1965 ел. 387 бит]. Монда китерелгән 13 куплетлы җыр 1951 елда Чаллы районының Борды авылында Раиса Тимофеевадан, Мамадыш районының Көек Ерыкса авылы укытучысы Асия Вәлиевадан һәм Магнитогорск шәһәреннән килгән эшче кыз Рәлия Халитовалардан язып алынды. Аны өчесе дә бер төсле җырладылар.

Бөек Ватан сугышы тәмамланугa чыккан бу җыр тиз арада ифрат популяр булып китте. Моның төп сәбәбе җырдагы сүзләрнең поэтик көчендә һәм бәетчән сюжетка корылуында дип уйларга кирәк.

Көендә әллә ни яңалык та юк кебек. Анда иске «Чегән егете белән качкан мулла кызы Хәмидә» бәетенең интонацияләре дә очрый. Шуның өстенә сүзләрнең бер фаҗигале сюжетка корылган булуын да искә алсак, һичшиксез, «Рамай»ны хәзерге заман бәете дип атарга хакыбыз бар. Без бу әсәрдә поэтик чагыштыруларны да, хәсрәтле вакыйганы үлгән кеше авызыннан сөйләтү алымын да, Рамайга мөрәҗәгать итүне дә күрәбез. Ә бу сыйфатлар бәет жанрының үзенчәлекләре бит.

Инде «Рамай» бәетенең тарихына килсәк, халык арасында мондый риваять йөри: Кама яки Агыйдел буена урнашкан авылларның берсендә була бу хәл. Авылның бер матур кызы Рамай исемле егетне сөя. Ләкин мәхәббәтен сиздерергә базмый:

Сөйдем сине, бәгърем, чын күңелдән, Рамай,
Аңлатырлык сүзләр тапмадым...

Сугыш башлану белән Рамай фронтка китә. Кыз кайгысыннан авырый башлый. Берничә елдан Рамайның үлгән хәбәре килә. Тәмам хәлсезләнеп урынга яткан кыз сөйгәне Рамай турында җырлар чыгара, аларны көйгә салып җырлый. Иптәш кызлары ул җырларны көе белән отып тирә-якларга тараталар. Ахырдан кыз үлә.


Бу кызганыч вакыйганың икенчерәк дәвамы да бар. Анда, Рамайның исән булып, сугыштан бер медсестрага өйләнеп кайтуы һәм шул кайгыдан кызның авырып үлүе турында сөйләнә.

Яшьли сөйгәнеңне ятлар алса, Рамай,
Бәхетсезлек шуннан башлана...
...Гел карамасаң да бер карарсың, Рамай,
Каберем өсләренә каерылып...

Бу риваятьнең чын булуы-булмавын ачык итеп әйтә алмыйм. Күреп, белеп сөйләүчеләрне очратып булмады. Имеш-мимешләргә ышанып кына катгый нәтиҗәгә килеп булмый, билгеле. Шуның өстенә «Рамай»ның бөтен сүзләрен шул бәхетсез кыз чыгарган дип уйлау да дөрес булмас иде. Шул эчтәлек белән дулкынланган халык дәвам иттергән аны. Яңадан-яңа җырлар әле дә туып кына торалар.

Инде Рамай дигән исемгә килик. Андый исем юк. Ул Рамазан яки Рәхмәтулла дигән исемнәрнең кыскартылып әйтелеше булырга тиеш. Мондый алымнар мишәр татарлары арасында очрый. Печәнне пакос дип әйтү дә аларга хас. Шуларны искә алсак, «Рамай» бәетенең Чистай, Чаллы районнарында чыгуы ихтимал дигән фикергә дә килә алабыз. Һәрхәлдә, «Рамай» — безнең чорда чыккан яңа бәет үрнәге.

# 136. Сәлам язам




Сәлам язам, якын дустым, сиңа,
Җәйге матур, җылы кич белән,
Йөрәгемдә алсу чәчәк кебек
Тамыр җәйгән дәртле хис белән.


Безнең дуслык кебек җылы дуслык,
Якты дуслык җирдә табылмас,
Чөнки безнең хисләр бөек чорның,
Бөек көрәшендә кабынган!

Кайнар хисләр, дустым, йөрәкләрдә,
Ялкынлансын гомер-гомергә;
Мәхәббәттәй көчле саф дуслыкка
Үрнәк булып яшик без бергә!

* * *

Бу җыр Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорда чыккан халык җырлары арасында иң яктысы һәм иң ачыгы дисәк, хата булмас. Якты лирикалы булуы белән, шулай ук диапазонының киңлеге, ритмик яктан катлаулы һәм форма төзелешенең камиллеге белән бу җыр яңа фольклорыбызның матур бер үрнәге. Озын көйләрнең романска тартым тирәнә керә торган бу җырны мин 1950 елда Татарстанның Олы Әтнә авылында райбашкарма комитетының культура бүлегендә эшләүче Гали Заһиров иптәштән язып алган идем. Ул аны сугыштан соң Казанда Горбунов исемендәге заводта эшләгән чагында отып алган. Бөек көрәш елларында туган чын дуслыкка гимн җырлаган бу җырны беренче булып сәхнәгә Усман Әлмиев күтәреп чыкты. Бу көйне мин «Тапшырылмаган хатлар» операсында файдаландым. Ул анда «Дуслык җыры» дип атала. Аны Галия, Вәли, Искәндәр һәм хор башкара.

## 140. Вәгъдә




Гашыйк булган яшь егеткә дөньяда
Керсез күңел, саф мәхәббәт, көч кирәк.
Иркәм хыянәтче булгач,
Үз вәгъдәсен үзе бозгач,
Газапланып әрни яшь йөрәк.

Вәгъдә биргәч, кирәк иде көтәргә,
Нигә инде хыянәтләр итәргә?
Зәйтүн гөлем дигән идем,
Гомерлеккә сөйгән идем —
Шат тормышта гомер итәргә.

Миндә кайгы, миндә хәсрәт, моңланам,
Синең утларыңда янам мин һаман.
Яшь йөрәгем, син ярсыма,
Давылдан соң диңгез тына,
Хәсрәтләрең бетәр бер заман.

Көзге ачы салкын җилләр исteләр,
Болыннарда чәчәкләр дә сулдылар.
Януларым, көюләрем,
Чын күңелдән сөюләрем
Барысы да әрәм булдылар.

* * *

1951 елда мин Татарстанның Мамадыш районы Яңа Камазан авылында булдым. Көннәрнең берендә фольклор сөюче карт укытучы Рәшит ага Мозаффаров мине бер-ике чакрымда урнашкан Көек-Ерыска авылына алып китте. «Анда безнең яшь укытучылар бар. Алар инде сиңа кирәк хәзерге заман җырларын яхшы беләләр», дип мине алдан ук сөендереп тә куйды. Менә шунда инде мин яшь укытучы Ахкәм Мофакаров иптәштән шушы җырны язып алдым. Ләкин ул миңа аны «Егет моңы» дип тапшырды. Дөресен әйтәм, бу матур көйнең сүзләре миңа бик үк ошап бетмәде, төшенкелек, сентиментальлек аңкый иде алардан.

Күп тә үтмәде, бу көй, башкарак сүзләр белән, «Вәгъдә» исеме астында җырлана башлады. Башлап Сөләйман Йосыпов җырлады шикелле. Көйнең сүзләренә карата булган шик һәм ышанмаучылык бетте. Чөнки көйдә дә, сүзләрдә дә байтак үзгәрешләр бар иде. Мин ул җырга ышандым. Еллар узды. «Вәгъдә» җыры халык теленә керде.

...1969 елда, көннәрнең берендә, миңа хат килде. Матур почерк, вак хәрефләр белән язылган биш битлек хат. Ул болай башлана.

«...Бу хатны сезгә кечкенә генә бер авылның клуб мөдире яза. Әгәр әледән-әле мине кузгатып, мине этәреп тора торган сәбәп булмаса, мин сезгә бу хатны язмас та һәм сезне — зур кешене — борчымас та идем.

Йөрдем-йөрдем дә язарга булдым»...

Татарстанның Бондюг районы Песәй авылының клуб мөдире Зиннур Мөхәммәтдинов иптәш тагын нәрсәләр хакында яза соң!

Җырның күп еллык тарихы бар икән. Ул тарих Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» исемле әсәрен кую белән башланып киткән: «Без «Тормыш җыры»ның сүзләрен белсәк тә, көен белми идек... Мин үз авылыбызның начар гына булса да җырчысы һәм начар гына булса да гармунчысы сыйфатында йөргәнемә күрә, бу «Тормыш җыры»ның сүзләре белән бик моңаеп гармунда уйнап шыңшый башладым... Ничәмә көннәр, ничәмә төннәр үтте икән!.. Ниһаять, мин «Тормыш җыры»на көй чыгардым. Аны клуб коллективы зур шатлану белән кабул итте. Спектакльне сәхнәгә куйдык. Кешеләр яраттылар. Бер ел үтте,— дип дәвам итә иптәш Мөхәммәтдинов,— без радио аша «Тормыш җыры»ның үз көен ишеттек... Узган ел чыгарган теге минем көем хәзер шул килеш калды бит. Ә үзе моңлы. Кешеләр җырлыйлар».

Шуннан соң Зиннур чыгарган көйнең икенче тормышы башлана. Песәй авылы укытучысы Нурулла Шәрифуллин (Нур Шәриф), шушы көйне истә тотып, «Чишмә буенда» дигән пьеса яза. Пьесадагы төп геройның йөри торган кызы, вәгъдәсендә тормыйча, ул сугыштан кайтуга башка кешегә тормышка чыккан була. Артист «Вәгъдә» дигән җырны әлеге Зиннур Мөхәммәтдинов язган көйгә җырлый. Халык җырны күтәреп ала. «Егет моңы», «Чишмә буенда» һәм, ниһаять, «Вәгъдә» исеме астында җыр бик тиз арада тирә-юньгә таралып та өлгерә.


Ә аның авторы Зиннур Мөхәммәтдинов бу вакытта Магаданда була. Берничә елдан соң гына авылына әйләнеп кайта. Кайтса, «Вәгъдә» җырын халык та, артистлар да җырлый. Тик аны «Халык көе» дип җырлыйлар. Авторларның исемен әйтмиләр. Шуңа хәтере калып, ул миңа хат язган.

...Әмма эш бит җырның авторын әйтүдә түгел. Аны халык яратып, үз көе итеп җырлауда хикмәт. «Вәгъдә» көе әнә шул бәхеткә ирешкән. Зиннур Мөхәммәтдинов кебек халык талантлары күп бездә...

## 147. Таһир-Зөһрә

Таһирны сандыкка салып,
Таһирны сандыкка салып
Агызганнар суларга.
Йөреп-йөреп кавыша алмасак,
Йөреп-йөреп кавыша алмасак,
Без охшарбыз шуларга.

Аклы ситсы күлмәккәем,
Аклы ситсы күлмәккәем,
Кисәм дә таушалмаган.
Таһир батыр, Зөһрә матур,
Таһир батыр, Зөһрә матур,
Тик алар кавыша алмаган.




Урамнарда йөргән чакта,
Урамнарда йөргән чакта,
Очраттым мин пар каен.
Таһир-Зөһрә кавыша алмаган,
Таһир-Зөһрә кавыша алмаган,
Без кавышырбыз, дускаем.

* * *

**1952 елның җәе. Агыйдел комкарында аунап, суларында йөзгәч, матур болын буйлап авылга кайтып барабыз. Каяндыр акрын гына моңсу бер җыр ишетелә. Калкулырак урынга утырган ниндидер бер кыз җырлый икән. Тыңлап торабыз. Ишетелгән көй түгел. Ул безне күрми, җырын дәвам итә. Янына бардык. Сөйкемле. Битен кояш ашаган бу кыз бозаулар көтә икән. Без аңардан тагын бер кат җырлавын үтендек. Ул — «Таһир-Зөһрә» булып чыкты...**

**Кич белән көтүче кыз Нәкыя Хакованы үзебезгә чакыртып «Таһир-Зөһрә» җырын фонографка язып алдым.**

**«Таһир-Зөһрә» — ул безнең көннәрдә чыккан бәет. Бер музыкаль теземнән торуы, ул теземнең кабатлануы, секвентлылыгы һәм ритмик бертөрлелек шуны раслый.**

**Намуслы яшьләребезнең көчле һәм турылыклы мәхәббәт мотивларын легендар Таһир һәм Зөһрә исемнәренә бәйләп җырлаулары бер дә гаҗәп түгел. Таһир-Зөһрә исемнәре бәет геройлары булып кына, фикер көчәйтү өчен генә искә алыналар бит:**

Таһир-Зөһрә кавыша алмаган,
Без кавышырбыз, дускаем.

**Гадәттә бәетләр күп санлы куплетлардан тора. «Таһир-Зөһрә»нең дә бик күп вариант сүзләре бар. И. Надировның «Татар халык җырлары» китабында, биредә китерелгән куплетлардан тыш, 9 куплет урнаштырылган. Бу бәеткә карата язылган искәрмәдә (434 бит) түбәндәгеләрне укыйбыз:**

**«Илленче елларда Татарстан районнарында таралган җыр. Халыктан артистлар репертуарына үтеп керде. 1954—55 елларда Тәмте, Чүпрәле, Кайбыч, Дөбьяз, Тельман районнарында экспедиция членнары Х. Ярми, Х. Гатина, И. Надиров, Н. Гатауллина тарафыннан язып алынган сигез варианты саклана. Биредә җыелма текст бирелде».**

**Урал якларында бу көйне «Гөлбакча» дип атап, бер төрле дә сюжетка корылмаган сүзләр белән җырлыйлар икән.**

**«Таһир-Зөһрә»не беренче булып радио аша һәм концертларда Усман Әлмиев башкарды.**

## Максим Глухов

# НАГАЙБӘКЛӘР ЯНЫНДА

Көньяк Урал буйлап йөргәндә, берничә кызыклы поселокка юлыктым. Беренче булып бу поселокларның исемнәре гаҗәпкә калдырды. Мәскәү, Варшава, Берлин, Варна, Кассель, Фершампенуаз, Париж... Тагын Балкан, Лейпциг, Рымник, Шипка. Ә инде бу поселокларның кайберләрендә яшәүчеләрнең нагайбәкләр икәнен дә белгәч, тәмам кызыксынып киттем. Чөнки нагайбәкләрнең Казан татарларына караучы үзенчәлекле бер этнографик группа икәнлекләрен белә идем. Кыскасы, мин бу поселокларның килеп чыгышы, аларда яшәүчеләрнең элекке йолалары һәм гореф-гадәтләре, гомуман тормыш-көнкүрешләре белән якыннанрак танышырга булдым.

Нагайбәкләр яши торган Париж, Кассель, Остроленко поселокларына сугылдым да, Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районы үзәге булган Фершампенуазга тукталдым. Бу язмамда Октябрь революциясенә кадәр махсус хәрби сословиедә — Оренбург казаклары составында булган шул нагайбәк татарлары арасында күргәннәрем һәм ишеткәннәрем турында сөйләмәкче булам.

* * *

Фершампенуазга килеп төшкәч, кунакчыл карт Байтираков мине үз өенә алып китте. Николай Васильевичның җирле тарихны бик шәп белүче карт икәнен әйткәннәр иде инде. Ул үзенең истәлекләре белән матбугат битләрендә дә күренгәләгән икән.

Байтираков ачык хәтерле һәм киң күңелле кеше булып чыкты. Өстәвенә күп укыган, инде менә ничәмә дистә еллар буе кызыклы елъязма алып бара, язмаларын төрле документлар һәм матбугатта басылып чыккан материаллар белән ныгыта килә икән.

— Җә, якташ,— дип башлады ул сүзен. Нагайбәкләр Татарстаннан килүче һәр кешене бабаларының туган җирләреннән килгән кунак дип кабул итәләр һәм «кискә җиребездән килгән кеше» дип йөриләр.— Мин күп нәрсәне белеп бетерә алмамдыр, үзем төгәен белгән, я булмаса ил картларыннан ишеткәннәремне сөйләсәм генә инде.

Аннары ул киңәеп бер сулыш алды да сөйләп китте:

— Шула-а-й. Без монда 1837—1842 еллар арасында килеп чыкканбыз булырга тиеш. Нәкъ менә шул чорда Оренбург крае кыгытмалары дип йөртелгән җырларне хәрби яктан көчәйтәләр бит. Әлбәттә, безнең казак бабайларның Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрен бер дә ташлап китәселәре килмәгәндер. Инде бит алар ул җирләрдә тәмам төпләнеп киткән булганнар. Тик ишлисең, казакның язмышы шундый инде аның. Кайгырганнар, елашканнар, шулай да алты меңгә якын кеше көчеп килгән бирегә. Падишаның казаклар өчен бирелгән азмы-күпме өстенлекләре дә кызыктыргандыр, күрәсең. Чөнки бит инде 1736 елда ук падиша указы «Күп сугышларда үзләрен батыр сугышчылар итеп күрсәткәннәре өчен» нагайбәкләргә берничә өстенлекләр вәгъдә иткән булган һәм алар хәрби казак сословиесе дип игълан ителгәннәр.

Николай Васильевичның сүзләрен колак очлары белән генә тыңлый-тыңлый газ плитәсе янында маташучы хуҗа хатын түзмәде:

— Сөйләмә дә генә инде ул «өстенлекләрне»,— дип куйды,— беләбез без ул өстенлекләрнең ни икәнен, үз җилкәбездә татыдык....

— Анысы да дөрес,— дип килешә Байтирәков карт,— менә кайберәүләр, казаклар крестьяннарга караганда шәбрәк яшәгәннәр, дип уйлыйлар. Нинди казаклар бит?! Сүз дә юк, ясауллар, атаманнар шәп яшәгәннәр. Ә без...

Николай Васильевич бер читкә карап кулын селтәде һәм авыр сулап куйды.

— Юньле тормыш күрмәдек без,— дип, ул яңадан сөйләп китте.— Ир-зат гомеренең иң таза, иң нык чаклары бетмәс-төкәнмәс походларда, казармаларда чери иде. Ә хәрби хезмәткә киткәндә, казак тулысынча үзеннән коралланырга һәм киенергә, үз хуҗалыгыннан ат алып китәргә тиеш. Ияр өстендә егерме ел буе сөңге һәм кылыч тотып яшәү саулыкны гына какшатып калмый, ә яшьтән өйрәнгән иген игү, мал үрчетү һөнәрен дә оныттырып бетерә торган иде. Яки менә хатын-кызны кара. Нагайбәкләр арасында хатын-кызга борын-борыннан хөрмәт зур. Шулай булмыйча, хуҗалык эшенең вак-төягеннән алып иң авырына кадәр бөтенесе алар җилкәсенә кала иде бит.

Мисалга мине генә алыйк. Әти исән була торып ярым ятим хәлдә үстем мин. Туганнан бирле әтине күргәнем дә булмады диярлек...

Байтирәков сөйләвеннән тукталды да нәрсәдер исенә төшереп кинәт сәгатенә карады һәм: «Бер сәгатькә генә барып киләсе җирем бар»,— дип, гафу үтенә-үтенә киенә үк башлады.

Николай Васильевичка, пенсиягә чыккач, китап җене кагылган икән. Шулай да ул җәмәгать эшләреннән дә ваз кичмәгән. Партиянең Нагайбәк район комитеты каршындагы карт большевиклар комиссиясе члены буларак, еш кына комсомоллар һәм пионерлар алдында чыгышлар ясый икән. Бүген иртән ул ниндидер бик кирәкле эш белән поселок Советына барырга сүз биргән булган. Шуңа күрә, мин аның түтисе Авдотья белән генә калдым.

Аука түти (поселокта Авдотья Васильевнаны шулай дип йөртәләр) тиз генә өстәл әзерли башлады. Почмак яктан каймак һәм кыргый сарымсактан ясалган үзенчәлекле салат, ягъни уксын, чыгарып утыртты, чүлмәк белән майда пешкән бөтен бәрәңге алып килде. Аннары ул:

— Ашагыз, ашагыз. Базардан сатып аласы юк, хәзер аллага шөкер, өстәлгә куяр әйбер бар...— дип, мине кыстый башлады.

Минем бу шәфкатьле карчыктан аның яшь чаклары, бу яклардагы тормыш-көнкүрешне күбрәк белеп каласым килде.

— Ничек яшәдек дип инде... Казан белән кисмәк арасында әйләнеп гомер үтте. Менә генә бер эш бетә дисең, мал-туар түйдырасы, печән әзерлисе бар. Ә утын бәтенләй бәла булды инде ул безгә. Бу якларда гомер-гомергә урман юк бит. Газны әле күптән түгел генә керттеләр. Ә тегә чакларда кара көн буе кизәк изәсең, мичек алдында чебен түе, әллә ниткән исләр, чыда гына. Җир инде ансы җитә иде. Тик бит әле җире белән генә түгел, әлеге дә баягы, серергә сабаны, сабан башы тотарга кешесе дә кирәк. Инде кара кан савып дигәндәй, чәчәсең дә, аннары тотына корылык. Хәзерге кебек урман полосасы утырту, ашлама дигән нәрсәләрнең төшкә дә кергәне юк иде. Менә шулай яши идек инде...

Урамнан бер төркем яшьләр гитарага кушылып җырлап үттеләр.

— Күршеләр туй итә,— диде Аука түти.— Инде өч көн буе бәйрәм итәләр... Кияү белән киленне загстан «Волга» белән генә алып кайттылар.

Туй турында сүз чыккач, мин:

— Ә элек туйлар ничегрәк үтә иде соң? — дип сорап куйдым.

— Анысы туйларны без бик олылап үткәрә идек, ләкин хәзерге туйларның аермасы бик күп инде. Элек синнән гомер итәсе кешеңне ярату-яратмавыңны сорап тормыйлар. Туган-тумачалар үзара килешәләр дә, бетте-китте. Килен сайлаганда беренче чиратта эшкә яраклылык күз алдында тотыла иде.

Кәбен коеласы[1] көнне кияү үзенең әнисен, яучысын, кияү егетен ияртеп кыз йортына килә. Өйгә кергәндә ул, булачак кайнанасы түр башындагы йомшак мендәргә утырырга чакырмыйча, бусаганы атлап керми. Аннан каенана: «Хатыныңа майдай йомшак, балдай татлы бул»...— дип такмаклый-такмаклый кияүнең башына бал-май сөртә.

Шуннан соң табынга ботка китерәләр һәм киленнең туганнары кияүдән бүләк таләп итәләр. Кияү, үз чамасын чамалап, бүләк биргәннән соң, барысы да ботка ашый башлыйлар. Кияү бу табынны шәрап белән сыйларга тиеш. Ашау-эчү тәмамланганнан соң, яшьләр — кияү һәм аның иптәш егетләре, килен һәм аның дус кызлары — атлар белән авыл буйлап җырлап йөрергә чыгып китәләр. Моны бездә «кәтәлчә чабу» диләр. Аннан кайткач инде кәбенгә әзерләнү башлана. Туган-тумачалар кулларына тәреләр алып ярәшелгән кыз белән егетне арулыйлар. Шуннан соң яшьләр чиркәүгә юнәләләр.

Кәбен кою вакытында кияү белән килен, гаилә мәхәббәте теләп, аяк асларына көмеш акча төшерәләр. Кияү йортына чакырылган кунаклар ишек алдында бер рәткә тезелеп, чиркәүдән кайтучы яшьләрне ипи-тоз белән каршылыйлар. Кияү белән килен, туган-тумачалар ризалыгын алганнан соң, ипи-тоз кабып тәберсен итәләр[2]. Бу йолаларны үтәү барышында килен башына бөркәнчек кигән була.

Шуннан соң төркемнән бер малай чыгып яшь килен янына килә һәм өч мәртәбә йөгән селки. Килен һәр селкегән саен йөгәнне тотарга һәм малайга бистәр бүләк итәргә тиеш. Бу йоладан соң барысы да өйгә керәләр. Яшь килен өйгә килеп керү белән чөйгә сөлге элә. Моның белән ул бу йортта үзенә бәхет теләвен белдерә.

Киленнең дус кызларыннан берәү бер кечкенә малайны чакырып ала һәм, аның кулына ау угы тоттырып, киленнең битеннән бөркәнчекне ачарга куша. Бу вакытта кыз: «Шулаймы», дип сорый һәм үзенә-үзе үк: «Юк, алай түгел» дип җавап бирә дә киленнең битенә бөркәнчекне яңадан яба. Моны ул өч тапкыр кабатлый һәм соңгы мәртәбәсендә «Шулай» ди дә, килен бөркәнчеген бөтенләй ачып җибәрә. Кунаклар шунда ук кияү белән килен янына киләләр, аларны котлыйлар, алып килгән бүләкләрен бирәләр...

Шуннан соң инде мәҗлес башлана. Бер арада кияүнең апалары яки сеңелләре киленгә көянтә-чиләк биреп, аңы су юлы күрсәтергә алып китәләр. Чөнки бит нагайбәкләр киленне күбесенчә күрше авылдан төшерәләр иде. Килен шулай итеп беренче мәртәбә кияү йортына су алып кайта. Ул шушы су белән табындагыларны сыйлый. Кунаклар аңа тагын акча өләшәләр.

Мәҗлес бетеп, кунаклар таралыша башлагач, кияүнең кече туганнары аларны юри тоткарлыйлар, тегеләр алардан акча биреп кенә котылалар.

Килен бирнәсе берничә атна, кайчакта хәтта берничә ай соңрак китерелә, аңынчы яшьләр кияү йортындагы кирәк-ярактан файдаланып торалар. Килен бирнәсе гадәттә теп бәйрәмнәрдә, Пыкрау я Троицын көннәрендә китерелә. Иң зур тантаналар нәкъ әнә шунда башлана да инде, бая сөйләгәннәрем барысы да туй алды мәҗлесләре генә әле.

Киленнең туган-тумачалары, якыннары, җыелышып, кодалар йортына киләләр. Атлар үзенә бер тәртип белән тезелеп бара. Иң алда аерым билгеләнгән җитәкче — эргыш, аның артында киленнең урын-җире, бирнәсе, аннары кызның әти-әнисе, алар артыннан, кыз бирүче йортка мөнәсәбәтләренә карап, туган-тумачалар тезелеп китә. Урын-җир өстенә ике малай менеп утыра. Кодалар ипи-тоз һәм ачы бал тотып кунакларны каршыларга чыгалар. Кияү егете урын-җир өчен малайлар белән сатулаша

---

[1] Кәбен кою — чиркәүдә язылышу (никах).

[2] Тәберсен итү — мәҗүсилектән калган йола. «Бабаларыбызның, әлкәннәребезнең — барысының да җомак (оҗмах) ашы булсын» дип, үлгән туган-тумачаларны искә алу.

башлый. Малайлар баштан берничә мең сум сорыйлар, соңыннан берничә тиенгә килешәләр. Шуннан соң бирнәне өйгә алып керәләр. Өстәл арасына дәрәҗәгә карап кына утырталар — башкодалар кара-каршы булырга тиеш. Шул арада кияүнең җиңгәсе яки апасы өйгә бирнә белән килгән сөлгеләрне һем пәрдәләрне элә башлый. Бирнә элү өчен ул алтын яки көмеш кадаклар сорый, ә кунаклар аңа алтын яки көмеш акчалар бирәләр. Шуннан соң кияүнең туган-тумачаларына бирнә бүләкләре тараталар һәм туй мәҗлесе башлана.

Туй мәҗлесләре бик күп җырлары, мәзәкләре, төрле уеннары белән үзенә күрә бер театр сыманрак тамашага охшый торган иде. Җырларны кияүнең һәм киленнең туганнары чиратлашып, кара-каршы җырлыйлар. Һәр җырның сүзләре алда җырлаучыга җавап булырлык итеп әйтелә. Мәсәлән, кияүнең әтисе, кунакларны каршылаганда, шундыйрак җыр әйтә:

**Кара урманнарны өч әйләндем**
**Зелпе таякларына таянып.**
**Сез кодаларны көтеп алдым**
**Ян тәрәзә төпләренә таянып.**

Килен ягы аңа болай дип җавап бирә:

**Айлар идек без, идек без,**
**Агыйделләр кичеп килдек без.**
**Агыйделләр кичеп, җилләр сүтеп,**
**Бер күрешер өчен килдек без.**

Ә инде кызның туганнары үзләре алып килгән ашамлыкны табынга чыгарганда мондыйрак җыр әйтәләр:

**Өстәлләргә куйган ашамлыкны**
**Чәчми генә, түкми ашагыз.**
**Кызыбызны сезгә бирдек,**
**Какмый гына, сукмый асрагыз.**

Шунысы кызык: бу җырлар барысы да махсус бер көйгә — кодалар көенә җырлана. Бу көй бик борынгы булырга тиеш, чөнки ул татар халкының борынгы көйләре кебек сузып җырлана. Әгәр дә кияүнең яки киленнең туган-тумачалары туй җырларын белмәсәләр, бу бик оят санала иде. Шуңа күрә һәр ике якта туй алдыннан бик күп җырлар отарга тырышалар һәм берничә мәртәбә репетиция ясыйлар...

Авдотья Васильевна берничә борынгы көйне җырлап та күрсәтә. Ул боларны яшь чагында үзенең әбисеннән өйрәнгән булган. Аука түти җырлаган җырларның һәм көйләрнең күбесен Татарстанның Мамадыш, Саба, Балык Бистәсе районнарында яшәүче иске керәшеннәр бәйрәм табыннарында әле хәзер дә бик еш җырлыйлар. Бу күренеш, нагайбәкләрнең ата-бабалары Казан артыннан чыкмадылар микән, дигән сорауга урын калдыра.

Ә инде бу этнографик группаның нагайбәкләр дип йөртелүенә карата фәндә төрле карашлар яши. Татар халкының көнкүрешен һәм культурасын өйрәнүче бериш галимнәр (Е. С. Малов һәм Н. И. Воробьев) Чиләбе өлкәсенең Увель һәм Нагайбәк районнарындагы югарыда әйтеп үтелгән поселокларда, шулай ук Башкортстан АССРның көнбатыш чикләрендәге Нагайбәк авылында яшәүчеләрнең төп үзәген чукындырылган нагайлар һәм башкортлар тәшкил итә дип фараз кылалар. Алар уенча, бу этнографик группа соңыннан татарлашкан булырга тиеш.

Ә икенче бериш галимнәр (П. И. Рычков һәм В. Н. Витевский) нагайбәкләрне беренче мәртәбә килеп утырган урыннары исеме (Нагайбәк ныгытмасы)[1] белән атаганнар дип уйлыйлар. Ул чорда бу тирәгә кыргыз-кайсак әсирлегеннән качкан төрле милләт вәкилләре килеп утырган. Алар христиан динен кабул иткән булганнар. Рычков болар арасында фарсылар, гарәпләр, бохаралылар, әрмәннәр, әфганлылар һәм башка

---

[1] 1736 елда төзелә. Риваятьләргә караганда, бик борынгы заманнарда бу тирәдә үзенең ыруы белән Нагайбәк исемле башкорт күченеп йөргән. Ул нигез салган авыл аның исеме белән Нагайбәк дип йөртелә башлаган (хәзер БАССРның Бакалы районы, Нагайбәк авылы).

халыклар вәкилләренең дә булуын әйтә. («...1752 елга кадәр кабул ителделәр һәм йорт-җир корып яшәү өчен Уфа провинциясендәге Нагайбәк ныгытмасы тирәсенә җибәрелделәр») [1]. Ләкин боларны алай вәруча игътибар итәрлек күп санда булмаган дип уйларга кирәк.

Соңрак, Екатерина II заманында, китерелгән чукынган төрекләрне дә нагайбәкләр дип гомуми исем белән атап йөртә башлаганнар. Алар барысы да Бакалы һәм аңа якын авыллардагы татарлар арасына килеп утырганнар.

Профессор Н. Ф. Катанов һәм нагайбәкләрнең үз арасыннан чыккан тикшеренүче Е. А. Бектеева нагайбәкләрнең ата-бабаларын Арча татарлары дип уйлыйлар. Алар фикеренчә, бу татарлар Казан ханлыгы рус дәүләте составына кергәч тә көчләп чукындырылганнар, әзакламый, Агыйдел һәм Ык буйларына күчереп утыртылганнар, ә соңыннан инде алар Урал артына ук күчеп киткәннәр [2].

Моның шулай икәнлеген раслау өчен Бектеева риваятьләр һәм картларда саклынып калган берничә документ китерә.

Әлегә соңгы нәтиҗәләрне ясарга нигез җитенкерәп бетмәсә дә, без Бектеевага кушылабыз. Нагайбәкләрнең фамилияләре генә дә бу фикерне яклый булса кирәк: Карабашев, Арапов, Әлмәтов, Аюбашев, Акмәмәтов, Ишимов, Ишмәмәтов, Дускин. Бу фамилияләр әле бүген дә нагайбәкләр арасында бик еш очрыйлар.

Менә тагын бер мисал. Түбәндәге җырлар Казан арты авылларында әле хәзер дә бик еш ишетелә торган җырлар белән сүзгә-сүз тәңгәл киләләр:

> Түгәрәк күлләрдә дүрт үрдәк
> Яр читенә чыгып куна лар.
> Өстәл башларын ямьле итеп,
> Кайлардин килдә безгә кодалар.
>
> Шыбыр-шыбыр яңгыр ява,
> Җөгерек каен астына.
> Күп ашадык, ай, күпләр эчтек,
> Башырыек аякай астына.

Нагайбәкләрнең гомумхалык бәйрәмнәре дә бик үзенчәлекле булган. Бу тирәләрдә «Сабан туе» дигән сүз тарихның кайсыдыр ерак борылышларында онытылып киткән булса да, бәйрәм үзе сакланып калган. Һәм ул һәр Пасхада (Олы көн) үткәрелә торган булган. Христиан дине әһелләре Сабан туе үткәрүне тыйгач, халык бу борынгы бәйрәмне әнә шул рәвештә саклап калган. Чиркәү күпме тырышса да, әлегә бәйрәмнең халыкчанлыгын югалта алмаган. Бу көнне Сабан туендагы шикелле үк ат чабышлары, татарча көрәш үткәрелгән. Нагайбәкләр, атлы казаклар буларак, бәйрәмгә үз уеннарын да өстәгәннәр. Ат өстендә җилеп барганда, кылыч белән агач ботагын чабып төшерү, ат сыртына аягүрә басып яки аякларны югары күтәреп чабу, ат бөтен көченә чабып барганда иярнең бер ягына асылынып җирдән әйбер алу буенча ярышканнар.

Нагайбәкләр, гомумән, бик шат күңелле, җыр-биюгә бик оста халык. Алар хәтта әлек-әлектән үк ураза да тотмаганнар. Христианлык һич кенә дә аларның кулын бәйләп тота алмаган, шул ук вакытта алар исламнан да азат булганнар. Менә ни өчен алар халык характерының табигый сафлыгын, борынгы уеннарны, гади сөйләм телен, борынгы музыка коралларын (гөслә һәм кубыз), халык җырларын һәм биюләрен бик озак вакытларга кадәр үзгәрешсез диярлек саклап кала алганнар.

> Яшьлек дәверендә без җирнек
> Япаннарда җилгән боландай,—

дип җырлаганнар алар.

---

[1] П. И. Рычков. Оренбург губернасы топографиясе. (Рус телендә). Оренбург. 1887, 137 бит.

[2] Е. А. Бектеева. Оренбург губернасы керәшен татарлары. «Җанлы тарих» җыентыгында. (Рус телендә.) СПБ. 1902; Н. Ф. Катанов. Минзәлә һәм Бәләбәй өязләренә сәяхәт турында. («Казан университетының гыйльми язмалары».) 1898, 1900, 1901.

Башка керәшеннәрдәге кебек үк, нагайбәкләрдә дә христианлыкка кадәр булган борынгы уеннарының берсе — «Нардуган» бик озак сакланган. Бу бәйрәм чын мәгънәсендә бөтен халык уены булып киткән. Бәйрәм кыш көне берничә атна бue, Качману[1] көненә кадәр дәвам итә. Болай итү халык бәйрәмен үткәрүне тыючы руханиларның күзен буяу өчен кирәк булган.

Гадәттәгечә, уеннарны башлап йөрүчеләр — яшьләр. Аулак өйдә утырганда, арадан берәү:

— Әйдәгез, авыл буйлап әйләнеп керәбез,— дип тәкъдим итә. Тәкъдим кабул ителү белән «гастроль»ләргә хәзерлек башлана. Беренче булып кем йортына керергә карар кылуга карап, кирәк-яракны әзерлиләр. Яшьләр төрле сәер киемнәр киялэр, йорт хуҗасы танымасын өчен, төрле төстәге битлекләр ясыйлар, кем нәрсә эшләргә тиешлекне билгелиләр (гадәттә, өйгә кергәч нинди дә булса сюжетлы комедия уйнала). Барысы да әзерләнеп беткәч, билгеләнгән йортка юнәләләр.

Төн уртасында, авылның бер очында тәрәзә яки капка каккан тавыш ишетелә. Йорт хуҗасы ишекне ачарга да өлгерми, өйгә, шау-гөр килеп, төрле битлекләр киган һәм кулларына камчылар, тукмаклар, ясалма кылычлар һәм башка әйберләр тоткан бер төркем яшьләр кереп тула.

Килеп керүгә, исәнлек-саулык та сорашып тормастан, алдан хәзерләнгән уен башлана.

Мондый өй спектакльләренең эчтәлеге уйнаучыларның зирәклеге һәм йорт хуҗасы тормышының үзенчәлегенә бәйләнгән була. Уйнаучылар яки «адашкан юлчы» ролен башкаралар, я бөкре кызларын кияүгә бирә алмыйча, яки азгын малайларын өйләндерә алмыйча азапланучы кодалар булып уйныйлар, я булмаса ярминкәдән кайтучы кырык тартмачы булып кыйланалар. Спектакль барышында бик күп такмаклар әйтәләр (кайчакта бу такмаклар хуҗага каршы юнәлдерелгән була), биилэр, мәзәк сөйлиләр. Йорт хуҗасы, төнге кунакларның кемнәр икәнен танырга теләп, әледән-әле уенчыларның битлекләрен, киемнәрен салдырырга тырыша. Ниһаять, хуҗа аларны танып, исемнәрен әйткәч, уен туктала һәм уенчылар битлекләрен салып өстәл арасына утыралар. Хуҗа аларны әйбәтләп сыйлый («Нардуган» көннәрендә һәркемнең өендә әзер сый-хөрмәт саклана), аннары ул үзе дә уенчыларга кушыла һәм бу шат төркем күрше йортка юнәлә. Бу йортта инде, хуҗасына карап, башка төр уен уйнала. Бу күренеш атналар буена дәвам итә. Шулай итеп, «Нардуган» авылның бөтен йортына диярлек кереп чыга.

Берничә атнага сузылган бу бәйрәм, «Йөзек салу» уены белән тәгалләнә. Чынында исә, «Йөзек салу» нингдидер бер багучылык кына булып калмый, ә күңелле яшьләр кичәсенә әверелеп китә.

Йөзек салу өчен авыл читендәге аулаграк зур бер йортны сайлыйлар. Идән уртасына зур казан куялар. Аның тирәсендәге урындыкларга һәм эскәмияләргә яшьләр тезелешеп утыра. Бу кичәгә алар бәйрәм киемнәреннән киләләр. Чөнки бит «Йөзек салу» кичәсендә егетләр, кызлар бер-берсе белән танышалар, кеше арасында ничек тә булса күркәмрәк булып күренергә тырышалар.

Уенчылар үз араларыннан әти-әнисе исән булган бер егет һәм бер кызны — түгәрәк яшьләрне — сайлап куялар. Түгәрәк яшьләр бәкедән «изге» су алып керәләр һәм казанга салалар. Уенны алып баручы (тамада) һәр кешедән берәр әйбер ала (балдак, тәңкә, ачкыч һ. б. ш.) һәм аларны башкаларга күрсәтмичә генә казанга сала. Шуннан соң алып баручы уенның шартларын игълан итә һәм җырлаучылар чиратын билгели.

Төнге сәгать 12 тулгач, уенның төп өлеше башланып китә. «Йөзек салу» уенының төп сере шунда: алып баручы казанга тыгылып кемнең дә булса әйберсен ала һәм аны башкаларга күрсәтмичә генә җырчыга ым кага. Тегесе гармунга яки гөсләгә кушылып нинди дә булса җыр башкара. Җырның эчтәлеге төрлечә — күңелле, сагышлы, теге яки бу кыз-егеткә киная рәвешендә булырга мөмкин. Җыр тәмамлангач, әйберне (балдак, тәңкә, ачкыч һ. б. ш.) бөтен кешегә күрсәтеп хуҗасына бирәләр. Димәк, яңа гына җырланган җыр нәкъ менә шушы кешегә багышланган була. Җырның эчтәлегенә карап әлеге әйбер хуҗасын нинди язмыш көтүе билгеләнә (йөзек

[1] Качману көне (крещение) — Юлиан календаре белән 19 январьга туры килә.

кызга чыккан булса, ул кайчан кияүгә чыгар, якынча, нинди егеткә чыгар, ә инде йөзек егеткә чыкса — ул кайчан хәрби хезмәткә китәр, кайчанрак өйләнер, нindирәк кызны алыр һ. б.).

Һичшиксез, «Нардуган» да, «Йөзек салу» да нагайбәкләр арасында мәҗүсилек калдыклары буларак кына сакланганнар. Чиркәү әһелләре мондый күренешләргә каршы һәрвакыт көрәшеп торганнар һәм нагайбәкләрне милли киемнәргә киенүдән дә тыйганнар. Бу чикләүләр халык арасында бик нык каршылыкка очраган. Ләкин шунысын да әйтеп китәргә кирәк: дини пропаганданың көчле басымы астында нагайбәкләрнең аңына әзмы-күпме христианлык мотивлары да сеңми калмаган. Без моны:

Кыр казы уза яз көне,
Күз кайтадыр күе кырауда.
Бер авыз иман без белмибез,
Ни әйтербез каты сорауда! —

диган һәм шуңа охшаш халык җырларында ачык күрәбез. Ләкин бу җырларда халыкның дингә карата битарафлыгы да сизелә.

Нагайбәк татарларының авыз иҗаты бик бай. Элекке заманнарда аларда китап грамотасының бик аз таралган булуы сәбәпле, халык авыз иҗаты нагайбәкләрнең рухи тормышында гаять зур роль уйнаган.

Икенче көнне Байтирәков мине поселок белән таныштырырга урамга алып чыгып китте. Хәзер инде элеккеге Фершампенуазның эзе дә калмаган диярлек. Алты почмаклы нык өйләрнең биек түбәләрендә заманыбызның символы булган телевизион антенналар. Фершампенуаз — үзенең аэродромы, автобус станциясе булган зур поселок. Монда урта мәктәп, дәвалау шәһәрчеге, культура йорты, кинотеатр, ресторан, универмаг һәм дистәләрчә башка төр кибетләр бар.

— Ә син безнең поселокның исеме каян килеп чыкканлыгын беләсеңме соң,— ди миңа Байтирәков карт, хәйләкәр елмаеп.— Ни өчен нәкъ менә Фершампенуаз! Бу бит бер дә татарча түгел.— Аннары ул яңадан сөйләп китә. Элек заманда Россия сугышларда бик еш катнаша иде. Билгеле инде, казаклар бу сугышларда иң алдынгылардан саналганнар. Безнең бабайлар 1760 елда ук фельдмаршал Салтыков җитәкчелегендә Берлинны алганнар. Ул чакта нагайбәкләр аерым полк төшкил иткән. Борынгылар болай дип сөйлиләр: безнекеләр Бранденбург капкаларын штурмлый башлыйлар. Ә пруссаклар бу капканы аеруча нык саклыйлар икән. Сугышның иң кызган чагында безнекеләрдән берәү кинәт «Ура!» дип кычкырып җибәрә, ягъни «урап ал, камап ал» диган сүз. Шуннан соң безнекеләр, минсиңайтим, урап та алалар, пруссакларны егып та салалар. Шуннан соң инде бу сүз бөтен рус армиясенә таралып китә, имеш.

Байтирәков тәмәкесен нык кына итеп бер суырды да сүзен дәвам итте:

— Һи-и, безнең бабайлар күп сугышканнар инде. Румянцевны да, Суворовны да, Кутузовны да яхшы хәтерлиләр иде. Сугыштан кайткач, улларына һәм оныкларына төннәр буе ерак походлар турында хикәяләр сөйлиләр. Аеруча батыр нагайбәкләр турында бәетләр әйтәләр иде.

Менә безнең күрше поселокның бабалары 1814 елда Парижга беренче булып басып кергәннәр, дип сөйлиләр. Алар моның белән горурланганнар һәм сугыштан кайтып үзләренә аерым поселок корып җибәргәч, аңа Париж дип исем кушканнар. Ә безнекеләр Фершампенуаз тирәсендәге сугышларда аеруча дан казанганнар. Бер төнне генә дә Наполеон үзенең алты меңнән артык солдатын югалткан. Менә безнең поселокның исеме кайдан килә.

Мин әле Шипка штурмында катнашкан картларны яхшы хәтерлим. Аларның күбесендә болгар орденнары бар иде, арада Георгий медаленең тулы кавалерлары да байтак була иде. Порт-Артур оборонасы өчен минем әти дә медальләр алып кайтты. Әйе, казаклар арасында хәрби традиция нык саклана иде...

Традицияләр... Шул ук вакытта уннарча, йөзләрчә нагайбәкләр «патша һәм дин» өчен чит җирләрдә башларын салганнар яки өйгә гарипләнеп кайтып төшкәннәр бит. Болар барысы да казак гаиләләренең материаль тормышына тәэсир итмичә калмаган,

әлбәттә. Һәм чыннан да ул чакта нагайбәк казакларының тормышы башка крестьяннарныкыннан аз аерылган, ә кайбер мәсьәләләрдә әле авыррак та булган. Моны картлар гына түгел, ә тарихи фактлар да бик ачык раслый.

Әгәр элек уртача казак хуҗалыгында бер дисәтинәдән 40—45 пот (6—7 центнер) бодай яки борай алынган булса, хәзер «Нагайбәк» совхозында гектардан 35 центнердан артык икмәк алалар. Элек нагайбәкләр көн аяк киемен бәйрәмнәрдә һәм хәрби хезмәттә генә кигәннәр, калган вакытларын чабата киеп үткәргәннәр. Ә хәзер фершампенуазлыларны шәһәр халкыннан аерып булмый.

Безнең заманның бөек үзгәрешләре, ниһаять, казакларны да Ватаныбызның тигез хокуклы кешеләре рәтенә бастырды. Бары тик Совет власте елларында гына алар «мәңгелек хәрбиләр» булудан һәм һәртөрле мыскыллы кушаматлардан арындылар.

Хәрби буйсынганлык казаклар өчен чын мәгънәсендә бәла була. 1904 елда армиягә алынган 86 яшьлек Михаил Егорович Толмачевның сөйләвенә караганда, хәрби хезмәткә озатулар һәрвакыт фаҗигале бер күренеш булганнар. Исерек есаулның яки атаманның армиягә алынган ярлыларны бөтен халык алдында мыскыл итүләрен бик еш күрергә мөмкин булган.

— Әй, казак, өстеңне кара. Мундирмыни бу, иске чүпрәк ич.

Мыскылланган егет акланырга тели:

— Әткәйдән калганны кидем, яңасын өлгертергә көч җитеп бетмәде.

— Менә без сиңа казак данын ничек мыскылларга икәнен күрсәтербез! Аннары ничек итеп яңа мундир өлгертергә икәнен белерсең. Хорунжий[1], язып куй шуны.

Ә бу инде егеткә хезмәт таягының юан башы төшәчәк дигән сүз.

Менә яшь сукрут[2] җыр сузып җибәрә.

**Сикереп атларга менгән чакта**
**Күрми калдым Гөмбәй[3] кичүен.**
**Үлем хәлләреннән читен хәл**
**Туган җирне ташлап китүе.**

Һәм авыл урамы буеннан-буена кызларның, хатыннарның елавы, илерүе, ялваруы, кемнәргәдер каргышлары белән тула. Ләкин есауллар һәм атаманнар рәхәтләнеп еларга да ирек бирмиләр. Хорунжий бар тавышын җыеп: «Атларга!» дигән әмер бирә. Урамда шау-шу тагын да көчәя. Чиркәүнең чаң кагучысы армиягә яңа алынганнарны «изгеләштерү» өчен кыңгыраулары янына менеп китә. Ләкин җиз кыңгырауларның саңгырау авазлары бушап калган урамнарга тагын да ныграк сагыш кына өсти.

Казак хатын-кызлары әле басу капкасы төбендә озак таптаналар. Алар һаман еракка китеп баручы җырны тыңлап шашына-шашына елыйлар. Ә җыр ераклашканнан-ераклаша бара:

**Биек тауның башында**
**Ялтырап ята гәүһәр ташлары,**
**Аккош очып җитмәс җиргә**
**Җитә казак башлары.**

Казакларны адәм түзмәслек хәрби һәм көнкүреш шартларына бары тик патриархаль тәрбия, властьларның рәхимсез басымы гына буйсындырып тора. Чыннан да, элек нагайбәкләрнең барысы да диярлек укый-яза белмәгәннәр. Хәтта Ильминский[4] системасындагы «халык» мәктәпләре дип йөртелгән нәрсәләр дә нагайбәк авылларына бары тик узган гасырның 60 нчы елларында гына килеп җитә. Анда да программа казак балаларын укыту өчен җайлаштырылган була. Бу мәктәпләрдә «махсус» фәннәргә аеруча басым ясала. Казак балаларын хәрби хәзерлеккә, поход җырлары җырларга, ат өстендә йөрергә өйрәтәләр, казакларның элеккеге походлары турында хикәяләр

---

[1] Хорунжий — казак гаскәрләре офицеры. (Өлкән лейтенант.)

[2] Сукрут — рекрут.

[3] Гөмбәй — Урал кушылдыгы. Фершампенуаз поселогы Гөмбәй елгасы буена урнашкан.

[4] Ильминский Н. И. (1822—1891) — билгеле ориенталист, педагог-миссионер.

укыталар. Һәр уңайлы очракта балаларга, икейөзлеләнеп, аларның казак катлавына керүләрен искә төшерәләр, шуның белән алар «мужиктан бер башка өстен», хәтта «купецлар белән дворяннардан да өстенрәк» дип ышандырырга тырышалар. Шулай итеп, сигез яшьлек нагайбәктән патша ялчысы, сукыр рәвештә атаманнар теләген үтәүче кол әзерләмәкче булалар.

Картлар элеккеге елларда нагайбәклардән кемнең дә булса югары белем алганлыгын хәтерләмиләр. Казандагы керәшен үзәк мәктәбен, укытучылар семинариясен яки юнкерлар училищесын тәмамлау хәтта бай казаклар өчен дә иң югары чик булган. Ә хәзер исә нагайбәкләрнең һәр кызы һәм егете диярлек урта белем ала, аларның байтагы вузларда укып инженерлар, врачлар, агрономнар булалар. Мәсәлән, Магнитогорскида гына да Фершампенуаз кешеләреннән РСФСРның атказанган врачы Василий Николаевич Дусмәнов һәм тау-металлургия институтында физика-математика фәннәре кандидаты Михаил Иванович Артемьев эшли.

Патша ялчылары күпме генә тырышсалар да, нагайбәкләрнең кешелек сыйфатларын җимерә алмаганнар. Халык чуалышлары елларында казаклар да өстен сыйныфларга каршы күтәрелеп чыга. Емельян Пугачев восстаниесе вакытында да, Октябрь революциясе елларында да нагайбәк казаклары халык ягында булалар.

Революция алды елларында Оренбург тирәсендәге казаклар арасында сыйнфый таркалу башлана. Ярлылар саны нагайбәк казаклары арасында аеруча күп була. Чөнки, гомуман, патша властьлары вак милләт казакларын аеруча нык изелүгә дучар иткән булалар. Империалистик сугыш окопларында революцион пропаганда тәэсире астында Беренче Оренбург казак дивизиясе частьлары Румын фронтына барудан баш тарталар. Монда, әлбәттә, соңыннан гражданнар сугышының атаклы геройлары булып киткән бертуган Иван һәм Николай Каширинnarның, Н. Д. Томин[1] һәм революциягә иярген казакларның башка вәкилләре дә зур роль уйныйлар. Болар арасында нагайбәкләр дә була: Василий Николаевич Айтуганов[2], Федор Николаевич Питеев, Василий Дмитриевич Байтирәков, Сергей Николаевич Григорьев. Соңыннан алар Фершампенуазда Совет власте урнаштыралар.

Бөек Октябрь революциясе җиңү белән үк Беренче Оренбург казак дивизиясе Совет властен яклау өчен көрәшә башлый. Дивизия казак комитеты председателе, соңрак дивизия командиры булган Н. Д. Томин Беренче Оренбург дивизиясен Украина эша чыгарып, Мәскәүгә алып килә һәм бу дивизияне Совет хөкүмәте карамагында дип игълан итә[3].

Казак-фронтовиклар, туган станицаларына кайткач, рәхимсез сыйнфый көрәш эченә килеп керәләр. Большевиклар ярдәмендә алар, атаманнарны куып, яңа власть органнары төзиләр, ә инде Дутов бандалары күтәрелеп чыккач, урта хәлле казакларны битарафлаштыру өчен көрәш алып баралар. «Алдауны күргәч, офицерларның, алпавыт һәм капиталист малайларының өзлексез көчләүләрен, суктыруларын, талауларын татыгач... Оренбург казаклары туп-туры Совет власте ягына чыктылар»[4].

---

[1] Каширин И. Д. (1890—1938). Казак гаскәрләрендә подъесаул булып хезмәт итә. 1919 елдан КПСС члены; Каширин Н. Д. (1888—1939). Казак гаскәрләре есаулы. 1918 елда коммунистлар партиясенә керә. Бу ике туган Көньяк Урал партизан отрядларын оештыручылар. Бу отрядлар соңыннан В. К. Блюхер армиясенә килеп кушыла. Икесе дә Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнгән. Томин Н. Д. Беренче Оренбург дивизиясенең элеккеге унтер-офицеры, Совет властеның беренче көннәреннән үк тормышын Кызыл Армиягә багышлый. В. К. Блюхерның партизан армиясендә ирекле Троицк отряды белән, соңыннан гаскәри армиянең кавалерия группасы белән җитәкчелек итә. Өч мәртәбә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1924 елда басмачыларга каршы көрәштә һәлак була.

[2] Айтуганов В. Н. (1886—1918). Казак гаскәрләрендә хорунжий булып хезмәт итә. Оренбургта Совет власте урнаштырылган көннәрдә казак частьларын битарафлаштыра. 1918 елның 18 апрелендә казак депутатларының Фершампенуаз поселок Советы председателе итеп сайлана. Ярлы казаклардан отрядлар оештырып Каширинnar җитәкчелегендәге партизаннар янына җибәрә. 1918 елның августында дутовчылар кулга алалар һәм Верхне-Уральскида җәзалап үтерәләр.

[3] Кара: Янгузов З. Ш. һәм Юдкевич Л. Г. Сквозь огненное кольцо. Казан, 1968.

[4] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә. 30 т. 55 бит.

Гражданнар сугышы башлану белән казак ярлылары, шул исәптән нагайбәкләр дә агалы-энеле Кашириннар оештырган Көньяк Урал партизан отрядларына кушылалар. Соңрак кызыл Оренбург казакларыннан Югары Урал һәм Степан Разин исемендәге Беренче революцион кавалерия полклары оеша һәм алар В. К. Блюхерның партизан армиясе составында сугышалар. Кызыл казак частьлары Дутов һәм Колчак бандалары өчен гаять куркыныч булалар һәм алар, шулай итеп, совет халкының эчке һәм тышкы дошманнарга каршы көрәшенә лаеклы өлеш кертәләр.

Тормышны социалистик үзгәртеп кору елларында атаманнар, офицерлар изүе астында төрле ышануларга бирелеп яшәгән кичәге казаклардан совет кешеләре үсеп чыга. Колхоз, совхоз оештыру, үз поселокларыннан ерак та түгел Магнит гигантын төзү казаклар өчен чын мәгънәсендә яңа тормышны өйрәнү мәктәбе була.

1936 елның мартында казакларның Совет хөкүмәтенә булган мөрәҗәгатендә мондый сүзләр бар иде:

«Атаманнар, офицерлар, кулаклар — эшче һәм крестьяннарны буучылар — тырнагы астында яшәгән иске, каһәрләнгән казак тормышы юк инде...

Яңа, бәхетле совет колхозы казаклары гына бар... Станицаларда, хуторларда, авылларда тыгыз, дусларча, бердәм семьяда яшәүче, бөек Ватаныбызны җилкәгә җилкә куеп сакларга әзер торучы, әгәр таләп ителсә, Ватан өчен һич икеләнмичә тормышларын да кызганмаучы колхозчылар...»[1]

Дәһшәтле сынау көннәре килеп җиткәч, казаклар үз сүзләрен намус белән үтәделәр. Бөек Ватан сугышы фронтларында генераллардан И. А. Плиев, Л. М. Доватор, П. А. Белов һәм башкалар җитәкчелегендәге кызыл казак берләшмәләренең исемнәре онытылмас дан белән күмелде. Алар Верховный Башкомандующийның Ставкасы тарафыннан тапшырылган махсус хәрби заданиеләрне үтәгәндә аеруча батырлыклар күрсәттеләр. Бу батырлыклары өчен алар соңыннан гвардия дигән мактаулы исемнәр алдылар. Элеккеге казаклар шулай ук Совет Армиясенең башка гаскәри төрләрендә дә үз-үзләрен аямыйча көрәштеләр.

Фронтта аеруча батырлык күрсәтүче нагайбәкләргә дә хөкүмәтебез Советлар Союзы Герое исеме бирде. Остроленко поселогында Евгений Архипович Бикбов яши. Аның күкрәгендә Алтын Йолдыз белән рәттән өч Ленин ордены һәм тагын бик күп хөкүмәт бүләкләре тезелеп тора. Шушы ук поселокта тагын ике герой бар. Элекке фронтовиклар, ә хәзер бөтен Көньяк Уралга даннары таралган комбайнчылар Николай Николаевич Васильев һәм Василий Степанович Байкин бу зур исемне тыныч хезмәттә яуладылар.

Ленин орденлы комбайнчылар нагайбәкләр арасында шактый. Бер Фершампенуазда гына да алар дүртәү. Чиләбе өлкәсендә Нагайбәк районын юкка гына ашлык амбары дип йөртмиләр, күрәсең. 1955 елда, Нагайбәк районы чирәм җирләр категориясенә кертелгәч, икмәк алу тагын да артты. Монда илебезнең төрле почмакларыннан яшьләр килде, яңа амбарлар, яңа поселоклар төзелде. Бу якларда хәзер туйлар ешайганнан-ешая. Интернациональ гаиләләр көннән-көн арта бара. Һәм бу гаиләләр чын мәгънәсендә матур тормыш белән яшиләр.

---

[1] «Правда» газетасы. 1936 ел. 18 март саны.

**Йолдыз Нигъмәтуллина,**
филология фәннәре кандидаты

# ҖИЛ ҖЫЛАМЫЙ...

*Габдулла Тукайның образлы фикерләү үзенчәлегенә карата*

Татар филологиясенең «үзәген» Тукай турындагы фәнни хезмәтләр тәшкил итә. Бу очраклы хәл түгел, әлбәттә. Габдулла Тукай иҗаты — безнең горурлыгыбыз, аның мирасы татар халкының иң мөкатдәс байлыгы санала. Әдәбият фәненең бүгенге үсеш дәрәҗәсе көн тәртибенә куйган мәсьәләләрнең һәммәсе диярлек аның иҗат мирасы мисалында хәл ителә. Тукай хакында яхшысыннан һәм яманыннан гаять күп санда мәкаләләр, йөзләрчә китаплар язылган. Киләчәктә алар тагын да күбрәк язылыр. Чөнки шагыйрь иҗатында ачыклыйсы һәм тирәнәйтәсе урыннар, өр-яңадан күзгатылырга тиешле мәсьәләләр җитәрлек әле. Габдулла Тукай әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше, әдипнең образлы фикерләү үзенчәлеге кебек проблемалар һәм халык шагыйренең индивидуаль иҗат йөзен билгеләү белән бәйле башка күп мәсьәләләр тагын да җитдирәк һәм игътибар беләнрәк өйрәнүне көтә. Бу мәкаләдә без шуларның кайберләренә тукталып узмакчы булабыз.

Сүзне Габдулла Тукайның образлы фикерләвенә бәйле мәсьәләләрдән башлап китәсе килә. Чыннан да, аның иҗатында халыкның милли үзенчәлеге ничек чагыла! Аның конкрет сәбәпләре нинди!.. Андый конкрет сәбәпләрнең берсе итеп, иң элек Тукайдагы фикерләү һәм юморның фольклорча нюанслыгын, ягъни теге яки бу шигырьдәге образга салынган төп эчтәлекнең, халык иҗаты әсәрләрендәгечә, бәләкәй генә эмоциональ детальләр һәм сизелер-сизелмәс кенә мәгънә төсмерләре аша алдан ук ишарә ясалып, сиздертеп куелуын күрсәтергә мөмкин. Шагыйрьнең милли үзенчәлекле стиле формалашуда төп рольне шулар уйный. Язмыш Тукайны бик яшьли гади халык массалары арасына ташлый. Булачак шагыйрь халык кулында үсә, аның әкиятләрен, җыр-бәетләрен тыңлап, фольклор әсәрләренә хас образлы фикерләү алымнарын үзләштереп үсә.

Тукайның «нюанслы» фикерләү алымында татар халкының характерына хас үзенчәлекләр, барыннан да бигрәк, халыкның үз-үзен тота белүе һәм эчке кайнарлыгы яки, Мариэтта Шагинян сүзләре белән әйткәндә, аның мөселман өйләрендәге тәрәзәләр кебек, үзенең бөтен дәртен эчкә каратып яшәве чагыла. Тукай талантында татар халкының гаҗәеп эчкерсез һәм саф, ләкин кайбер шәрык халыкларындагыча күзгә бәрелеп тормаган, ә тын алу кебек, елмаю кебек гаять табигый һәм нәфис юморы да гәүдәләнә.

Шуны истән чыгармаска кирәк, фикерләү «нюанс» характерында булганда, әдәби иҗат процессы капма-каршылыгы соң чиккә җиткәнче гиперболаштырылган күзаллауларның кинәт алмашынуы нигезендә түгел, ә бәлки үзара охшаш, бердәй диярлек ассоциацияләрнең сизелер-сизелмәс хәрәкәте яки болай караганда берничек тә

янәшә тора алмастай тоелган, бары тик «вак-төяк» сыйфатлары буенча гына якынаю төшкән күзаллауларның үсеше рәвешендә бара. Әдипнең фикерләү процессындагы иҗади башлангыч әнә шул «вак-төяк» сыйфатларны, мәгънә төсмерләрен тотып ала белүдә күренә. Әдәби фикерләүнең шушы үзенчәлеге халык җырларында ачык чагыла, моны да вакытында Тукай күрсәтеп узган иде. Билгеле булганча, халык җырларының һәр куплеты, гадәттә, ике кисәктән тора. Еш кына әлеге ике кисәкне бәйләүче җепләр күренеп тормаска, кисәкләрнең эчтәлеге дә төрле-төрле булып тоелырга мөмкин. Әмма һәр очракта диярлек сизелер-сизелмәс мәгънә төсмерләре белән әлеге кисәкләр үзара бәйләнгән була, һәм җырның бөтен күркәмлеге дә шул мәгънә төсмерләрендә ачыла. Образлы фикерләүне характерлый торган чыганаклар, ахыр чиктә, халкыбызның үзенчәлекле тарихи үсеш юлына барып тоташа. Шул хакта сөйли торган күп төрле үзенчәлекләр арасыннан иң әлек искелек белән яңалыкның үрелеп килүен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Тормыштагы яңа фикерләргә колак сала бару белән бергә, халыкның сәнгатьчә фикерләве күп гасырлар буе тарихи үсешнең характерына яраклаша килгән. Образлы фикерләү процессы халыкның тарихи үсеш процессына карап формалашкан.

Гаилә тәрбиясе, мәдрәсәдә уку, тормыш мәктәпләре, алдынгы карашлы татар интеллигенциясе арасында хөкем сөргән атмосфера — шуларның һәммәсе Тукай психикасына мәгълүм бер милли фикерләү алымнары һәм калыплары салган була. Ул калыплар халыкның бай, тарихи тәҗрибәсен дә, классик шәрык мәдәниятен, аның гаять кызыклы һәм мөһим үзенчәлекләрен иҗади үзләштерүне дә үз эченә ала. Шуның белән бергә, татар халкының тормышына һәм психикасына киң рәвештә рус һәм Көнбатыш цивилизациясе үтеп керә башлагач, әлеге калыплар җимерелә, яңалары формалаша тора. Үз вакытында А. И. Герцен дөрес билгеләп үткәнчә, «Казан — ике дөньяның очрашкан һәм көрәшкән урыны. Шуңа анда ике: Шәрык һәм Гәреп башлангычлары, сез аларны һәр чатта очратасыз; биредә алар, бер-беренә өзлексез тәэсир итешүдән, үзара якынайган, дуслашкан, характеры буенча өченче бер яңа башлангыч оештыра башлаган»[1]. Бу җәһәттән, географик урыны, тарихи роле белән дә Казан борынгы Ереванны хәтерләтә. Һәр ике шәһәр Шәрык белән Гәрепнең, Көнчыгыш мәдәнияте белән Көнбатыш мәдәниятенең очрашкан ноктасында урнашкан, аерма шунда гына, Ереван бу ноктаның чигендә, тышкы ягында, ә Казан исә аның эчке ягында. Һәм Казанның шушы хәле татар халкының сәнгатьчә фикерләвенә дә тәэсир ясый, Шәрык һәм Гәреп традицияләренең бер-берсенә йогынтысы монда аеруча көчле була. Тагын шуны истән чыгармаска кирәк: үз территориясендә яшәүче төрки халыклар белән Европа илләре арасында мәдәни арадашчы ролен үтәгән Россия үзе дә, Көнбатыш халыклары күзлегеннән караганда, Шәрык иле саналган.

Тукай стиленең новаторлыгын тәэмин иткән төп фактор, шулай да, заман үзе. XX йөз башындагы революцион һәм милли азатлык хәрәкәтләре эпохасы үзенең эстетик асылы белән дә бай була. Революцион чынбарлыкның рәхимсез нурлары яктылыгында иске җәмгыятьнең ямьсез шешләре һәм җыерчыклары аеруча ачык беленә башлый. Ә халык тормышы Х. Ямашев, Г. Коләхметов кебек батыр улларының көрәше белән тагын да ачылып, нурланып китә. Халык тормышындагы трагик хәлләр дә меңтөсле төсмер ала, бу үз чиратында татар романтизмындагы берничә тармакның үсешенә нигез бирә. Шуларның һәммәсе Г. Тукай психикасының характерын билгели, бу — шагыйрьнең чынбарлыкка эмоциональ мөнәсәбәтендә дә чагылыш таба.

Г. Тукайның үзен чолгап алган тирә-юньгә мөнәсәбәте күпкырлы һәм катлаулы, шул ук вакытта искиткеч камил дә. Шагыйрь үз заманындагы чынбарлык белән берничек тә килешеп яши алмый. Ул буржуаз дөньяның «тимер читлегендә» интегә һәм шул хис аның шигъриятенә трагик авазлар сала, бу — Тукайны М. Ю. Лермонтовка якынайта. Тукай тормышның комик якларына да кискен мөнәсәбәтен белдереп бара. Бары аңа гына хас үтергеч ирония белән бай һәм муллаларны, сатлык нәширләрне һәм милләтчеләрне камчылый һәм Тукай шигырьләрендә Гейне сулышы, Сабир көлүе ишетелә башлый. Социаль симпатия һәм антипатияләрнең аныклыгы, халык алдындагы шәхси җаваплылык һәм гражданлык бурычларын тирән аңлау Тукай

---

[1] Литературное наследство. Рус телендә. 61 том. Мәскәү. 1953 ел. 19 бит.

мирасын Некрасов мирасына якынайта. Тукай лирикасы, аның өзелгән өмет һәм кайнар яшь белән сугарылган җырлары кайчак төрек шагыйре Тәүфыйк Фикрәтнең «Сынган сазы» белән авааздаш булып китә. Тукайның дөньяга карашы күпкырлы булу һәм үзгәреп-алмашынып торуы хакында сөйли торган мондый аналогияләрне күп китерергә мөмкин.

Тукай иҗатын башлап тикшерүчеләрдән Җ. Вәлиди, шагыйрь хисләренең гаять катлаулы һәм күпкырлы булуын күздә тотып, болай дигән иде: «Ул таулардан чылтырап ага торган бик күп вак чишмәләр мәҗмугасы, бу чишмәләр, бик вак булу белән бәрабәр, бик матурлар. Алардан һәрбер узып баручы эчеп, сусынын кандырып китә» [1]. Шулай да Җ. Вәлиди иң мөһимен күрми кала. Ул башлаган чагыштыруны тагын да киңәйтә, үстерә төшкәндә, Тукай иҗаты таулардан ага торган вак чишмәләр генә түгел, шул чишмәләрнең үзләренә дә, күңел елгаларына да тормыш биргән гигант бер тау дияргә булыр иде. Тукайның дөньяга карашындагы эстетик идея, төп эстетик сыйфат гүзәллек хисендә чагыла. Ул хис аның йөрәгендә халыкка булган искиткеч зур һәм көчле мәхәббәте тәэсирендә, аның рухи мөмкинлекләренә, акылына, киләчәк бәхетенә тирән ышану нәтиҗәсендә туган. Тукай өчен халык: мәхәббәт тә, акыл көче һәм гүзәллек символы да иде.

Трагик һәм комик хисләренең басынкылыгы, сабырлыгы, аларның гүзәллек тойгыларына буйсындырылган булуы Тукай карашының татарча «моңын», милли колоритын билгели. Поэтик фикернең нечкәлеген билгели торган трагик һәм комик хисләр гүзәллек тойгысының тирәнлеген, аның эмоциональ буяулар белән куертылган булуын гына көчәйтәләр. Болар һәммәсе образлы фикерләү тибын да, аны чагылдыруның милли үзенчәлеген дә билгели.

Тукайның образлы фикерләве реалистик характерда [2], чөнки аның фикерләү процессында тормышны объектив рәвештә чагылдыру өстенлек итә. Реаль чынбарлык Тукай өчен һәрвакыт халык язмышы белән бәйле була, шуңа күрә аның лирик «мине» тормышны каплап тормый. Халык язмышы өчен борчылып яшәү шагыйрьдә тормышны аңлау теләген көчәйтә, аны тасвирлаганда ахырга кадәр объектив булырга ярдәм итә. Аннан соң үз таланты көче белән шагыйрь образлы фикерләүдәге милли үзенчәлекне яңа баскычка күтәрә: фикер «нюанслыгы» Тукайда төп фикернең тотрыклылыгына омтылыш белән чиратлаша. Шул рәвешчә, Тукайның образлы фикерләвендәге эстетик закон бу процесстагы ике тенденциянең каршылыклар берлеге: фикерләүнең «нюанслы» характерда булуы һәм төп фикернең тотрыклылыгына омтылу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Фикерләүнең «нюанслыгы» Тукайга хас образлы фикерләүнең шундый үзенчәлекләре белән бәйләнгән ки, бер караганда, аларны һич кенә дә акылга сыйдырып булмый. Без Тукай стиленең Х. Госман мәкаләсендә [3] ышандырырлык итеп ачылган антитезалар белән фикерләү, афоризмнарга тартымлык кебек индивидуаль сыйфатларын күздә тотабыз. «Нюанслылык»ның һәм фикерне куертып, җыйнап (антитезалар, афоризмнар һәм башка формалар аша) гәүдәләндерүнең катлаулы мөнәсәбәте Тукайдагы образлы фикерләү процессының үзенчәлекле сыйфатын тәшкил итә дә инде. Фикернең предметына һәм авторның аны ничек бәяләвенә карап, фикерләү стилендәге бу мөһим закончалык аның әсәрләрендә төрлечә гәүдәләнә.

Игътибарны шушы закончалыкның төп өч формасына яки, башкача әйткәндә, Тукайның стиль манерындагы өч төрле үзенчәлеккә юнәлтик.

Иң әүвәл фикер төсмерләре бер үк образны кабатлаганда яки үзара охшаш, бердәй образларны чагыштырып караганда барлыкка килә. Кабатланып килгән әлеге образлар символик образлар да, антитезалы образлар да һәм сатирик гротеск та булырга мөмкин. Бу очракта төп фикернә нәкъ менә нюанслар — мәгънә төсмерләренең үзгәрүе сиздереп бара. («Көзге җилләр», «Кулың», «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» һ. б.) Бу группага керган әсәрләрдә яңа заман рус һәм Шәрык шагыйрьләренә якынлык сизелә.

---

[1] Тукай турында замандашлары. Казан. 1960 ел. 265 бит.

[2] Бу әле Тукай иҗатында романтик әсәрләр булмаган дигән сүз түгел.— Й. Н.

[3] «Казан утлары» журналы. 1968 ел. 5 сан.

Тагын Шәрык поэзиясендәге символик образларның күпмәгънәлелеге белән бәйләнгән икенче төрле нюанслар бар. Аларда символның бер мәгънәсеннән икенче мәгънәсенә күчелә. («Өмит», «Хөррият», «Өзелгән өмит».)

Соңгы өченче төркемгә шагыйрь тарафыннан махсус аерып куелган фикерне типик торган һәм еш кына афоризмнар формасында бирелгән яки әсәрнең исеменә күчерелгән фикер һәм настроение нюанслары керә. («Гыйшык», «Толстой сүзләре», «Толстой фикере», «Үтенеч», күп санлы «Кыйтга»лар һ. б.).

Үзенән-үзе аңлашылса кирәк, бу — шактый шартлы бүленеш. Саф, чиста хәлендә әлеге фикерләү формаларының һәркайсы сирәк очрый, күпчелек очракта алар катнаш, үзара кушылган хәлдә булалар. Һәм Тукайның образлы фикерләвендәге мондый стилистик байлык аның поэзиясенең тирән интеллектуаль характерда булуы хакында сөйли.

Шушы очракларны төрле елларда язылган, формалары, тематикалары ягыннан төрле-төрле, ә стильләре белән үзара бертөсле булган берничә әсәргә анализ мисалында карап узыйк. Әсәрләрне шул рәвешчә сайлап алу, берьяктан, стиль билгеләренең тотрыклыгын, икенче яктан, стиль алымнарының күптөрлелеген күрсәтү өчен кирәк.

«Көзге җилләр» (1911 ел) шигырендә, мәсәлән, нюанслар — мәгънә төсмерләренең ишарәсе бер үк «җил җылый» образын кабатлау процессында хасыйл була. Тукай иҗатындагы социаль лириканың гүзәл үрнәге саналган бу шигырь буйдан-буйга халык язмышы өчен борчылу хисе белән сугарылган. Бөтенләй диярлек Ф. Достоевский рухында иҗат ителгән «җылау»ның трагик образы, бөтен дөньяны иңләп алган халык кайгысы образы романтик формага салынган. Бу образның нигезендә гадәттән тыш эмоциональ көчкә ия булган романтик гипербола ята: көзге җил җылый, бөтен ил җылый. Тора-бара бу гипербола чын мәгънәсендә космик күләм ала: ачлар җылавына изге, шәфкатьле җир-ана җылавы, пәйгамбәрләр, хәтта җан алырга курыккан Газраил җылавы кушыла. Көзге төннең караңгылыгы халык тормышындагы бетмәс-төкәнмәс кайгыны белдерә.

Шулай да сәнгатьчә фикерләү тибы ягыннан бу реалистик әсәр. Тукайның образлы фикерләвендәге реализм шуннан гыйбарәт: бергә җыеп алганда символ дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән поэтик ассоциацияләр тасвирлана торган предметның төп, асыл сыйфатларын чагылдыралар. Символик образ ачык беленеп торган бер төп мәгънәгә ия. Бу — ач үлемнән курку, ачларның настроениеләренә психологик характеристика, социаль тигезсезлекне аңлау. Символик образ объектив, ягъни лирик геройның психологик хәленә бәйле булмаган чынбарлыкны гәүдәләндерә. Лирик геройның хисләре «җылаган җил» белән өлешчә генә (халык кайгысына теләктәшлек белдерүе) авазлаш яңгырый. Алар, әлеге хисләр, төп образда чагылган нәрсәләрдән бәеракта, мөһимрәк тә. Лирик герой белән символик образ арасындагы бу аерымлыкка шигырь алдыннан китерелгән эпиграфта ук ишарә ясала.

Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен,
Ядыма тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен.

(Русчадан)

Шигырь текстының үзеннән әлеге «күңел йолдызын», «өмет алласын» табу күп тапкыр кыенрак, чөнки алар фикер һәм хисләрнең үтә нечкә төсмер-ишарәләрендә, үсеш-үзгәрешләрендә гәүдәләнә.

Шигырьнең беренче куплеты халык җырларына хас кире параллелизм принцибына нигезләнеп төзелгән:

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

Бу строфада лирик геройның кичерешләрен (көзге йокысыз төндәге күңелсез хисләр, ач халык кайгысы турында уйлану) сурәтләүгә төп игътибар бирелгән. «Алмыйм-җыламый» кебек эчке рифмалар ярдәменә лирик герой белән символик образның бердәмлегенә басым ясала. Алм, ач, җи, җы авазларының үзара кабатланып килүе, ягъни аллитерация алымы да шул ук максатка хезмәт итә. Тышкы рифма исә (җил җылый — ил җылый) символик образның эчтәлегенә ишарә ясый.

Икенче строфадан алып, лирик герой символик образдан аерымлана, әгәр шулай әйтергә ярса, символик образ объектив характер ала башлый. Лирик геройның конкрет, социаль уйлары (кешеләрнең ашарга икмәге юк) җир-ананың җылавы төсендә бирелә. Шигырьнең лирик подтексты (Көзге төн караңгылыгындагы өмет йолдызы) җир-анага бирелгән характеристикада чагыла: ул — «изге, шәфкатьле, мәрхәмәтле». Бу строфадагы фикер нюансы (дөньяда әйбәт кешеләр дә юк түгел) нәкъ аның аша белдерелә. Өченче строфада социаль контрастка бик мөһим яңа фикер өстәлә: алтын теш куйдырып яткан байлар, туклар — картлык, искелек символы, ә ачлар, ялангачлар — тормышның яшьлеге. Бу фикер сизелер-сизелмәс кенә детальләр аша белдерелгән. Алтын теш куйдыртучы корткага нәфис яшьлекнең символы булган «назлы нечкә бил» каршы куелган.

Алдагы строфада лирик подтекст традицион мифологик образның мәгънәсен көтелмәгәнчә яңарту («Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый») ярдәмендә көчәйтелә. Бишенче строфада кабат антитеза калкып чыга:

Келсә монда тук вә ихлассыз халык тәкбирләре,
Һәр ишеткән җан җыларлык, андагы тәкбир җылый.

Үзенең төп мәгънәсе белән ул өченче строфадагы антитезадан берни белән дә аерылмый диярлек. Әмма аңа яшерелгән нюанс мөһим: ачлар җылавы хәзер көзге җил тавышында түгел, ә дини бәйрәм алдыннан алла исәнлегенә әйтелә торган тәкбирдә ишетелә. Массалар настроениесен чагылдыруның бу яңа эмоциональ формасы лирик геройны котылгысыз кайгыдан тагын да ераклаштыра төшә.

Һәм, ниһаять, соңгы строфа безне кабат беренче куплетта тасвирлаган күңелсез күренешкә кайтара:

Көзге төн, ямьсез, караңгы... Өй түрендә җил җылый;
Җил хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

Ләкин бу картинада инде лирик герой образы юк. Курку, сагыш, өметсезлек хисләре җиңелгән. Шагыйрь күңелендә нурланып «өмет йолдызы» яна...

Шулай итеп, шигырь исеменең мәгънәсе — «Көзге җилләр» — шагыйрь тарафыннан алгы планга чыгарылган, кабатланып килгән «җ и л  җ ы л ы й» образының һәм бу образның лирик яктан аңа каршы куелган нюансларының үзара мөнәсәбәте аша ачыла. Образлы фикерләү процессында ул нюанслар әсәрнең төп фикерен, аның поэтик идеясен хасыйл итәләр.

Бу шигырьне демократ һәм гуманист төрек шагыйре Т. Фикрәтнең шундыйрак кайбер шигырьләре белән чагыштырып караганда, Тукайның образлы фикерләвенә хас үзенчәлек аеруча ачык күренә. Замандашларының фикеренә караганда, Тукай Т. Фикрәт поэзиясен дә, аның әлгәрсләре саналган романтиклардан Г. Хәмид һәм Н. Кемалләр иҗатын да яхшы белгән.

Шигъри ассоциацияләрнең милли характерын билгеле бер күләмдә колоритлы әдәби детальләр гәүдәләндерсә дә, образлы фикерләүнең милли үзенчәлеген ул детальләр генә билгеләми. Т. Фикрәт иҗатында, мәсәлән, җәйге төн коңгырт йөзле чибәр төрек кызы белән, изелгән ил — корган чинар агачы, халык — дөя образы, өзелгән өметләр шагыйрьнең сынган сазы белән чагыштырыла, әдипнең ялгызлыгы Босфорның таш ярлары буенда калган ялгыз әзләр төсендә тасвирлана. Әлеге шигъри ассоциацияләрдән Төркиянең романтик табигатьле шагыйрь тарафыннан тасвирланган «экзотик» географиясе күз алдына баса. Фикрәт шигырьләрендәге күптөслелек, ачык буяулар нигездә романтик функция башкара, алар күбрәк укучыга шагыйрь йөрәгенең эчке хәле турында сөйлиләр. Алар, Төркия пейзажы булудан бигрәк, әдипнең «күңел пейзажы».

Тукай шигырьләре бөтенләй башка типта. Бу аңлашыла да, чөнки Тукай поэзиясендәге милли колорит бөтенләй башка тормыштан, башка географияне чагылдыра. Тукайда без Казан арты табигатенең тыйнак матурлыгы («тау башындагы авыл», «киң сәхраләр», «нурлы Казан» һ. б.), образларның татар әкиятләренә һәм халык җырларына хас самими мелаемлыгы («табигать иркәсе Шүрәле», «Су анасы», «Кабан күле төбендәге пәри шәһәре») белән очрашабыз. Хикмәт тагын шунда, Фикрәт иҗатыннан аермалы буларак, Тукай әсәрләре «җирле», «милли колоритлы» детальләргә алай бай

түгел, табылган очракларда да алар социаль яктан үткенәйтелгән: табигать күренешләре, Татарстан географиясенә хас детальләр халыкның социаль тормыш күренешләренә ишарә ясарлык итеп алынганнар.

Үз вакытында Тукай поэзиясенең бу үзенчәлегенә Г. Нигъмәти дә игътибар иткән. Тәнкыйтьченең «Тукай иҗаты»[1] исемле мәкаләсендә китерелгән кайбер мисалларга мөрәҗәгать итик: шагыйрь кар болытлары арасыннан елмайган айны чарлагында коелеп басып торган байга, ә үзен михнәттә яшәүче фәкыйрьгә тиңләштерә («Буран»), яз көне сазлыклардан чыккан бакалар иске мәдрәсәнең схоласт шәкертләрен искә төшерәләр («Яз галәмәтләре»), көзге табигатьнең ялангачлыгы татар мещаныңың кырылган башын хәтерләтә («Көз»). Т. Фикрәт поэзиясендә очрый торган формадагы милли колорит Тукайда бөтенләй юк диярлек. Үз әсәрләрен әнә шулай милли детальләр белән типчергә теләмәүдә (бәлки, шагыйрь моны аңлы рәвештә эшләгәндер[2]) Тукайга хас реалистик фикерләүнең милли үзенчәлеге: аның нюанслыгы, хис һәм фикерләренең мәгънә төсмерләрен үстерә-үзгәртә бару аша әдәби гомумиләштерүләргә бару юлы чагыла. Специфик, милли детальләрнең күплеге үзләренә игътибарны тартып, фикернең нюанслыгын сиземләргә комачаулар, аны томалап калдырыр иде.

Шуңа күрә Тукай традицион образлар, гомуми кешелек, барыннан да бигрәк, Шәрык халыклары әдәбияты (татар, фарсы, гарәп, әзербәйҗан һ. б.) өчен традицион саналган төшенчә һәм образлар белән эш итә. Бөтен хикмәт шуларны яңача аңлауда, аларның яңа мәгънә төсмерләрен, яңа сыйфатларын ачуда. Күреп үткәнчә, «Көзге җилләр»дә без әлеге әсәрнең романтик формасын тәшкил итүче бик күп символик образлар белән очраштык, ләкин аларның берсен генә дә бары татарларга гына хас чагыштыру дип булмый. Шәрык шагыйрьләре иҗатыннан аларның теләсә кайсын табып була. Әмма аларның үзара мөнәсәбәте, бер-берсе белән бәйләнеше бары тик аңа гына хас, бары Тукайча гына.

Үзенең яңгырашы, рухы белән «Көзге җилләр»гә аваздаш шигырь Т. Фикрәт иҗатында да бар. «Күз яшьләре аша көлү»[3] дип атала ул. Анда шагыйрьнең тормыш кыенлыкларын күреп өзгәләнүе, хәсрәт утында януы тасвирлана.

Тукай шигыре кебек үк, бу лирик миниатюра да капма-каршы хисләрне, өмет һәм өметсезлек, сагыш һәм шатлык тойгыларын чагылдыра. Шулай да, биредәге «көзге җил» образына тирәнрәк колорит салынган: аның җиле, шашкын дулкыннар тавышына кушылып, диңгездән исә, ул шагыйрьнең күңел киңлекләренә омтыла һәм анда хәвефле кичерешләр давылы кузгата. Төрек тормышының коточкыч картиналары Фикрәт күз алдына төнге диңгезне чайкаган көзге ачы җил сурәтендә килеп баса. Шул ук вакытта бу образ шагыйрьнең психик хәлен, һәлакәтне алдан сизеп борчылуын да аңларга ярдәм итә. («Чөнки дөнья бетәчәк, чөнки кыямәт...») Паузалар белән бүленгән икеюллыклар шагыйрь йөрәгенең сиркәк, әмма көчле тавышы кебек яңгырыйлар... Капма-каршы хискә күчү («но вскоре волною заплещет улыбка в тиши») бернинди хәзерлексез, дәлилсез һәм көтмәгәндә эшләнә. Лирик хиснең үсеше юк, тирәюньгә булган трагик караш шул көенчә, җиңелмичә, хәл ителмичә кала. «Көзге җил» образы Фикрәттә күбрәк рәсемгә тартым, Тукайда исә символиграк.

Тукай һәм Фикрәт стиленең әлеге ике шигырьне чагыштыру барышында күзгә ташланган кайбер милли үзенчәлекләре тагын шул яктан кызыклы: алар дөньяга карашның образлы фикерләү стиленә ничек тәэсир итүен аңларга булышалар (Тукайда трагизмны җиңү һәм фикерләүнең нюанслыгы; Фикрәттә образларны романтик планда каршы кую аша трагизмны раслау).

Фикерләүнең нюанслыгы Тукайның сатирасында да чагыла. «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасында, мәсәлән, гаять кызыклы, ләкин татар әдәбиятында сирәк очрый торган күренешкә тап булабыз. Сүз сатирик гротескның, сатирик фантастиканың шагыйрь фикерләренең нюансларына буйсынган булуы хакында бара. «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасындагы фикер үсеше үзара охшаш, бер типтагы, төп эчтәлекләре белән берсе икенчесеннән аерылмаган образларның кабатлана килүенә нигезләнгән. Р. Ганиева дөрес күрсәткәнчә, Карәхмәт, Дию, Кисекбаш, «Камчылы ишан»

---

[1] Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. Казан. 1958 ел.

[2] Г. Тукайның «Хасият» дигән шигыренә игътибар итегез.— Й. Н.

[3] Т. Фикрет. Белый парус. Стихи. Рус телендә. Мәскәү. 1967 ел.

асылда бер үк җыелма образның — XX йөз башы татар буржуазиясенә һәм дин әһелләренә хас дини фанатизм, икейөзлелек, наданлык, шәхси милекчелек психологиясе һәм политик реакциянең җанлы гәүдәләнеше булган Печән базарының — төрле вариациялӘре генә. Шагыйрь тарафыннан Кисекбашка бирелгән характеристиканы, мәсәлән, әлеге образларның теләсә кайсына күчерергә мөмкин. Бер үк сатирик алымнарны (гипербола, фантастика, гротеск, пародия) куллануы белән дә шагыйрь аларның охшашлыгына басым ясый.

Поэманың татар пәһлеваны Карәхмәт турындагы хикәя белән башланып киткән беренче бүлегендә, болай сүз арасында гына әйтеп узылган кебек, әмма әсәрнең образлы системасын аңлау өчен ифрат мөһим булган бер фразага юлыгабыз:

Хак тәгалә нәрсә кылса ирке бар,
Рус Микитинның Казанда циркы бар.

«Кодрәтле хак тәгаләне һәм цирк хуҗасы Микитинны бер шигъри рәткә кую «хак тәгалә ирке» белән Печән базарында барган гаять зур һәм җирәнгеч спектакльне тасвирлау өчен таяныч ноктасы булып тора. Аның тамашачылары һәм катнашучылары мәш килгән итчеләр, тиречеләр, шәмчеләр һ. б., һ. б. Циркның үз «җәнлекләр әйрәтүчесе» дә бар, ул — Камчылы ишан, ул кулга ияләндерелгән җәнлекләр дә бар. Бу спектакльдә шау-шу күп, хәрәкәт күп. Кешеләр дә, этләр дә, җансыз әйберләр дә — һәммәсе хәрәкәттә, кайнамакта.

Йөгерешәләр сөртенә дә абына,—
Барча мөэминнәр «Кәфер почмагына»...

Мин дә чаптым шунда мөэминнәр белән,—
Мәскәвски якка күз салсам, күрәм:

Тәгәрәп юл уртасыннан таш килә,—
Таш түгел лә — бер киселгән Баш килә...

Әрҗәдә читек-кәвешләр кузгала,
Һәм өеп куйган кәләпүшләр ава...

Толпа җылый, үкси, дога кыла, шөкерана кыла, шатлана, кабат җылый, кабат мәш килә... Шушы шау-гөр, мәш килү асылда «корыны бушка әйләндерү» генә булып чыга. Сатирик моны беренче карашка күзгә ташланып тормаган бәләкәй-бәләкәй детальләр аша һаман сиздерә, искә төшерә тора: йөгерүче толпа һәрвакыт «Кәфер почмагы»на житүгә туктап кала, җилдәй кузгалып киткән вагон сахрага барып җитүгә туктый, мәдрәсә шәкертләре Кабан күленең кипкәнен көтеп гомер уздыралар, әсир ителгән Дию киныт Яңа бистә якка ут булып оча, Карахмәткә алтын сәгать бүләк итәләр, тик нилектәндер чылбыры юк һ. б. ш. Поэманың алка рәвешендәге түгәрәк композициясе дә Печән базарында барган вакыйгаларның файдасыз, кирәксез бер эш булуына ишарә ясый. Бу яктан караганда, поэманың ахыры аеруча мөһим. «Кайнамактагы» базар күренеше классик гарәп поэзиясе үлчәүләреннән берсен схематик кабатлау белән тәмамлана, бер үк вакытта бу гарәп телендәге «эшләргә» дигән инфинитив фигыль белән сүз уйнату да:

Фагыйлатын, фагыйлатын, фагыйлат,
Ну, Печән базары халкы күңеле шат!

Сизелер-сизелмәс кенә детальләр, әлеге спектакль картинасына өсте-өстенә өелеп, аны Коръәннең үзендә тасвирланган тәмугка охшатып калдыралар. Бу — добердап кайнап торган галәмәт зур казан, эче тулы тәмуг ияләре, алар акыралар, бакыралар, шау киләләр... Фикер тәсмерләренең акрынлап үзгәрүе нәтиҗәсендә туган «Печән базары» — «цирк» — «тәмуг» кебек поэтик ассоциацияләр үз чиратларында яңа нюанс тәсмерләре тудыралар. Фикернең әлеге яңа нюанслары әсәрдә сурәтләнгән вакыт рамкаларын бик нык киңәйтәләр, бүгенгене ерак үткән белән бәйлиләр һәм шагыйрьнең киләчәк турындагы хәвефле уйларын чагылдыралар. Әдәби фикерләү процессында поэмадагы сатирик образларның бөтен системасы беренче карашка әллә ни мөһим

тоелмаган, ләкин кинәт беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия булып киткән ике детальга кайтып кала:

«Дию нигә фәсле!» — дип «аптырый» автор.

«Киселгән баш, үзе тере»,— дип гаҗәпләнә базардагы халык. Диюнең су асты патшалыгын автор Кисекбашның авырлыгы белән үлчи:

Ул Карәхмәтнең билендә бавы бар:
Бауның алты мең колачлы буе бар.

Бау белән ул эшне яхшы җайлады:
Бәр очын башның тенәнә бәйләде.

Бер очын учлап, Кабанга чумды ул,
Туп-туры шуннан коега тотты юл...

Шул юл белән Дию пәрие, Печән базары һәм Кисекбашның кан кардәшләр бу.уына басым ясала. Ә бит Дию, Иван Грозный гаскәрләре Казанны алганда, Кабан күленә батырылган ханлыкның башлыгы[1]. Шул рәвешчә, Дию башындагы фәс символик мәгънә тәсмере ала. Фәс артына күп нәрсә, барыннан да бигрәк, фанатик муллалар, хезмәт ияләре язмышына төкереп караучы комсыз байлар тарафыннан тормышы җәһәннәмгә әйләндерелгән татар халкының фаҗигале язмышы яшеренгән. Әгәр без Кисекбаш белән Дию образларын янәшә куеп карасак та, аларга зур сәяси мәгънә салынганын күрәбез: сатирик 1905 елгы революциядән соң да тормыштагы искелек калдыкларының, милли һәм феодаль гореф-гадәтләрнең һаман сөйрәлеп йөрүләренә ишарәли. Бер фактта, бер образда гади көнкүреш күренешләренең һәм политиканың бергә үрелүе, комиклык белән трагиклыкның, юмор белән гротескның үзара кушылуы Тукайның социаль сатирасына политик төс бирә, «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасын С. Щедринның иң күренекле әсәрләренә аваздаш итә.

Поэмадан күренгәнчә, Тукай фикеренең нюанслы характеры, образның сизелерсизелмәс кенә үсеш-үзгәрешләре, күзгә ташланып тормаган штрихлар һәм детальләр аңа тарихилыкны көчәйтергә, социаль күренешләрнең асылын ачып салырга ярдәм иткән.

* * *

Тукайдагы нюанслы фикерләүнең халыкчан, милли чыганаклары аның шигырьләрендәге символиканы һәм символлар белән уйлау үзенчәлеген классик гарәп шигъриятендәге символлар белән янәшә куеп, чагыштырып караганда да ачык күренә. Билгеле булганча, гарәп шагыйрьләре үз иҗатларында сүзнең күпмәгънәлелегеннән, бер үк сүзнең төрле мәгънәләр белдерә алуыннан бик оста файдаланганнар. Бу аларга чынбарлыктагы күренешләрнең яңадан-яңа якларын ачарга булышкан. Гарәп шагыйрьләренең шушы матур традициясен дә Тукай иҗади үстерә, тагын да камилләштерә. Тукай лирикасында бер үк образның төрле якларын ачарга омтылу еш кына аларны диалектик капма-каршы куеп карауга китерә, моның төп максаты — теге яки бу образда чагылган тормыш күренешенең эчке каршылыгын күрсәтү.

Шул хакта сөйли торган мисал төсендә «Өмит» (1908 ел) шигырен алырга мөмкин. Ул күп буынлы символикага, бер үк образның мәгънә төсмерләрен үткенәйтүгә һәм каршы куюга корылган. Бу шигырьдә кояш образы капма-каршы характердагы өч төрле мәгънәдә кулланылган. Беренчедән, классик гарәп шигърияте ндәге кебек үк, ул традицион мәгънәдә — фикер, акыл символы. Аны «үлгән вөҗданга» каршы кую XIX йөз ахыры һәм XX йөз башындагы татар мәгърифәтчелеге рухында («Акыл» — искергән этик нормаларны җимерергә, кешенең намусын,— гражданлык бурычларын аңлау хисен уятырга сәләтле көч) эшләнгән.

Икенче куплетта символ үзе («кояш») капма-каршы ике образга: «утлы кояшка» һәм «гыйсъян утына» бүленә. Фикер — хакыйкать кояшы (символның яңа мәгънә төсмере) ялган идея, ышану һәм күзаллауларга каршы куела. Шуннан «гыйсъян уты» барлыкка килә, аны «хакыйкать кояшы» сүндерергә тиеш. Өченче куплетта символ мәгънәсендәге бу төп нюанс Хафиз рухындагы метафора белән («Мәңге тотынып нәрсә юктыр, ул килеп җеп салмаса») тагын да көчәйтелә төшә. Дүртенче куплетта

[1] Дию образын башкача аңлатучылар да бар.— Й. Н.

шагыйрь «фикер коялшы»ның функцияләрен, һич тә уйламаганда, «шәмгә» тапшырган дай була:

> И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр жирдә шәм,
> Нәрсә ул дөнья кояшы, син миңа нур бирмәсәң!

«Фикер кояшының» бу яңа варианты яңа мәгънә төсмере дә бирә. («Чәчәкләр атсын өмит бакчамда ал гөлләр минем»). Шәрык поэзиясендә «бакча», «чәчәкләр бакчасы» иҗат эшен, «шигърият бакчасын» аңлата. Шәм образы исә Тукай биографиясенең кайбер фактлары белән бәйле берничә ассоциация кузгата. Бу образ туберкулез белән авырган татар шагыйренең үзенең салкын бүлмәсендә, шәм яктысында, ялкынлы шигырьләр язып утыруны күз алдына китерә.

Шул рәвешчә, «Өмет бакчасы» — «шигърият бакчасы», ә «кыйммәтле шәм» шагыйрьнең иҗат энергиясе символы — илһам булып китә. Символик образның бу өченче мәгънәсенә шагыйрь әируча басым ясый һәм бу очракта да ул халык жырларының художество принципларына таяна. Кире параллелизмга корылып шуннан соң килгән өч куплет илһамсыз, иҗади фикерсез яшәүнең күңелсез күренешләрен тасвирлый. Әмма халык мәкаленең көлкеле, жанлы интонациясе («Күп вакытта сискәнәм, яңлыш тотып, кош дип бака») символик буяулар ярдәмендә ясалган картинаның трагизмын шактый киметә. Шуннан соңгы куплетка искиткеч осталык белән килеп кергән «кыскасы»:

> Кыскасы: җансыз да, вөҗдансыз да мин, яктырмасаң;
> Мин әле кая барам? Жуйган эзем таптырмасаң? —

трагизмны тулысы белән диярлек алып ташлый. Мондый контекстта әлеге сүзне куллану Тукай юморының искиткеч нечкәлеге һәм тирәнлеге турында сөйли. Соңгы куплетлардагы абстракт образлылык аша бик тә конкрет тарихи ассоциацияләр төсмерләнә. Шагыйрь күңеле белән күптән түгел узган «болытсыз елларга» (1905 ел) әйләнеп кайта, ул үзенең «югалткан эзләрен» табарга өметләнә. Шигырь гражданлык хисләрен белдерүче искиткеч көчле юллар белән тәмамлана:

> Юк! Түбән калмас бу жан: фитратта гали булган ул;
> Кисмәк өстендә кара кош — иттифакый кунган ул!

* * *

Тукай фикеренең нюанслыгын күзәтү өчен аның фәлсәфи-публицистик характердагы шигырьләре бай материал бирә. Андый шигырьләрдә фикер-тема (еш кына афоризм формасында) турыдан-туры атала һәм темага анализ бирелә яки аны раслау өчен дәлилләр китерелә. Дәлилләү процессында туган фикер нюанслары темада ук гәүдәләнгән фикерне яңа баштан бәяләүгә, ә еш кына бөтенләй кире кагуга китерә. Менә, мәсәлән, Тукайның 1911 елда Л. Толстойның этик тәгълиматы, аерым алганда, аның никах хакындагы өйрәтмәләре белән мавыгып йөргәндә язган «Толстой фикере» дигән шигыре. Бу шигырьнең төп фикере баштагы юлларда ук бирелгән:

> Әле мөмкин икән иркеңне тоткынлыкка сатмаска,
> Жаның көчсезлеген һич тә бу дөньяга сынатмаска,
> Өйләнмә . . . . . . . . . . . . . . . .

Толстойның әлеге фикерен дәлилләү өчен, Тукай төрле характердагы күп кенә аңлатулар һәм мисаллар китерә. Шул ук вакытта «дәлилләүләрнең» буеннан-буена сузылган нечкә ирония әлеге идеянең практик кыйммәте булуына Тукайның үзенең үк шикләнеп каравын белдерә:

> Ышандык без ходайга, без вә бардыр, дип, вә ялгыз, дип;
> Сөйли тел: «Кайнигәч, кайне, кәләш, дип, һәм дә балдыз», дип.

Образлы фикерләүнең шул рәвештә үсешен кайбер лирик шигырьләрдә дә күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, «Мәхәббәт» шигырендә төп теманы чагылдырган фикер шулай ук башта бирелгән һәм афоризм төсендә кабул ителә:

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас, төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъри шагыйрь, булмаса илһамчысы.

Үзләренең рухлары һәм формалары белән бу юллар фольклорга шул кадәр тартым, алар хәтта җыр булып яңгырыйлар. Шигырьнең калган барлык строфалары әлеге куплетны шәрехләү, аның киңәйтелгән кисәге кебек кабул ителә, шагыйрьгә мәхәббәт илһам бирә дигән традицион темага вариацияләр кебек яңгырый. Фикер нюанслары шигырьне үтәдән-үтә кисеп узган нечкә юморда чагыла. Икенче куплетның кирәгеннән артык пафослы яңгырашында да:

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтегез, рухланмаган?
Байроның, Лермонтовыңмы, Пушкиныңмы — кайсыгыз?

прозаик чагыштыруларга да:

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк...

метафораларга да:

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъри . . . . . . . . . . . . . . .

һәм шигырьдәге юри күпертелгән мактануларга да:

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы,—

һәммәсенә җиңелчә юмор салынган.
Шагыйрьнең:

Кайда Фәрһат белән Мәҗнүн! Мин аларның таңчысы! —

дигән соңгы юллары баштагы куплеттагы беренче юлларга янәшә кую рәвешендә алынган. Алдагы юлларга салынган юморда (бу шигырьдә фикерләүнең нюанслы характеры нәкъ менә юморда чагыла) әлеге янәшәлекнең мәгънәсе ачыла. Экзотик, гадәттән тыш көчле, күз камаштыргыч якты мәхәббәт Фәрһат, Мәҗнүн кебек аерым шәхесләргә генә хас дигән карашка яңа, гуманистик ноктадан торып үзгә мөнәсәбәт белдерә. Мәхәббәт хисе, кеше тормышының әлеге «яңгыр тамчысы», баксаң, бөтен кешегә хас нәрсә икән һәм ул теләсә нинди гади кешене дә легендалар каһарманы дәрәҗәсенә күтәрергә сәләтле икән.

...Югарыда тикшерелгән мисаллар Тукайдагы образлы фикерләүнең аеруча характерлы очракларын гына үз эчләренә алалар. Күреп узганча, нюанслыкның төп фикердәге тотрыклылык белән чиратлашуы аларның һәммәсе өчен уртак закончалык булып тора. Инде бер тапкыр әйтелгәнчә, милли үзенчәлек Г. Тукай әдәби фикерләвенең реалистик тибында гәүдәләнә.

● ● ● ●

# ИРТӘГӘГЕ КӨНГӘ АТЛАГАНДА...

Татар халкына хас күркәм сыйфатларның берсе — тыйнак гадилек. Бу сыйфат Энҗе Мөэминованың «Бүләгем»[1] исемле җыентыгына кергән шигырьләренә дә үз мөһерен баскан. Алар да үзләренең гади һәм аңлаешлы булулары белән аерылып торалар.

Тагын шунысы да игътибарга лаек: Э. Мөэминова тематик тарлыкны белми. Киресенчә, аны һәрнәрсә илһамландыра, һәрнәрсәдән ул үзенә шигърият таба. Менә шагыйрәнең үз сүзләре:

Болыны да, кырлары да, урманы да,
Кояшы да, яңгыры да,
бураны да —
Бар да мине гашыйк итә,
әсир итә,
Бар да минем күңел кылын
чиртеп үтә —
шатланам мин!

Ләкин Э. Мөэминова ни турында гына язмасын, аның игътибар үзәгендә торган нәрсә бер — совет кешесенең олылыгын, матурлыгын, гүзәллеген раслау.

Сыгылмалы билкәйләрең
өзелеп тора.
Толымнарың иңнәреңә
сибелеп тора...
Керфекләрең кояш нурын
сирпеп тора,
Нәфис тә син, тыйнак та син,
гүзәлсең дә!

Шагыйрь күңелен кузгатырдай
көч бар синдә.

Бу юллар асылда «Туган илем табигате горурлыгы» саналган каенга төбәлгәннәр. Ләкин автор теманы шулай борып җибәргән ки, шигырьдән укучыга «сафлык бәркеп торган» кыз образы күл суза. Ул матурлыгы белән масаймый, һаваланмый, үзен башкаларга каршы куеп, борын чөермә. Аңарда — ачык чырай, якты йөз, югары зәвык. Һәм ул укучыны да дусларча, иптәшләрчә шундый ук гүзәллеккә чакыра.

Матурлыкны болай раслау Э. Мөэминованың шигърият дөньясын һәркем өчен ачык итә. Керергә телисең икән, рәхим ит.

Баскан җирдән китеп булмый,
Китеп булмый —
Баскан урыным магнитланган!
Туган җиргә,
торган җиргә,
үскән җиргә,
Мәхәббәтем мине шулай
бәйләп куйган! —

ди Э. Мөэминова үзенең туган илне сөюгә багышланган бер шигырендә. Беренче карашта бу хис тарлыкны, җирле йомыклыкны алга сөрү булып күренергә мөмкин. Ләкин, юк. Шигырьнең пафосы башка: анда милли эгоизм түгел, дуслык-туганлык хисе — хуҗа, анда пролетар интернационализм рухы — хаким. Мондый идея-эстетик яңгырашка автор ничек ирешкән соң? Принцип шул: туган җирне сөю хисе күрше матурлыгын тирән хөрмәт итү нигезендә тәгъбир ителә. Дөрес, бу алым татар совет поэзиясе өчен яңалык түгел. Алыгыз зур талант иясе Нури Арслановның «Сагындым» исемле шигырен. Биредә дә шул ук принцип кулланылган. Ләкин уртаклык шуннан узмый. Чөнки Э. Мөэминова остазлар салган юлдан баргында да үзенчә эш итә. Моны әлеге ике шигырьнең төзелешеннән — композициясеннән үк күрергә мөмкин. Нури Арсланов шигырендә һәр куплет икегә бүленә. Аның беренче өлеше күрше матурлыгын сурәтли:

Диңгез, диңгез!
Кояш нурларында
Миллион төсләр белән кабындың.
Син ирекләй иркен...

Бер-берләренә дәрт һәм темперамент өстәп чиратлашкан бу юллар «иркен» сүзен-

[1] Энҗе Мөэминова. Бүләгем. Казан, 1970. Редакторы Мәхмүт Хөсәен.

дә авазларның яңгырашын иң югары ноктага күтәрәләр. Кыска пауза барлыкка килә. Аннары куплетның соңгы юлеше яңгырый:

Мин, шулай да,
Иделемне өзелеп сагындым.

(«Казан утлары». 1968. № 4. 45 бит.)

Күренә ки, куплет идея-эстетик яктан очланган, шагыйрь әйтергә теләгән төп фикер укучыга хәзер үк билгеле. Алда бу фикер яңа вариантларда кабатлана гына. Э. Мөэминова шигыренең композициясе икенче төрле.

Кайда көчле тарту көче?
Кай яктарак?!
Җанга якын,
җанга газиз
Кайсы тараф?

Бу сорауга җавапны укучы бары тик шигырь ахырында гына таба.

Гомумән Э. Мөэминова укучы күңеленә үз сукмагын салырга тырыша. Хәер, башкача булырга да мөмкин түгел. Чөнки бүгенге сәнгать таләбе шундый — һәр талант үзенчә булсын! Әйтергә кирәк, авторның бу юнәлештәге эзләнүләре бушка китми. Э. Мөэминованы бүгенге көндә башкалар белән буташтырырга мөмкин түгел. Чагыштыру өчен өч яшь автор: Мөхәммәт Садыйков, Илдус Әхмәтҗанов, Энҗе Мөэминова. Алар бер үк темага — бөек юлбашчыбыз Ленинга багышлап шигырь язганнар. Шигъри фикерләү объекты уртак булуга карамастан, шигырьләр бер-берләрен кабатламыйлар. Чөнки һәр автор темага үзенчә якын килгән, һәркайсының үз буявы, үз тавышы бар. Һәркайсы теманы үзенчә фикерли, үзенчә тәгъбир итә. Мөхәммәт Садыйковның «Кинән бер, күңелем» исемле шигырьләрендә Ленин образын сурәтләү бурыч итеп куелмый. Автор бары тик юлбашчы тормышына бәйле детальләрне ала һәм шулар мөнәсәбәтендә Ленинга булган үзенең эчкерсез мәхәббәтен җырлый:

Ильич торган музей-йортка килэм.
Юлым — чирәм түгел, келәмдер.
Даһи салган сукмакларда йөреп
Кинән бер, күңелем, кинән бер.

Шигырь — хисле, ягымлы, самими. Ул — темага лирик планда якын килү мисалы булып тора.

Минә икенче шигырь: исеме — «Ленин», авторы — Илдус Әхмәтҗанов. Ленин — тормышны үзгәртеп коручы, даһи фикер иясе. Автор юлбашчы образының менә шушы ягын шигырьгә салган:

Коры җирләр ил бакчасын
Коммнар белән кайчак күмә.
Шул чагында илбакчага
Яңгыр булып бирәү килә —
Ленин!

Җир өстендә шартлау, үлем —
Кемнәр җиңә, кем җиңелә...
Шул чагында яу кырына
хаклык булып бирәү килә —
Ленин!

(«Соц. Татарстан», 16 август, 1970 ел.)

Игътибар итик: шигырь тукымасында образны конкрет төсмерләрлек анык буяулар, реаль детальләр юк. Биредә алар урынын шартлы рәвештә гәүдәләндерелгән гомумлек, метафора алган. Сурәтләү мәйданы да соң дәрәҗәдә гомумиләштерелгән: «Илбакча» — ул гомумән илбакча, «Җир»— гомумән җир. Аларның берсе дә урын, вакыт ягыннан чикләнмәгән, конкретлаштырылмаган. Ни өчен? Авторга образны күтәрергә, сурәтләү мәйданын киңәйтергә һәм, ниһаять, кыска, ләкин сыйдырышлы итеп әйтергә кирәк. Шигырьдә Ленин образының бер ягы чагылыш таба — аның бөеклеге, даһилеге. Шушы ук сыйфат Э. Мөэминованың «Россия тудырды Ильичны» исемле шигырендә дә сурәтләнә. Ләкин биредә максатка юл башка. Барыннан да элек авторның буяулары — тормышчан, детальләре — конкрет.

Бер тубал чәчүлек,
Әремле, кантар җир...
Сукага иелгән хәлсез ир.
Күз яше,
тир белән бураэна чылатып,
Ялварып, аллага табына.

Китерелгән юллар укучыны турыдан-туры Бөек Октябрь Социалистик революциясенә кадәр булган чорга алып китәләр. Әйе, бу— шул заман тормышы сурәте. Аны буташтырырга мөмкин түгел, ул — анык, тарихи конкрет. Икенчедән, шигырь үзенең төзелеше ягыннан да шактый үзенчәлекле. Кинематография термины белән әйткәндә, аның тукымасы кыска-кыска «кадрлар»дан үрелгән. «Бер тубал чәчүлек» — менә шигырьнең кереш кадры. Моннан соң: «Әремле, кантар җир». Аннары: «Сукага иелгән хәлсез ир»... Күрәсез, һәр кадр үзенчә бетен, һәркайсының үз буявы, үз сурәте бар. Аларның чиратлашуыннан образлы фикер алга атлый, шигырьдә хәрәкәт, үсеш туа, күренеш киңәя, тулылана. Ниһаять, менә соңгы кадр: «күз яше, тир белән бураэна чылатып, ялварып, аллага табына».

Хәзер кирәкле барлык буяулар салынган. Күренеш әзер. Автор шунда ук укучыга мөрәҗәгать итә:

Җиңелме шул ирдә ышаныч уяту,
Мул тормыш,
трактор,
электр хакында?

Сурәтләү тукымасында бу сорауның вазифасы зур. Беренчедән, ул кабул итүне активлаштыра, укучы тыңлаучы гына булып калмый, автор белән бергә хис итәргә, фикер йөртергә, уйланырга алына. Икенчедән, һәр яңа күренештән соң кабатланып килгән әлеге сорау укучыны шигырьнең финалын кабул итәргә әзерли. Ниһаять, менә финал:

Башкарыр өчен бу авыр һәм зур эшне,
Россия тудырды
даһины —
Ильичны!

Бу юллар шигырьнең иң югары ноктасын, композиция үзәген тәшкил итәләр. Алар Ленинның даһилыгын, аның тормышны революцион нигездә үзгәртеп коруга багышланган титаник хезмәтен берьюлы яктыртып җибәрәләр. Укучы алдына Ленин образы килеп баса.

Үзенә генә хас шигъри фикерләү алымын раслау җәһәтеннән Э. Мөэминованың тагын бер шигырен күрсәтеп үтәсе килә. Ул — «Синең бәхет җиңел бәхет түгел». Шигырь укытучы эшчәнлеген олылый, аның катлаулылыгын ача, иҗади булуын күрсәтә. Шунсы да игътибарга лаек: шигырьнең сурәтләү тукымасы бүген — хәзер афоризм булып китәрлек тәгъбирләрдән үрелгән.

Әзер юлдан үз көенә
бару җиңел,
Тигез җирдә юл салу да
читен түгел.
Кыяларга сукмак салу —
читенрәк!
Тик күңелгә юл салудан
җиңелрәк!
Синең бурыч —
Күңелләргә сукмак салу!
Сукмак салыр үзәннәрне
табып алу!

Бу юллар ифрат сыйдырышлы һәм тирән. Әйтелгәннәрдән күренә ки, Э. Мөэминованың укучы күңеленә үз сукмагы бар.

Ләкин иҗат эше — ул өзлексез эзләнү, даими тынгысызлык. Аның табигате таләпчән: бүгенге нәтиҗә иртәгә яңа ачышлар белән баетылсын, йөрәк типсен, акыл эшләсен, күңел талпынсын! Бары тик шушындый иҗади атмосферада яшәгәндә генә бүгенге үзенчәлекне иртәгә ныгытырга, үстерергә мөмкин.

Хәлбуки, иртәгәге көнгә атлаганда Э. Мөэминова өчен бүген хәл итәсе мәсьәләләр дә юк түгел. Барыннан да элек авторның кайбер шигырьләрендә чәчмәгә тартымлык нык сизелә. Урыны-урыны белән исә бу сыйфат шигырьнең ритмик хуҗалыгын бөтенләй туздырып ташлый, аны гади сөйләм дәрәҗәсенә төшерә. Әйтик менә юллар:

Син бит минем өчен
җир йөзендә
Иң кадерле кеше...
Бүген мин китәм...
Сугышка...
Көт син мине, яме!.. —
Дигән сүзләреңне ишетәм...

Китерелгән өзеккә шигырь сыйфаты бирүче берданбер сыйфат — җөмләләрне баскычлап язу. Аны алып ташласак, шигырьлектән һич ни калмый.

Чәчмәгә тартымлыкның тагын бер билгесе бар. Ул — шигъри фикерләүдәге корылык. Бу очракта шигырьнең үлчәве дә саклана, ритмы да төзек, рифмалары да аһәңдәш була. Ә шигырь тәэсир итми. Менә «Лампа яктысы» исемле шигырь. Аның эчтәлеге шулай: кыз беренче мәртәбә гашыйк була, ә егете шуннан соң күп тә үтми үлә. Әйтәсе дә юк, тетрәткеч драма. Тик шунсы кызганыч: шигырьдә аны югары температурада тәгъбир итәрлек хис юк, кайнарлык юк. Биредә шигырьне драматургик яктан дөрес оештыру осталыгы җитенкерәми. Чыннан да:

Бүген синең табут янында
Башым иеп, кайгы кичерәм...

Ситуация ачык: егет табутта, кыз табут янында. Вакыйганың вакыты — бүген. Укуны дәвам итәбез:

Һич онытмыйм, авыр ел иде —
Илдә сугыш барган чор иде...

Биредән исә вакыйга бүген түгел, бәлки Ватан сугышы елларында булган кебек аңлашыла. Ул чагында ничек итеп егет бүгенгә кадәр табутта ята алсын икән? Аннары тагын бер сорау туа: егет сугыштамы, әллә өйдә авырып үләме?

Кышның... салкын бер көне
Фаҗигале хәбәр китерде:
Синең гомер,
гомер өзелде...

Бу юллар әлеге сорауга җавапны бирмиләр, контекст та ситуацияне ачыкламый. Сурәтләү тукымасындагы мондый буталчыклык — ул шигырьне драматургик яктан оештыру җитенкерәмәү бәласе.

Сүз уңаенда автор игътибарын тагын бер мәсьәләгә юнәлтәсе килә. Мәгълүм ки, шигырьләр кешеләр кебек: аларның кайберләре бик тиз үлеп китә, кайберләре исә яши дә яши. Андыйларга вакыт җиле кагылмый, еллар тузаны кунмый. Сер нәрсәдә соң? Моңа җавап итеп конкрет мисал китерик. Менә Нури Арсланов шигыре — «Нигә?»

Мин елмаеп килəм ерактан ук —
Шəүлəң генə синең күренсен...
Эчемдəге тышымда шул минем,
Син дə нигə шулай түгелсең?

Игътибар итик: шигырьнең беренче куплетында ук бəхəс башлана, драматик конфликт калкып чыга. Әһəмиятле бəхəсме бу, тормышчан конфликтмы? Әйе, тормышчан конфликт, чөнки ул бик күп кешелəрнең үзара мөнəсəбəтлəрендə чагылыш таба; ниһаять, бу — тирəн мəгънəле конфликт, чөнки аның нигезендə кеше матурлыгын раслау, аның сафлыгын, турылыгын, эчкерсезлеген, принципиальлеген, кыскасы, кешедə югары əхлак нормаларын раслау ята. Шигырьдə нəкъ менə шушы җəһəттəн чыгып бəхəс бара:

Уйлыйсындыр: «Бу — кол инде миңа,
Түгелə икəн яше түгелсен».
Сөйгəнне кол итү, колны сөю —
Сөюмени! Хаклы түгелсең...

(«Казан утлары». 1968. № 4. 46 бит.)

һəм бу бəхəс көн тəртибеннəн төшми торып, əлеге шигырь үзенең əһəмиятен югалтмаячак. Э. Мөэминованың «Бүлəк» исемле җыентыгында да тормыш конфликтларын чагылдырган шигырьлəр юк түгел. «Әйтегезче шуны, аналар!» — шундыйларның берсе. Лəкин аларның саны əлегə аз.

Тормышны үсештə, хəрəкəттə, андагы конфликтларны җыңу процессында сурəтлəү урнына, автор еш кына күз ачып йомганчы туган хислəрне беркетеп калырга омтыла. Бу хəл исə шигырьлəрнең гомерен кыскартуга илтə. Ниһаять, Энҗе Мөэминова алдында торган бурычларның берсе — шигырьлəрнең эстетик камиллеген күтəрү. Бу җəһəттəн карaганда, шигырьлəрнең бүгенге көн дəрəҗəсе дə түбəн түгел кебек. Аларның ритм-рифма киеме эчтəлеккə ярашып тора, тел чаралары укучының эстетик зəвыкларын күтəрүгə хисапланган. Автор авазларның аһəңлегенə дə тиешенчə игътибар итə. Укучыны борчыган нəрсə хəзерге көндə бары шул: «чи» калган, эшкəртелмəгəн урыннар бар.

Мəктəп залы.
Түрдə стенд тора.
Ә стендтан карый рəсемнəр.

Соңгы юл башындагы «ə» ритм агышы белəн «стендка» тоташа һəм бозылган сүз — «эстендтан» барлыкка килə. Шул ук куплетның дəвамы да эшлəнеп җитмəгəн.

Алар арасында синең дə
Миңа бүлəк иткəн рəсемең бар.

Өченче юлда бер иҗек җитмəү, дүртенчесендə бер иҗек артык булу сəбəпле, өченче юлны тотлыгып, дүртенчесен йөгереп укырга туры килə. Тагын бер мисал:

Өй арасында да адаша.

Биредə «да» авазларының чиктəн тыш бергə өелүе җөмлə аһəңлегенең əсəрен генə дə калдырмый.

Китерелгəн мисаллар берəүлəргə бик вак, авторны юкка борчу булып күренергə мөмкин. Җавап шул: шигырь яме — фикер белəн, фикер яме — форма белəн. Э. Мөэминованы алда яңа үрлəр көтə. Шундыйларның берсе — Ленин образын тудыру. Бу юнəлештə автор тарафыннан билгеле адымнар ясалган инде. «Россия тудырды Ильичны» шигыре нəкъ менə шушы турыда сөйли. Лəкин Ленин бөек юлбашчы, даһи фикер иясе, тормышны революцион нигездə үзгəртүче титан гына түгел, ул иң кешелекле кеше дə. Бурыч менə шундый образны тудырудан гыйбарəт. Дөрес, яңа иҗат үрлəренə менү өчен талант кирəк. Лəкин ул гына да җитми, өстəвенə тагын хезмəт кирəк. Бу уңайдан Флобер сүзлəрен хəтергə төшереп үтик: «Мопассан: Әйтегезче, миңа язучылыкны дəвам иттерергə кирəкме, моның өчен миндə талант бармы?

Флобер: Талант — ул хезмəт һəм чыдамлык. Эшлəгез!»

Флобер сүзлəренең мəгънəсе шунда: талант ачыклангач төп игътибар хезмəткə юнəлдерелергə тиеш. Чөнки талантка ия булып та, тəртипле, культуралы хезмəт җитешмəү аркасында вакытсыз сүнеп калган «йолдызлар» сирəк күренеш түгел.

Шушы хакыйкатьне истə тоткан хəлдə Э. Мөэминова үзенең алдагы иҗат эшчəнлегендə талант һəм хезмəт берлеген тагын да нəтиҗəлерəк кулланыр дип ышанасы килə.

**ШƏРƏФ ƏХМƏДУЛЛИН,**

**Казан дəүлəт педагогия институтының чит теллəр кафедрасы мөдире, доцент.**

# *БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР*

**С. ХӘКИМ. Торыгыз, Мусалар! Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Узган сугыш кешеләр йөрәгендә мәңге төзәлмәслек авыр яралар калдырды. Кешелекне фашизм коллыгыннан коткарып калу өчен героик көрәш алып барган совет халкының ул сугышта күрсәткән батырлыклары, түземлеге, мораль бөеклеге, башка әдәбиятлардагы кебек үк, безнең татар әдәбиятында да шактый киң яктыртылды. Күп кенә әдипләребез бүгенге көндә дә Ватан сугышы темасына әледән-әле мөрәҗәгать итәләр. Бу өлкәдә шагыйрьләребездән Сибгат Хәким аеруча актив эшли. Аның узган елда басылып чыккан «Торыгыз, Мусалар!» исемле яңа җыентыгы моны бик ачык раслый. Җыентык ике бүлектән — «Хисап бирәм» һәм «Васыятьләр» дигән бүлекләрдән тора. Беренче бүлеккә шагыйрьнең Муса Җәлилгә, Бухенвальд корбаннарына, изге яу кырында мәңгелеккә ятып калган якташларына, азат тормыш юлына аяк баскан яңа Германиягә багышланган шигырьләре урнаштырылган. «Якын дуслар...» дип башланып киткән шигырь белән ачылган бу бүлектә, моннан тыш, авторның сугыш еллары һәм шул елларда үзләренең якыннарын җуйган кешеләрнең бүгенге язмышлары турында уйланып-борчылып язган шигырьләренә дә шактый киң урын бирелгән. Әйе, Сибгат Хәким шигырьләрендә, барыннан да элек, аның гади кешеләр язмышы өчен борчылуын тоясың.

Ул тол. Ялгыз... Илдә күпләр
Андый язмыш белән...
Тора да иртән сөйләшә
Радиоалгыч белән:
Җаным, әйтче, бармы кабереи —
Урын күргән кешең?
Җаным, тагын ничә кеше
Үлде дип әйтерсең?

Дәһшәтле елларда ут эченә киткән сөеклесен җуйган тол апаның кичереш-хисләрен, тирән моңын чагылдырган мондый юлларны тыныч күңел белән уку һич мөмкин түгел. Замандашларының уй-тойгыларын уртаклашып яшәүче шагыйрь «Тышта буран», «Монтерларга ачуланып кайтам», «Нәзер аты» һ. б. шигырьләрендә дә ясалма, ялган хисләрдән ерак тора. Муса Җәлил турындагы шигырьләр, берсен-берсе тулыландыра барып, берничә бүлектән торган поэманы хәтерләтә. «Якын дуслар, минә ни турында», «Соры ташка утырып шигырь язган», «Идел буйларында таңнар моңсу», «Өч үлем», «Җәлил шәһәре», «Һәйкәл турында уйланулар», Өлкән буын сафы сирәгәя», «Бер генә ян икән» шигырьләренә шагыйрьнең Германия Демократик Республикасына барып кайткач язган шигырьләр циклы өстәлә. «Торыгыз, Мусалар!» шигыре белән тәмамланган бу циклдагы «Юллар, юллар» шигыренең ахыргы строфасында авторның йөрәк тибеше аеруча көчле ишетелә:

Мин Германия буйлап атлыйм, әйлә,
Төрмәләрнең ишеген как барып.
Бер елыйсым килә алар узган
Шул юлларга минем капланып.

Сибгат Хәким — Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр алгы сызыкта булган шагыйрь. Үзе хезмәт иткән дивизия солдатлары белән бергә ул атаклы Дуга сугышларында катнаша. Сугыштан соң бу хакта аның «Курск дугасы» исемле әсәре дә басылып чыккан иде. Моннан ике-өч ел элек ул үзе сугышып йөргән җирләргә яңадан барып кайтты һәм, аннан алган тәэсирләрен чагылдырып, «Дуга» исемле яңа поэма иҗат итте. Бу поэма китапның «Васыятьләр» бүлегенең төп өлешен тәшкил итә. Шагыйрь аның кереш өлешендә поэманың ничек язылуы турында укучы белән үзенең фикерен уртаклаша, әсәрдә тасвирланган вакыйгаларга тукталып үтә. Поэма шагыйрьнең истәлек-биографиясе рәвешендә язылган һәм ул хисләргә, кичерешләргә бай булуы белән аерылып тора.

Шушы ук икенче бүлектә басылган «Васыятьләр» поэмасында сүз туган җир, туган нигез турында бара. Шагыйрь бу поэмасына да кыска гына кереш сүз язган.

«Торыгыз, Мусалар!» җыентыгына кергән әсәрләр Сибгат Хәким иҗатының һаман үсә, күтәрелә баруы турында сөйли.

**Ш. МӘДӘРРИС. Дуслар җыры. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Татарстан китап нәшрияты әдипләребезнең җыентыкларын «Мәктәп китапханәсе» сериясендә чыгара башлады. Ул җыентыкларга теге яки бу язучының мәктәпләр программасы буенча балаларга дәрестән тыш уку өчен тәкъдим ителә торган әсәрләре сайлап алына. Бу сериядә басылып чыккан китаплар арасында поэзиябезне үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән мәрхүм шагыйрь Шәрәф Мәдәрриснең «Дуслар җыры» исемле җыентыгы да бар. Олы һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына атап чыгарылган бу җыентыкка шагыйрьнең берничә шигыре һәм «Яшәү көче», «Йолдыз атыла», «Тупчы Ваһап» поэмалары сайлап алынган. Аларда автор халкыбызның үткәне һәм бүгенгесе турында тирәнтен уйлана, бәхетле тормыш, азатлык һәм ирек өчен көрәштә үзләренең гомерләрен кызганмаган каһарманнар исеменә дан җырлый. «Кызыл бант» шигырендә ул безнең күз алдыбызга Кызыл гвардия сафында Кышкы сарайга бәреп кергән куркусыз картны китереп бастыра. «Әнием минем» һәм «Партизан» шигырьләрендә без башкалар бәхетле тормышта яшәсен өчен үзләренең яшьлек көчләрен, кирәк икән, гомерләрен дә кызганмаган олы җанлы кешеләр белән очрашабыз. «Кадерле бүләк», «Кояш чыга», «Таулар янында» шигырьләрен укыганда исә үзеңнең азат Ватан кочагында яшәвең, аның тулы хокуклы гражданины булуың белән горурланасың, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә:

Һәм шуңар да җанга рәхәт, йөрәктә
Кичермәгән бәхет хисен тоясың:
Сәламлисең данлы эш һәм көрәштә
Балкып туган коммунизм кояшын!

«Яшәү көче» әсәрен шагыйрь әкият-поэма дип атаган. Әмма анда тасвирланган вакыйгаларның күбесе чынбарлыкка бик якын тора. «Җирнең яшәү көче — мәңге яшь, мәңге нык, мәңге батыр кеше» — шагыйрьнең поэмада әйтергә теләгән төп фикере әнә шуннан гыйбарәт. Бу фикерне ул кырда бер-берләре белән ярышып үскән һәм башкалага күргәзмәгә бару хокукын яулап алган игеннәрнең, үсемлекләрнең үзара бәхәсләшүләре аша ачып бирә, укучы күңеленә аны әкияткә хас булган алымнар аша җиткерә.

Җыентыктагы «Йолдыз атыла» поэмасы шагыйрьнең пионерда үткәргән, комсомолга кучкән еллардан сакланган истәлекләренә нигезләнеп язылган. Ләкин автор ул чорда — ягъни утызынчы елларда үзе күргән аерым фактларны рифмага салып, аларны бер-бер артлы тезеп чыгу белән чикләнмәгән. Әсәрдә шул давыллы, көрәшле чорның кайнар сулышы бәркелә, үткән көн бүгенге көн белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Аерым бүлекләрдә без пионер сафларында үскән лирик геройны Бөек Ватан сугышы кырларында күрәбез, аның белән бергә Куба, Корея якларына юл тотабыз. Бу поэмада без гражданнар сугышы елларында Сембер, Буа, Канаш һәм Алатыр тирәләрендә хәрәкәт иткән кыю командирлар, Эрнест Тельман кебек ялкынлы революционерлар, электр урындыгында җәзалап үтерелгән Сакко һәм Ванцетти, утызынчы еллар башында эзәрлекләнгән, төрмәгә ябылган Америка пионеры Гарри Айзманнар белән кабат очрашабыз. Поэма гади һәм җиңел тел белән язылган. Аның күп кенә строфалары бер уку белән күңелдә ятланып кала:

Бүген тагын дөньяга
Көек исе аңкый,
Балачакта электрың
Җанга суккан, янки!

Азап чикмә борыгра
Рубильникны тагын,
Шартлатырга бирмәбез
Җирдә дары базын!

Әсәр моннан шактый еллар элек язылган булса да, әле дә үз көчен югалтмый, бүгенге көндә дә актуаль яңгырый.

Шәрәф Мәдәрриснең «Тупчы Ваһап» поэмасы укучылар тарафыннан заманында бик җылы кабул ителгән әсәр. Аны шагыйрьнең «Мәктәп китапханәсе» сериясендә чыккан ике китабына кертеп, төзүче бик дөрес эшләгән. Чөнки илнең бәйсезлеге, безнең иркле тормышыбыз хакына корбан булган каһарман Ваһаплар турындагы әсәрләрне өлкәннәр дә, мәктәп балалары да көтеп алалар һәм яратып укыйлар.

**Х. КАМАЛОВ. Өмет. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Шагыйрь Хисам Камаловның яңа җыентыгы «Өмет» дип атала һәм шул исемдәге поэма белән ачыла. Поэмада Бөек Ватан сугышы елларында әсирлеккә төшкән яшь сугышчы Әсгатьнең авыр кичерешләре сурәтләнә. Фашистлар тоткынлыгында батырларча көрәшеп һәлак булган бу яшь егетнең соңгы хаты, әйләнмәле юллар үтеп, аның әнисенә барып ирешә. Улының үлемен ишеткән чал чәчле ананың җуелмас кайгысы поэмадагы драматизмны тагын да

кочәйтә, тирәнәйтә. Әсәрдәге вакыйгалар Әсгатьләр йортында тәрбияләнеп үскән ирлекче кыз Зифаның яшьлек хисләре белән бергә үрелеп бара. Буйга җиткән бу үнган кызны күзләп йөрүчеләр, сорап килүчеләр аз түгел. Ләкин Зифа үзен карап үстергән, кеше иткән апаны япа-ялгыз калдырып китәргә теләми. Тормышта күпне күргән, күпне кичергән киң күңелле бу кешеләрдән аерылган чагында лирик герой исеменнән әйтелгән сүзләр, безнеңчә, табигый яңгырый:

Алар өчен бөтен авырлыкны
Үз җилкәмдә килде илтәсем.
Кирәк булса алар тормышы өчен
Теләсә нинди сират кичәсем.

Җыентыктагы «Минем әти кая» поэмасының сюжеты, автор әйткәнчә, үзе билгесез калырга теләгән кеше язмаларына корылган. Бу язмалар үз баласыннан баш тарткан начар уйлы хатынның һәм коллектив булышлыгы белән дөрес юлга баскан «пырдымсыз» малайның тулы канлы образларын күз алдына китереп бастыралар. Укучы күңелендә аларның беренчесенә карата нәфрәт, икенчесенә карата мәхәббәт хисе уяна.

Күренгәнчә, һәр ике поэмада кеше язмышы, яңа кеше тәрбияләүдә ата-ананың һәм коллективның роле кебек әһәмиятле проблемалар күтәрелә. Шуның белән бергә, һәр ике поэма өчен уртак булган бер кимчелек турында әйтеп китми булмый. Поэмаларның икесе дә артык озын сузылган, вакыты-вакыты белән аларда автор да, геройлар үзләре дә кирәгеннән артык күп сөйлиләр, шуның белән алар вакыйгаларның табигый үсешен тоткарлыйлар. Шигырьнең техник эшләнешенә тиешенчә игътибар биреп җиткермәү, аңа вак-төяк нәрсә итеп карау шикелле кимчелекләр дә Хисам Камаловта еш күзгә ташлана.

Җыентыкның икенче бүлегенә шагыйрьнең соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре тупланып бирелгән. «Шуңа, ахры, җылы туфрагың», «Туган җирем — Идел йорт», «Истәлек», «Бер оядә», «Дәмин» һ. б. шигырьләрендә ул тормышны, туган илне, үзе туып үскән җирнең иминлеге хакына гомерләрен дә кызганмаучы дусларын ихлас күңелдән сөеп бәлдерә.

Безне шулай итеп үстерә,
Туган җирем, синең кулларың;
Өрәм дими сиңа гомерен
Туган җирем, батыр улларың.

Һәлак була Ватан өчен
Саклап ядан — туган учагын,
Йөрәкләре җиргә күмелә,
Шуңа, ахры, җылы туфрагың.

Хисам Камалов иҗатына ихтирамлы укучы киләчәктә аннан көрәшчеләрнең йөрәкләре күмелгән җылы туфраклы туган җир турында тагын да югарырак идеяле, тирәнрәк фикерле әсәрләр көтә.

**Г. ЛАТЫЙП. Бәләкәй музыкант. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Шагыйрь Галимҗан Латыйп, зурлар өчен күңелне сөендерерлек әсәрләр язу белән бергә, балалар өчен дә күп санлы шигырьләр, поэмалар иҗат итә. Узган ел ахырында Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Бәләкәй музыкант» исемле җыентыгына аның урта һәм олкән яшьтәге мәктәп балаларына атап язылган әнә шул шигырьләре һәм поэмалары тупланган. Җыентык дүрт бүлектән — «Миләшем», «Елмайсын гел кояш», «Тамчылар» һәм «Поэмалар» дигән бүлекләрдән тора. Беренче өч бүлеккә урнаштырылган шигырьләрнең күбесе яшь укучыда илгә, партиягә, туган җир табигатенә, хезмәткә һәм өлкәннәргә карата мәхәббәт тәрбияли, аны зур авырлыклар бәрабәренә яулап алынган бүгенге матур тормышның кадерен белергә, һәр җирдә, һәрвакыт тәгәл һәм тыйнак булырга енди. Үзләрен тәрбияләп үстергән әниләр турында сөйләүче пионерларның куанычларын автор «Җилферди лагерь байрагы» шигыре аша башка балалар белән дә уртаклаша:

Бездән бигрәк алар меңә
Шатланалар безнең өчен.
— Кадерен белеп яшәгез сез!
Дөнья, — диләр, — сезнең өчен.

Җылы, якты классларда бер-берсе белән ярыша-ярыша тырышып укучы малайлар һәм кызлар, яз көннәрендә безнең якларны сагынып кайтучы җырчы кошларны каршылау, җәйге походларда үткәргән истәлекле көннәр, яңа җырлар белән килгән олы бәйрәмнәр турында язылган шигырьләрне китапның һәр бүлегендә очратырга мөмкин. Җыентыкның соңгы бүлегендә укучы «Аучы малае», «Дозор», «Басмантау» һәм «Итекче» поэмалары белән танышачак. Бу поэмаларда балаларның сизгерлеге, кыюлыгы, хезмәт сөюе һәм батырлыгы сурәтләнә. Дөрес, бу поэмаларда, бигрәк тә «Аучы малае» поэмасында, җыентыктагы кайбер шигырьләрдәге шикелле үк, автор тарафыннан гына уйлап чыгарылган вакыйгаларга корылган ясалма

урыннар да юк түгел. Аннан соң китапның исеме дә җисеменә бик үк туры килеп бетми. Ләкин, шуңа да карамастан, узган ел балалар өчен басылып чыккан әйбәт китапларның берсе — Галимҗан Латыйпның «Бәләкәй музыкант»ы диясе килә.

**Ф. ЯРУЛЛИН. Гел ашыгам. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Авыру ана үзенең соңгы көннәрен көтеп ята. Шул чагында аның тәрәзәсе каршына диңгез ягыннан бер акчарлак очып килә һәм, бу җирләрдә һава тар сиңа, дип, хәлсезләнгән ананы үзе белән бергә диңгез буйларына китәргә өнди. Ләкин авыру ана диңгез илләре матур, сулары шифалы булса да, анда барырлык егәре калмаганлыгын әйткәч, акчарлак кире очып китә. Чәчәк илләренә дәшеп килгән сандугачка да ана шул ук җавабын бирә. Менә тәрәзәне ачып өй эченә көчле җил бәреп керә һәм карт анага улы турында бик авыр хәбәр китерә.

Ишеткәчтен яман хәбәрне
Торып баса ана шул ара.
Баласына килгән җил-давыл
Түшәгеннән аны кубара.

Шагыйрь Фәнис Яруллинның «Ана» балладасы өнә шулай тәмамлана. Бу баллада аның «Гел ашыгам» исемле җыентыгында басылган. Күңелне тирән дулкынландырган мондый шигырьләрне җыентыкта күпләп санарга мөмкин. «Каз кычкыра», «Үпкәләмим шулай да», «Атлар», «Кеше кирәк», «Алчы, болыт», «Сез әйтегез», «Балтик җилен ачы диләр» шигырьләре кыска һәм тыгыз язылулары, кичереш-хисләргә бай булулары белән аерылып торалар. «Тормыш дустыма» циклына кергән шигырьләр дә Фәниснең үз иҗатына карата таләпчәнлеккә көннән-көн арттыра баруы турында сөйли. Җыентыкта урнаштырылган сигезьюллыкларында шагыйрьнең фәлсәфи фикерләре теге яки бу вакыйганы, күренешне күз алдына китереп бастырырлык поэтик образлар, детальләр аша ачыла. Тормышта кемгә тыйнак булырга кирәклеге турында искәртеп, ул менә болай ди:

Кайвакыт тауларга менсәк,
Горурлана башлыйбыз.
Күрегез, янәсе, безне,
Болытларда башыбыз.
Тауда чакта кем дә күрә,
Кычкырмасак та җирсәп,
Биек булсаң, үзеңне син
Түбәндә чакта күрсәт.

Фәнис Яруллинның күпчелек шигырьләре гади кешеләргә ышаныч һәм ихтирам хисләре белән сугарылган. Менә шуңа күрә дә ул шигырьләрне укыганда күңеленнең чистара, яктыра баруын тойгандай буласың. Үзенең биографиясенә кагылышлы шигырьләрендә дә Фәнис тормыш сөючән көр күңелле шагыйрь булып кала. Тормышында да, иҗатында да төшенкелеккә бирелмәү аңа укучыны елмайта, көлдертә торган матур-матур юмористик шигырьләр тудырырга ярдәм итә. Андый шигырьләрнең кайберләрен («Мәрдән һәм Мәрьям», «Өч көн алдан», «Үземә тәнкыйть», «Малаен тартып кайта», «Кай җирем ким кешедән,дип», «Яңа телевизор алдым» һәм «Бер күршем бар») җыентыкның соңгы битләреннән укыйбыз.

Тынгысыз шагыйрь үзенең дусларына суынмас хисләренең шактый зур букетын бүләк иткән. Киләчәктә ул букетның тагын да зуррак булуын телибез.

**Н. МАДЬЯРОВ. Җәйге яңгыр. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Нәҗип Мадьяров үзенең күпчелек шигырьләрендә колхоз авылы кешеләренең эшләрен, аларның тынгысыз тормышындагы үзгәрешләрне чагылдырырга омтыла. Аның узган ел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Җәйге яңгыр» исемле яңа җыентыгында да төп урынны авыл темасына багышланып язылган шигырьләр алып тора. «Язгы кырда» шигырендә «алакола басу уртасында Алыптай» басып торган игенченең ашкынулы хисләре тасвирлана. «Игенче», «Июнь төне», «Җәйге яңгыр», «Инеш ярында», «Күл», «Үзәннәргә тагын кыш әйләнде» кебек шигырьләрдә лирик герой җирне бизәп яшәүче кешеләрнең хезмәтенә, үзе туып үскән якларның гүзәл табигатенә карап соклана. Туган як кышларының матурлыгы турында сөйләгәннән соң шагыйрь:

Бураннарның үрдә — җәяүлесе,
Юлчыларның анда — атлысы.
Бу кырларның хәтта йолдызларга
Төшә булыр карның яктысы, —

ди. «Үзәннәргә тагын кыш әйләнде» шигырендә. «Таң атканда тәүге алтын нурлар», «Балкый офык таң нурлары белән», «Тепләре бик тирән диңгезләр бар», «Ничек итеп күңелең әрнемәсен», «Яшьлек безне уйната да иде», «Җил», «Сөйрәлеп тә, кайчак йөгереп тә» дип башланган сигезьюллыклар фәлсәфи рухта язылганнар һәм аларда авторның дөньяга карашы, тормыш-

ка, кешеләргә карата булган мөнәсәбәте шактый тулы гәүдәләнә. Менә ул сигезьюллыкларның берсе:

Таң атканда тәүге алтын нурлар
Өсләренә төшә тауларның.
Кояш баеганда соңгы балкыш
Кыясында яна аларның.
Ярамыйдыр әмма күпсенергә
Бу бәхетне һич тә таулардан.
Иң беренче булып шуларга ук
Кунаклый бит салкын карлар да.

Тормышыбызда очрый торган теге яки бу кимчелекләрне фаш итү өчен, Нәҗип Мадьяров еш кына очракларда сатира жанрына мөрәҗәгать итә. Аның әлеге җыентыгындагы «Нихәлләр итәр идек», «Диалог», «Җамалый», «Җилләр уйный кесәсендә» шигырьләре әдипнең бу жанрда уңышлы гына эшләвен күрсәтәләр.

Җыентыкның ахырында «Разведчик» исемле озын шигырь урнаштырылган. Автор, җәя эчләренә алып, шигырьнең исеме астына «Абдул абзый хикәясе» дип куйган. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, Абдул абзыйның 300 юлдан арткан бу шигъри хикәясе укучыга берни дә яңалык алып килми. Шагыйрь бу шигырендә безнең поэзиябездә инде күп тапкырлар кабатланган, һәркемгә күптән таныш булган нәрсәләрне яңа бер тапкыр кабатлап чыгудан уза алмаган.

Нәҗип үзенең бер шигырен:

Кешеләр бар. Алар йөрәгенә
Кыен әмма юллар табуы, —

диган сүзләр белән тәмамлый. Шушы кырыс хакыйкатьне дөрес аңлаган шагыйрьдән кешеләр йөрәгенә үтеп керерлек тирән фикерле яңа әсәрләр таләп итәргә укучының тулы хокукы бар.

**Ш. МАННАПОВ. Хәят көндәлеге. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

«Дуслык», «Адымнар» җыентыкларында, «Беренче карлыгачлар» сериясендә һәм вакытлы матбугатта шигырьләре басылып, инде поэзия яратучылар тарафыннан үз итеп кабул ителгән Шамил Маннапов күптән түгел укучыларга яңа шигырьләр җыентыгын — «Хәят көндәлеге»н тәкъдим итте. Аны укып чыккач, яшь авторның иҗат колачы шактый киңәюен тоясың. Китапка кереш сүз язган шагыйрь Хисам Камалов сүзләре белән әйткәндә, Шамил Маннапов шигырьләре кешеләрдәге кешелеккә ышанудан, алар күңелендәге байлыкны поэтик күрсәтүгә омтылудан туа. Бу аның әсәрләрен шактый эмоциональ эшләүгә ярдәм итә. Шамил шигырь хистән һәм фикердән башка була алмый икәнлеген яхшы төшенеп эш итә... Шигырьдә иң мөһиме — чын күңелләлек һәм ялганламау, хисләрне уйлап чыгармау.

Дөрестән дә, «Хәят көндәлеге»н укыганда һәр шигырьдә, тормыш пульсы белән бергә, шагыйрьнең йөрәге тибүен дә сизәсең. Авторның симпатиясе кешеләр бәхете өчен үзен аямаучылар, тормыш каршылыклары аша үткәндә идеалларын, кешеләргә мәхәббәтләрен югалтмаучы көчле рухлылар ягында. Ул үз поэзиясе өчен тормыш материалын әнә шул җирлектән эзли. Шул хис аны Тобол зиратына алып килә («Тобол зиратында»), ил азатлыгын яклап һәлак булган әтисе («Әйтерсең төсле»), фронтовик-шагыйрьләр («Бакчада»), кара җирне икмәк итүче кешеләр («Гашыйк») турында уйландыра. Шуларны укыганнан соң лирик геройның:

Җилләр искәндә дә тып-тын торган,
Ботаклары каерылган агач кебек
Япа-ялгыз булуымнан куркам —
Барыннан да битәр, кешеләрнең
Минем янымда үзләрен
Ялгыз итеп тоюыннан куркам, —

дип әйтүе яхшы аңлашыла.

Ш. Маннапов шигырьләрендә детальләрнең мәгънә йөге сизелерлек зур. Автор кайбер образларга да мәгънә салырга омтыла. Бу яктан «Әниемә багышлыйм» һәм «Солдат дәфтәреннән» диган бүлекчәләр игътибарга лаек. Аларда ана һәм урман образларына кешеләр күңелендәге идеал һәм ил төшенчәсе дә салынган. Автор тикмәгә генә болай дими бит:

Ана —
Картайганчы кешегә кирәк,
Газиз ул җан.
Ана —
Балаларын бала диган коры җилдән
Саклап торган яшел урын.
Юлдан язган, адашкан бер кеше күрсәм,
Моның, димен, мөгаен,
Әнисе үлгән...

«Хәрәмләштең, тормыш», «Нигә шунда күпер төземәскә», «Бер җылы сүз кешегә җитә диләр», «Бабаларыбыз безнең мәҗүсиләр» һ. б. шигырьләрендә дә Шамилнең үз тавышын ишетәсең, аның каләме тудырган лирик геройның олы хисләрен уртаклашасың.

Шамил Маннапов еш кына очракларда Армия темасына мөрәҗәгать итә. Аның әлеге җыентыгында да бу темага багышлап язылган берничә шигыре бар. Шулар арасыннан «Безнең якташ» исемлесе күңелгә әверүча җылы тәэсир итә. Шигырь мондый юллар белән тәмамлана:

Син бәхетле кеше авылда,
Лаек булса нәселең хөрмәткә.
Син бәхетле бөтен дөньяда,
Хөрмәт булса синең милләткә.

Җыентыкка кергән кайбер шигырьләр яшь әдипнең сатира-юмор өлкәсендә дә уңышлы гына эшләве турында сөйлиләр. «Кайралды», «Хәтер начар» шигырьләрен укыганда, мәсәлән, ирексездән елмаеп куясың һәм Шамил иҗатында мондый шигырьләрнең күбрәк булуын телисең.

Җыентыкта, әлбәттә, әле тиешенчә эшләнеп бетмәгән шигырьләр дә юк түгел. «Тормыш агымына каршы», «Хаким булмакчы» кебек шигырьләрне кертмәгәндә дә җыентык күп нәрсә югалтмаган булыр иде. «Тавышлар» поэмасының да, нигездә әйбәт кенә язылуына карамастан, озынгарак сузылуы, урыны-урыны белән буталчык фикерләр очравы эчне пошыра. Соңгы айларда вакытлы матбугат битләрендә Шамилнең бу китабындагы шигырьләреннән дә өлгеррәк һәм тирәнрәк фикерле яңа әсәрләре басылгалады. Шул рәвешле, шигырьдән шигырьгә үсә барып, алдагы көндә ул тагын да яратыбрак укырлык яңа җыентыклар бастырып чыгару бәхетенә ирешсен иде.

### Теория литературы в связи с проблемами эстетики. Рус теленде. Мәскәү. 1970 ел

Казан дәүләт университетының рус һәм чит ил әдәбияты кафедралары укытучылары, укыту-тәрбия эшләре белән бергә, фән өлкәсендә эшләүгә дә җитди игътибар бирәләр. Алар төрле фәнни җыентыкларда әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләренә караган мәкаләләр белән катнашалар, югары уку йортлары студентлары өчен кулланмалар, дәреслекләр язалар. Мәсәлән, соңгы берничә ел эчендә үзәк һәм республика нәшриятларында университет укытучыларының «Әдәби анализ методикасы», «XVIII гасыр чит ил әдәбияты» исемле хезмәтләре чыккан иде. Күптән түгел китап кибетләрендә «Эстетика мәсьәләләре белән бәйләнештә әдәбият теориясе» дигән тагын бер яңа кулланма сатыла башлады. Аны профессор Н. А. Гуляев, доцент А. Н. Богданов һәм әдәбият белгече Л. Г. Юдкевичлар язган.

Моңа кадәр дәреслекләрдә әдәбият теориясе үзенә, ә эстетикага караган мәсьәләләр исә үзенә аерым тикшерелә иде. Бу бер очракта сәнгатьнең төрле өлкәләрендә карала торган уртак темаларны кабатлауга китерсә, башка очракларда әдәбият теориясен гадиләштереп, тарайтып аңлауга илтә иде. Университет укытучылары эстетиканың төп проблемаларын әдәбиятка хас гомуми закончалыклары белән органик берлектә тикшерергә тырышканнар. Алар, сүз сәнгате әсәрләренә характеристика бирү белән генә чикләнеп калмыйча, сынлы сәнгать һәм музыка, театр һәм кинематографиягә караган мәсьәләләрне өйрәнүгә дә киң урын биргәннәр. Алай гына да түгел, хезмәттәге махсус бүлекләрдә әдәбият теориясе сәнгатьнең башка өлкәләрендәге үсеш белән янәшә куелып, чагыштырылып өйрәнелә. Ә китапның «Жанрлар һәм төрләр» дигән бүлегендә, филологик дәреслекләрдә беренче мәртәбә буларак, вокаль әдәбият, музыкаль драматургия һәм кинедраматургия чиктәш әдәби жанрлар төсендә карала.

Шулай да төп игътибар сүз сәнгатенә бирелгән. Иң әүвәл иҗат процессы үзе ифрат кызыклы һәм мавыктыргыч итеп күздән кичерелә. Әдәбият теориясе буенча моңа кадәр басылган дәреслекләрдә бу һәм моныңише башка күп кенә проблемалар бөтенләй кузгатылмый кала иде. Язучының иҗат лабораториясенә үтеп керү әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм формасы белән бәйле күп кенә проблемаларны тагын да нечкәрәк һәм тирәнрәк итеп ачып бирергә булыша.

Казан галимнәре әдәби процесс мәсьәләләрен дә дөрес позициядән торып тикшергәннәр. Хезмәттә төп урынны әдәби методлар һәм юнәлешләр турындагы бүлек алып тора. Профессор Н. А. Гуляев тарафыннан язылган бу бүлектә мәгърифәтчелек реализмы, романтизм, критик реализм кебек әдәби методларга һәм башка иҗат юнәлешләренә гомуми характеристика бирелеп кенә калмый, аларның барлыкка килү һәм үсү закончалыклары да ачыла.

Авторларның сәнгатьтәге декадентлык агымнарына, төрле реакцион юнәлешләргә һәм буржуаз әдәбият галимнәренә кискен һәм дәлилле каршы чыгуларын да хезмәтнең бер уңай сыйфаты дип билгеләп үтәсе килә. Бу — студентларның эстетик карашлары формалашуга зур ярдәм итәчәк.

Әлбәттә, хезмәттә кимчелекләр дә юк түгел. Кайбер бүлекләр артык кыска, аларда җентекләп сайланган мисаллар җитәрлек түгел, нәтиҗәләр беркатлырак яңгырый. Бу аеруча кинедраматургия турын-

дагы ахыргы бүлеккә хас. Китап авторы белән мәгърифәтчелек реализмына караган кайбер проблемалар буенча да бәхәсләшергә мөмкин.

Терминология дә тиешенчә эзлекле түгел. «Жанрлар һәм төрләр» дигән бүлектә, мәсәлән, чуарлыктан котылу өчен, әдәби әсәрләрнең төрләре турында гына сөйләргә һәм «сәнгать өлкәсе» дигән төшенчә генә кулланырга тәкъдим ителә. Ләкин башка бүлекләрдә бу принцип сакланмый. Образлы фикерләү тибы, дөньяга караш һәм иҗат тибы кебек төшенчәләр арасындагы чикләр дә анык билгеләнмәгән. Бәлки, дәреслеккә фәндә урнашып җитмәгән мондый терминнар белән чуарламаска кирәк булгандыр.

Гомумән алганда, китап үзенең фәнни җитдилеге һәм актуаль мәсьәләләрне мәстәкыйль хәл итүе белән аерылып тора. Ул вуз студентларының гына түгел, мәктәп укытучылары һәм язучыларның, әдәбият һәм эстетика мәсьәләләре белән кызыксынучы киң катлау укучылар массасының да игътибарын җәлеп итәр, дип ышанасы килә.

**В. МОНАСЫЙПОВ. Тайга печән кем сала! Хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Республикабыз газета-журналларында Вахит Монасыйповның юмореска һәм сатирик хикәяләре 50 елларның ахырларында ук басыла башлаган иде. Ләкин аның «Утсыз төтен чыкмый» исемле беренче китабы 1964 елда гына дөнья күрде. Шуннан бирле яшь язучының ел саен диярлек берәр китабы чыгып тора. (Сак булыгыз. 1965 ел; Көлү гөнаһ түгел. 1967 ел; Сәләхетдин бүреге. 1968 ел; Наполеон булырга теләмим. 1969 ел.)

Узган ел ахырында В. Монасыйповның тагын бер яңа китабы басылып чыкты. Кече яшьтәге мәктәп балаларына адресланган ул китап «Тайга печән кем сала?» дип атала.

Китапка бәләкәй-бәләкәй унбер хикәя кергән. Тема-проблемалары, максат һәм характерлары ягыннан аларны якынча икетөркемгә бүлеп карарга мөмкин. Җыентыктагы хикәяләрнең бер өлеше балаларны тирә-юньдәге табигать күренешләре, үсемлекләр, кошлар һәм җәнлекләр дөньясы белән таныштыруга багышланган. Икенчеләрендә тәрбия мәсьәләләре күтәрелә. Аларда автор мактанчыклардан, үз файдасын гына кайгыртучы эгоистлардан, ялкау һәм



булдыксызлардан көлә. Шул юл белән балаларга начар гадәтләрдән арынырга булыша, аларда күркәм характер сыйфатлары тәрбияли.

В. Монасыйпов үз хикәяләре өчен кызыклы вакыйгалар, мавыктыргыч ситуацияләр тапкан. Шуңа алар яратып укыла һәм бер уку белән хәтердә кала. Бу яктан «Шифалы врачлар» исемле хикәя аеруча характерлы. Ул болай башланып китә:

«— Ромашка, ромашка! Кая болай чабасың?

— Чапмый хәлем юк! Гыйлаҗ бабайга салкын тигән, тамагы авырткан. Шуны дәваларга чабам!

— Әрем, әрем! Кая болай йөгерәсең?

— Йөгерми хәлем юк! Сәрби әбинең ашказаны бозылган. Шуны төзәтергә йөгерәм!..»

Шул рәвешчә дәвам иткән хикәянең ахырына автор бөтенләй көтелмәгән, юмористик юнәлеш биреп җибәрә:

«— Кычыткан! Кычыткан! Ә син кая?..

— Искәндәр дигән малай янына! Арт сабагын укытырга! Бүген тагын икеле әләктергән! Юньсез!»

«Кем белән кем» дип исемләнгән икенче бер хикәядә дә нигездә шул ук тема— табигать белән таныштыру дәвам иттерелә. Урамда йөргән бер малай янына кемдер килә дә аның бүреген, пальтосын, киез итекләрен салдырта. Биш-алты айдан ул шуларны ук кабат киярга мәҗбүр итә. «Кемнәр соң әлеге чишендерүче белән киендерүчеләр?» — диярсез. Әйтмим, үзегез белегез»,— ди автор. Аңлатып торуның кирәге дә юк. Җавапны янәшәдәге рәсемнән ук табарга була. «Алдакчы кошлар» һәм «Карак» исемле хикәяләр дә җыйнак һәм матур итеп язылган. Тик «Карак» хикәясендә автор белән художник фикерләре арасында аерымлык килеп чыккан. Автор: «Малик кухняга чыкты, кулына балта алды»,— дип яза. Художник исә үз рәсемендә малай кулына пистолет тоттырган.

Тәрбия мәсьәләләренә багышланган хикәяләр арасыннан «Борынга атланган колак», «Тайга печән кем сала?», «Тиен башы» дип исемләнгәннәре аеруча уңай тәэсир калдыра. «Борынга атланган колак» хикәясендә фотосөючеләр түгәрәгенә йөрмәсәм дә рәсемгә төшерә беләм дип мактанган Сәлимнең хурлыкка калуы турында сөйләнә.

Хәлаф белән Хәнифкә «Йолдыз» исемле тайчыкны карарга беркетәләр. Ләкин болар «син кара, юк, син кара» дип үзара

ызгышкан арада «Йолдыз» зур ат булып җитә. «Тайга печән кем сала?» исемле хикәя әнә шул хакта... «Ике каен арасында» дигән хикәя урманда адашып калган малайлар турында. Язучы аларны, кырмыска ояларына, каен кабыгына, чыршы-нарат кәүсәләренә карап, юнәлешләрне билгеләргә өйрәтә.

Китаптагы һәр хикәя төрле төстәге матур рәсемнәр белән бизәлгән. Бу — Илдар Юзеевның «Пони малае нәни Җирәнкәй» китабын иллюстрацияләгән өчен Матбугат идарәсенең дипломы белән бүләкләнгән художник Эрот Зариповның казанышы.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: В. Монасыйповның каләме китаптан китапка, хикәядән хикәягә шомара бара, осталыгы һаман арта тора. Хәзер без аннан олылар өчен дә җитди хикәяләр көтәргә хаклы.

**Ш. ХАММАТОВ, Ф. ӘГЪЗАМОВ. Матбугат — дуслык байракчысы. Татарстан китап нәшрияты. 1970 ел**

Татарстан китап нәшрияты Ш. Хамматов һәм Ф. Әгъзамовларның «Матбугат — дуслык байракчысы» исемле китабын дөньяга чыгарды. Исеменнән үк күренгәнчә, ул матбугатта интернациональ тәрбия алымнарын өйрәнү һәм аларның нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә багышланган. Ике идеология арасында көрәш кискенләшә барган хәзерге чорда — социализм дошманнары халыклар арасында милләтчелек хисләрен куертырга, социалистик стройның куәтле көче — халыклар дуслыгын какшатырга, төрле уйдырмалар белән милләтләр арасын суытырга тырышкан бүгенге көннәрдә — шундый бер хезмәтнең басылып чыгуы гаять кирәкле һәм мөһим эш.

Авторлар: «Китапның төп максаты — партиянең XXIII съездыннан соңгы чорда халыклар дуслыгы һәм социалистик интернационализм идеяләрен пропагандалауның аерым мәсьәләләрен, форма һәм алымнарын Татарстан матбугаты мисалында яктырту»,— диселәр дә, асылда алар халыклар дуслыгы идеяләрен күп тапкыр киңрәк, ерактанрак алып өйрәнәләр һәм аерым проблемаларга кабат-кабат әйләнеп кайталар.

Коммунистик матбугатның интернациональ характеры марксистик-ленинчыл тәгълиматның, идеологиянең интернациональ характерда булуы, иҗтимагый үсештәге милли һәм интернациональ моментларның диалектикасы, буржуаз идеологиягә, буржуаз милләтчелек идеологиясенә каршы килешмәүчән көрәш алып бару зарурлыгы белән аңлатыла. Коммунистик матбугат үзенең беренче адымнарыннан ук интернационализм байрагын югары күтәрде. Татар совет матбугаты исә коммунистик матбугатның интернационалистик традицияләрен элек-электән уңышлы дәвам иттереп килә. «Интернационализм — безнең матбугатның байрагы» дип исемләнгән беренче бүлектә коммунистик матбугатның беренче адымнарыннан алып бүгенге көнгә кадәрге үсеш юлына кыскача күзәтү ясала, аның күркәм традицияләре һәм новаторлык сыйфатлары тикшерелә. Авторлар җирле матбугат органнарының эшчәнлеген өйрәнүгә аеруча зур игътибар биргәннәр.

«Ленин, Октябрь, Татарстан! Бу өч изге сүз безнең күңелләрдә бергә яши»... Китапның икенче бүлеге әнә шундый сүзләр белән башланып китә. Өйрәнелә торган чорда халыклар даһие В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстанның төзелүенә 50 ел тулу кебек даталар булуын хәтергә алсак, мәсьәләне шундый аспектта карауның отышлы икәне ныграк аңлашылыр. Ленинизм үзенең асылы белән интернационалистик тәгълимат, ә социалистик Татарстан Октябрь яулаган казанышларның берсе булганлыктан, бу ике дата уңае белән оештырылган материалларда халыклар туганлыгы темасына зур урын бирелгән. Басылып чыккан китапларның исемнәрен («Безнең Ильич», «Татарстанда ленинчыл милли политиканың тантанасы», «Туганлык һәм дуслык көче», «Октябрь кояшы астында» һ. б.), газета-журнал мәкаләләренең («Совет Татарстаны — Октябрь казанышы», «Без — ленинчылар, без — миллионнар» һ. б.) исемнәрен санау гына да моны ачык күрсәтә.

Мөһим теманы ачуда редакция хезмәткәрләре күп төрле алымнар кулланганнар. Китап авторлары махсус сан, тематик сәхифә, берничә республика һәм өлкә газеталарының бергәләп әзерләнгән уртак саннарын чыгару, материаллар алмашу кебек формаларның бу чорда киң кулланылуын күрсәтәләр, моның уңай күренеш булуын раслыйлар. Китаптагы фактлар, башлыча, «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Коммунист Татарии», «Казан утлары», «Азат хатын» кебек республика газеталарыннан һәм журналларыннан алынган. Әмма авторлар «Яшь ленинчы» газетасына, «Ялкын» журналына һәм район газеталары битләренә дә еш күз ташлыйлар. Шушындый күләмле һәм күп төрле фактик

материал белән эш итү матбугатта халыклар дуслыгы һәм социалистик интернационализм темасын яктыртуны һәр яклап карарга мөмкинлек биргән.

Билгеле булганча, матбугатның хезмәт ияләрен халыклар дуслыгы һәм социалистик интернационализм рухында тәрбияләве төрле алымнар һәм формалар белән тормышка ашырыла. Шулар арасыннан халыклар дуслыгының экономик сферада, бердәм хезмәт процессында, материаль байлыклар алмашуда ныгый баруын чагылдыру һәм рухи байлыклар алмашу, әдәбият һәм сәнгатьләрнең бер-берсенә йогынты ясавы аша туган дуслык хисләрен өйрәнү аеруча актуаль мәсьәлә булып тора. Хезмәтнең өченче һәм дүртенче бүлекләрендә нәкъ менә шул мәсьәләләр игътибар үзәгенә куелган.

Авторлар халыклар дуслыгы турында язылган теоретик мәкаләләрне, аерым милләтләрнең әдәбият-сәнгать өлкәсендәге казанышларын күрсәтүче яки төрле милләт кешеләренең туганнарча аралашып яшәүләре, эшләүләре хакындагы язмаларны карау белән генә чикләнмиләр. Алар газета һәм журналлардагы барлык материалларны социалистик интернационализм призмасыннан карап өйрәнәләр.

Хезмәттә тагын бер мөһим мәсьәлә куела. Ул—журналистларның хәзерлеге, аларның дөньяга карашлары һәм белем дәрәҗәләре мәсьәләсе. «Мавыктыргыч алымнар куллану, материалларны газета битләрендә урнаштыра белү һәр редакциядәге бүлек һәм секретариат сотрудникларының хәзерлегенә, тәҗрибәсенә һәм зәвыгына бәйләнгән», диләр авторлар. Тик шунысы кызганыч, мондый характердагы искәрмәләр күп кенә очракларда гомуми төстә әйтеп узылган. Менә тагын бер дәрес күзәтү: «Матбугатның социалистик ярышны яктырткандa эзлексезлек күрсәтү, кампаниячелеккә бирелү кебек кимчелекләренә күз йомып булмый. Газеталарда бик күп социалистик йөкләмәләр игълан ителә, ялкынлы чакырулар ташлана. Тик еш кына бу йөкләмәләр онытыла, аларның үтәлешенә тиешле контроль урнаштырылмый. Яңа башлангычларның экономик нәтиҗәләрене җитәрлек яктыртылмый». Менә шушы фикер конкрет мисаллар өстендә расланса, аның әһәмияте нәтиҗәлерәк булыр иде, әлбәттә. Китапта кайбер бүтән кимчелекләр дә юк түгел. Мәсәлән, хезмәтнең беренче өлеше фәнни тикшерену рухында язылса, соңгы бүлекләрендә отчет характеры сизелә. Кайбер өлешләрендә, бигрәк тә район газеталарына багышланган битләрдә, авторлар материалларның эчтәлеген сөйләү белән мавыгалар. Бу — билгеле бер дәрәҗәдә тасвирчылыкка алып бара. Ә гомумән алганда, алар кирәкле һәм файдалы хезмәт язганнар. Ул журналистлар өчен дә, журналистика тарихын өйрәнүче галимнәр өчен дә кирәкле кулланма булыр, дип ышанасы килә.

## Шәүкәт Галиев

### Мәче дөньясы



Ак та кара
Төсне генә
Белә мәче,
Дөньяны тик
Шундый итеп
Күрә мәче.

Зәңгәр тубың,
Кулыңдагы
Кызыл алма —
Аның өчен
Кара төстә
Икән бар да!

Кара икән
Синең яшел
Күлмәгең дә,
Кызыл, зәңгәр
Чәчәк аткан
Гөлләрең дә.

Хәер, тагын
Белә мәче
Соры төсне —
Ялгыш күрә
Дип әйтәлмәс
Тычкан, күсе!

### Тукран сые



Тукран тукый —
Нарат чукый.
Тамак туйгач
Тукып туктый.

Сиздерә бит
Инде сусын,
Ничек басар
Икән бусын?

Юк, җиргә дә
Төшмәде ул,
Кар суын да
Эчмәде ул;

Тукый-тукый
Каен тиште
Һәм ширбәтле
Суын эчте.



## Кар бүрек

Баганаларның башында
Күпереп торган кар бүрек,
Җилләр ничек тырышса да,
Төшерелмәгән өреп.

Бу көннәрдә баганалар
Күр, яланбаш калганнар —
Яз каршында һәммәсе дә
Бүрекләрен салганнар!

## Пошн



Урманда җәйли,
Урманда кышлый,
Азыгы бетсә
Пошына поши.

Әнә аланда
Хуш исле кибән —
Кеше абыйлар
Аңа дип өйгән.

Бик тәмләп ашый
Печәнне поши —
Яхшы абыйлар
Аңа бик ошый.

## Куяннар кайда?

Кача-кача
Уйнарга
Уйладылар
Куяннар.

Бу уен бик
Кирәкле,
Әниләре
Өйрәтте;

Әйтә башлый
Санамыш,
Балалары
Тыңламыш:
— Әккә, бәккә,
Көләмән, төккә,
Һәвә, бибә,
Ләңгел-ләңгел,
Куян, кач!



Качарга бик
Осталар —
Дүртесе дә
Посалар!
Ә текәлеп
Карасаң,
Берсен бик тиз
Табарсың —
Сырты тора
Беленеп,
Койрык тора
Күренеп...
Әни куян
Күзләде,
Берәм-берәм
Эзләде...

Җыелдылар
Мыш та мыш,
Китте яңа
Санамыш:
— Иян, биән,
Карга, чыпчык,
Син кал, бу чык!



Гөр-гөр килгән
Арада
Кайсы кая
Тарала.

Әни үрнәк
Күрсәтте,
Ай-һай, озак
Эзләтте:
— Куян белеп
Качар, ди,
Белмәсә эш
Начар, ди.
Туктагыз, тын
Калыгыз!
Ни бар? Колак
Салыгыз!
Бүре??
Бүре!!

Качтылар,
Бишесе дә
Постылар.

Борын тертеп
Эзләргә,
Бүре килә —
Эзләнә.

Куяннарның
Эзе бар,
Эзләренең
Исе бар,
Ә үзләре
Күренми...

Әрле-бирле
Йөренде,
Җыергалап
Борынны
Бүре кире
Борылды...

...Рәсемгә күз
Салыгыз,
Куяннарны
Табыгыз!

## Таган

Атыныпмы арганнар,
Балалар таралганнар —
Таганнар тын калганнар,
Таганнар тукталганнар.
Җилләр көтеп торганнар,
Тизрәк шунда барганнар,
Тотынышып алганнар,
Утырышып алганнар,
Башны кыңгыр салганнар...
Салмак кына таганнар
Тирбәлә башлаганнар!
Әлли-бәлли дигәндә
Әрле-бирле тирбәлә —
Рәхәт була җилләргә.
Шаян җил малайлары
Шактый шулай шаярды.
Чүктеләр дә тордылар,
Чумдылар, калкындылар,
Узышып атындылар,
Тора-бара тындылар.
Нигә тындылар алар?

Әлли-бәлли иттеләр,
Әллә черем иттеләр,
Әллә җил малайлары
Изрәп йоклап киттеләр?..





## Ботка

Болай булгач
Эш пеште —
Пеште, пеште,
Ботка пеште!
Ботка пеште —
Ботка төште,
Бот пеште...
Житте, житте,
Салма ботка!
Салсаң ботка
Сал табакка!

# ДУСЛАРЧА ШАЯРУЛАР



## *Аяз Гыйләҗевка*

Урам артларында ни бар, диеп,
Уйлап вакыт әрәм итмәгез:
«Урам артларында яшел болын»,
Болын артында ни? —
Кетәбез!..



## *Газиз Мөхәммәтшинга*

Повесть бит ул, малай, шутке түгел,
Әйбәт язган кеше сирәктер...
Уйланырга кирәк әле, парень,
Может ешрак язу кирәктер.

ЗАЯ эпиграммасы.

Б. Альменов шаржлары

## *Атилла Расихка*

Буйдакларны язып мәшһүр булды,
«Каһарманнар...» язып — каһарман...
Доцент булды, доктор булыр бәлки —
Калышасы килми заманнан.

Нури Арсланов эпиграммасы.



## *Нурихан Фәттахка*

Нурихан — ханнар янында,
Язар сүзен таба торып.
«Кайт, дип, хәзерге чагыма!»
«Әтил суы ака торур».

Зәлфәт эпиграммалары.



Фатих Хөсни

# КЕМ КЕМНЕ ҖИГӘ?

*Кыскы этюд*

Мин — пенсионер, әмма бик үк сәлперәйгәннәрдән түгел, гамәлемә ярыйм. Гамәлен нәрсә, дип сорау куелса, бар инде шунда: халык контроле комиссиясенә булышып, төрле тикшерену эшләренә катнашам, якын-тирәдә берәр буш лекция булса, анда барып утырам, сораулар бирергә остарып киттем. Аннары тагын, хатын кушкан йомышларга йөрим, шулардан бушап торган арада тәрәзәдән карыйм. Бавырга кереп утырган таш кыймылдап тенкәмә тимәгән чакларда, нәкъ конституциядә әйтелгәнчә, «тәэмин ителгән тыныч картлык кичерәм».

Тәрәзәдән карап торам дигәннән, бер көнне шулай...

Тукта, аңа хәтле аңлашып китәсе бер урын бар икән. Мин үземнең төшеп калганнардан түгел икәнлегемне бер әйттем бугай инде, шуның өстәвенә, белмәгән кеше белеп торсын, мин профессор күршесе дә. Юлыбыз очрашса, баш кагып исәнләшеп үтәбез. Башка ягы ярый профессорның, әмма бер ягын һич ошатмыйм: өендә, ачуым килмәгәе, бозау хәтле бульдог асрый. Буй житкән бер малае, ишеккә сыймастай симез хатыны, үзе, аннары шул ямьсез авызлы бульдогы. Минем бик өнәп житкермәгәнне сизенәме дип әйтим, очраганда шул бульдог миңа күзенең агы белән ничектер астыртын-хәтәр итеп карап уза. Авызы бүрек чаклы, кара мунча миче кебек караңгы авыз, иреннәре акчадан бушаган янчыктай салынып төшкән. Шул «янчык» читләреннән өзлексез селәгәе агып тора. Үзе зур, үзе иләмсез симез, үзе тавышсыз-тынсыз. Бер караганда, мине — күршесен таныган да кебек. Шулай таныган килеш тә әлеге теге астыртын-хәтәр күзләре белән әйтәдер төсле бу миңа: «Менә селәгәем генә агып бетсен дә, тураклап-ваклап тормыйча, берьюлы кабам да йотам мин сине», — дип әйтә кебек. Мин үзем алай усал кеше түгел, әйткәнемчә, гамәленә ярый торган бер пенсионер, алай бер кабуда ук йотмас йотуын да... Шулай да бульдогның мич хәтле авызы тирәсеннән уратыбрак узуны хәерлерәк саныйм, ишеткәнем бар: тешләгән җиреннән җибәрми, ди, ул, хәерсез.

Җибәрмәскә ни хакы бар аның? Ә минем ашыгыч барып кайтасы җирем булса? Әйтик, гонорар алырга. Бушлай куелган лекция тыңларга. Я булмаса — алла сакласын да хатын ишетеп тора күрмәсен — нәкъ шул бульдог тешлисе кичне мине берәр кыз-кыркын чакырган булса!..

Кыскасы, профессорның үзе белән арабыз ярыйсы, әмма бульдог белән бер дә борчак пешми. Бульдог мине тешләрме-юкмы, тешләсә — кайчанрак тешләр, ук чаклы нечкәлекләрен белмәстән, шулай да эт белән минем арада тышка бәреп чыкмаган дошманлык яши бирә. Фактически алып әйткәндә, бәлки, ул мине тешләмәс тә, астыртын-хәтәр күз карашы дигәнем дә, бәлки, миңа гына шулай күренәдер, ник ачу сакласын ул миңа, хуҗасы белән баш иеп исәнләшеп йөргәнне күреп тора ич. Мәгәр шулай да мин аның белән дуслык җепләре бәйләү ягында түгел. Ник дисәң, сәбәбе бар: бушка әпәй черткәнне җенем сөйми. Җитмәсә әле, хатын әйтә, шул ямьсез авызлы этләре өчен ит комбинатыннан сөяк-санак, ары-сенгер алып кайтып, этнен үзенә атап сөяк шулпасы пешерәләр, ди. Биллаһи-газим, бер эш эшләмәгән шул

эрэмтамакка! Эшләмичә ашаучыны гомерем буена җенем сөймәде, инде килеп, картаймыш көнемдә, мә, рәхим ит, күз алдында ялт-йолт килеп шул эрэмтамак йөрсен.

Тукта, чү, тәрәзәдән карап торам ич әле мин. Урра, үз күзләрем белән күреп алдым: бульдогка да эш тапканнар, әле нинди генә эш! Җиккәннәр тегене ярыйсы гына зур чанага. Шлеясен, йөгәнен дигәндәй, бөтен әсбапларын җиткереп җиккәннәр. Чанага менеп утырган ике аяклы бер күсәк. Күсәкнең кулында чыбык. Болгап торып җибәрә, хайван-мескен нишләсен, баш өстендә кылычтай чыбык сызгырып торса, хайван түгел, үзең дә йөгерерсең. Шулай итеп шул, минем бульдогка булган дошманлыгым, уйламаганда, аны кызгану белән алышынды.

Безнең тәрәзә каршында гына «Эрмитаж» бакчасы. Эрмитаж французча тын почмак дигән сүз икән. Итәрсең безнең ул бакчаны тын почмак. Җәен эскәмия саен кочаклашып-үбешеп утыручы пар-пар гашыйкларга тимик тә инде — гыйшык тоту пәйгамбәрләрдән калган. Кышын менә эт җигеп йөри башладылар шул бакчада. Эчемдәге иблис куана, тәрәзәдән башымны алмыйча карап торам. Ашаганыңны чыгаралармы, бульдог җаный!

Бер әйләнәләр бакчаны, ике әйләнәләр, эт-тә-тә, сызгырамы баш очында сыек чыбык, өч әйләнәләр бакчаны...

Анда кар бураннары туздырып әйләнә торалар, мин моннан тәрәзә аша саный торам: өч, биш, сигез, тугыз, ун... Эт-тә-тә-тә, чыгаралармы кәҗә маеңны, бульдог җаный, шулай ул дөнья, буш ашап ятканны яратмый ул дөнья.

Тукта, чү! Әйбәт кенә санап килгәндә, тормоз килеп чыкмасынмы! Бармак ун гына икән ич минем. Үз чиратымда бу эшкә мин хатынны да җикмәкче булып, аңарга кычкырдым:

— Китер бармакларыңны, тизрәк китер, юкса учетны чуалтабыз, — мин әйтәм.

Җигәрсең хәзерге хатыннарны юк-бар эшләргә! Һәрвакытта шулай булганы кебек, бу юлы да хатын бозды эшемне. Аның ул бармаклары нәкъ шул миңа кирәк минутта бәрәңге әрчеп маташа, имеш. Фактически алып әйткәндә, хатын эшне бозмады, хатын күземне ачты.

— Әйтәсе дә юк, эш табылган профессор малаена, — диде хатын, исе китмичә генә тәрәзәгә күз салып, — ВУЗга керә алмады, эшкә керергә ялкаулык куәтле, эт җигеп чапмаса соң...

Анысы гына бер хәер иде, бер авыз ачылгач, кызган шәптән мине дә кырып салды:

— Ә син, карт тиле, шаккаткансың. Һич югы, энә ипигә барып кайтыр идең, кибет ябылганчы...

Ипигә барып кайтырга була. Берәр җирдә бушлай лекция сөйләмиләрме? Аны да тыңлап чыгарга була. Ишек төбендәге киезне селкеп керсәң дә бер эш.

Ә менә бульдог белән дошманлашып йөрүне бүгеннән үк бетерәм. Бульдогның ни гаебе бар, авызы ямьсез булса да, хайван ич. Җитмәсә, әнә җигеп тә йөри башладылар үзен, мескенне. Ә менә профессорның күсәк хәтле эшлексез малаен җигәргә кемнең дә башы җитми. Киресенчә, әлегә малай үзе җигә. Бер көнне бульдогны җиксә, икенче көнне атасын җигә. Дөресрәге, атасы белән анасын көне-төне җигә.

Ә хатын мине тәрәзәдән карап торган өчен ачулана. Тәрәзәдән карап тору да эш. Ипигә бару да эш. Ишек төбендәге киезне селкү дә эш. Бушка лекция тыңлау да эш.

Әнә профессор өчен борчыл син. Бөкресе чыкса чыккан, тартырга калган баш тарта. Бульдогы малайны, профессор икесен дә — бульдогны да, бульдогтан башка эш тапмаган малай-күсәкне дә тарта.

*1971.*

# БЕРВАКЫТ ШУЛАЙ БУЛА...

## Киңәш

Бернард Шоу янына, үз шигырьләрен укырга дип, бер яшь шагыйрь килгән. Шуларны тыңлагач, Шоу егеткә сорау биргән:

— Шигырьләр яза башлаганчы сез ни белән шөгыльләндегез?

— Башта мин врач булырга теләгән идем, аннары, медицинаны ташлап, шагыйрь булырга карар кылдым. Чөнки кешеләргә күбрәк файда китерәсем килде.

— Мин сезгә поэзияне дә ташларга кушар идем. Медицинаны ташлап сез кешеләргә шактый күп файда китергәнсез бит инде,— дигән Шоу.

## Тегүче белән язучы

Атаклы инглиз язучысы Бернард Шоу турында, ул теләсә нинди сорауга да бик үткен җавап бирә икән, дип сөйлиләр. Лондонның бер тәнкыйтьчесе шуны үзе тикшереп белмәкче була һәм Шоуга четерекле бер сорау биреп карый:

— Тәнкыйтьче белән тегүче арасында нинди аерма бар?

— Минем тегүчем минем тәнкыйтьчеләремнән күп тапкыр акыллырак. Тегүче бит костюм тегәр алдыннан һәрвакыт үлчәү ала. Ә тәнкыйтьчеләр минем әсәрләрне үзләренең иске үлчәүләре белән үлчиләр,— дип җавап бирә язучы.

## Диңгез турында әсәр

Бер яшь француз язучысы үз әсәренә Мопассан биргән бәя белән килешми. Ул «Диңгез» исемле роман язган булган.

— Бу китабымда диңгез сулышы да, аның ароматы да, аның гайрәтле шаулавы һәм дулкыннарының сикерешеп уйнавы да бар дип уйлыйм мин,— ди автор.

— Боларның бөтенесе дә бәлки бардыр, ләкин диңгез турындагы әсәргә суны нигә шул хәтле күп тутырырга кирәк булды икән? — ди Мопассан.

## Танышларның берсе

Күренекле француз язучысы Ежен Сю «Тарих мәгарәләре» дигән китабын язганда бик күп караклар һәм бандитларны күзәтә, аларның тарихын өйрәнә, портретларына штрихлар яза. Ләкин шулай йөргән көннәренең берсендә ул кесәсендәге шул язмаларын һәм 150 франк акчасын югалта. Икенче көнне исә аның адресына бер пакет китерәләр һәм анда шундый язу да була: «Янчыгыгызны ачып карагач ук сезнең кем икәнлегегезне белдем. Язуларыгызны кире кайтарам. Мин аларны зур кызыксыну белән укыдым. Ләкин кайбер сүзләрне дөрес аңламыйсыз икән. Мин шуларга төзәтмәләр керттем. Шуның өстенә тагын үземнән 35 сүз өстәп яздым. Миндә калган 150 франкыгыз шул эш өчен түләү булыр. Сезнең күптәнге танышыгыз...»

## Матур күлмәк

Бер яшь шагыйрь күптән түгел генә никахланган хатыны белән кунакка килә. Хатынын аның бик ошаталар.

— Ул искиткеч чибәр! — дип кычкырып ук әйтә өй хуҗасы.

Ә хуҗаның хатыны исә, иренең сүзенә өстәп:

— Өстендәге күлмәге — менә дигән бер поэма бит! — дип сокלануын белдерә.

— Алай гынамы соң! Ул күлмәк — ике поэма, ун эпиграмма һәм калын журналларда бастырган ике тәнкыйть мәкаләм минем,— ди яшь шагыйрь, үпкәләп.

## Киресенчә эшләргә

Бер яшь рәссам Швейцариянең атаклы художнигы һәм сынчысы Беклинга болай дип зарлана икән:

— Мин бер сурәтне ике-өч көндә ясап өлгертәм, ләкин аны сатар өчен ике-өч ел вакыт кирәк була.

— Ә сез киресенчә эшләп карагыз,— дип киңәш бирә Беклин,— рәсемегезне ике-өч ел ясагыз, аннары ул ике-өч көндә сатылыр.

## Алдану

Опера җырчысы премьерадан соң өенә кайткач үксеп-үксеп елый икән:

— Һәммәсе алдакчылар, эшәке җанлы нахаллар!

— Нәрсә булган, әнкәсе? — дип сорый аңардан ире.

— Миңа нибары алты букет бүләк иттеләр.

— Ник, азмыни бу?

— Ә мин бит унике букетлык акча биргән идем,— ди хатын.

## Спектакль әзерләгәндә

— Беләсең бит инде, дус кеше, миңа бу спектакльдә бик дуамал, бик тискәре кеше ролен башкарырга кирәк. Шуңа нинди грим яхшырак булыр икән? Әйт әле киңәшеңне?..

— Минемчә, сиңа бернинди грим да кирәкми. Үзең тормышта ничек булсаң, сәхнәгә дә шулай чык. Шуннан яхшысы булмас! — ди икенче артист үзенең дус кешесенә.

## ЮБИЛЕЙ ТАНТАНАЛАРЫ

Республикабыз җәмәгатьчелеге татар совет әдәбияты классигы Һади Такташның тууына 70 ел тулган көннәрне зурлап бәйрәм итте.

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты дирекциясе һәм Татарстан язучылар союзы идарәсе шагыйрьгә багышлап фәнни утырыш үткәрде. Фәннәр академиясенең Казан институтлары конференц залында үткәрелгән бу утырышны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы, профессор М. К. Мөхәррәмов ачты.

Институтның өлкән фәнни сотрудникы Хәсән Хәйри «Революция һәм яңалык җырчысы» дигән темага, өлкән фәнни сотрудник Халиф Курбатов «Һади Такташ — шигырь остасы», өлкән фәнни сотрудник Азат Әхмәдуллин «Егерменче еллар драматургиясе һәм Һади Такташ», кече фәнни сотрудник Рашат Гайнанов «Гасырлар һәм минутлар» поэмасының сәнгатьчә эшләнеше» дигән темаларга докладлар ясадылар.

Ялкынлы шагыйрьнең каләмдәш дуслары Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Риза Ишморатлар истәлекләр сөйләделәр.

Утырышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

* * *

11 январьда Казан тамашачылары Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына Һади Такташның тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичәгә килделәр.

Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында докладны филология фәннәре докторы Гали Халит ясады. Язучылардан Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Сибгат Хәкимнәр Һади Такташ турында истәлекләр сөйләделәр, шигырь һәм нәсерләр укыдылар.

Кичәнең тантаналы өлешеннән соң булган зур концертта шагыйрьнең шигырьләре укылды, җырлары башкарылды, «Камил» спектакленнән өзек күрсәтелде. Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов укыган «Киләчәккә хатлар» поэмасы белән кичә тәмамланды.

* * *

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршындагы иҗади яшьләр берләшмәсе Казан шәһәренең Актерлар йортында «Зәңгәр күзләр» дигән шигъри тамаша күрсәтте. Һади Такташка багышланган бу кичәдә Татар дәүләт академия театры артистлары шагыйрьнең шигырьләрен укыдылар.

* * *

Һ. Такташка багышланган бәйрәм тантаналары шагыйрьнең туган авылы Сыркыдыга күчте.

Язучылардан Г. Минский, Х. Туфан, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Зәйнашева, Р. Батуллин, композитор З. Хәбибуллин, нәфис сүз остасы Ә. Яһүдин, шагыйрьнең улы Аван Такташ, Язучылар союзы каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросының җитәкчесе М. Шәймөхәммәтовлар, Мордва АССРның Сыркыды авылына барып, шагыйрьнең якташлары белән очраштылар, мәктәптә укучылар, клубта колхозчылар белән әдәби кичә үткәрделәр.

* * *

Һ. Такташка багышланган әдәби кичәләр Татарстан дәүләт музеенда, республикабызның шәһәр һәм авыл клубларында, мәктәпләрдә, китапханәләрдә үткәрелде.

## ӨЛКӘН КОМПОЗИТОР ХӨРМӘТЕНӘ

15 январьда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында СССРның халык артисты, СССР дәүләт премияләре лауреаты, композитор Нәҗип Җиһановка 60 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Бу бәйрәмгә катнашу өчен СССР һәм РСФСР композиторлары союзыннан, Казагыстаннан, Башкортстан, Чувашия, Мари АССРдан һ. б. җирләрдән кунаклар килгән иде.

Тантаналы утырышны ТАССР Культура министры Б. М. Гыйззәтуллин ачты. КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советы исеменнән юбилярны өлкә комитеты секретаре М. Ф. Валиев котлады.

Композитор Нәҗип Җиһановның тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турындагы докладны ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Монасыйпов ясады.

Кичәгә килгән композиторлар, язучылар, культура-фән әһелләре, журналистлар, партия, совет, комсомол, профсоюз эшлеклеләре, шәһәребезнең хезмәт ияләре юбиляр

Нәҗип Җиһановның чыгышын котлап каршы алдылар.
Нәҗип Җиһанов әсәрләреннән төзелгән концерт булды. Концертта 300 кешене берләштергән хор башкаруында «Минем республикам» кантатасы зур тәэсир калдырды.
Танылган композитор Нәҗип Җиһановка 60 яшь тулган көнгә багышланган тантаналы кичәдә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы председателе Г. И. Усманов, КПСС-ның Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин катнашты.
Совет музыка сәнгатен үстерүдәге, яшь көчләрне тәрбияләүдәге зур хезмәтләре һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен алтмыш яше тулган күренекле композиторы, Казан дәүләт консерваториясе ректоры профессор Нәҗип Җиһановны хөкүмәтебез Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде.

## ЗУР БҮЛӘКЛӘР

Совет әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтләре, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән, язучы Гомәр Бәширов Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләнде.

* * *

Хөкүмәтебез халкыбызга поэзиянең искиткеч җәүһәрләрен биргән күренекле шагыйрь Хәсән Туфанны 70 яшь тулу уңае белән Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләде.

* * *

Яңа ел татар әдәбияты өчен тагын бер куанычлы хәбәр китерде. Россия Федерациясенең Министрлар Советы карары белән «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты», «Ленин фәрманы белән», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән поэмалары һәм соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре өчен шагыйрь Сибгат Хәкимгә Максим Горький исемендәге премия бирелде.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘ

Түбән Кама промышленность челтәрендә төзелеш башлануга ун ел тулды. Шул вакыттан башлап промышленность предприятиеләре генә түгел, яңа шәһәр үзе дә үсте. Ул көннән-көн зурая, матурлана бара. Яңа йортлар, яңа урамнар салына. Әле күптән түгел генә барлыкка килгән шундый урамнарның берсенә шагыйребез Габдулла Тукай исеме бирелде.

## САЛИХ СӘЙДӘШЕВ КИЧӘЛӘРЕ

Халкыбызның яраткан композиторы Салих Сәйдәшевны искә алу кичәләре дәвам итә.
Уфа шәһәренең Актерлар йортында композиторның тууына 70 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде. Салих Сәйдәшевның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында Татарстан композиторлар союзы правлениесе секретаре, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина доклад ясады. Башкорт артистлары башкаруында зур концерт бирелде.

* * *

Оренбург хезмәт ияләре Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган кичәләргә яратып йөрделәр. Ул кичәләр Хәсәен Ямашев исемендәге шәһәр китапханәсендә, Культура, тарих истәлекләрен саклау өлкә советы идарәсе йортында, «Россия» культура сараенда булып үтте.
«Россия» культура сараенда үткәрелгән тантаналы кичә, татар, башкорт, рус һәм казакъ халыкларының вәкилләре катнашында булып, зур интернациональ бәйрәмгә әйләнде. Тамашачылар композитор әсәрләреннән төзелгән зур концерт тыңладылар. Фойега Салих Сәйдәшев тормышына багышланган фото-күргәзмә, композитор турында язылган китап һәм журналлар куелган иде. Кичәгә килгән халык аларны зур кызыксыну белән карады.

* * *

Түбән Кама шәһәренең концертлар залында Салих Сәйдәшевка багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Яшь шәһәрнең тамашачылары композиторның әсәрләрен тыңладылар. «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенә йөрүче яшь каләмнәр С. Сәйдәшевка багышланган шигырьләрен укыдылар.

## ИҢ ЯХШЫ ТӘРҖЕМӘ

СССР Культура министрлыгы союздаш һәм автономияле республикаларда яшәүче язучылар иҗат иткән һәм РСФСР театрларында куелган драма әсәрләре фестивален үткәргән иде. Соңыннан фестивальдә билгеләнеп үткән пьесалар башка телләргә дә тәрҗемә ителде һәм аларның иң уңышлылары бүләкләнде. Р. Ишморатның «Давылга табан» әсәрен русчага тәрҗемә иткәне өчен И. Ингвар, Җ. Җаббарлының «Айдын» әсәрен әзербайҗанчадан татарчага тәрҗемә иткәне өчен Г. Минский икенче премияне алдылар. Х. Хәмзәнең «Бай һәм батрак» әсәрен үзбәкчәдән татарчалаштырганы өчен Р. Ихсанов өченче премияне алды.

## Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБТА

Инде берничә ел рәттән Казанның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Себергә фәнни экспедицияләр оештыра. Әнә шул экспедицияләрнең берсе турында институтның фәнни сотрудникы Илгиз Кадыйров Тукай клубында чыгыш ясады.
«Себер татарларының җыр иҗаты» дип аталган бу концерт-әңгәмәдә Себер татарлары җырларын җырчы Флёра Сәләймәнова башкарды.

* * *

Язучылар берничә тапкыр инде тарих фәннәре кандидаты, археолог Равил Фәх-

рстдинов белән очрашып, аның татар халкының борынгы тарихына караган кызыклы әңгәмәләрен тыңлаганнар иде.

Соңгы очрашуда яшь галим язучыларга Казан шәһәренең борынгы тарихы турында сөйләде. Соңыннан Равил Фәхретдинов бик күп сорауларга җаваплар кайтарды.

## ЯҢА КИТАП

1970 елда Пермь китап нәшрияты, туганлаш халыклар иҗатына багышлап, «Четыре ветра» дигән китап чыгарган иде. Анда Татарстан шагыйрьләренә дә зур гына игътибар бирелде. Бәйрәм ашы кара каршы, диләр. Татарстан китап нәшрияты быел укучыларны «Идел белән Урал арасында» дигән яңа китап белән шатландырды. Бу китапта, татар язучыларыннан тыш, башкорт, мари, мордва, удмурт һәм чуваш әдәбияты вәкилләренең әсәрләре урнаштырылган. Туганлаш әдәбиятларның үрнәкләре Н. Арсланов, З. Нури, М. Садри, Р. Гәрәй, Г. Рәхим, М. Хөсәен, М. Мазунов һ. б. тәрҗемәләрендә бирелгән.

## КОМПОЗИТОРЛАР УФАДА

Башкортстан композиторлар союзының чираттагы пленумына Татарстан композиторларыннан Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтовлар бардылар. Алар башкорт музыка сәнгатенең үсеше турындагы сөйләшүгә катнаштылар, соңгы вакытта язылган әсәрләрдән Х. Әхмәтовның «Замандашлар» операсын, Н. Сабитовның «Сөям сине тормыш» балетын карадылар. Яңа төзелгән дәүләт хор капелласы башкаруында башкорт композиторларының хор өчен язган әсәрләрен тыңладылар.

## ХЕЗМӘТЕ ЗУРНЫҢ ХӨРМӘТЕ ЗУР

Совет театр һәм музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләрен искә алып, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы бер төркем артистларга мактаулы исемнәр бирде.

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры актрисалары Шәхсенем Әсфәндиярованы һәм Рауза Хәйретдинованы Татарстанның халык артисты исемен алулары белән, Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры актрисасы Асия Хәйруллинаны, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры солисткалары Лариса Георгиевна Башкированы һәм Роза Михайловна Новицкаяны Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр алулары белән Татарстан язучылары һәм «Казан утлары» журналы тәбрик итә, аларга сәламәтлек, иҗат уңышлары тели.

## ИҖАТ РАБОТНИКЛАРЫ СЕМИНАРЛАРЫ

Иҗат интеллигенциясе вәкилләре, иҗат оешмалары һәм сәнгать учреждениеләре җитәкчеләре өчен КПСС өлкә комитеты каршында берничә ел инде даими семинар эшләп килә.

Иҗат эшчеләре октябрь аенда «Совет театры традицияләре һәм хәзерге заман» дигән темага сөйләшү алып барганнар иде. Бу сөйләшүләрдә «Театральная жизнь» журналының баш редакторы, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ю. А. Зубков та катнашты.

Ноябрь аеның семинар утырышы исә «Производствоның һәм промышленность предприятиеләре коллективларының социаль үсеше комплекс планы» дигән темага багышланды. Бу семинар Куйбышев исемендәге химия заводында үткәрелде. Семинарда катнашучылар завод цехларын карап йөрделәр, соңыннан «Татарстан, 1970 ел», «Республиканың юбилее» һәм «Космос» дигән документаль фильмнар карадылар.

Декабрь аенда үткәрелгән семинар яшь эшчеләр тормышына багышланган иде. Иҗат эшлекләре, Казан шәһәренең 33 номерлы профессиональ-техник училищесында булып, училище директоры Б. Г. Машканцевның тәүге кадрлар әзерләү турындагы чыгышын тыңладылар, уку корпусларын карадылар, заманча җиһазландырылган производство биналары белән таныштылар.

Семинарда Татарстан республика профессиональ-техник белем бирү идарәсе начальнигы Ф. М. Илялова эшчеләр сыйныфы һәм аның яшь алмашы турында доклад ясады. Семинар соңында училище укучылары зур концерт бирделәр. Бу семинарлар алга таба да дәвам итәчәк.

Семинарга йөрүче язучылар, артистлар, композиторлар, художниклар, кино, телевидение һәм радио работниклары «Хәзерге заман шәһәр төзелеше һәм Татарстан шәһәрләренең архитектурасы», «Совет фәнендә яңалыклар», «Авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән идарә итүнең тәҗрибәләре» һ. б. темаларга сөйләшүләр алып барачаклар. Партиянең 24 нче съезд делегатлары белән очрашачаклар. Колхозларда, фән йортларында, иҗат союзларында һ. б. урыннарда булачаклар.

Бу семинарлар иҗат эшчеләренең теоретик белемнәрен күтәрүгә зур ярдәм итәләр һәм республикабыз практик тормышын күрергә булышалар.

## АРХИТЕКТОРНЫҢ КҮРГӘЗМӘСЕ

Казан шәһәре Архитекторлар йортында Татарстанның, Башкортстанның һәм Төньяк Осетиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, архитектура профессоры Исмагыйл Гайнетдинов күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәгә архитекторның проектлары, рәсемнәре, үзе төзегән объектларның фото-рәсемнәре куелган.

## КОНКУРС НӘТИҖӘЛӘРЕ

Татарстан АССР эчке эшләр министрлыгы, Татарстан язучылар союзы белән бергә, җәмәгать тәртибен саклаучылар тормышыннан язылган иң яхшы әсәрләр өчен конкурс игълан иткән иде. 1969 елның 1 апреленнән 1970 елның 19 апреленә кадәр сузылган бу конкурска утызга якын әсәр килде.

Жюрига Татарстанның эчке эшләр министры урынбасары Салих Хәлилович Минушев председательлек итте.

Язучы Гариф Ахунов һәм эчке эшләр министрлыгының политик-тәрбия эшләре начальнигы Семен Тимофеевич Тайбинский председатель урынбасарлары булды.

Татарстан Культура министры урынбасары Юныс Әминов, «Казан утлары» журналы редакторы, язучы Зәки Нури, партиянең Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге инструкторы Гөлсинә Мөхәмәдова, республика газеталары, радио һәм эчке эшләр министрлыгы работниклары жюрида член булып эшләделәр.

Жюри комиссиясе февраль аенда конкурсның нәтиҗәләрен игълан итте:

Конкурска килгән иң яхшы хикәяләр өчен бирелгән беренче премияне «50 ел сафта» дигән повесть өчен журналист Рәмзи Максудов алды.

Журналист Николай Шевченкога «Авыр көрәш» дигән хикәясе өчен, А. Е. Кувшиновага «Милиция турында кечкенә хикәяләр» дигән циклы өчен, З. А. Шәфигуллинга «Тыныч булсын» дигән хикәясе өчен кызыксындыру премияләре бирде.

Иң яхшы очерклар өчен икенче бүләк журналист Н. Г. Гиндуллинга «Күңел ачкычы» дигән очеркы өчен бирелде.

Радик Фәизов һәм Рәфис Әминевка «Милиция лейтенанты» дигән очерк өчен, С. В. Волковка «Хезмәт границадан башланды» дигән очерк өчен кызыксындыру премияләре бирелде.

Иң яхшы шигырь өчен икенче премияне «Милиция турында балалар сүзе» дигән шигыре өчен шагыйрь Мөхәммәт Садри алды.

«Горурлык» дигән шигырь өчен шагыйрь Фәнис Яруллинга, «Пелевскидагы печәнлек» дигән поэма өчен Николай Шибаловка кызыксындыру премияләре бирелде.

Иң яхшы җыр өчен билгеләнгән премиядән «Регулировщик җыры» дигән музыка өчен Арслан Батыршинга, «Минем милициям» дигән җыр өчен, В. Ф. Десятниковка кызыксындыру премияләре бирелде.

Конкурска килгән иң яхшы әсәрләрне аерым җыентык итеп бастыру турында карар да кабул ителде.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Язучыларның әдәбият сөючеләр белән очрашулары дәвам итә.

Январь аенда Илдар Юзеев, Ләбибә Ихсанова, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, композитор Заһид Хәбибуллиннар, Казан шәһәренең Дербышка культура сараенда китап сөючеләр белән очрашып, бүгенге әдәбиятыбыз һәм музыкабыз яңалыклары турында сөйләделәр. Шигырьләр, хикәяләр укыдылар. Заһид Хәбибуллин үзенең соңгы вакытта иҗат иткән әсәрләре белән таныштырды. Соңыннан күп төрле сорауларга җаваплар бирелде.

*
* *

Герой шагыйрь Муса Җәлил һәм аларның көрәштәшләре турындагы материаллар халкыбызны көннән-көн ныграк кызыксындыра. Мусаның тормышын өйрәнүчеләрдән Рафаэль Мостафин укучылар арасында еш була һәм үзенең эзләнүләре турында сөйли. Соңгы вакытта ул Зеленодольск шәһәренең механика техникумында укучылар белән очрашты.

*
* *

Ульяновск өлкәсе Кулатка районы хезмәт ияләре татар язучылары белән әледән-әле очрашып торалар. Декабрь аенда язучы Гөлшат Зәйнашева, РСФСРның халык артисткасы Венера Шәрипова, музыкант Зиннур Гыйбадуллин һәм нәфис сүз остасы Рафаэль Галиевлар Кулатка районы авылларында булып, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр.

*
* *

Язучылардан И. Юзеев, Ш. Галиев, Т. Миңнуллин, композитор Ф. Әхмәтов, җырчылардан М. Имашев, В. Гыйззәтуллиналар Зеленодольск районының Тукай исемендәге колхозында булдылар.

Бу кичәдә яшьлек турында шигырьләр, җырлар яңгырады, күңелле хикәяләр укылды.

Колхоз яшьләре үзләренең яраткан язучылары, композиторлары һәм җырчыларын алкышлап каршылады.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

«Казан утлары»ның 6, 7, 8 саннарында түбәндәге әсәрләр басыла:

Ф. Хөсни. «Мәйдан». Повесть.

Б. Камалов. «Ялыкмаслар». Повесть.

Д. Зөбәерова. «Куш өянке шаһит». Повесть.

С. Сөләйманова. «Йолдызларга йодрык». Хикәя.

И. Салахов. «Карлыгач». Хикәя.

Т. Миңнуллин. «Кульяулык һәм өч йөз сум акча». Хикәя.

Журналның тугызынчы саныннан Әхсән Баянның «Ут һәм су» романы басыла башлаячак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ